ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.2006



# РОССИЯ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ



*Леонид Любовский*



*Нурлан Канетов*



*Ренат Харис*

**Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында куелган «Йосыф кыйссасы» балеты өчен композитор Леонид Любовскийга, биюче Нурлан Канетовка һәм либретто авторы шагыйрь Ренат Хариска 2005 елда әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Россия Федерациясе Дәүләт премиясе бирелде.**

*Июнь, 2006 ел.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2006

# 7

(1005)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


*Бу санда*


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Локман БАДЫЙКШАН. Тәкъдирем. *Повесть-истәлек.* ..... 5
Фәрит ГАБДЕРӘХИМ. Милли җанлы киңлекләрдә. *Шигырьләр.* ..... 37
Илдус ХУҖИН. Кызыл тәнлеләр юлбашчысы. *Хыялый бәян.* ..... 41
Равил РАХМАНИ. Хәтер. *Шигырьләр.* ..... 73
Фәнзаман БАТТАЛ. *Сатирик хикәяләр.* ..... 77
Луиза ЯНСУАР. Сөю кадәр сөю – мирасыбыз. *Шигырьләр.* ..... 107
Лилия СӘГЫЙДУЛЛИНА. Җирдә – чәчәк йолдызлыгы. *Шигырьләр.* ..... 120

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Габдулла ШӘРӘФИ. Тәфтиләү. ..... 112

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Рифат СӘЛАХОВ. *Шигырьләр.* ..... 122

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рафаэль ХӘКИМ. Татар рухы. ..... 124

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Илшат ВӘЛИУЛЛА. Буыннар чылбыры өзелмәс... ..... 142

**ХӘТЕР**

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Гыйбрәтле язмышлар. ..... 149
Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Оренбургның фидакарь заты. ..... 167

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ..... 169
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ..... 172
Җәмил ЗӘЙНУЛЛИН. Амазиглар кемнәр алар? ..... 177

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ..... 182
Бер сорауга – бер җавап. ..... 176

«Казан утлары» архивыннан. ..... 186
Укучы сүзе. ..... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повести Л. БАДЫКШАНА «Рок», И. ХУЗИНА «Вождь краснокожих», сатирические рассказы Ф. БАТТАЛА; стихи Ф. ГАБДРАХИМА, Р. РАХМАНИ, Л. ЯНСУАР, Л. САГИДУЛЛИНОЙ.
«Творчество молодых»: стихи Р. Салахова.
«Из сокровищницы татарских рассказов»: А. ШАРАФИ. «Тафтиляу».
«Публицистика»: статья Р. ХАКИМА «Метаморфозы духа».
«Литературная критика»: рецензия И. ВАЛИУЛЛИНА на книгу Р. АЙМАТА и М. ЗАКИРА.
«Память»: статья М. УСМАНОВА «Судьбы»; статья Л. ХАМИДУЛЛИНА «Национальный герой Оренбурга».
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации»; статья Ф. ГАРИПОВОЙ «История наших деревень»; статья Дж. ЗАЙНУЛЛИНА «Кто они амазигы?»
Страницы из «Татарской энциклопедии».
Слово читателя.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Лето». Фотоэтюд; писательница Саима Ибрагимова.

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: stories by L. BADIKSHAN «Fate», I. HUZIN «Redskins' Leader», satirical stories by F. BATTAL; verses by F. GABDRAHIM, R. RAHMANI, L. YANSUAR, L. SAGIDULLINA.
«Creativity of youth»: verses by R. SALAHOV.
«From treasuries of Tatar stories»: story by A. SHARAFI «Taftilau».
«Publicism»: article by R. Hakim «Metamorphosises of spirit».
«Literary critic»: review by I. VALIULLIN on books by R. AYMAT and M. ZAKIR.
«Memory»: article by M. USMANOV «Destinies»; article by L. HAMIDULLIN «National Hero of Orenburg».
«Science»: A. TIMERGALIN «Dictionary of nation»; article by F. GARIPOVA «History of our villages»; article by J. ZAINULLIN «Amazigs, Who are they?»
Pages from «Tatar encyclopedia».
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Summer». Photoetude; writer Saima Ibrahimova.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 20.06.2006 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 3–473. Тираж 7100.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2006 ел.



Локман
Бадыйкшан

# ТӘКЪДИРЕМ

ПОВЕСТЬ-ИСТӘЛЕК

• • •

1919 ел. Урак өсте. Әнием Шәмсекамәр, ике абыем белән үзебезнең кырда булган. Төш житүен көтмәстән, әниемне тулгак тота башлый. Ул урагын куя да абыем Габделбарыйны үзе янына дәшеп ала:

—Улым, бар тизрәк. Әнә теге көлтә бәйләүче әбине чакырып китер әле,—ди.

Күпмедер вакыт үткәч, кендек әби аларны үз янына чакырып ала.

—Балалар, сөенегез, сезнең тагын бер энегез дөньяга килде!

Кич кырын әнием, мине—төш вакытында дөньяга килгән нарасыйны алъяпкычына төргән дә аягына торып баскан.

—Балалар, сез икәү идегез, менә хәзер өч малай булдыгыз инде. Әйдәгез, өйгә таба атлыйк. Әтиегезнең дә эштән кайтыр чагы житеп килә. Яна сабыйның дөньяга килүенә ул да сөенеп туя алмас әле.

Без кайтканда кояш баеп барган инде. Әкренләп кенә кайтканбыз. Чөнки әниебезнең хәле, аңлашыла, бик үк шәптән булмагандыр.

Безнең йортыбыз Әлмәт урамындагы Якуб атлы байның таш пулатыннан әлләни ерак түгел. Кайтып житсәк—өйдә һичкем юк ди.

Әниебез өйгә керүгә үк түр сәкедәге мамык ястык белән түшәккә мине кочып яткан. Абыйларым урамга чыгып китеп, күрше малайларына мактанырга керешкәннәр.

Көтү кайткан, сыерыбыз, мөгезе белән жил капканы ачып, ишегалдына кергән. Сарыкларыбыз да ачык капкадан үзләренең сараена кайткан.

Олы абыем Габделбари аптырап:

—Әниебез урын өстендә ята, сыерыбызны кем савар икән инде?—дигән.

Зәкәрия абыем һич аптыраусыз-нисез:

—Хәзер каршыдагы сәүдәгәр Әмирхан абзыйның хатынын чакырам,—дигән.

Бераздан әтиебез дә кайткан. Аның атын олы абыем йөгән өзәнгесеннән тотып:

—Әти, әни кырдан бәби апкайтты. Ир бала. Хәзер өйдә. Түшәк өстендә авырып ята,—дигән.

—Бик әйбәт, хәзер инде сез өч малай булдыгыз,—дип, ул шундук әни белән минем янга ашыккан.

---

Локман БАДЫЙКШАН (1919) – *фронтовик язучы; «Атау кызы», «Атау егете» һ. б. китаплар, повестьлар авторы. Казанда яши.*

Еллар үткән. Мин туп кебек тәгәрәп үскәнмен. Зәкәриянең мине кабык арбада, ишегалды буенча әрле-бирле этеп-тартып йөрткәннәрен әле дә хәтерлим.

Сугыш беткән иде инде. Әтиебезнең өйгә кайтып төшкән чагы. Ул гомере буена иген иккән кеше. Анар бу эшләр белән озак шөгыльләнергә туры килмәгән. Сугыштан кайткан солдатның аң-белеме ярыйсы гына ич инде. Аны Әлмәттән якындагы бер авылга авыл советы рәисе итеп куйганнар. Ул һәр көнне иртән атыбызны җигеп эшенә киткән, кичләрен генә кайтып кергән. Йорт эшләрен, мал-туарны абыйларым караган. Аты, сыеры, сарыклары булган безнең кебек хуҗалыкларны авылда урта хәлле дип йөрткәннәр.

Әтиебезгә эшендә озаклап утырырга туры килми. Аны кантон җитәкчеләре бик тиз күреп, рәислегеннән Бөгелмә шәһәренә зур эшкә чакырып алганнар. Бу эшеннән ул инде көн дә түгел, ә атнасына бер-ике генә кайткалый башлый.

1924 елның августы. Әтиебез өйдә юк. Әниебезнең авырып киткән чагы—яңадан ике игезәк бәбәй тапты. Әниебезнең сәламәтлеге көннән-көн начарлана барды. Шунлыктан ул сабыйларны имезә алмый иде.

Әтиебез кайтмый да кайтмый. Мин әниемне кочаклап йоклаганмын. Урам яктагы күрше сәүдәгәр Әмирхан хатыны мине әниемнән йолкып алырга тырышкан. Ә мин һаман карышканмын...

Елап, Әмирханнар ишек алдында алма төялгән арбада утырам. Һаман елыйм. Соңрак кына белдем: шул хәтле алманы җыеп, арбага тутырырга сәүдәгәрләргә ияргән Зәкәрия абый булышкан икән. Мине алма гына юатмагач, елаганмын да елаганмын. Нигә мине әниемнең куеныннан алдылар икән?..

Арбада елый торгач, акылыма килгәнмен. Төшкәнмен дә капкага таба барганмын. Җил капканы ача алмаганмын, күрәсең, ул бикле булган. Аннары, бәрәңге бакчасына чыкканмын да читән аша тыкырыкка төшкәнмен. Бу тирәләрдә күп тапкырлар йөргәнлектән үзебезнең йортыбызга йөгергәнмен. Ишекне ачып керсәм, ни күрим: беркем дә юк. Елый-елый ишегалдына чыкканмын, йорт-кураның бар җиреннән әниемне, абыйларымны эзләгәнмен.

Тик таба алмаганмын...

* * *

Бөгелмә шәһәрендә яшибез. Йортыбыз зур, бүлмәләре күп. Тышкы яктан ул сыек зәңгәргә буялган. Элек монда нинди дер бер бай яшәгән диделәр. Колчак армиясе чигенгән вакытта качып киткән...

Әтиебез зур хуҗалык эшендә эшли икән. Ат карауч ыбыз, аш-су пешерүчебез дә бар. Без балаларга өс-башыбызны юып, үтүкләп торучы Бану дигән апабыз да бар. Абыйларым укый. Мин көннәремне өйдә уенчыклар белән мавыгып үткәрәм. Әтиебез әни вафатыннан соң әйбәт хатынга өйләнгән икән. Абыйларым кебек үк, мин дә аны «әни» дип атап йөртә башладым. Әле дә хәтеремдә: шулай бер-бер бәйрәм-сәйрәм көнендә барыбыз да демонстрациягә чыктык. Шунда мине яшь әнием Газзә сөеп кулына алып күтәрде. Күрәм, урам халыкка тулган. Чәчәкләр тотканнар, кайберләре кызыл байраклар күтәргән.

Бу бәхетле көннәр купкә сузылганмыдыр—белмим. Мин аларны бары тик абыйларым сөйләүләреннән генә хәтерлим.

Әниемнең игезәкләре озак яшәмәгән. Әтиебез кайтып төшеп, аларга исем кушарга өлгергән-өлгерүен. Кызыбызга Һава исеме, малайларына—Җир дип кушкан булганнар. Әлбәттә, болары минем төшемдә күргәннәрем кебек кенә исемдә калган инде.

Без янадан Әлмәткә әйләнеп кайтканбыз. Тормышыбыз үзгәреп киткән. Әтиебезне Казанга бүтән эшкә чакырганнар. Ә яшь әниебез табиблыкка укырга киткән. Мин әтиемнен энесе Сәхибҗан абзыйларда—төп йортыбызда калганмын.

Беренче сыйныфны укый башлаганда миңа инде сигезенче яшь киткән. Җәй көннәрендә Сәхибҗан абзыйның ике баласын карап тордым. Олы кызлары миннән бер-ике генә яшь—Бриллиант исемле, малае—Алмаз. Бүтәннәр жиз дә бакыр, пыяла да чүлмәк диярсең. Алмаз үтә көйсез малай. Ата-анасы май заводында эшли, ә миңа малайлары янынннан бер адым да читкә китмәскә кушалар. Бриллиант энесенә әйләнеп тә карамый. Әти-әнисе эшкә китү белән үк урамга чыга да йөгерә. Ә мин Алмаз белән калам. Төрле бала-чага уенчыклары белән аның күңелен табам. Ә яшьтәшләрем мине кәшәкә сугарга, кузна уйнарга чакыра. Чыгып китә башласам Алмаз «разбой салып» акыра башлый.

Шулай бер көнне күрше малае—яшьтәшем Әхмәр йөгереп керде дә:

—Әйдә, Локман, кузна уйнарга! Синдә алар күп бит, малайлар чакыра,—диде дә көтеп тора. Мин кузналарымны алып өйдән чыга гына башлаган идем, Алмаз уенчыкларын ташлап акырырга тотынды. Ул әле сөйләшә белми, анарга нибары яшь чамасы гына. Күпме уенчыклары була торып, миңа китәргә ярамый, имеш. Акырыплар елый гына бит бу. Түзмәдем, күт битен чеметеп алдым. Елавыннан шып туктады. Мин исә иптәшем белән шундук урамга чыгып йөгердем.

Капка төбебездә бераз кузна уйнап туйганнан соң, малайлар берәм-берәм таралышты. Мин өйгә кердем. Алмаз үз уенчыклары белән уйнап утыра. Керүемә игътибар да итмәде. Чеметкәнемә үпкәләгән диярсең.

Әсма апа миңа бәрәңге әрчергә дип бер таба калдырган иде. Мин шуңа тотындым.

Кичкырын Алмазның әти-әнисе эштән кайтты.

Әсма апа аш пешерергә керешге. Аннары улы янына килде. Алмаз мин чеметкән күт битен бармагы белән төртеп күрсәтте. Әсма апа кара янган җирне күреп:

—Сабыйны нишләттең, Локман?—дип кычкырды. Яныбызга Сәхибҗан абзый да килде. Малаеның җәрәхәтен күреп, бер сүз дә әйтмәстән, кинәт кенә кул учы белән минем яңагыма сугып җибәрде. Күземнән утлар чәчрәде. Һичбер сүз әйтмәстән, мин ишегалдына чыгып киттем. Үз-үземне кая куярга белмичә йөргәләп алдым да абзар ягына атладым. Анда ярылып бетмәгән утын пүләннәре тәгәрәшеп ята иде. Шуларны балта белән ярырга керештем.

Күпме вакыт үткәндер—белмим, Әсма апа ачык тәрәзәдән:

—Локман, ашарга кер,—дип эндәште. Ачуы басылмаган иде әле.

—Юк, ашыйсым килми,—дидем. Ул, башка бер сүз дә әйтмәстән, тәрәзәсен япты да куйды. Ашыйсым килә иде югыйсә, ләкин яңагым ут булып янганлыктан, ашарга юри кермәдем.

Кичен утлар алынгач кына өйгә кердем дә, үземнең ятагыма йомарланып яттым. Мине бер генә нәрсә борчыды: нишләргә? Шуңа җавап эзләп, бик озак йокыга китә алмый яттым. Башыма бер ачык уй керде: качарга болардан, үз авылыбыз Әлмәткә—Сөләйман абзыйларга качарга! Шуннан соң гына, тынычлана төшеп, йоклап киткәнмен.

Уянып киткәндә, яктырган иде инде. Ашык-пошык кына киенеп алдым да ишегалдына чыктым. Кояш яңа гына күтәрелеп килә. Бәрәңге бакчасы буйлап киттем. Бакчалары бик зур. Ул биек читән белән уратып алынган. Минем буем җитәрлек түгел. Уйланып торырга вакыт юк: үрмәли-әрмәли ниһаять өскә менеп җиттем дә теге якка төшү әллә ни кыен булмады инде. Кеше бакчалары аша авылны чыгарга ашыктым.

Төш вакыты җитте. Үтерепләр ашыйсым килә. Эчемдә бүреләр улый. Түзмәдем, юлдан чыгып, арыш кырына кердем дә башакларны йолкып, изүемә тутырам. Ыштаным бөрмәсе нык. Янадан юлга чыгып, сабактан бөртекләрне авызыма тутырам гына, карыным ачуы бераз басылгандай булды. Юл йомшак. Яланаягым астында мул тузан.

Арыдым. Юлдан чыгып бер карт каен төбенә барып утырдым да янадан башак угалап ашыйм. Арыганмын икән. Уянып китсәм, кояш төшлектән авышкан.

Тамагым чатнап су эчәсем килә. Уң якта—арыш басуының арткы ягында, Урсал таулары итәгеннән Әлмәткә таба Зәй суы ага да ага. Шунда җитеп, су эчәсемне басасым бар. Иген кырын арыш арасыннан үтә-үтә Зәй ярына барып җиттем. Яры тәбәнәк, шунда төшеп, ике ташка тотынган килеш туйганчы су эчтем дә олы юлга таба киттем.

Әнә, Әлмәт тә күренә башлады. Ул—Урсал тауның итәгенә Зәй буена урнашкан. Анда минем бала чагым үтте. Басу капкасына көтү кайтыр алдыннан гына килеп җиттем. Күрәм: капка алдында—тавык кетәгедәй кечкенә йорт. Анда былтыр авылдан чыгып киткәндә каравылчы булып Гылмастый бабай тора иде. Тагын күрәм: бүген дә шул ук икән. Аның белән исәнләшеп алдым. Ул миннән:

—Каян кайтып киләсең, улым—дип сорады.—Таныдым, улым, син Сәхибҗаннарда торасың бит әле. Атаңны да беләм. Әхмәтхан малае бит син. Нигә Әлмәткә үзең генә кайтып киләсең?

Дөресен әйттем:

—Әниемнең абыйсы Сөләйман абзыйларга кайтышым иде. Алар мине ярата.

—Хәер, син ятим бала шул. Атагыз яшь хатынга өйләнгәч, сезне ташлады да читкә китеп барды,—диде ул.

Олы кешенең сүзе бетми. Миннән һаман төпченеп-төпченеп сораштыра бу. Ләкин минем тизрәк кайтып китәсем килә. Бабай белән саубуллашып, авылга кереп киттем. Сөләйман абзыйлар Чатра елгасы ярындагы күпергә якын торалар. Бакчалары да инеш буенча Зәйгә таба сузылган.

Капкаларына килеп җитүем белән Сөләйман абзыйның, ат йөгәнен иңенә салып, капкадан чыгып килеше иде. Мине күрүгә ул:

—Каян кайтып киләсең, улым?—дип сорады.

Ирен озатырга капка төбенә Саҗидә апа да чыккан икән. Ул мине күреп алды. Шундук хәлемне аңлады булса кирәк:

—Әйдә, улым, ачыккансыңдыр. Өйгә кереп, ашап ал,—диде.

—Сөләйман абзый, кая барасың?—дип сорадым мин.

—Болыннан атымны апкайтырга барам.

—Барма, атыңны үзем алып кайтырмын,—дидем мин.

—Танырсыңмы икән?

—Танымаска! Баш уртасында агы бар. Исемен дә беләм—«Акмангай» дип йөртәсең.

—Ярый, улым, бар, Саҗидә апаң ашатсын. Аннары йөгәнне сиңа бирермен,—дип ул капка төбенәрәк эскәмиягә утырып, тәмәке көйрәтә башлады. Мин Саҗидә апа белән өйгә кереп киттем. Ишекне ачу белән каршыдагы кечкенә сәкегә күрсәтеп, Саҗидә апа:

—Бар, улым, утыр. Хәзер сыйлыйм,—диде дә, аш-су бүлмәсенә кереп китте. Ул аннан агач кәндигә тутырып салган чөгендерле катык белән зур гына ипи телеме алып чыгып, алдыма китереп куйды. Мин бик тә яратып ашадым. Сөләйман абзый тәмәкесен көйрәтеп бетергән иде инде. Аның кулыннан йөгәнне алып, җилкәмә салдым.

—Акбаш кайсы болында?

—Төгеч болынында. Улым, Акбашны тапсаң, менә бу ипи телемен дә ашатырсың.

Мин Чатра елгасын күпердән чыкмый су аша гына үтеп, болынга таба киттем. Болын ерак түгел—басу капкасыннан узасы да Зәй болынына чыгасы. Тиз барып життем, ә анда йөзләп ат утлап йөри. Әлләни озак эзләп маташмадым, Акбашны шундук танып алдым.

—Акбаш, әйдә кайтабыз, Сөләйман абзый көтә.

Ул мине ишетүгә башта кешнәп алды, аннары яныма килә башлады—таныдым... Мин аны тай чагыннан ук беләм бит. Атланып йөргәнем дә бар. Куенымнан икмәк телемен чыгарып, яртысын сындырып бирдем. Ул аны рәхәте килеп ашап алды.

—Әйдә, Бахбай,—дигәч, ул миңа иярде. Басу читәненә житкәч, ипи телеменең калганын ашаттым. Аннары йөгәнен кидердем дә читәнгә терәп бастырдым, ул арада атланып та өлгердем. Сөләйман абзый безне капка төпләрендә каршылап:

—Улым, зур үскәнсең икән,—диде.

• • •

Көз житте. Укулар башланды. Мәктәп Якут байның таш коймага уратып алынган ихатасы каршысында гына, анысында бишенче сыйныфтан алып тугызынчыга кадәрге үсмерләр укый.

Мәктәп каршысында гына зур мәчет бар—ул да мәктәп, без, дүртенчеләр Саттаров Үзбәк атлы малай белән бер партада утырабыз. Укытучыбыз—мөләем йөзле,Сәмигъ абзый. Ул барчабызны да кеше итәргә тырыша. Мин укуда үтә сүлпән барам. Бигрәк тә арифметикасы авыр бирелә. Өй эшләрен Үзбәктән күчереп алам. Тактага чыгарсалар, тораташ кебек катам да калам, бирелгән мәсьәләне чишә алмый аптырыйм.

Кайбер көннәрдә дәрес әзерләшергә өлкән класс укучысы Кәүкәп безгә керә. Ул бигрәк тә әкиятләр укырга ярата, ә мин тынлыйм. Ул—матур кыз. Үсеп килә инде. Аның урамыбыздагы егетләр белән йөргәнен дә күргәләгәнем бар. Тик мин көнләшә белмим. Шулай да аны яратам... Бик.

Бер, шулай, мәктәптән кайтып килешли Үзбәк дустым белән Якуп байның өе яныннан үткән чакта, тыкырык башында таш койманың аскы өлешендә чүп-чар белән күмелә язган тәрәзә күреп алдык. Иелеп карасак, ни күрик: анда баз бар икән. Кызыксынып, тәрәзә алдындагы чүп-чарны чистартып, шул базны тикшерергә булдык. Ничек төшәргә анда? Озак уйлап тормыйча, Үзбәк өйләренә йөгерде, күп тә үтмичә озын бау алып килде.

—Син төшәсеңме, минме?—диде ул.

—Мин!

Тәрәзә пыяласыз иде. Күпме генә карасак та, аста бернәрсә дә күренми. Шырпысыз эш чыкмас. Үзбәккә янадан өйләренә кайтып, шырпы белән шәм кисәге алып килергә туры килде. Мин аларны кесәгә салып, бау буенча базга төштем. Шырпы сызып, шәмне яндырып жибәрдем. Ул баз китаплар белән шыплап тулган. Үзбәккә мондагы байлыкны хәбәр иттем.

—Бауга бәйләп бирә башла,—диде ул.

Шулай берничә бәйләм китапны тәрәзәдән Үзбәккә озаттым.

—Житәр, Локман. Үзең чык инде, мин сине бау белән күтәрәм.

Сыдырыла-сыдырыла тышка чыктым.

—Әйдә, бу китапларны безгә илтик. Укып карыйк әле. Нәрсәләр бар икән?—диде Үзбәк.

Китапларны көч-хәл белән Үзбәкләргә илттек. Аларның ишегалды түрендә сарайлары бар. Шунда бушаткач исемнәрен укый башладык. Гаяз Исхакый дигән язучының калын-калын китаплары, Коръән тәфсирләре, Галимжан

Ибраһимовныкылар—тагын-тагын бер дә ишетмәгән китаплар икән. Аларның барысы да гарәб әлифбасында язылган. Без Сәмигъ абыйдан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Мансур Крымов, Әбүзәр Турай, Һади Такташ кебек язучылар бар икәнлеген белә идек инде. Шундый зур язучыларның китапларын кулыбызга төшерүгә бик сөенештек. Кинәштек тә иртәгә янадан шул базга төшеп карарга булдык.

Ә мин исә берничә әкият белән хикәяләр китабын үземә алып кайтып киттем.

Бәхеткә, бүген дә Сәхибҗан абзый белән Әсма апа клубка чыгып киттеләр. Аларның китүләрен тәрәзәдән карап торган күрәсең, безгә Кәүкәп килеп керде. Китапларны күргәч, аның исе-акылы китте. Шундук «Теләнче кыз» дигән китапны укырга да кереште. Матур итеп укый. Мин дүртенче сыйныфка йөрсәм дә кычкырып укый алмыйм, тотлыгам. Ә бу китапның эчтәлеге миңа аңлашылмады. Кәүкәп:

—Ярый, Локман, мин моны үземә алырмын. Сиңа башканы укыйм,—дип, ул калыннардан калын китаптан «Гөлчәчәк» әкиятен укый башлады.

Бу кичне без әллә ничә әкият укыдык. Әллә Кәүкәп укыганга—аларның барысы да кызык иде.

...Икенче көнне мәктәптән кайтышлый янадан базга барырга булдык. Бу юлы Үзбәк үзем төшәм диде. Монда киләсебезне алдан ук чамалап, шырпышәм дә алган.

Ул чыккач, китапларны бәйләдек тә аркабызга асып кайтып киттек. Үзбәкләрнең сараена китереп аударгач исебез-акылыбыз китте. Нинди генә китаплар алып кайтмаганбыз икән. Гарәпчә язылганнардан башка русча китаплар да күп эләккән икән!

Бу юлы бүлешеп тормадык; мин букчама сыйган кадәрле алдым.

Кояш баерга күп калмаган иде инде. Мине Әсма апа чакырып алды.

—Локман! Казларыбызның бер атна кайтканы юк, бар әле, басуда йөриләрдер, эзләп кара,—диде.

Кулыма чыбык алып, басуга йөгердем. Басу капкасы ачык. Каравылчы юк. Игеннәр урылып, көлтәләр ташылып беткәч, ул капканы ачып куялар да шуннан казлардыр, үрдәкләрдер кырга симерергә чыгып китәләр. Коелып калган бөртек, башаклар күп әле анда аларга.

Кырга чыгып, йөзәрләгән каз-үрдәк арасыннан казларыбызны эзли башладым. Озак маташмадым, таптым үзебезнекеләрне. Күрәсең алар мине үзләре таныдылар булса кирәк: якыная башлавыма ук кангылдашырга керештеләр. Кулымдагы тал чыбыгы белән аларны авылга таба куа башладым. Куа дигәч тә... Менә бервакытны казларым йөгерешеп киттеләр дә дәррәү һавага күтәрелделәр... очтылар да киттеләр. Шундый курыктым, болар жылы якка китмәгәйләре, мәйтәм...

Боегып кына кайтып киттем. Өйгә кереп, Әсма апага:

—Казларны таптым-табуын, тик алар жылы якка очып киттеләр,—дидем.

Әсма апа көлә:

—Бар, Локман, абзарга кереп кара әле. Алар шунда түгел микән?—ди.

Керсәм—казлар шунда. Исем китте. Күпме очып, үзебезнең ишегалдыбызга кайтып төшкәннәр!..

* * *

Кыш житте. Көннәр салкынайды. Мин тула оек белән чабата киеп йөрим әле. Атна да үтми, чабатамның мыеклары чыга башлый, баулары өзелеп бетә. Чабата киярга бер дә яратмыйм инде. Нишлисең, бүтән чарасы юк. Без чабатаны ярминкәдән сатып алабыз. Бәясе утыз-кырык тиен тора, ә акча бер дә кулга керәм дип тормый.

Шулай бер көнне мәктәптән кайтышлый мәчет янындагы таш кибеткә барып кердем. Анда китаплар сатыла. Өстәлләргә тезеп куелганнарының исемнәрен укыйм, «Улак белән еракка» дигәнен күреп алам. Мөдир Бәһаветдин абзый күзәтеп тора икән. Яныма килде дә:

—Мин сине беләм бит, Сәхибжаннарда торасың. Ә атаң яшь хатыны белән Ленинградта яши. Әхмәтхан абзый бик тә булдыклы кеше иде. Әниең иртәрәк үлеп китте шул,—дип, минем йөрәгемне әрнетеп җибәрде, күземнән мөлдерәмә яшьләр саркыганны тойдым. Кибеттән чыга гына башлаган идем, ул:

—Локман, якынрак кил әле. Иртәгә базар көн. Менә мин сиңа бер кочак китап бирәм. Шуларны сата алсаң, күзең төшкән китапны алырга акчаң да булыр. Ризамы?

—Нишләп риза булмыйм? Булам! Базарда газет сатучылар да күп,—дидем мин.

Ул миңа чутта саный-саный бер кочак китап бәйләп бирде:

—Базар беткәндә сатылмаганнарын кертерсең. Акчасын да.

Мин биргән китап бәйләмен алып, кибеттән чыгып киттем. Кылт итеп башыма бер матур уй килде. Туктале, мин әйтәм, атна саен Сөләйман абзыйларга атлары белән базарчылар кунарга төшә бит. Өйләре халык белән тулган була. Шуны искә төшереп, туп-туры букчамны, китапларымны күтәргән килеш, шунда киттем. Сөләйман абзыйның миңа яшьтәш кече кызы Рәхимә кулымдагы китапларны күреп:

—Каян алдың, Локман, бу кадәр китапны?—диде. Без бер сыйныфта укыйбыз. Икебез бер елны туганбыз.

Рәхимәгә бу китапларны кибеттән Бәһаветдин абзый сатарга җибәргәнен әйттем дә, туп-туры базарчылар чәй эчеп утырган зур якка чыктым.

—Абзыйлар, авылларыгызда сезнең дә минем кебек укучы малайларыгыз, кызларыгыз бардыр. Бу китаплар бик очсыз, ун-унбиш тиенлекләр генә. Сатып алыгыз, үкенмәссез, балаларыгыз сөенер,—дидем.

Паласта зур самовыр тора. Дистәдән артык агай күлмәкчән генә утыра, бик тәмләп, тирләп-пешеп чәй эчәләр. Күпләре миңа күтәрелеп карады. Аннары берсе Сөләйман абзыйга игътибарын юнәлтеп:

—Нинди малай була бу?—дип сорады ул.

Сөләйман абзый бер дә исе китмәстән:

—Күптән вафат булган сеңлемнең угъланы була бу. Әтисенең энесендә тора. Күбрәк миндә тукланып яши,—дип куйды.

Мин эндәшмичә генә басып торам. Агайларның берсе:

—Энекәш, әнә теге иң өстәгесен миңа бир әле,—диде.

Мин шундук аңа теге китапны суздым.

—Бәһасе кыйммәт түгел икән. Нибары егерме тиен. Алам,—диде ул.—Кызым укыр әле.

Ул кесәсеннән акча янчыгын чыгарып, аннан егерме тиен көмешне миңа сузды. Аны гына көткәннәр диярсең, башкалары да:

—Миңа бусын бир... Тегесе дә әйбәт икән,—диешә-диешә китапларны тиз арада алып та бетерделәр. Кесәм көмеш, бакыр акчалар белән тулды да куйды. Агайларга рәхмәт әйтеп, Рәхимә янына икенче бүлмәгә чыктым.

Мин барып җиткәндә кибет ябылмаган иде әле. Бәһаветдин абзый мине күреп:

—Китапларың кайда?—дип сорады.

—Сатып бетердем!

Ул миңа ышанмыйчарак кырын карап куйды.

—Менә, акчалары,—дип, өстәлгә кесәмдәге бар тиеннәрне чыгарып салдым. Шунда бер көмеше бармак арасыннан идәнгә чыңлап төште дә, тәгәрәп китеп, ишек янына җиткәч капланды. Аны барып алганчы Мөдир акчаларны санап өлгергән икән:

—Егерме тиене җитеп бетми,—диде ул. Мин:

—Менә ул егерме тиенлеге,—дип теге көмешне учына салдым.

—Булган малай икәнсең. Менә тагын ал. Иртәгә базарда сатарга күбрәк бирәм,—диде Бәһаветдин абзый.—Боларны сата алсаң, үзеңә кирәгеп кибеттән сайлап алырсың.

* * *

Бүген базар көн. Иртән торгач та, башта чәй эчеп алдым, аннары сатарга дигән китапларны букчама тутырып, берничә төштән ямау салган тула оегымны, туза башлаган чабатамны киеп, яктыра башлау белән базарга чыгып киттем.

Әле яктырып бетмәсә дә, Әлмәт базарында халык күп иде инде. Шулар арасына кереп:

—Агайлар! Менә бик матур китаплар, алып калыгыз!—дип кычкыра-кычкыра кешеләр арасында йөри башладым. Алучылар бер дә күренми. Шулай да, шигырь китапларын сирәк-мирәк алгаладылар, ә калын китапларымны кулларына тотып карыйлар да бәһасенә карап:

—Бигрәк кыйммәт икән,—дип кире сузалар. Берничәсе «Җир тыңлый» дигән китапны кызыксынып кулларына алсалар да, кире бирделәр. Шулай да «Өч нарат» дигән калынын алдылар. Аның язучысы Фатих Сәйфи Казанлы икән.

Базар тарала башлагач, сатылып бетмәгән китаплар белән акчаны тапшырырга киттем.

Кибеттә утлар алынган иде инде. Бәһаветдин абзый мине елмаеп каршылады. Кулымда аз калган китапларны күреп:

—Унган малай икәнсең!—дип, өстәлгә куйган китапларымның бәһаләрен чутка санап та куйды.

—Локман күп саткансың. Хәзер сиңа тигән акчаңны бирәм. Шуларга җаның теләгән әйберләреңне сайлап ал,—диде ул.

* * *

Ул кыш бик салкын килде. Мин урамга рәхәтләнеп яңа тула оек киеп чыктым. Укуларым әллә ни алга китмәсә дә, бераз өлгерә башладым. Монарчы гел «икеле-өчле»гә генә укый идем ич. Язга җиткәндә бар фәннәрдән дә икеләремне бетердем. Укытучы Сәмигъ абый гел «өчле», «дүртле» билгеләре генә куя башлады. Татар теленнән, әдәбияттан да әйбәт кенә барам.

Яз җитеп, Май бәйрәме дә якынлашты. Шулай бер көнне, төшке аштан соң, зур мәктәпкә кердем. Балалар тәнәфескә җыела торган залда бәйрәмгә багышлап чыгарылган гәҗиткә күзем төште. Өлкән сыйныф укучылары эше инде. Ни күрим, беренче, икенче баганаларда зур гына шигырь урнаштырылган. Язучысы Хәйретдин икән. Аның шигыренә исем китеп, бик кызыксынып укыдым. Юл саен Май бәйрәмен мактаган. Ләкин юллары бер-берсенә ябышмаган, «Туктале, мин әйтәм, язып карыйм әле мин дә»—дидем.

Өйгә кайткач, тиз генә мал-туар эшләрен бетердем дә, дәрес хәстәрләргә дип өстәл янына килеп утырдым. Һаман күңелемдә күрше малае, өлкән класс укучысы Хәйретдиннең шигыре. «Язып карыйм әле мин дә Беренче май турында» дип, шигырь яза башладым. Күп язмадым, ни барысы биш кенә куплет. Майны мактамадым, халык ни өчен бу яз бәйрәменә атлыгып чыга—шуны ачыкладым.

Икенче көнне укырга баргач, зур мәктәпкә кердем.

Гәҗит читендә кечкенә бер тартма бар—укучылар үзләренең хәбәрләрен, шигырьләрен салсын өчен. Мин дә үз шигыремне шул тартмага төшердем.

• • •

Икенче көнне укулар бетәр алдыннан мине өлкән сыйныфтан берәү эзләп килде.

—Локман, сине безнең әдәбият укытучыбыз Әбүзәр Түрәев укытучылар бүлмәсенә дәште,—диде дә китеп барды.

Аптырап киттем. Нигә чакырды икән? Зур тәнәфес вакыты иде. Бөтенесе тәнәфес залында. Чакырылган бүлмәгә барып кердем. Түрдәге өстәл янында, калкурак буйлы, ябык йөзле, шәп чәчле, ак күлмәгенең изүе ачык бер укытучы мине күргәч:

—Әйдәле, Локман, якынрак кил,—дип, үз янына чакырды.

Килдем.

—Беренче май турындагы шигыреңне укыдым әле. Үзең яздыңмы?—ди.

Чөгендердәй кызарып киткәнемне сизеп алдым.

—Хәйретдиннекеннән матуррак булсын дип тырышкан идем шул.

—Ярый. Бүген дәрестән соң минем фатирга кил,—диде ул.

Дәресләр беткәч, өйгә кайтып тормадым, чакырган җиргә ашыктым.

Кыяр-кыймас кына Әбүзәр абыйның ишеген ачтым.

—Оялма. Түргә уз, Локман,—дип каршылады ул мине. Башта җентекләп мина күз йөртеп чыкты, аннары үз янына утыртып:

—Шигырең мина ошады. Ләкин шикләнәм: үзең язмагансыңдыр син аны.

—Билләһи, Әбүзәр абый. Хәйретдиннең стенада чыккан шигырен укыгач, көнләштем. Аныкыннан яхшырак язарга тырыштым.

Укытучы елмаеп бер мина карады, аннары ике тәрәзә арасына эленгән рәсемгә ымлап:

—Әнә, күрәсеңме, диңгездә нинди давыл. Кораб һәлакәткә очраган. Шул турыда менә хәзер язып күрсәт әле,—диде.

Монарчы бишләп шигырь язган идем инде. Көен-көйгә китерә беләм. Шул батып барган корабка янадан карап алдым. Нигә батты икән ул? Зур-зур дулкыннар кочагында бер бүрәнә тибрәлә, шуна берничә кеше тырышып-тырмашып үрмәләп менергә маташа. Чын күңелдән кызгандым мин аларны. Матур уйлар килде башыма. Җыр калыбына салып, беренче куплетын язып куюым булды, шигырь үзеннән-үзе күңелемнән акты да акты.

—Ышандым, шигырьне үзең язгансың икән. Болай булгач, киләчәктә матур язарсың. Кемнәрне укыганың бар,—дип сорады укытучы.

—Такташ шигырьләрен. Сирин дигән шагыйрь дә матур яза. Сиринның «Булмый, булмый» дигән шигырен сөйләп күрсәтимме?

—Ышандым инде, Локман. Яза аласың икән. Бар, кайт. Тагын да матуррак шигырьләр язарга тырыш,—дип, ул мине кайтарып җибәрде.

Шуннан соң бер ай вакыт үтәр-үтмәстә зур мәктәпкә Казаннан шагыйрьләр килеп төште. Алар зур залда укучылар белән очрашу оештырдылар. Мин алдарак урын алырга тырышып, башка малайларны этә-төртә, идәнгә тезләнеп утырдым. Түрдә—сәхнә өстәленә яшел постау җәелгән. Өстәл артында биш кеше утыра.

Мәктәп мөдире урыннан калкып:

—Укучылар, менә сезнең алдыгызда танылган татар шагыйрьләре. Берсе—менә бусы—шагыйрь Мансур Крымов, ә икенчесе—Габдрахман Теләш, ә менә бу иптәш Сирин була. Аның шигырьләрен күпләр ятлап йөри. Ә менә бу кырыйда утырганы—безнең укытучыбыз шагыйрь Әбүзәр Түрәй,—дип безне алар белән таныштырып чыкты.—Шагыйрь Һади Такташ та килергә тиеш иде. Ләкин ул бик каты авырып киткән,—диде дә беренче итеп трибунага шагыйрь Сиринны чакырды.

Мин бик дикъкать белән барысына да сөзеп карап өлгердем, мөнбәргә

чыккан шагыйрь урта буйлы, чәчен артка тараган, ябык йөзле иде. Менә ул залдагыларга күз йөртеп алды, аннары без белгән «Тамчылар» дигән шигырен сөйли башлады.

Тамчы там, там,
Тамуыңны яратам,
Мин дә тамчы булып тамар идем
Тамчы булып тамалсам...

Безнең кул чабулардан соң ул «Татарстан» дигән озын шигырен яттан сөйләп бирде. Ошады инде. Тере шагыйрь үзе укыгач. Сирин чыгышыннан соң Габдрахман Теләш, Мансур Крымов, аннары үзебезнен укытучыбыз Әбүзәр Түрәй сөйләде. Әле моңа кадәр мин укытучыбыз Әбүзәр абыйның танылган шагыйрь икәнлеген белми идем.

Ул башта залдагы укытучыларга, аннары барыбызга да күз йөртеп чыкты да «Текә тауда» дигән шигырен тын гына, ашыкмыйча сөйләп китте:

Бүген Гайшә белән без икәү
Тау шуарга чыктык бергәләп.
Салкын һава бәрелеп битләргә,
Сөйгән кебек була иркәләп.
Юк чана таудан төшкәндә,
Кар бураны өскә сырыша.
Мин шаркылдыйм,
Гайшә үпкәләп:
—Житәр инде!—диеп кычкыра.
Кар дулкыны бора чананы,
Чана кагылып кыйгач юл ала.
Кар дулкыны усал.
Нигә аны
Жилләр шунда өеп куйганнар?
Чана ава.
Без дә икәүләп
Тәгәрәшеп аска төшәбез.-
Беребез көлә...
Беребез үпкәләп,
Тауга менә чана күтәреп.
Яз йоклаган әле,
Безнең болай
Шаяруны сизә күрмәсен.
Кояш, әйтмә аңа, ишетәсеңме
Вакыты житми килә күрмәсен.

Үзебезнең мәктәптә үк шагыйрь барлыгын белгәч, мин бик куандым. Бу очрашу күңелемдә, күзем мәңгелеккә йомылганчыга кадәр хәтеремдә калыр дип уйлыйм.

* * *

Китап кибетенә һаман баргалап йөрим. Баһаветдин абзый миңа кочак-кочак яна китап бирә. Мин аларны букчама тутырып, кичен өйгә алып кайтам да иртәгесен базарга ашыгам. Латинча хәрефле китапларны алучылар бик сирәк. Инде өч ел яңача укыталар югыйсә.

—Энекәш, гарәпчә имлялы китаплар алып чык син, без шуны укып үстек. Нигә кирәк булды икән ул латин дигән нәрсә? Балаларыбыз кабер ташларын укудан да мәхрүм булып үсә,—дип әйтүчеләр дә бар. Шуны искә алып,

икенче базарда үземдәге Якуп бай базыннан алып чыккан китапларны да алып килдем. Исем китте: күп йөрергә туры килмәде, ул китапларны шундук алып бетерделәр.

* * *

Якуп байның зур йортында ЗАГОТСКОТ дигән оешма эшли башлаган. Анда халыктан мал-туар җыялар. Әлеге малларны авыл көтүенә кушмыйлар, аерым көтәргә кеше яллыйлар. Үзебезнең урамдагы Сабир дигән җиткән егет мине очратты да:

—Локман, сиңа да эш бар. Конторга йөгер. Көтү көтәргә генә син дә ярыйсың. Көненә өч тәңкә акча бирәләр. Әз акча түгел. Җәй буена бергә эшләсәк, өс-башны карарга җитәр,—диде.

Шушы көннән башлап, үземнең үсеп җиткәнемне аңладым.

Мин инде хәзер көтүче малай. Йөзгә якын сыер-сарыкны әрәмә болынына куып чыгарабыз да Зәйнең аръягына качмасыннар дип көне буе көтәбез. Кайткач кына Якуп байның ишегалдына ябабыз. Безне эшкә алган олы яшьтәге абзый һәр көнне аларны санап кына кертә. Бүгенгә кадәр һичберсе югалганы юк әле. Шуның өчен безне яраталар. Ашарыбызга бер бөтен калач, көне буена җитәрлек ит, суган, бәрәңге бирәләр.

Бер ай дигәндә хәтсез генә акча җыелды.

Беренче кар төшү белән малларны әрәмәгә кумый башладык. Эш беттеме, белмим, бер көнне Якуп бай ишегалдына күз салсам, ни күрим: маллар юк, барысын да каядыр куып алып киткәннәр.

Укырга йөрим. Бер көнне базарга Әсма апа белән икәүләшеп чыктык. Акча аның кулында. Бүрек, пәлтә, пинжәк сатып алдык. Акчам һаман бар әле. Йөри торгач, аяк киемнәре сатыла торган җиргә килеп чыктык. Шунда үземә яраклы өр-яңа киез итеккә тап булдык. Чабатамны салып ыргыттым...

* * *

Минем өчен Яңа ел бәйрәме иртәрәк килде... Көтмәгәндә Барый абыем кайтты. Ул техникумын тәмамлап эшли дә башлаган. Өйдә икәү генә калган бер кичне ул мине сөендерде:

—Энем, дәфтәрләреңне, көндәлегеңне карап чыктым. Укуың әйбәт түгел икән. Ни бары татар теленнән, ботаникадан гына «дүртлең» бар. Калган фәннәрдән «икеле», дә «өчле» генә. Болай укысаң, надан каласың. Аңлыйм, эш белән бөтен вакытыңны алалардыр. Мин сине үзем белән алып китәм. Эшләгән авылымда җитмешләрне узган бер әбидә яшим, өе зур, алты почмаклы. Кечкенә ягында әби үзе көн күрә, ә мин зур ягында. Мәктәп тә әлләни ерак түгел...

Котылам икән, мал караудан. Күңелемне биреп укысам, бәлки «икеле»ләремне бетерермен...

Бу кичне абый белән күп нәрсәләр турында сөйләштек. Ул минем шигырь язуыма игътибар итмәде дә, бары тик:

—Язучы булыр өчен ай-яй яхшы укырга кирәктер,—дип телен генә чартлатып куйды.

Барый абый мине үзе белән алып китте. Мине җибәрергә теләмәгәннәр иде, ләкин Барый абый сүзендә нык торды: «Үземдә торып укыр»,—дип кырт кисте.

Икенче көнне кич авышканда Казаннан әлләни ерак булмаган Төрләмә станциясенә килеп җиттек. Төнне-көнне рәхәтләнеп йоклап бардым. Станциягә төшкәч, абзый ат эзләргә чыгып китте. Тагын егерме чакрымга якын барасыбыз бар икән әле. Ул миңа авылның зур икәнлеген, район үзәге дә шунда булуын әйткән иде инде. Шулай да мин, безнең Әлмәттән зур

түгелдер әле, дип уйладым. Хәтсез вакыт абыйны көттем, менә ул килеп тә керде.

—Энекәш ат булды, бер чуашны ялладым. Төрләмә тирәсендә чуаш авыллары күп. Акчаны каермакчы булганнар иде дә, барыбер үземнекен иттем. Бик арзанга килештек,—диде ул.

Абый чуашча яхшы белә икән. Утырдык та, чикмән ябынышып, юлга чыктык. Ат Норлат юлыннан юыртты.

Бөтен тирә-якны ак кар каплаган. Урман-фәлән күренми.

Мине нинди язмышлар көтә икән дип, уйланып бардым. Абый да эндәшмәде.

Нindидер үрне үткәч, алда утлар җемелдәгәне күренде.

—Энекәш! Әнә шул була инде мин торган авыл. Ярты сәгатьтән барып җитәрбез,—диде абый сөендереп.

Өйгә керүгә, безне бер әби каршылады.

—Шушы буламы инде синең энең. Үскән малай икән,—диде ул.—Ни атлы буласың соң?

Мин әйттем.

—Бүген кайтырсыз дип, коймак та пешергән идем. Хәзер кертәм,—дип, әби үз ягына чыгып китте.

Бик юмарт әби бу. Мине үз улы шикелле күрә. Ире Герман сугышыннан кайтмаган. Кызлары кияүгә чыгып беткән.

* * *

Мин инде Норлат мәктәбендә бишенче сыйныфта укыйм. Яңа иптәшләрем була башлады. Алар да минем кебек әлләни яхшы укымыйлар. Уздырасым килеп, үземчә тырышкан булам.

Мәктәп каршысында гына районның «Ярыш» дигән гәҗит редакциясе урнашкан. Язга таба шунда берничә шигыремне кертеп бирдем. Әдәби бүлек мөдире—Шәйхелислам абый берсен укыды да:

—Энекәш, мондый шигырьләр бездә күп. Аларның иң яхшыларын гына чыгарабыз. Менә син хикәя язып китерсәң иде. Эчтәлеге әйбәт булса, без аны төзәтеп басар идек,—диде.

Рәнҗемәдем, шигырьләремне алып чыгып киттем.

Күңелемдә вакыйгалар күп. Берәр мәктәп баласы турында хикәя язырга булдым.

Дүшәмбе көн иде. Миргасим абый, хезмәт дәресе беткәч:

—Син калып тор әле, энем,—диде, фамилиямне әйтеп. Классташларым чыгып киткәч, күңелемнән, нигә кирәк булдыям икән мин аңар, дип уйлап, ишек төбендә басып торам.

Миргасим абыйның өстәле иң түрдә—шомартып куелган вак librарлар янында. Ул, елмаеп, өстәл тартмасыннан гәҗитә чыгарды.

—Энекәш, менә «Ярыш»та синең «Сөтле комган» дигән хикәяңне басканнар. Моңарчы язуыңны белми йөри идем.

Комсызланып гәҗитәне алдым. Карыйм: соңгы битен тутырып, хикәямне басып чыгарганнар. Күз йөртеп алу белән төзәткәннәрен шундук сиздем.

Бик сөендем. Гәҗитәне үземә сорап алдым.

Казаннан абый да кайтып төште. Ул бу авылдагы җиләк-җимеш бакчасында агроном иде. Казанга эшкә чакырганнар икән. Озакламый ул башкалага китәчәк. Укулар беткәнче, мине Хәдичә әбидә калдырырга булды.

* * *

Абый Казанга күчеп китте. Аның урынына яңа агроном—Каһарманов атлы яшь бер егет килде. Ул да мин яшәгән Хәдичә әби фатирына урнашты.

Шулай икәү олы якта торабыз. Вакыт-вакыт ул минем дәресләремне тикшергәләп ала.

Кыш көне өч хикәямне «Яшь ленинчы» гәҗитенә җибәргән идем. «Кечкенә аучылар» дигәне басылып та чыкты. Күп тә үтмәде, балалар язучысы Абдулла Алиштан мина хат килеп төште. Шундый сөендем—башым күккә тигәндәй булды. «Локман, язуын язасың, алай атна саен безгә җибәрмә. Башта әдәбият укытучыгызга күрсәт. Ул яхшы дип тапса гына җибәрерсең. Ә менә ике хикәянне балалар иҗаты конкурсына тәкъдим иттем. Газетабызны күзәтеп бар», дигән Алиш абый.

Болай күп язмыйм да бугай инде—ай саен өч-дүрт битле хикәя. Район гәҗитенә биргәлим. Ләкин алар басарга ашыкмыйлар.

Китапханәгә кердем. «Яшь ленинчы» төпләмәсен карыйм. Ни күрим, өченче биттә зур хәрефләр белән «Конкурс йомгаклары» дигән хәбәр бар! Минем хикәям икенче урынны алган! Бүләккә—Шәриф Камалның бер томын мина бирергә дип язып куйганнар. Еш кына шигырьләре басылып килгән шагыйрь Шәрәф Мөдәррискә дә икенче урын биргәннәр. Бүләккә Һади Такташ томы тәтегән. Өченче бүләкләр дә бар, ләкин беренче бүләк беркемгә дә эләкмәгән!

• • •

Һөнәр укытучысы Миргасим абый мине бик якын итә. Укулар бетүгә, аны колхоз умарталыгына эшкә алдылар. Ул оста умартачы да икән. Шулай бер көнне без торган өйгә килде дә:

—Локман, җәйне минем белән умарталыкта үткәрәсенме? Казанга көзен китәрсең,—диде.

Урманны бераз кергәч, киң генә бер аланлык бар. Шунда колхозның умарталарын тезеп куйганнар. Бик күп. Барысы да бер төсле. Бал кортлары ялгышмыйча үз ояларын ничек табалар икән, дип гаҗәпсендем. Умарта өе зур түгел, юан-юан бүрәнәләрдән бурап салынган. Керсәк, умартачы агай чәй эчеп утыра. Өстәлдә бер табак кәрәзле бал. Миргасим абый:

—Әйдүк, егет, вакытында килеп җиттең. Бүген бераз яна балны аерып карадым әле, авыз ит,—диде.

Балны агач кашык белән умыртып алып, чәй эчә башладым.

—Энекәш, сиңа бер йомышым бар. Чакыруым да шуна. Мин латин әлифбасын өнәп бетермим. Нигә кирәк булгандыр аны безгә көчләп тагу. Шулай инде безнекеләр: Мәскәү ни кушса шуны эшли. Менә күр дә тор, исеңә төшерерсең әле: озакламый безгә урыс хәрефләрен дә тагарлар. Руслаштыру бара бит. Аңламасаң да, үсә төшкәч төшенерсең әле. Менә бит, керәшеннәр рус хәрефендә гәҗит тә чыгара. Безне шуларга илтеп кушарлар.

Шунда Миргасим абый бераз туктап торды.

—Берүк мин әйткәннәрне кешегә сөйли күрмә. Замана четрекле. Латинга каршы чыкканнарның бик күпләрен төрмә-лагерьларга утыртып бетерделәр. Бүгенге көнгә кадәр берсенен дә кайтканы юк,—диде ул.—Сине чакыруымның максаты болай: мин урта мәктәпләр өчен агач эшләре турында дәреслек яздым. Ул гарәп алфавитында. Менә шуны латин хәрефләренә күчереп чыгасы бар. Әгәр минем язуымны танымасаң, әйтеп торырмын, син язарсың.

—Була ул. Эшләрмен,—дидем мин.

Әле төш вакыты җитмәгән иде. Ашап-эчеп алгач, өстәлне җыештырдык та эшкә керештек.

Миргасим абый әйтеп бара, мин язам. Хәтсез яздык. Карыйм: аның дәфтәре шактый калын. Эшебез бер көнлек кенә булырга охшамаган. Кич җиткәч, умартачы ут алды. Лампасы унлы икән. Йорт эче ялт итеп, без әле янадан ике сәгать чамасы утырдык. Аннары, бераз тавыш-тынсыз торгач, Миргасим

абый шүрлектән китаплар алды да берсен миңа бирде. Гарәп алфавитында икән. Зиһенемне туплап, авырлык белән генә авторының кем икәнлеген укый алдым. Миргазиз Укмаси. Умартачының исеме дә—Миргазиз. Бу—Укмаси. Ә умартачыныкы—Зәбиров. Шиккә калып, мин:

—Укмаси кем була?—дип сорадым.

—Мин булам,—диде елмаеп Миргасим абзый. Аннары безнең авылыбыз—Укмас. Бер дә гаҗәпләнмә. Элек-электән язучыларның, шагыйрьләрнең күбесе үз фамилияләрен алыштырып башкача атап килгән. Бу—псевдоним дип атала. Кушамат дисәң дә ярый.

Китапның битләрен ачкалап карасам, барысы да—шигырьләр.

—Шигырьләремне редакцияләргә биргәндә Миргазиз Укмаси дип язып куям.

Ул шунда «Байлар фикере» дигән шигырен бик матур итеп укып бирде. Аннары берничә шигырьне күз йөртеп чыкты да, аларын яттан—язмага карамыйча сөйләде. Бер-икесен үзем дә сөйләп бирә алырлык итеп хәтеремә сеңдердем.

Миргасим абыйда бер ай чамасы кунак булдым. Һәр көнне туйганчы кәрәзле бал белән сыйландым. Умартачының гарәп хәрефләре белән язылган «Урта мәктәпләрдә хезмәт» дигән китабы йөз бит чамасы булса, латин хәрефләре белән йөз кырык биткә сузылды. Ул әлеге китабын, көзгә умарта эшләре беткәч, Казанга барып, китап нәшриятына тапшырырга булды.

Әлеге умарталыктан әлләни ерак түгел генә Зөя елгасы ага. Анда бер тегермән дә бар. Үткән ел пионерлар лагеренда җәемне шунда үткәрдем. Андагы буада балык күп. Абзый үз эше белән шөгыльләнгәндә балыкка йөргәләдем. Бу безгә бик әйбәт була торган иде. Балык шулпасы да чөмерәбез, кыздырып та ашыйбыз. Абзыйның көнбагыш мае, ул булмаса, балык мае да җитәрлек.

* * *

Миргасим Укмаси Тукайны да күреп белгән. Миңа, зур шагыйребез турында акрынлап кына байтак сөйләде. Тукай аның шигырьләрен ошата торган булган икән.

Миргасим Укмаси гарәп хәрефеннән латинга күчкәч, шигырьләрен гәҗитләргә, нәшриятка бирмәгән.

—Менә бит ул ничек. Яңа буын балаларын тарихыбызны укымаслык итеп, ата-бабаларыбызның кабер ташларын да танымаслык итеп тәрбияли башладылар. Без кая барабыз, энем, ә? Аңлап житкермим әле,—дип, ул миңа еш әйтә иде.

Августның егермеләрендә Миргасим Укмаси белән саубуллашып, мин Казанга—Барый абыем янына киттем.

Плацкарт вагонында кешеләр әллә ни күп түгел иде. Аскы утыргычта утырган килеш тәрәзәдән узган юлны карап барам инде. Нинди матур җирләрне үтәбез, елгаларны кичәбез. Кич кырын Идел аша салынган зур күперне чыктык. Инде хәзер Казанга да күп калмагандыр, дип, күнелемнән сөенеп барам. Шулай да Барый абыйның: «Укуыңны гына бел, юк-бар белән мавыкма «писака»! Вузны бетермичә, андый эшләргә тотынырга мин сиңа киңәш бирмим»,—дигән сүзләре күңелемне борчып тора.

Юк шул. Башка фәннәрдән бераз алга китсәм дә, рус теле әле һаман куркыта. Казанда татар техникумына керергә уйлыйм.

Уйланып, хыялланып бара торгач, Казанга да килеп життек.

Менә ул трамвай дигәннәре. Поезд вагонына охшаган охшавын, ләкин кечерәк. Кызылга буялган. Тәрәзәләре зур. Вагон туктау белән мин дә кердем. Буш урыннар күп. Яныбыздан билет сатучы апа да узып китте. Янәшә утырган абзыйдан:

—Билет ничә тиен?—дип сорадым.

—Я по татарски не понимай, говори по русски,—диде ул.

Кешеләрнең өчәр тиен генә биргәннәрен күреп, кесәләремне капшый башладым. Вак акчам бөтенләй юк, бер тәңкәлегем дә берәү генә. Юк әле, моны тотмыйм, өч тиен өчен бернәрсә дә эшләтмәсләр.

Бара торгач, «Суконный» дигән сүз дә ишеттем. Абыем хатында өйрәткәнчә мина монда төшеп калырга кирәк. Ишеккә житкәч, беләгенә кызыл бәйләгән олы яшьтәге апа:

—Молодой человек, ваш билет?!—диде. Ә мин билет алмаган бит.

—Юк,—дип жилкәмне сикерттем.

—С вас штраф,—диде кондуктор.

Соңгы бер сумымнан да колак кактым.

Абый яшәгән жирне тиз эзләп таптым.

Ишекне матур гына бер апа ачты—абыйның хатыны Мөнирә икән...

Кичке чәйне эчеп алдык. Өстәлдәге хәлвә, ак күмәч, май мина аеруча ошады. Әле караңгы төшмәгән, эңгер-меңгер вакыт. Радио сөйләп тора, татарча концерт тапшыралар. Гөлсем Сөләйманова жырлый. Авылда да тыңлаганым бар минем аны—күңелемә хуш килә. Менә хәзер Казанда тыңлыйм. Ятагыма барып аудым. Озак юл килүдән бик талчыккан идем. Тиз йоклап киткәнмен.

• • •

Абый әйтеп калдырган техникум Карл Маркс урамында иде. Шуның канцеляриясенә кердем. Анда утыручы сылу гына бер татар кызы мина:

—Чибәр егет, сынаулар күптән бетте инде, башка беркемне дә алмыйбыз,—дип кырт кисте.

—Тагын бу тирәдә нинди техникум бар?—дип сорадым мин чарасыз калып.

—Моннан әлләни ерак түгел авиация техникумы бар,—дип озатты ул.

Ерак түгел икән, урамның теге башында гына.Тик анда да кабул итү тәмамланган иде инде.

Жинел промышленность техникумына бардым. Анда да шул хәл. Нишләргә белмичә тәмам аптырап калдым.

Иртәгә башка уку йортларын эзләп карарга кирәк булыр. Эш сәгатьләре беткәнче дип, «Яшь ленинчы» газетасына барырга ниятләдем. Мина былтыр «Кечкенә аучылар» дигән хикәямә акча килгән иде. Аннан соң берничә хәбәрем, кыска гына хикәям дә басылып чыкты. Шуларга исәп тотып туры шунда киттем.

Бауман урамының уртасында күксел төстәге зур йорт бар. Аның аскы катында китап кибете. Йортның ишеге белән янәшә игъланнар элenгән.

Мин эзләгән газета икенче катта икән. Мәрмәр баскычтан менеп киттем. Зур коридорга чыккач, чамалап, сулга борылдым. Анда да ишек. Шул ишекне ачсам, яңадан бер озын коридор китә. Һәрбер ишектә редакцияләр исеме язылган. Эзләгән бүлмәмдә ике өстәл. Тәрәзә янындагысына чәчен кистергән матур гына бер кыз утырган. Аның каршында бер үсмер малай басып тора. Шундук чамаладым—авыл егете. Өстенә минеке кебек үк мамык тукымадан тегелгән пинжәк кигән, башында кепка, аякларында калын табанлы эш ботинкасы.

—Түргә узыгыз!—ди теге кыз мина.—Ул минем исем-фамилиямне сорады.—Менә шагыйребез Шәрәф Мөдәррисов та килгән әле,—дип, мине әлеге үсмер малай белән таныштырды.

Шәрәф исә:

—Локман синмени инде ул? Беләм, хикәяңне дә, хәбәрләреңне дә укып барам,—диде.

—Әйдәгез, егетләр, башта мин сезне бухгалтериябезгә алып барыйм әле. Анда сезгә дигән акча жыелып тора. Килгәч- килгәч, баеп чыгарсыз.

Без анын исемен дә белдек: бүлек мөдире Мәрьям апа Дибаева икән. Ул безне үзенә ияртеп китте.

Шулай итеп, икебез дә баеп, шатланышып, урамга чыктык. Шәрәф белән сүз алышкалап барабыз. Ул документларын алдан ук жибәргән булган. Сынаулары беткән, укыйсы жиренең тулай торагыннан урын да биргәннәр—Кремльгә якын гына университет янындагы Лобачевский бюсты каршысында.

Мин кайтып житкәндә абый да, Мөнирә апа да өйдә түгел иде әле. Капка төбендә аларны көтеп утырырга туры килде.

Абыйның шкафтагы китапларын караштырам. Барысы да авыл хужалыгы турысында. Бер генә әдәби китап та юк. Үзенең һөнәренә кагылганнарын гына жыйган.

* * *

Вакыт иртә әле, төш житмәгән. Шәрәф белән Лобачевский һәйкәле янындагы бакчада очрашырга килешкән идек. Жәяүләп кенә шунда таба атладым. Яңа танышым мине көтеп тора иде инде.

—Ничек, урнаша алмадыңмы?—диде ул.

Аңар документларымны рабфакка калдырганымны әйттем.

—Алырлар, кая китсеннәр. Әйдә «Яшь ленинчы»га барабыз. Яна шигырь яздым.

Аңар ияреп киттем. Ерак жир түгел, түбән урамга гына төшәсе ич.

—Кичә, бухгалтериядән чыккач, Мәрьям белән исәнләшкән бер кызны күрдеңме?

—Шәйләдем шунда.

—Ул беләсеңме кем?

—Каян белим ди инде?

—Шагыйрә Әминә Бикчәнтәева—менә кем!

—Беләм, беләм, анын шигырьләре газетада да, «Пионер каләме» журналында да еш басыла.

—Ул кыз әдәби бүлекне житәкли,—диде Шәрәф.

Без шулай сөйләшә-сөйләшә тагын редакциягә дә барып кердек. Кичәге кызлар безне елмаешып каршы алдылар.

Әминә Бикчәнтәева каршысында—утыз яшьләр тирәсендә булыр—әйбәт кенә киенгән бер егет басып тора. Мәрьям миңа:

—Локман, менә, танышыгыз, Абдулла Алиш,—диде.

Аннары:

—Локман Бадыйкшанов белән Шәрәф Мөдәррисов—хәбәрчеләр, кичә генә авылдан килделәр,—диде кыз.

Калкурак, матур буй-сынлы, куе кара кашлы, жем-жем итеп торган зур кара күзле, кучкыллы кара озынчарак йөзле. Кыскасы, көньяк кешеләренә тартым кыяфәтле иде Абдулла Алиш.

Сөенечем эчемә сыймады. Керүебез юкка булмаган икән. Олы язучы белән таныштык.

* * *

Беренче сентябрьдә укулар башланды.

Дәресләребез төштән сон—сәгать икедән алып кичке сигезгә, кайвакытны унга кадәр бара. Ана телебездә укуыбыз мине бик куандырды. Янәшәмдә яна танышым—Рашат Бакиров дигән егет утыра. Казанныкы, атасы безгә татар теленнән керә. Әдәбияттан Нәкый Исәнбәт укыта. Анын шагыйрь икәнлеген инде күптән белә идем. Өлкән яшьтә—кырык яшьләр чамасында.

Бик мавыктыргыч итеп өйрәтә. Язучылар турында сөйли башласа, вакыт узганын сизмичә дә калабыз. Шулай беркөнне аның дәресе кичке жиделән тугызга кадәр тоташ барды.

Менә дәрескә Нәкый Исәнбәт килеп керә, башта барыбызга да игътибар белән карап ала, шуннан мина текәлә:

—Бадыйкшанов, алга чыгыгыз әле!

Шикләнеп кенә аның янына чыгып бастым.

—Заһир Бигиевнен «Олуг гөнаһлар» дигән романын калдырам. Син аны сабакташларына кычкырып укырсын,—диде ул.

Кулымдагы романның исемен укыдым да сүзне икенчегә бордым:

—Беләсезме, иптәшләр, бүген Нәкый Исәнбәтнең Академия театрында «Миркәй белән Айсылу» дигән драмасының премьерасы була. Китап башка вакытта да качмас. Әйдәгез, театрга, күгәрчен оясында булса да безгә дигән билетлар бардыр әле.

Сабакташларым көлешеп алдылар да сумка- портфельләрен эләктереп чыгу юлына ашыктылар.

Зал гына түгел, барлык балконнар да халык белән шыгрым тулган. Нәкый Исәнбәтнең мона кадәр «Хужа Насретдин» дигән үтә мавыктыргыч комедиясен караганым бар иде инде. Бусы фажига икән. Бик тә ошады мина. Яшь йөрәкләрнең язмышын карадык.

Сәхнә ябылгач, халык галәмәт итеп кул чаба башлады. Кемдер: «Авторны!»—дип кычкырды. Кул чабулар тагы да көчәеп китте.

Менә сәхнә алдына артистлар чыгып басты, аннары салмак кына адымнары белән Нәкый Исәнбәт—кукрәгенә кулын куеп тамашачыларга баш иде, барча артистларның кулын кысып, аларны әйбәт уйнаулары белән тәбрикләде.

• • •

...Ни күрим, тактадагы «Миркәй белән Айсылу» драмасының игъланын умырып алып аяк астына ташлаганнар. Аның урынына эре хәрефләр белән «Урманда» дигән спектакльнең исемен язып куйганнар. Авторы—Фатих Хөсни. Аның «Йөзек кашы» дигән бик тә мавыктыргыч повестен беләм. Барырга кирәк булыр дип уйлап юлымны дәвам иттем. Кемгә ошамады икән Нәкый абыйның шундый матур әсәре?! Күрәсен, обком түрәләренә ярамагандыр. Югыйсә тикмәгә генә пьесаны икенче көнне үк туктатмаслар иде...

Татарстан Язучылар берлегендә бер бүлек бар: анда илнең төрле өлкәләреннән шигырьләр, хикәяләр килеп тора. Бүлекнең житәкчесе—язучы, тәнкыйтьче Гази Кашшаф. Булышчысы—Галиәсгар Камалның улы Әнәс Камал. Ул килгән язмаларны укып чыгып, яраклыларын бүлек мөдиренә тапшырып бара.

...Мин килеп кергәндә Әнәс Камал өстәлгә өелгән хатларны ачып утыра иде. Әнәс Камал—язучы. Безнең авылда аның «Бишмең Гайнетдин» дигән әсәрен һәвәскәрләр куйган иде. Үзен күрү белән шул искә төшеп китте. Башта исәнләшеп алдык:

—Гайнетдинне «баеттың-баетуын», ә үзен һаман сәркатип булып утырасың,—дидем.

Ул көлеп:

—Юк инде, брат, баеп булмады. Менә әле күптән түгел генә бер гаилә тормышыннан «Март бураннары» дигән пьеса яздым. Укып чыгарга дип Тажи Гыйззәткә тапшырганнар. Анардан бәя көтәм...

Бераз аны-моны сөйләшеп алдык.

—Локман, бүген кич язучылар клубында жыелыш була, кил.

Укырга төштән соң гына барасы булганга күрә ашыкмадым, өйгә кайтып киттем. Абый белән апа эштә. Дәресләремне әзерләргә утырдым. Шул рус

теле белән алгебра җәфалый мине. Башка фәннәрдән өлгерсәм дә, боларын бик йомшак сукалыйм.

Язучылар берлегендә әле җыелыш башланмаган иде. Минем кебек яшьләр дә килгәннәр. Габдулла Галиев, Шәрәф Мөдәррисовлар белән исәнләштек. Бу егетләрнең беренче китаплары басылып чыкканга әле күптән түгел. Галиевнеке «Яшел бөреләр», Шәрәфнеке—«Үскәндә»... Ә минеке әле һаман яшьләр-балалар редакциясендә ята. Җыелыш башланганчы, шагыйрь дусларымны калдырып, түбәнге катка—китабымның язмышын белергә төшеп киттем.

Редакциянең бүлек мөдире Зәкия апа Садыйкова мине ачык йөз белән каршылады:

—Локман, синнән сөенче: китабыңның корректурасы килде. Мә, карап чык. Ләкин бер шартыбыз бар: өч хикәяңне төшереп калдырырга булдык. Латиннан рус алфавитына күчәргә торабыз, шунлыктан синекен генә түгел, башка өлкән язучыларның әсәрләрен дә кыскартырга туры килә,—диде ул.

Әллә нишләп киттем, йөрәгем сыкрап алды.—Унсигез хикәянең кайсыларын төшереп калдырдылар икән?

Вакытында өлгергәнмен: язучылар залы халык белән тулган иде инде. Президиум өстәле артында Габдрахман Әпсәләмов, Кави Нәҗми, Ибрай Гази, «Совет әдәбияты» журналының өлкә комитеттан куелган редакторы Имаметдинов белән Муса Җәлил утыра.

Мин кергәнче җыелышның рәисен сайлап куйганнар икән. Ул—Муса Җәлил. Урыныннан торып басты да залдагыларга игътибарын юнәлтеп:

—Җыелышны башлап җибәргәнче, беренче сүзне Имаметдиновка бирәбез. Рәхим итегез, иптәш,—дип, аңа йөзен борды.

Имаметдинов трибунага килде, аннары залга текәлде дә сүзен башлады.

—Җәмәгать, бу залда буржуаз язучы Нәкый Исәнбәт тә утыра. Җыелыш исеменнән аның һәм язучылар әгъзасы булмаган иптәшләрнең залдан чыгып китүләрен зарур дип беләм,—диде ул.

Нәкый абый торып басты да, зал уртасындагы келәмгә чыгып, башын югары күтәргән килеш чыгу юлына таба атлады. Без яшьләр дә аның артыннан кузгалдык. Бактың исә бу—язучыларның ябык җыелышы икән.

Башкалар белән бергә мин дә мәрмәр баскычлардан аска төшеп киттем.

Нәкый абыйны күздән югалтмас өчен, аның артыннан бик ерак калмаска тырышып атлыйм. Урамның аргы башындагы трамвай юлы кисешкән җиргә житкәч, Нәкый абый сулга таба борылды. Балык кибетенә житкәндә аның белән янәшә бара башладым.

—Нәкый абый, бер дә борчылмагыз. Бу вакытлы күренеш кенә, әле синең артыннан үзләре килерләр,—дим.

Нәкый абый елмайды:

—Үзем дә шулай уйлыйм. Башлары әйләнгән аларның,—дип куйды.

Өйгә кайтып, ятагыма аудым. Озак уйланып яттым. Минем укытучымны шулай башка язучылар алдында мәсхәрә итүләренә әрнедем.

* * *

Бүген дүрт кенә сәгать укыдык. Соңгы дәрес—әдәбият. Әмма Нәкый абый бүген килмәде.

Ярты сәгатьләп көткәннән соң барыбыз да кайтып киттек.

Трамвай тукталышында нәшриятның нәфис әдәбият редакторы Рахман Ильясны очраттым. Ул мине таныП белә икән. Трамвай килгәнче сөйләшә башладык. Утызынчы елларда басылып чыккан, «Штык» дигән романның да авторы Рахман. Аның кем икәнен беләсем килде.

—Әйе, ул китап бар миндә. Аны минем абыем язган иде. Трамвай да килде. Ирек мәйданына җиттек.

Икебезнең дә шунда төшәсебез бар икән.

—Локман, әйдә мина кереп чык. Ничек яшәгәнемне күрерсең. Әнә, КАИны борылгач, икенче йортта гына торам.

Зур язучының тәкъдименә сөендем генә.

Безне аның үзе кебек үк калку буйлы, калын гәүдәле хатыны каршылады.

—Менә, шушы инде минем җәмәгатем—Мәрьям апаң булыр. Икәү генә бер бүлмәледә яшәп ятабыз. Зур фатирымны шушына алыштырып, Бакудан килдек,—дия-дия мине түргә дәштеләр.

Мәрьям апа аш-су әзерләп калды.

Ильяс абыйның китап шүрлегенә күз йөртеп алдым. Китаплары хәтсез, өстәлдә шактый калын кульязма ята. Шуңа күрсәтеп, ул:

—Менә «Кеше» дигән роман тәмамладым. Машинкада бастырып, Гази Кашшафка илтәсем бар,—диде.

Шүрлектән бер китап алып, миңа язып бирде. Карыйм: «Тавыклар арасында» исемле хикәяләр җыентыгы... Үткән ел мин аны кибеттән сатып алган идем инде. Авторының имзасы белән булгач, миңа калса, бу бик ярап куйды.

—Энекәш, Зәкия бик кире хатын. Өч хикәянне ул төшереп калдырырга булган. Ә син ризалык бирмәгәнсең. Белмим, чыгар микән ул китабың, юкмы?! Латиннан рус хәрефләренә күчәбез бит...

• • •

Язучылар арасында әвәрә килеп йөрү минем үземә дә бик ошап китте. Җае килгән саен берәрсен эзлим.

Мине «Дуслар» дигән язмам кызыксындыра. Гази Кашшаф яраклы дип тапты микән, юк микән? Шуның язмышын беләсем килә. Иртәнге якта укырга барганчы язучылар берлегенә киттем. Әнәс Камал үз урынында иде. Гадәттәгечә ачык йөз белән каршылады.

—Локман, сине Гази абый чакырды. Бар, шунда кер,—диде Әнәс, минем белән иркенләп сөйләшеп тормастан.

Гази абый ачык күңелле кеше. Бүген аеруча мәхәббәтле күренде:

—«Дуслар»ыңны карап чыктым. Миңа ошады. Быел чыгасы «Туган ил» альманахына басарга бирдем. Анда синеке генә түгел, Габдрахман Әпсәләмовның «Маһинур» дигән озын хикәясе дә бар. Сез икегез дә өметле күренәсез.

Сөендем. Бу соңгы язмам да зур язучы күңеленә хуш килгән икән.

Бераз сөйләшми торгач, ул:

—Педагогия институты каршында укытучылар хәзерләүнең кыскартылган бүлеге ачылды. Локман, синең барыбер химик-инженер буласың юк. Ышанам, киләчәктә язучы булуыңа өмет бар, каләмең шома. Кешеләрнең эчке тойгыларын тоя беләсең. Бу сыйфат бары тик язучыларга гына хас. Сине бүгеннән үк шул институтның татар теле-әдәбияты бүлегенә тәкъдим итә алам. Яшең дә җитеп килә инде, армиягә китәренә дә күп түгел. Шунарчы институт бетереп кал. Сине тәкъдим итеп, директорына әйтермен.

—Әйбәт булыр иде. Алсалар,—дидем мин.

—Алырлар, алырлар. Иртәгүк бар.

Бер-ике көнем документлар юллау белән йөреп үтте. Институтта инде биш атна укыганнар икән. Мине шартлы сынау белән кабул иттеләр. Бер ай эчендә өлгерә алсам, укып калачакмын. Миңа уку-укыту мөдире шулай аңлатты.

Татар бүлегендә укый башладым. Исем-акылым китте: институтка әниемнең абыйсының кызы—яшьтәшем Рәхимә дә килгән. Төркемдәгеләрнең яртысыннан күбесе—кызлар, калганнары минем ишеләр. Укытучыларыбыз Җамал апа Вәҗиева борынгы татар әдәбиятын укыта. Профессор Хангильдин

татар теле буенча, Рөстәмова дигән яшь кенә кыз психологиядән керә. Институтта гуманитар фәннәр генә: математика, химия, геометрия шикелле минем җаным сөймәгән бер генә дә фән юк.

Хыялларым җитәрлек минем. Тик яза башлаганда хикәянең исемен таба алмый азапланам. Менә бүген авыл малаеның, тома ятим калгач, туганнарсыз үзен кая куярга белми йөрүләрен, шуңа өстәп әтиемнең энесендә торуларымны, дүртенче сыйныфка җитеп тә, җүнләп укый алмауларымны күз алдыма китереп, ятим малай турында яза башладым. Малайның җәфа чигүләрен язганда күзләремнән яшьләр тәгәрәде...

Хикәямне тәмамлаганда яктыра башлаган иде инде. Бүген ял көне, укырга барасы юк. Шуның өчен йоклап калырмын дип борчылмадым.

Мөнирә апаның:

—Локман, исәнме син?! Сәгать тугыз тулып килә бит инде!—диюенә күземне ачып, торып утырдым.

—Мөнирә апа, төне буе яздым...

—Ул хикәянне син уянганчы укыдым инде мин. Безгә килеп-китеп йөри торган иптәшең турында язгансың икән. Гел үзе инде, төс-кыяфәтләре, йөрешләренә хәтле гел үзе. Болай язсаң, әллә кем булырсың әле, ышанам. Абыенның сүзләренә карама. Ул агроном, үз эше белән мавыккан. Татар китаплары укымый. Аңар Бальзак, Мопассан гына булсын. Ә мин татар язучыларын укыйм, тыелганнарын бигрәк тә. Әниемнең гарәп хәрефләре белән чыккан китаплары җитәрлек. Гаяз Исхакый дигән олы язучыны бүген танырга да теләмиләр. Китаплары тыелган. Революциягә кадәр басылып чыкканнары гына өлкән буын кешеләрендә яшерен саклана. Ул эмигрант, Төркиядә яши булса кирәк. Ә бездә аны хурлап мәкаләләр бастыралар. Гаяз Исхакый Германиядә татарча гәҗитә чыгара. Локман, берүк мин сөйләгәннәрне үзең генә бел. Хәзергә алар турында сөйләргә дә, китапларын укырга да ярамый,—дип, Мөнирә апа мине кисәтеп куйды.

—Юк, миннән сүз чыкмас. Болар турында Нәкый Исәнбәтнең дә кисәтеп сөйләгән чаклары булды.

Ишек шакыдылар. Барып ачсак, телеграмма килгән. Абый алып укыды.

—Телеграмманы әти суккан. Сәгать уннар тирәсендә Мәскәү поездын каршыларга барырбыз. Энем, әти гаиләсе белән безгә кайта. Читтә яшәп туйганнардыр, күрәсең. Нишлисең, үз атабыз бит. Синең бүлмәнне аларга бирергә туры килер,—диде.

Кайтучыларның өс-башлары ару, яшь әни дә, балалар да матур гына киенгән. Әти исә бик ябыккан: яңак сөякләре калкып чыккан, чырае ак, күзе әүвәлгедәй нурлы түгел инде. Мин аның сырхау икәнлеген сизендем.

Җәйгә чыккан идек инде. Мин ишегалды түрендә тактадан эшләнгән, тәрәзәләре алма бакчасына караган сарайга күчтем. Абый ут кертеп бирде. Дәресләремне шунда әзерлим.

Шулай бер иртәне ишегемне кактылар. Мөнирә апа икән.

—Локман... бүген төнлә әтиегез вафат булды. Кереп кара,—диде ул.

Ни күрим: әти идәнгә тезләнгән көенчә караватка төртелгән. Без аны, авырттырмаска теләгәндәй, ипләп кенә караватка салдык. Мин йөземне яшереп чыгып киттем. Абыйның Кремльдәге эшләгән җиренәдер инде, инге-минге хәлемдә барам да барам, барам да барам. Ник барам, нишлим, кайгыраммы, елыйммы, үрсәләнәмме—белмим. Ышанмыйм, авыр төш кенә күрәм шикелле.

* * *

Институттан сонарып кайттым. Ишекне Мөнирә апа ачты.

—Шагыйрь иптәшең килгән,—диде ул елмаеп, Шәрәф өстәл янында «Туган ил» альманахын укып утыра иде.

—Ике сәгатьтән артык көтәм инде сине,—ди.

Шәрәфнең кәефе шәп түгел—йөзе боек. Ул укуын ташлап, авылына кайтып китәргә уйлаган. Өлкә комсомолда эшләгән галим Мөхәммәтҗановны кулга алганнан бирле ана курсташлары кырын карый башлаганнар. Абыйсыннан инде менә өч ай буена берниндн хәбәр юк. Күрәсең, аны да кая булса озатканнардыр...

Мина килүенең төп сәбәбе—кайтырына акчасы юк икән. Ярый әле стипендия алган вакытыма туры килде. Дустымны озатырга чыктым. Ул бүген үк кайтып китә икән.

* * *

Казанның Черек күле кыш көне каток була. Ул цирк бинасыннан алып, Ленин бакчасына хәтле сузылган. Җәй көннәрендә күлгә чиста су өстиләр, уртасында берничә җирдән фонтан атып тора. Һәр елны күлгә зоопарктан ике аккош алып килеп җибәрәләр. Алар шунда хозурланып йөзеп йөри. Кешеләр аларны күрер өчен шәһәрнең әллә кайсы ерак урамнарыннан да килә. Ә менә хәзер фонтаннар юк. Күл боз белән капланган. Күлнең урта бер җирендә зур йорт бар, анда тимераякларны ботинкалары белән бергә, очсыз хакка гына биреп торалар. Хәрби оркестр уйный. Шугалакта халык күп. Шулай шуып йөри торгач, язучы Гомәр Толымбайны очраттым. Спорт киеме үзенә бик килешеп тора. Кырыклар тирәсендә булса да яшьләр кебек житез.

Оркестр туктаганчы рәхәтләнеп шудык. Аннары, тимераякларыбызны тапшыргач, трамвай тукталышына таба атладык. Гомәр абый күләмле генә әсәр язуын әйтте. Авылда беренче колхозлар төзелә башлаган катлаулы, бик тә тынычсыз еллар турында икән. Кулаклар халыкны колхозга кертмәс өчен астыртын эш алып бара, Совет хөкүмәтенә жаннары-тәннәре белән бирелгән коммунистларны кеше яллап үтертә...

Икенче көнне укудан кайтышлый Әнәс Камал янына бардым. Күнеле боек иде.

—Локман, кичә төнлә Гомәр Толымбайны кулга алганнар. Хатыны телефоннан хәбәр итте,—диде ул, як-ягына каранып.

Үземнең кичә Гомәр абый белән бергәләп шуганыбызны әйтмәдем. Әнәснең үзе сыман сак сөйләштем.

—Заманалар үзгәрде, Локман. «Яшьләр газетасы»ннан Ибраһим Салаховны да, аның белән бергә Ялтага Галимжан Ибраһимов янына барган язучыларның күпләрен кулга алдылар. Син боларны беләсең. Чамалап кына йөр,—диде ул.

Башымны иеп кенә кайтып киттем.

* * *

Төнге берләр тирәсе булгандыр.

Мөнирә апа үз бүлмәсендә балалары белән йоклый, без икенче бүлмәдә. Ишекне бик каты кага башладылар. Мөнирә апа барып: «Кем?» дип сорагач, никтер, абыйны да уятты. Ишекне абый ачты.

Хәрби киемдәге өч кеше килеп керде. Аларның берсе абыйдан:

—Бу фатирда хужа сезме?—дип сорады.

—Әйе, мин,—диде абый.

—Киенегез!

Һичнәрсә аңламастан, абый бүлмәгә керә башлады. Килүчеләрнең берсе кырыс кына:

—Туктагыз! Беркая да китмәгез!—диде.

Абый Мөнирә апага киемнәрен китерергә кушты. Киенеп бетергәч, ул:

—Кая барабыз?—дип сорады.

—Баргач күрерсез.

—Туктагыз әле, документларыгызны күрсәтегез. Югыйсә мин фатирымнан чыкмыйм,—диде абый.

Керүчеләрнең өлкәне куен кесәсеннән озынча бер кәгазь чыгарды да абыйга сузды.

—Монда бит «Шамсутдинов» дип язылган, ә минем фамилиям—Бадыйкшанов,—диде абый.

—Паспортыгызны күрсәтегез!

Абый кулына ордер тоткан кешегә паспортын сузды.

Ул тиз генә укып алды да:

—Ә Шамсутдинов кайда икән? Без аны эзләп килдек.

Абый алар сораган кешенең өстәге катта яшәгәнен әйтте. Килүчеләр гафу да үтенмичә, ничек кергән булсалар, шулай тиз генә чыгып та киттеләр.

Барыбыз да тынычланган булдык, тик йокы тәмам качты, пошаманлык, шом басты.

Көннәр шулай уза торды. Июль аенда сынаулар башланды. Күбебез уңышлы тапшырдык.

Абый белән апага димломымны күрсәттем. Абый аны кулына алып, билгеләргә күз йөртеп чыкты. Анда бер генә «өчле» дә юк иде. «Бишле» дә «бишле», бары тик рус теленнән генә «дүртле». Боларны күргәч, абый:

—Менә хәзер хикәяләр язсаң да ярый, булдыра алуыңа ышанам. Бүтән сиңа «писака» дип әйтмәм инде,—диде.

* * *

Абый белән Кремльдәге мәгариф бүлегенә—укытучыларны эшкә билгели торган җирне эзләп чыктык. Трамвайдан төшеп, тар бер тыкрыктан университетка таба атладык.

Менә ул Кремль урамы! Әнә, каршыда Сөембикә манарасы да күренә.

Бу урамда студентлар күп йөри. Аның бер ягында—халык китапханәсе, монда минем күп вакытым үтте. Аның өске катында матур-матур заллар. Шунда лекцияләргә, дәресләргә әзерләнгән чакларым искә төште. Бу йортның каршысында университет. Мәһабәт ак колонналарына карап барам. Шулар каршысында кечкенә бакча, аның эчендә Ленинның яшь чагын сынландырган һәйкәл тора. Университет колонналары янына бөркәүле кара машина килеп туктады. Башта аннан солдатлар чыкты, аннары—бер хатын-кыз. Аны машинадан култыклап төшермәкчеләр иде.

—Кирәкми, үзем,—дип, ул асфальтка сикереп төште, аның артыннан ир кеше. Мин аны шундук таныдым. Ул мин яшәгән йорттагы Шәмсетдинов иде. Аны да култыклап, асфальтка бастырдылар. Шуннан соң дүрт сакчы аларны университетка таба алып бара башлады. Теге хатынны да таныдым—Сәрвәр Әдһәмова! Элек тә нәшрият йортында күргәләгән идем. Галимҗан Ибраһимовның романнарын урысчага тәрҗемә итүче. Миндә «Тирән тамырлар»ның ул тәрҗемә иткән нөсхәсе әле һаман саклана.

Минем белән янәшә атлаган өлкән яшьтәге бер ир кеше:

—Аларны монда судка китерделәр,—диде. Читләтеп кенә сакчылар яныннан үтеп киттек.

Шәмсетдиновны кулга алуларына бер елга якын вакыт үткән бит инде. Ул минем абый эшләгән Кремльдәге Авыл хуҗалыгы халык комиссариатының зур түрәсе иде.

* * *

Сарманның Иске Минзәләбаш авылы дөя сырты сыман үр итәгенә урнашкан. Авыл бакчалары артыннан Минзәлә суы Каманы эзләп ага. Безнең

Әлмәт янынннан узган Зәйгә караганда ул кечкенә, төбенә карасаң, чиста, саф суыннан чуер ташларына тиклем ап-ачык күренеп тора. Яр буйларын сирәк-мирәк куе, вак таллыклар сарган. Боларга күз салып, янадан олы урамга чыктым. Ләкин, башка авыллардан аермалы буларак, мәктәптән битәр, клуб бинасын шәйләмәдем. Фатирга әйләнеп кайткач, Гөләндәм апага зарландым.

—Авылыгызда клубыгыз да юк икән!

—Нигә булмасын ди?! Безнең урамның теге ягындагы мәчетне күрденме?.

—Күрдем. Манарасында ае да исән...

—Шул була инде безнең клубыбыз. Мулланы, мөәзинне комсомоллар, коммунистлар авылдан куып чыгарды. Алар китү белән мәчетне клуб ясадылар да куйдылар. Яшьләр вакытларын шунда үткәрә. Кай көннәрне, районнан килеп, театр-концерт куялар.

Беренче айны укытканда өлкән сыйныф укучылары белән стена гәҗитәсе чыгару өчен редколлегия сайлау үткәрдек. Араларында язарга һәвәсләре, рәсемгә осталары бар. Сигезенче класс укучысы Әбүзәр, рәсем ясауга үтә оста икән. Анардан «Бүген кич әдәбият сөючеләр түгәрәге оеша. Теләүчеләр рәхим итегез» дигән белдерү яздырып, гәҗитә белән янәшә элеп куйдык.

Кичен билгеләнгән вакытка унбишләп үсмер җыелган. Араларында кыз балалар да бар.

Түгәрәкнең максаты турында, язучылык эшен ничек башлап җибәрергә кирәклеген аңлаттым. Араларында шигырь, хикәя яза алучылары беленде. Үткән елда да стена гәҗитәсенә язышканнар.

Тәбәнәк буйлы, чандыр гына бер малайга игътибар иттем:

—Син, энем, нәрсә язасың?

—Әлегә язмыйм. Кызыксынам гына. Миңа Жюль Верн әсәрләре ошый. «Серле утрау» дигәне кызык,—дип җавап бирде ул. Фамилиясе Тимергалин икән. Мәктәп мөдире малае икәнлеген шундук чамалап алдым инде.

Бүген дәрестән соң әдәбият түгәрәге утырышы була. Үсмерләр нәрсә язып китерерләр икән? Шуны уйлап, кич кырын мәктәпкә кердем. Җыелышканнар. Мине, дәрес бирергә кергәндәгечә басып каршыладылар.

—Ягез, кем нәрсә язды?—дип сорадым. Өлкән класста укучы бер кыз шигырь язган.

—Тагын кем нәрсә язды?—дидем. Балалар бер-бер артлы шигырьләр, хикәяләр ише язмаларын өстәлемә китереп куя башладылар. Беренче шигырьне алып, башта үзем генә укып алдым. «Сагынам» дип куелган.

Зәңгәр күктә йолдыз балкый,
Шундый матур, җем-җем итә.
Энҗе-мәрҗән чәчкән төсле
Бөтен күкне балкыта.
Йолдызларга карыймын да,
Сине сагына башлыйм:
Безнең йолдызны бер күрсәм,
Синсез тора да алмыйм.

—Ничек, бу шигырьне килештерәсезме?—дип сорадым. Партада утыручыларның барысы да елмаешып шигырь язучыга карадылар. Ул исә, оялып, башын аска иде.

—Җә кайсыгызның фикере ничек? Әйтегез,—дидем.

Берсенең бер сүз әйтәсе килмәгәч, нәтиҗә ясап, үз фикеремне әйтергә туры килде.

—Миңа ошады бу шигырь. Чын күңелдән, ихлас язылган. Киләчәктә шулай язсаң, шагыйрә дә булып китәрсең әле дип куйдым.

«Балык каптырдым» дигән хикәяне укып чыктым. Анда бер малай Минзәлә елгасы буасында үзенең кармакка балык тотуы турында язган. Бактың исә балык урынына аңа кармак салу белән бака капкан икән. Шуны үзенчә матур итеп шәрехләп язган. Бу язма мине ышандырды. Түгәрәк әгъзалары көлешеп куйды.

—Ягез әле, алайса сүзегезне әйтеп карагыз әле?—дидем. Сүз әйтүче булмады. Кем дәшсен инде? Болар бит арган, талчыккан, ачлы-туклы балалар. Тыйнаклар. Тормыш аларны дәшмәскә, эндәшмәскә көннән-көн артыграк өйрәтә бара. Ата-аналары көне-төне эштә. Дәшмәү—халык хәйләсе, ижат—яшертен гамәл.

Язу осталыгы турында үзем уйлаганнарны сөйләп алдым. Гади генә бер мисал да китердем.

—Кулымнан идәнгә акчам төшеп китте. Менә күрдегезме?.. Болай язсаң—әдәби алым түгел. Аны менә ничек язсаң әдәби була: акча идәнгә төшеп, чынлап тәгәрәп китеп ауды. Менә монда инде әдәби алым бар. Акча төшкәч, чынлап ала; аннары тәгәрәп китә—бу әдәби табыш була. Сез дә үз язмаларыгызны һәрбер җөмләне уйлап, көен-көйгә туры китереп язарга тырышыгыз,—дидем.

* * *

Ноябрь актыкларында әнидән хат килеп төште. Конвертта Казанның мин яшәгән район хәрби комиссариатыннан повестка да бар. Шуны тотып, мәктәп мөдиренә бардым.

—Миңа тагын кеше сорап Казанга—мәгариф бүлегенә барырга туры килә инде. Сиңа кадәр укыткан Сәгъдине дә, запастагы офицер буларак, армиягә алганнар иде. Инде менә сине дә...—дип көрсенеп алды мөдир.—Иртәгә колхоздан ат сорап сине Чаллыга кадәр озатырга бирәр малайны җибәрергә туры килә.

Икенче көнне мәктәп мөдире Тимергалин колхоздан минем өчен ат сорап алды. Мин юлга чыгарга әзер идем инде.

Колхозның иң шәп айгырына җигелгән тарантаста өлкән сыйныф укучысы Әлтәф килеп туктады. Гөләндәм апа капкасыннан ерак түгел сиртмәле бер кое бар. Күрәм, шунда көянтә-чиләкле бер кыз тора. Шундук таныдым—унынчы сыйныф укучысы Роза. Без кучер егет белән аның яныннан үткәндә теге кыз заты:

—Локман абый, китәсез дә мени инде бездән?—диде.

—Әйе, матурым. Армиягә китәм.

—Хәерле булсын. Исән-сау әйләнеп кайтырга язсын инде,—диде кыз.

Без авылның зират читендәге юлыннан чыгып киттек. Башымда төрле уйлар өермәсе: әйләнеп кайтырмын микән монда, юк микән? Халыкара хәлләр бик мөшкел. Германия Польшаны басып алды. Яртысына безнекеләр килеп керде. Зур сугыш башлануы да бик ихтимал.

* * *

Инде пароходыбыз Идел портына килеп туктады. Халык басма салыну белән төшә башлады. Мин дә, халыкка ияреп, портка индем.

Суконный бистәсенә җиткәч, трамвайдан төшеп, югарыга таба сузылган урамнан барам. Менә ул—мин әзме-күпме яшәгән ике катлы таш йорт. Анда хәзер өч баласы белән яшь әни тора. Әтиемнең вафатына өч ел була инде. Безнең йортка каршы агач йорт та бар, анда мин яшәгән районның хәрби комиссариат җитәкчесе Рафиков дигән кеше яши. Бүген үк аның эшләгән җиренә барып, армиягә җибәрүләрен сорарга кирәк.

—Егет, озакламый Тын океан хәрби-дингез флотына синдәй егетләрне чакыра башлыйбыз,—диде ул, хәл-әхвәлне сорашып алгач.
—Кайчанга хәтле көтәсе?
—Бер ай чамасы.
—Вакыт бар икән әле.

* * *

Яшьләр-балалар редакциясендә редактор булып минем якташым Ләбиб Гыйльми эшли иде. Военкоматтан чыккач, туп-туры анын янына керергә ниятләдем.
Аңа үземнең авылдан килүемне, армиягә алачакларын әйттем.
—Бер ай вакытың бар икән әле. Алайса болай ит,—диде ул,—син бездә эшләп ал. Әдәби бүлегебез мөдире Кәтиевне моннан өч кенә көн элек армиягә алдылар. Анын урыны буш.
Берсүзсез риза булдым.
Шул көннән үк нәшриятның әдәби бүлек мөдире сыйфатында эшләргә керештем. Шигырьләр, хикәяләр шундый күп килгән—бер атна буена укысаң да очына чыгарлык түгел. Яхшы дип табылганнарын газетада, журналда басарга тәкъдим итеп, Ләбибкә керттем. Ул аларның күбесен хуплады.

* * *

Бер ай гомер сизелмичә үтте дә китте. Повестка килеп төште. Безне үзәк комиссариатка җыйдылар. Озатырга дип Шәрәф Мөдәррис, Габдулла Галиев—болар шагыйрьләр, күрше егете Габбас, әни килде.
Үзәк военкомат ишегалдына кергәч, шәһәргә бүтән чыгармадылар. Сафка тезеп Казан тимер юл вокзалына алып киттеләр. Шул ук кичне яшелчә ташый торган йөк вагоннарына төяп, ерак Көнчыгышка озаттылар.
...Владивосток. Ерак Көнчыгышның гүзәл шәһәре. Ул Япон дингезенең Алтын Мөгез дип аталган култык буена җәелеп утырган.
Безне төркемнәргә бүлеп, ике катлы йортларга урнаштырдылар. Икенче көнне үк, сафка тезеп, флот мунчасына кертеп юындырдылар, һәрберебезне флотча киендерделәр. Козерексыз фуражкабызның тасмасы гына юк. Электән хезмәт итүчеләргә карап сокланабыз. Бигрәк матур шул тасмасы. Аның исеме дә жисеменә туры килә бит—«Тын океан флоты»—алтын хәрефләр белән язылган. «Нигә безгә дә бирмәдегез бу тасманы?» дип сорагач, командирлар: «Хезмәт урыныгызга баргач алырсыз»,—дип кенә җавап бирәләр.
Экипажда берничә көн торырга туры килде. Вакытында ашаталар-эчертәләр, вакытында йоклаталар.... Лекцияләр укыйлар, кино күрсәтәләр. Шулай көннәребез үтә тора. Болай яшәү айга якын сузылды. Шәһәргә чыгу юк.
Шулай бер көнне без торган корпуста «ЧП» булып алды. Яшь дингезче койма аша шәһәргә качып чыккан булган. Кичке ашка сонарган. Шул көнне, кизү өстәленнән ерак түгел стенага ябыштырып куелган бөек юлбашчы Сталинның рәсемен ертып алганнар. Кем икәнен белмиләр. Барлау вакытында корпус комиссары:
—Юлбашчыбызның рәсемен ертып алучыны тапмыйча отбой булмаячак!—дип белдерде.
Дежурныйлар барлык тумбочкаларны тикшерә башладылар. Берсеннән повидло савыты төреп куелган Сталин рәсемен табып алдылар. Кем эше икәнлеге шундук ачыклынды. Ул шәһәргә качып чыккан егет булып чыкты. Егетне, күз ачып йомганчы дигәндәй, каядыр алып та киттеләр.
Без аны бүтән күрмәдек.
Ниһаять, безнең корпуска чират житте, зур гына катерга тагып алып

киттеләр. Алтын Мөгез култыгын чыгып, вак урман белән капланган атауга таба йөзәбез. Озатучыбыз аның Рус атавы икәнлеген әйтте. Катер туп-туры әлеге атауга китерде.

Портта оркестр уйнап каршыладылар. Без ике йөзләп егет идек.

Безне әүвәл хәрби мәктәпкә, аннары корабларга таратачаклар икән.

Озакламый, безне сафка тезеп, хәрби мәктәпнең ашханәсенә алып бардылар. Борынга тәмле аш исе килеп бәрелде. Озын-озын зур өстәлләрне ян-яктан урап тезелешеп бастык. Команда белән генә утырырга рөхсәт бирделәр. Кичке аш башланды: итле кәбестә ашы, аннары кара бодай боткасы. Тукланып алгач, янадан сафка тезеп, казармабызга алып киттеләр. Кичен киногa барырга рөхсәт бирелде. Мин дә башка егетләр белән шунда киттем. «Волга-Волга» дигән кино була. Казанда бу фильмны берничә тапкыр караган идем инде. Барыбер ошый ул миңа, һич туйдырмый, караган саен карыйсы гына килеп тора. Клубның бер бүлмәсендә китапханә урнашкан. Кичә күреп алган идем. Бүген ял көне булгач, вакыт үткәрергә шунда киттем. Анда яшь, сап-сары кыска чәчле чибәр генә бер кыз эшли. Аннан битәр кеше юк. Шүрлектәге китапларны караштыра башладым. Ни күрим, Габдулла Тукайның Мәскәүдә чыгарылган катыргы тышлы шактый калын шигырьләр китабы! Беренче битен ачу белән Тукаебызның рәсемен күреп сөендем. Апушыбыз Тын Океан ярларына кадәр барып җиткән! Яшь диңгезчеләр укысын дип, аны монда алдырганнар. Бүген Барый абыема хат язганда бу хакта да әйтәм әле. Алай гына да түгел, Казанга, Татарстан газетасына да язып җибәрәм. Тукайның Тын океан диңгезендәге атауда «яшәве» турында басмый калмаслар.

1905 елгы рус-япон сугышы алдыннан төзелгән казармада без өч йөзләп яшь егет яши башладык. Урнашуыбызга ике-өч көн үтмәде, безкозырькаларыбызны бизәргә, алтын хәрефләр белән «Тын океан флоты» дип язылган, якорь сурәте төшерелгән тасмалар өләштеләр. Алар безне гайрәтләндереп, канатландырып җибәрде. Сокланып туя алмыйбыз.

Рота командиры, утыз яшьләр тирәсендәге майор Бондаренко иде, мине үз янына чакырып алды:

—Яшь диңгезче Бадыйкшанов! Синең шәхси тормыш юлың белән таныштым. Журналист икәнсең, флотка редакциядән алганнар. Безнең корпуста стена газетасы чыгарырга кирәк булыр.

Шул көннән башлап ай саен гәҗит чыгара башладык. Редакция әгъзалары һәр көнне икешәр сәгать диңгез буендагы зур мәйданда марш йөрүләрдән котылды.

Шагыйрь дусларым Шәрәф Мөдәррис, Габдулла Галиев, Әнәс Камал, авылдашым Үзбәк Саттаров, химия-технология рабфагында бергә укыган дустым Рашат Бакиров, бер йортта торучы эшче дустым Габбастан хатлар килә. Барысы да мине диңгезче булуым белән тәбрикләп язалар.

Янадан берничә көн үтмәде, Уралдагы Копейск шәһәрендә яшәүче шагыйрь һәм прозаик Габдрахман Теләш йөрәгемне әрнетерлек хәбәр ирештерде. Ул хат «Халык дошманнары» Кәрим Тинчурин, Гомәр Толымбай, Мөхәммәтшин, минем якташым—Ләбиб Гыйльминең хөкем ителеп атылулары турында иде. Йөрәгем әрнеде. Ышанмадым. Теләшнең язганнары дөресме-юкмы икәнлеген белешеп, хат юлларга ашыктым.

Әлеге хатны алганнан соң, икенче көнне, Сарман районы Иске Минзәләбаш авылыннан—үзем укытып киткән урта мәктәптән, Роза Яхина дигән кыздан да хат килеп төште. Ул минем язганыма карата җылы хис белдереп, хезмәтең беткәнче элемтәбезне өзмәбез дигән. Әле моңарчы мин унтугыз яшькә җитеп, бер генә кыз заты белән язышканым, мәхәббәт дигән ләззәтне кичергәнем юк иде. Күрәсең, егетләрнең дә кызларга омтылу вакытлары җитә икән. Мин аңа каршы җавабымда, нәкъ җырдагыча итеп: «Таулар җимерелеп, шулар

астында калсам да, барыбер бөтен газапларны үтеп, җәһәннәмнән чыгармын, сине эзләп табармын», дигән юлларны яздым.

Хәрби мәктәптә укулар тәмамлангач безне Рус атавында озак тотмадылар. Янадан баржага төяп, флот экипажына урнаштырып, дингез буеннан башта Хабаровск шәһәренә, аннары Амур елгасының түбән агымы буена урнашкан Комсомольск шәһәренә китерделәр. Монда да флот экипажы бар икән. Без шуннан елга буендагы кирханәгә (токка) эшкә йөри башладык. Монда ике зур крейсер төзеп яткан эшчеләргә булышабыз.

* * *

Көтмәстән фашистлар Германиясе Советлар Союзына бәреп керде. Крейсерларны төзеп бетерергә ашыктыралар. Сменаларга бүленеп, көн-төн эшлибез.

Көнбатышта бик каты сугышлар бара. Бер ай чамасы үтмәде, фашистлар Ленинградны камап алды, Мәскәүгә килеп җитте. Бөтен җирдә каты бәрелешләр бара. Башкомандующий Сталинның катгый боерыгы шул: «Бер адым да чигенмәскә!».

Ерак Көнчыгыштан, Себердән яна дивизияләр Көнбатышка җибәрелде, Тын океан дингезчеләре, шул исәптән десант гаскәрләре дә фронтка озатылды.

Абыем Барый да агрономлыгын ташлап, үз теләге белән фронтка киткән. Аның мина: «Энем, андый-мондый һәлак була калсам, балаларымны ташлама, кеше итәргә тырыш аларны»,—дигән хаты килде.

Күп тә үтмәде, абыемның җәмәгате Мөнирә ападан авыр хәбәр алдым: аерым чаңгы батальоны командиры Барый абыем Сталинград фронтында һәлак булган.

* * *

Безнен крейсер төзелеп бетте. 1943 елның язында кирханәдән крейсерны Амурга чыгардык. Ул инде бөтенләй коралланып беткән иде. Урта җиренә өчәр көпшәле өч туп, ике ягында берәр гидросамолеты бар. Чал Амурдан түбәнгә—Япон дингезенә таба йөзәбез. Безнең арттан икенче крейсер ияреп килә.

Без тулысынча сугышчан хәзерлектә. Берничә көн эчендә Япон дингезендәге Татар бугазына да килеп җиттек. Сахалин ярлары буйлап башта Охотск дингезенә чыктык, аннары юлыбызны Япон дингезенә таба дәвам иттек. Бу көннәрдә көчле штормнар булмады.

Японнар эндәшми. Сталинградта Гитлер армиясе тар-мар ителде. Мәскәү, Ленинград фронтларында да безнекеләр өстенлек алды. Дошман чигенә башлады.

Ике крейсер да, хәвеф-хәтәрсез генә Япон дингезенең Алтын Мөгез култыгына кайтып, якорь салды.

* * *

Крейсерны ягулык, су, азык-төлек белән тәэмин итә башладык. Зур походка әзерләнәбез. Күрәсең, эскадрабыз кая да булса маневрларга чыгарга җыена.

Таң алдыннан крейсер Алтын Мөгез култыгыннан ачык дингезгә юл алды. Безне сугыш кораблары озата чыкты. Оскольт атавы да артта калды. Эскадра Төньякка юнәлде. Һавада безне самолетлар каравыллый. Алар вакыт-вакыт югалып торалар да янадан эскадра өстендә пәйда булалар. Өч көн вакыт үтмәгәндер, Сахалин, Камчатка да артта калды. Беринг бугазына якынлашканда сугышчан тревога бирелде, шартлаулар яңгырап алды. Тынычлык урнашкач, эскадра никтер кирегә борылды. Бу бәрелештә безнең

ике корабыбыз батырылган. Көтеп кенә торганнар икән—японнармы, немецлармы һөҗүм иткән. Су асты көймәләре белән торпеда җибәреп, эскадрабызны һәлак итәргә ниятләгәннәр. Безне озатып барган Себер дингезчеләре командующие бәрелеш бетү белән үк телеграф аша Мәскәүгә хәбәр иткән. Аннан кичекмәстән эскадраны кирегә—Япон дингезенә кайтарырга боерык алынган.

Димәк, Мурманскига Боз дингезе аша бару туктатылган. Янадан Алтын Мөгез култыгына кайтып, хәрби портка якорь салдык...

Ниһаять, 1945 елның маенда, Германия Совет гаскәрләре алдында баш иеп капитуляция ясагач сугыш бетте дип бик сөенгән идек тә... иртәрәк икән әле...

* * *

Август ае килеп җитте. Ерак Көнчыгышта тынычлык әле. Ләкин Япония Тын океанда Америкага каршы һөҗүмнәрен дәвам итә. Инде японнар Индонезия һәм Англия, Голландия biləмәләрен үз кулына төшереп, Австралиягә барып җитте.

Көтмәгәндә Хиросима, Нагасаки шәһәрләренә әле моңарчы һич тә күрелмәгән яңа төр корал—атом бомбасы ташладылар, һәлакәт коточкыч зур иде. Хиросима шәһәрендә генә дә бер бомбадан җиде йөз меңгә якын кеше һәлак булды. Диңгез култыгында якорьда торган кораблар ярга сикереп янды.

Советлар иле, Америка, Англия белән союзда торганлыктан, Манчжуриягә бәреп керде. Бер миллионлы Квантон армиясе чигенергә мәҗбүр булды.

Тын океан флоты Кореяга десант төшерде. Атна-ун көн үтмәде, флот десанты японнарның Гинзан, Юки, Расин кебек ныгытылган портларын алды.

Безнең крейсер башка сугыш кораблары озатуы астында Кореяның баш шәһәре Сеул портына барып җитте. Десант төшердек, Квантон армиясенен чигенеп килгән калдыклары моннан Япониягә качмакчы булганнар. Ләкин без аларга киртә куйдык.

Шундый зур һәлакәттән соң Япон императоры сугышны туктатырга, кичекмәстән капитуляция кабул итәргә ризалашкан. Безнең Сеул порты култыгында торган крейсерга армиябезнең җитәкчеләре әсир төшкән японнарның өч генералын, ике адмиралын тапшырдылар. Аларны аерым каютага урнаштырдык. Минем чын самурайларга исем китте—бик матур киенгәннәр, погоннары ялт-йолт итеп тора.

Кылычлары үзләрендә, аларны бары тик утлы коралдан гына мәхрүм иткәннәр...

Эскадрабыз янадан Владивосток ягына юл алды.

Корея икегә бүленеп, үзара сугыша башлады. Көньякта Америка булышса, төньякта без булышабыз. Бәрелешләр һаман дәвам итә. Шунлыктан демобилизация тукталып тора. Минем туган ягыма кайтасым килә, тәмам җирсендем. Чөнки сигез ел бит инде мин һаман сугышчан корабта...

1947 елның март ае иде. Кичке аштан соң кораб клубында кино карыйбыз. Америка боевигы. Тын океанда Америка солдатларының японнар белән сугышуы тасвирланган. Ни арада кинога төшереп тә өлгергәннәр...

Кубрикка алып төшә торган траптан яртылаш күренеп, кораб дежурные сыбызгысын кычкыртып алды. Барыбыз да аңа борылып карадык.

—Өлкән матрос Бадыйкшанов, сезне офицер Кошкарев кабинетына чакыралар. Тиз булыгыз!

Мин өс-киемнәремне ашык-пошык кидем дә чакырылган каютага юнәлдем. Барып җитсәм—анда мине өч офицер көтеп тора. Икесе армия

киемендә, өченчесе дингез офицеры. Анысын беләм—ул безнең корабның оперуполномоченные. Мин ана укырга дип «Лже-нерон» китабын биргән идем шуны тапшырырга чакыргандыр дип уйладым.

Мин белмәгән офицерларның берсе куен кесәсеннән озынча кәгазь чыгарып, мина суздьі:

—Мәгез, кул куегыз. Сез кулга алынасыз!

—Ни өчен?

—Баргач белерсез.

Каюта бик кечкенә, бер генә кешегә исәпләнгән. Шунлыктан бөркү булып китте. Кораб оперы дингез култыгына караган. Ул иллюминаторны ачмакчы булды. Ләкин тегеләр аны шундук туктаттылар, коридорга караган иллюминаторны гына ачарга рөхсәт иттеләр.

Офицерларның берсе:

—Бадыйкшановның әйберләрен китерсеннәр,—диде. Кораб оперы шундук телефон трубкасын алды.

Күп тә үтмәде, старшина белән бер матрос дингез чемоданымны каютага китереп тә куйдылар. Старшина белән килгән матрос—Моталлап Хөсәенов иде. Әлегә алар яныбызда басып тора. Дингезче чемоданын ачып җибәрүгә минем өстә яткан зиннәтле бил каешым күренде. Хөсәенов:

—Локман, каешыңны мина бир, сина ул кирәк булмас,—диде.

—Алмыйрак тор әле,—дидем мин.

Чемоданымнан бар мөлкәтемне берәм-берәм өстәлгә куя башладылар. Аларның барысы да—минем кулъязмаларым, көндәлекләрем.

Офицерларның берсе:

—Сезнең башка кирәгегез юк. Барыгыз, каютага кайтыгыз,—диде.

Старшинам белән Хөсәенов чыгып киттеләр. Офицер язмаларымны актара. Шунда бер язуга тап булды. Анда: «Хризантема чәчәгеннән дә гүзәл чәчәк юк, япон солдатыннан да батыр солдат булмас»,—дип язылган иде. Ул шуна бармагын төртеп:

—Коллега, карале, егет японнарны бик ярата икән,—диде. Мин бу язманы рус язучысы Степановның «Порт-Артур» дигән китабыннан күчереп язган идем. Алар һаман актарына. Шул вакыт коридорга ачылган иллюминаторга күзем төште. Ни күрим—кораб повары (когы) кулы белән ымлый, кулына урталай кисеп, калын май ягылган икмәк тоткан. Мин бу ризыкны үрелеп алдым. Егет коридор буенча чабып китеп тә барды. Бу хәлне күргән офицер, ашыгып коридорга чыгып китте. Тик бик тиз әйләнеп тә керде: егетне тота алмаган.

—Нинди матрос иде ул?

—Белмим! Мин кичке ашны ашамадым әле,—дидем. Офицер кулымнан икмәкне тартып ала башлады. Карышам, бирмим.

Тикшерүчеләр, эшләреннән туктап, мине стенага китереп терәделәр. Икмәкне тартып алып, сындырып карадылар, аннары гына кире бирделәр.

—Партбилетың бармы?

—Бар.

—Чыгарып сал!

—Аны сез бирмәдегез—алырга хакыгыз юк!

Бераз тарткалашканнан соң алар мине корабның политбүлек башлыгы Почупайло Яков Гурьевич янына иртәп алып киттеләр.

Төнге сәгать унберләр тирәсе иде. Начальникның каютасына килеп җиткәч:

—Әллә иртәгә калдырабызмы?—дип киңәшеп тордылар. Зур начальникны уятырга кодрәтләре җитмәде ахрысы.

Кораб оперының сүзен тыңламадылар. Офицерларның берсе кабинетның ишеген какты. Озакламады, анда Яков Гурьевичның озын таза гәүдәсе күренде. Ул:

—Ни булды?—дип сорады.

—Кергәч әйтербез,—диде офицерларның берсе.

Каютага кердек. Кораб оперы эшнең нәрсәдә икәнлеген ачып салды. Яков Гурьевич башта тиз генә ачык нәтиҗәгә килә алмый торды. Аннары:

—Бадыйкшанов, ачыклангач, билетыңны кире бирермен,—диде.

Мин тельняшкамның күкрәк кесәсеннән партбилетымны чыгарып бирдем.

Без янадан опер каютасына киттек. Килүчеләр язмаларымны, көндәлекләремне белән бергә каяндыр шнур табып бәйләделәр дә үзләре белән мине дә алып чыгып киттеләр.

Палубадан барабыз, берсе алдан—мин уртада. Оперыбыз гына үз каютасында калды. Бу минем корабльдән соңгы тапкыр атлап чыгуым булды.

Крейсерның коерык өлешендәге баскычтан ярга чыктык. Каршыбызда безне кара «Волга» машинасы көтеп тора икән.

Владивостокның урамыннан барабыз. Порт ягына күзем төште, анда дистәләгән сугыш кораблары электр лампалары белән яктыртылган.

Озак бармадык, ниндидер өч катлы йорт янына килеп туктадык. Бар тәрәзәләре дә якты. Төнге уникеләр булуына карамастан, монда һаман эшли. Бу—КГБ йорты икән.

Машинадан чыккач, зур имән ишекне ачып кердек. Мәрмәр баскычлардан бер катка аска төштек. Озын коридор буенча атлагач кара ишек янына килеп туктадык. Аның урта бер җирендә кечкенә тәрәзәсе бар иде. Без килүгә ул шундук ачылды да ябылды. Аннары, кара ишек тулысы белән канатларын җәйде. Аннан яшел төстәге армия киеменә киенгән офицер чыкты. Ул безне күрүгә бер генә сорау бирде:

—Китердегезме?

Аннары ул минем каршыма килеп басып, погоннарымны умырып ташлады:

—Сина, моряк, болар бүтән кирәк булмас инде!

Мине монда китерүчеләр үзара сөйләшеп алдылар да китеп бардылар.

Мин әлләни зур булмаган эңгер-меңгер бүлмәдә калдым. Тәрәзә сыман уелып ясалган җирдән коридордагы яктылык төшеп тора. Аптырап киттем. Урындык та, өстәл дә, ятак-фәлән дә юк. Ишектән башка өч тарафта өч стена гына. Бүлмәнең озынлыгы биш метр чамасы, киңлеге өчтән дә артмас. Бүгенгә торак урыным шушыдыр инде дип шинелемне таш идәнгә җәеп яттым.

Нәрсә бу, нинди капкынга эләктерделәр мине? Һич кенә дә башыма китерә алмыйм. Газаплы уй диңгезендә йөзәм.

...Сигез елга якын Ватанга тугры хезмәт иттем. Бәрелешләрдә катнаштым. Япон самураеның кылычын сындырдым, башка крейсердагы диңгезчеләр кебек, зур җиңүдә минем дә өлешем юк мыни?..

Шулай хыялланып күпме ятканмындыр—белмим. Йоклап китәм дигәндә генә шылтырап тимер ишек ачылуга сискәнеп куям. Анда озын буйлы офицерның калын тавышы:

—Әйдәгез, тикшерүчегә!

Якты зур бүлмәгә уздым. Ул ике тәрәзәле, уң як стена буенда өстәл тора. Чәче чалара башлаган, ак йөзле, ябык өлкән лейтенант миңа үзенең каршысындагы урындыкка утырырга ымлады.

—Йә, диңгезче егет, танышыйк: мин. өлкән тикшерүче Шумихин булам. Эшегезне алып барырга миңа боердылар. Башлыйк. Хәзер үзегезнең җинаятьләрегезне сөйләгез.

Җинаятьчеләр турында ишеткәнем бар: сатлык җаннар, кеше үтерүчеләр, дәүләт акчасын яки әйберләрен үзләштерүчеләр, көчләүчеләр, тагын шуның ише кемсәләр беткәнмени?! Ә мин ни кылдым? Чәчкән идем дә, урган идемнән кала ни майтардым? Уку да укыту, каләм тибрәтү дә Ватанга

кушылганча хезмәт итүдән гайре ни кылдым? Йа Аллам, анламыйм! Корабта хезмәт итеп сугышлардан исән-имин калып, хөкүмәткә каршы нинди җинаять кылдым икән мин? Һич кенә дә башыма китерә алмыйм!

Тикшерүче кулына каләм алды да язарга әзерләнде.

—Йә, башлыйбыз.

—Иптәш өлкән лейтенант, сигез елга якын крейсерда хезмәт итеп, үземнен нинди җинаять эшләгәнемне башыма китерә алмыйм.

—Мина иптәш димәгез! Сезнең иптәшләрегез көнбатышта—Брянск урманнарында!

—Гафу итегез, минем Көнбатышта булганым юк. Сез әйткән Брянск урманнарында партизанлыкта да йөрмәдем.

Тикшерүче Шумихин мина җентекләп карый. Күрәм, анын күзләреннән усаллык бөркелеп тора, ут булып яна. Бит яңакларында кып-кызыл буй-буй юллар пәйда булды.

—Кабатлап әйтәм, башлагыз!

—Башларга... җинаятьләремне башыма китерә алмыйм бит. Бәлки исемә төшерерсез?

Бу җавабым аны чыгырыннан чыгарды. Ул торып басты да:

—Вон!!!—дип кычкырды.

Анын баш очында стенага зур сәгать элengән, шуңа күзем төште. Төнге дүрт—иртәнге дүрт икән.

Ишеккә таба атладым, ул шундук ачылды. Коридорда мине монда озата килгән ике солдат белән офицер көтеп тора. Алар мине ничек китергән булсалар шулай итеп алып та киттеләр. Янадан кара ишек ачылды. Мине тагын бикләп куйдылар. Ялгыз калдым. Могҗиза! Вакыйгасыз могҗиза!..

• • •

Тикшерүчеләрнең таләбе бер генә: «Җинаятенне, безгә сөйләп бир», имеш! Нинди җинаять турында сүз бара соң?! Зиһенем тәмам таралган. Төне буе йоклый алмый яттым. Фәкать тан алдыннан гына тәмам йончыган күзем йомылды. Күпме йоклаганмындыр, белмим, дежурныйның: «Торыгыз! Иртәнге чәйгә!» дигәненә уянып киттем.

Ачык ишек янында бер солдат кулына кружка, икмәк тотып басып тора. Сикереп тордым да китергән ризыкларны алдым.

Кулымдагы кружка белән икмәкне идәнгә куеп янадан шинелемә барып капландым. Шундук йокыга талганмын.

Бүген чакырып борчымадылар. Ял көне булган икән. Икенче көнне дә тимәделәр. Борчуларым уйларымны төйнәргә ирек бирми. Алай да ике көн тоташтан диярлек йокының кирәген бирдем. Мина нигә дип борчылырга? Мин үземне гаепле санамыйм. Бу уйдырма—аңлашылмаучылык.

Мине өч айга якын шулай борчыдылар. Тикшерүче үзе дә аптырагандыр инде:

—Без синдәй байтак «кошчык»ларны сайрарга, җинаятьләрен танырга мәҗбүр итәргә өйрәнгән,—диде.

—Бәлки аларның гаепләре булгандыр. Минем гаебем юк.

Май аенын соңгы көннәре... Иртә белән мине шул ук коридордагы башка ишеккә алып килделәр. Бу зур бүлмәнең, өч тәрәзәсе бар, түрдә кызыл постау ябылган зур өстәл. Генерал-майор погоннарын ялтыратып зур башлы, чәчләре артка таралган, Джугашвилиныкына охшаган мыеклы бер хәрби утыра.

Килеп басуыма ул:

—Матросик, утырыгыз!—диде. Аннары:—Сез инде бездә өченче ай. Тикшерүчебезнең теңкәсенә тиеп беткәнсез. Ул сездән җинаятегезне сөйләтә алмаган.

—Минем җинаятем булмады. Бер кайчан да!—дип җавап бирдем мин, кырт кисеп.

Генерал белән әңгәмәбез шулай кыска булды. Аның соңгы сүзе:

—Матросик, җинаятегезне сөйләп бирсәгез, сезне яхшы лагерьга җибәрергә боерырмын. Барыгыз.

Ишек артында көтеп торган офицер, ике солдат белән мине шундук теге өлкән лейтенант Шумихин кабинеты янына китерделәр.

—Генералга дөресен сөйләргә вәгъдә биргәнсез. Утырыгыз, башлыйбыз,—диде ул, нәрсәгәдер ышанган төсле.

—Минем җинаять эшләгәнем юк. Беркетмәгезгә шулай дип язсагыз, кул куям—дидем.

Тикшерүче әле монарчы бер дә әйтмәгән сүзләр белән җикеренде.

—Акырмагыз мина, өлкән лейтенант...—дип җавап бирдем тыныч кына.

Мине яңадан камерага озаттылар.

Өч көннән соң хәрби трибунал суды алдына китереп бастырдылар.

Соңгы сүземне әйттерделәр.

—Сугышта һәлак булган ике абыемның ятимнәрен үстерергә ярдәм итәргә мөмкинлек бирегез,—дидем.

Суд киңәшмәгә чыгып китте. Озакламый миңа хөкем укылды:

Матрослар алдында Советка каршы сүзләр сөйләп йөргәне өчен, җинаять кодексының 58-п 10 матдәсе нигезендә биш елга ирегеннән мәхрүм итәргә... һәм өч елга сайлауларда катнашу хокукыннан мәхрүм итәргә».

Мине камерамнан төрмәгә, озак тотмыйча, лагерьга озаттылар.

* * *

Лагерь Владивостоктан әллә ни ерак түгел—диңгез буенда иде.

Бригадаларга бүленгән тоткыннарны диңгез буендагы карьерга көн дә эшкә алып баралар. Кеше башына өч кубометр таш төяргә. Коралларыбыз кәйлә белән лом. Ташны күпме чыгарып өюебезгә карап кичен икмәк бирәләр. Ашаткан ризыклары—«затлы» баланда. Анда күзгә кырып салырлык кына дигәндәй солы бөртекләре йөзә. Шулпасы, болай икмәк белән ашарлык. Ашыйсың инде, кая бармак кирәк. Мин беренче көннәрдә икмәкне күбрәк алыр өчен тырышып-тырмашып эшләдем. Хәтта тугызар йөз грамм икмәк алган көннәрем дә булды. Тора-бара үземне болай җәфаламаска дигән катгый нәтиҗәгә килеп, норманы өч кубометрдан арттырмаска тырыштым. Монысы—лагерьның кырыс сабагы.

Ә күрәселәрем алда иде әле, алда...

*2004 ел.*



Фәрит
Габдерәхим

## МИЛЛИ ҖАНЛЫ КИҢЛЕКЛӘРДӘ

### Туктар идем

Белсәм—кайда икәнлеген
Әткәемнең кабере;
Измәгән булса әнкәмне
Түрәләрнең җәбере;

Күңелемне бертуктаусыз
Өтмәсә үкенечләр;
Югарыдан шелтә булып
Кайтмаса үтенечләр;

Китсәләр кара болытлар
Татарымның күгеннән...—
Әрнүле шигырь язудан
Туктар идем бүгеннән!

### Тере кеше сыман...

*Урыс империясенең бөтенләгән вә иминләгән саклап корбан булган татар егетләренең якты истәлегенә*

Сыңар кулын Кафтау өзеп алган,
Дуслар калган мәхшәр эчендә.
Шул дуслары өчен сызлый җаны,
Иртәсен дә сызлый, кичен дә.
Күкрәгендә орден. Уйга чумып
Утырабыз елга ярында.
Көтмәгәндә исән кулы белән
Орденын ул йолкып алды да

Атып бәрде дулкын кочагына.
Сорау белән тулды күзләрем.
«Тере кеше сыман... йөргән булам...»
Иңри-иңри чыкты сүзләре.

---

Фәрит ГАБДЕРӘХИМ (1933) — *шагыйрь; татар һәм башкорт телләрендәге уннан артык китап авторы. Уфада яши.*

## Хыял

Үтеп китте Егерменче гасыр,
Тик яумады шифа яңгыры.
Яңа гасырның да яңгыры юк,
Күкрәүләре генә яңгырый.

Без нишлибез?!
«Берүк безне яшен
Суга күрмәсен!»—дип телибез.
Болай булса, Егерме икенче йөзне
Күрә алмас илсез телебез.

Болай булса, чынга ашуы бар
Гаяз Исхакыйның фаразы...
Бердәнбер көн ачып ташладым да
Шыткан бәрәңгеле карбазын,

Юлга чыктым. Булмасам да, әлбәт,
Күз бууччы яки сихерче,
Егерме икенче йөзгә барып җиттем,
Ник җитмәскә—мин бит шигырьче.

Сөбханалла! Монда күргәннәргә
Ышанырсыз микән, туганнар?
Күк чалт аяз. Кургаш болытларны
Көчле җилләр ерак куганнар.

Муллык монда. Әдәплелек монда.
«Нинди ил бу?»—иттем сорыйсы.
«Татар Урдасы бу!»
Күз тимәсен:
Җәйрәп ята очсыз-кырыйсыз!

Һушка килгәч бераз, китердем дә
Гаяз Исхакыйны чакырып,
Татарымыз илен әйләник дип,
Чаптар атта киттек чаптырып.

Ат эчердек Ульян каласында:
Ул әйләнгән кабат Сембергә.
Хозурланып Урал тауларына,
Сәлам биреп киттек Себергә.

Ат утлатып Алтай буйларында,
Килгән якка киттек борылып.
Татар өчен татар үләр монда,
Уныбызга берсе торырлык.

Тубыл буе. Гаяз абыз белән
Яшь чирәмгә яттык сузылып.
Саф татарча гәпләшәләр әнә,
Синең белән миннән уздырып.

Төрле сортка телләр бүленмәгән,
Бар телләр дә монда тигезләр.
Татар телен өйрәнәләр, имеш,
Урыс, нимес, хәтта инглизләр.

Бер үләксә ята чик буенда,
Каракошныкы ул үләксә.
Күпме мөлкәт кирәк булыр икән,
Шул гуҗ тыгынганны түләтсәң?!

...Исхакый бәй телгә килде: «Дөрес
Аңлаганнар «Инкыйраз»ымны[1].
Чынга ашкан хыялыңны күрдем—
Күрдем, халкым, яңа языңны!»

Күзләрендә яшьләр...
Китеп барды
Канлы Егерменче гасырга...
Ә мин килдем—шушы шигыремне
Сөйләр өчен—сезнең каршыга.

## Ялвармаган

Заманында кол халыклар—бүген
Азатлыкта яши, иректә.
Ялвармаган—богауларын алар
Көрәш ялкынында эреткән.

## Татар иле

Сулкылдый бәгырь, сулкылдый
Кагылганда тарих җиле:
«Милли җанлы киңлекләрдә
Гөрләп торды Татар иле».
...Ник иртәрәк тумаганмын?!

Бәгырьләрне назлап исә
Киләчәкнең гадел җиле:
«Милли җанлы киңлекләрдә
Гөрләп тора Татар иле!».
...Нигә соңрак тумаганмын?!

## Күләгә

Көн яктысын күргән дә юк безнең,
Күләгә дә һаман күләгә.
Охшаганбыз Кояш нурларыннан
Мәхрүм булган зәгыйфь үләнгә.

Хуҗабыз бар. Беркем сайламаган.
Мирасы ул ерак үткәннең.
Яше аның әллә ничә гасыр,
Күләгәсе, димәк, күптәнге.

Түзәр хәлләребез калмаганда,
Ачу-нәфрәтләрне ук итеп
Очырабыз... күләгәгә. Ләкин
Күләгәгә уклар атып кына
Буламы соң аны юк итеп?!

## Әллә...

Дөм-караңгы. Җир-күк балкып алды,
Ымсындырып, алгысытып җанны.
Ачылдымы әллә күк капусы,
Әллә берәр шагыйрь дөрләп янды?!

[1]«Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре күздә тотыла.

## Соравым бар

Мәрхәмәтле, миһербанлы Аллам,
Син бирдәнбер кодрәт иясе.
Әмма килми бәгъзе колларыңның
Синең алда башын иясе:

Көче житкәннәргә ташланалар,
Әйтерсең лә инде кыргыйлар.
Хәкимнәргә түгел, хакимнәргә
Эттән болай койрык болгыйлар.

Каргышлары төшәр дип тә тормый,
Сата алар ата-анасын.
Килештереп тәүбә иткән була
Һәм гөнаһның кыла яңасын.

Ә угрылар, караңгыга чумып,
Рәхмәт укый синең төнеңә.
Хәрам яклыларга хөкемеңне
Калдырасың Хисап көненә.

Бу заманда хәтта Аллага да
Жиңел түгелдер ул, мөгаен...
Соравым бар: нигә ярлыкыйсың
Имансызларыңны, Ходаем?

## Йа Рабби...

Мин булдым менә шулай итәргә—
Синнән алдарак анда китәргә.

Хәлләре ничек теге дөньяның?
Сиңа кадәрле күрим мин аны.

Карап чыгармын бөтен жирләрен,
Кай яктан исә ачы жилләре?

Таңнар атамы, Кояш байыймы,
Анда да карак-угры байыймы?

Бармы жәйләре, бармы кышлары,
Назлы гөлләре, сайрар кошлары?

Алдан китәрмен—шулай хәл иттем.
(Юкны сөйләмәс синең Фәритең.)

Синең килүгә сарай салырмын,
Кайчан килсәң дә каршы алырмын

Теге дөньяның гүзәл төшендә...—
Шундый ниятләр керде төшемә.
Йа Рабби...

## Киндер күлмәк

Күлмәкләрнең кидем зәңгәрләрен,
Караларын кидем, акларын.
Гомер буе мин шуларның берсен
Күз карасы кебек сакладым.

Ул күлмәкне кидем малай чакта,
Минем өчен затлы-кыйммәт ул.
Киндерен дә Әнкәм үзе суккан,
Үзе тегеп биргән күлмәк ул!

## Гафу итә алмыйм

Күпләр миңа югарыдан бага,
Гүя ашкан күккә—гарешкә.
Бер гөнаһсыз итеп тоя үзен,
Әйтерсең лә инде фәрештә.

Гөнаһларым, хаталарым байтак,
Йома алмыйм моңа күземне.
Башкаларны гафу итә алам,
Гафу итә алмыйм үземне.



Илдус Хуҗин

# КЫЗЫЛ ТӘНЛЕЛӘР ЮЛБАШЧЫСЫ

ХЫЯЛЫЙ БӘЯН

*Татар халкының күренекле улы, академик, тарихчы, язучы, Г. Тукай исемендәге премия лауреаты, филология фәннәре докторы, "рыцарь Маркиз де Туран" дәрәҗәле исем иясе Әбрар Кәримуллинга багышлыйм.*

Әбрар Кәримуллинның казанышлары хакында белмәгән кеше сирәктер. Әдипнең киң тармаклы эшчәнлегенең бер юнәлеше, ул да булса, Америка континентында төп халыклар белән безнең ата-бабаларыбызның кан һәм тел кардәшлеге турындагы гипотезасы шушы бәянны язарга этәргеч булды.

Ә. Кәримуллинның тирән тарих катламнарына күмелгән әлеге теманы "чокый" башлавы егерменче гасырның җитмешенче елларында ук башланган булган. Беренче этәрешне Пруссия галиме Ф. Л. Отто Ригрнның 1861 елда, ул вакытта инде дөнья куйган мәшһүр И.Хәлфинга язган хаты ясый. Галим бу мәктүптә кайсыбер Америка аборигеннары теленең төрки телләргә тиңдәш булуы турында белдерә. Ә. Кәримуллин мондый хәбәрне игътибарсыз калдыра алмый, шундук төрле дәверләрдә һәм илләрдә яшәгән галимнәрнең, сәяхәтчеләрнең әлеге темага мөнәсәбәтле мәгълүматларын эзли башлый.

Эзләнүләренең нәтиҗәсен Ә. Кәримуллин "Прототюрки и индейцы Америки" (Мәскәү "Инсан" 1995 ел) дигән китабында китергән. Анда Отто Ригртан кала тагын дистәгә якын авторның язмаларына таянып, югарыда китерелгән гипотезаның бик тә табышлы икәнлеге һәм татар галимнәре өчен гыйльми хезмәтләр этәргече булырга тиешлеге турында яза.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәктер, әлеге гипотезаны заманыбызның күп кенә күренекле шәхесләре дә инкяр итмиләр икән. Аларның исеме әлеге китапта бирелгән.

---

Илдус ХУҖИН (1942) — *прозаик; повестьлары һәм хикәяләре «Казан утлары», «Идел» журналларында басылды. Свердлов өлкәсендә яши.*

Ошбу язманы аз булса да җанландыру өчен Ә. Кәримуллинның китабыннан бер мисал китерәбез.

| Хока – сиу телендә | Майя телендә | Татар телендә |
|---|---|---|
| Коке | | Күке |
| Тан | | Тан |
| Екта | | Якта |
| Таңним | | Таныйм |
| Ате | | Әти |
| | Йаш | Яна, яшел |
| | Куи | Көн |
| | Ич | Эчтә |
| | Ош | Өч |

Шушындый тел уртаклыклары китапта бихисап китерелгән. Болар, автор фикеренчә, һич тә очраклы була алмыйлар, киресенчә, дистәләрчә мең еллар элек бу халыкларның уртак мәйданнарда яшәп, борынгы гомуми кавемнәрдән чыккан булуын күрсәтә. Без дә бу фикергә кушылабыз.

**Автор**

Маратның күчтәнәч итеп китергән юан сигарасын кабыздым да кофе кайнатып маташкан иптәшемнән сорап куйдым:

—Штатлардан нәрсәләр алып кайттың?

—Әнә ич авызында,—дип җавап бирде ул.

—Күчтәнәчләрең өчен рәхмәт, әлбәттә. Ләкин мин синнән икенче нәрсә турында сорарга телим: Америкада исең китәрлек ниләр күрдең?

—Күп нәрсә күрдем,—диде Марат,—Америка бит ул! Буш вакыт булганда сөйләрмен әле үзеңә.

—Син нәрсә, аларның шәһәрләре, техникасы, байлыгы турында сөйләп, мине шаккатырмакчы буласыңмы?—дидем мин көлемсерәп.—Кем хәзер Америка турында белми?

—Алай булгач, сине нәрсә кызыксындыра соң ?—дип сорады ул аптырап.

—Кешене гаҗәпкә калдырырлык нәрсә күп булмый, булса берәү генә була. Сүз уңаеннан сорыйсым килә, син кайсы штатта булдың әле?

—Орегонда,—дип җавап бирде ул, уйчанлана төшкән тавыш белән.—Ә бит син хаклы, мине гаҗәпкә калдырган нәрсә чыннан да бар, менә ул,—дип, кайдандыр бик иске бер калын дәфтәр китереп чыгарды һәм миңа тоттырды.

Искереп таркала башлаган бу дәфтәрне бик зур саклык белән генә кулыма алдым. Тышы калын, эче төрле төстәге юкарак кәгазь битләрдән тегеп эшләнгән бу дәфтәргә ике йөз-өч йөз еллап бар иде бугай. Ә иң гаҗәбе—дәфтәр битләре вак кына итеп язылган гарәп хәрефле язулар белән тулган иде.

—Син нәрсә, моны тегеннән алып кайттыңмы?—дип сорадым мин исем китеп.

—Әйе, индеецлардан алдым.

—Индеецлардан?!—дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым.—Сөйлә тизрәк, ничек булды бу!

—Фермерлар ассоциясе штатларга стажировкага барырга тәкъдим иткәндә,—дип башлап китте сүзен Марат,—миңа берничә штат атадылар. Мин көнбатыш тарафындагы Орегонны сайладым. Нигәме? Минем күптән инде Рокуэлл Кент картиналарындагы Кыялы тауларны күрәсем килә иде.

—Күрдеңме ?

—Күрү генәме соң!

—Ничегрәк?

—Таулардан да гүзәлрәк бары тик Кыялы таулар гына булуы мөмкин! Ләкин күреп торам, хәзер сине Кыялы таулар да, Америка үзе дә кызыксындырмый. Дәфтәр...

—Өстенә бастың,—дидем мин.

—Мин эшләгән фермерда бер индеец та бар иде. Оло Джон диләр иде үзен. Безнеңчә олы Джон кебегрәк була инде. Тумышы белән ул Монтанадан икән, ләкин аларны бирәдәге резервациягә күчергәннәр. Без аның белән дуслашып киттек. Аннан ул мине кунакка чакырды, дөресрәге мин үзем тагылдым.

Резервация дигәннәре әйбәт жир түгел икән. Берни үсми торган тау-таш арасына урнашкан ярлы авыл инде. Кыскасы, аборигеннар бетеп бара. Эшләгән жирләре юк дип әйтерлек. Наркоманлык, эчкечелек хөкем сөрә. Күбесе чирле...

Анда мин күп кенә индеецлар белән таныштым. Арада Мәр Гән исемлесе дә бар иде. Ул Монтана штатындагы дакота кабиләләреңен берсендә юлбашчы булып торган нәсел ярчыгы булган. Ә хәзер аларның жир-суларына башкалар хужа икән.

Беркөн шулай, мин Мәр Гәндә кунакта утырганда, ул минем нинди кавемнән булуым белән кызыксынды. Мин аңа татарча сөйләшеп күрсәттем. Хужаның исе китте.

—Сезнең телегезне аңламыйм, ләкин ул миңа шундый якын булып тоела,—диде.

Шуннан соң әлеге дәфтәрне китереп чыгарды. Мин, гарәп язуларын күреп, аптырап калдым.

—Бу язмаларны укый аласыңмы?—дип сорады ул миннән.

—Элек безнең халык шундый хәрефләр белән язган,—дидем мин,—үзем дә азрак укый-язам.

—Укы,—диде хужа.

Мин, тырыша торгач, берничә сүз укый алдым.

—Бу чыннан да безнең телдә,—дидем мин,—ләкин моны укып чыгар өчен белгеч булу кирәк.

—Сезнең телдә булгач, син моны ал,—диде хужа. Бу дәфтәрне миңа әтием калдырган иде. "Язуны укый алырдай кеше очратсаң, биреп жибәр!"—дигән иде ул. Ә әтиемә бабамнан калган булган.

—Мәр Гән!—дидем мин бераздан.—Синең исемең нәрсә аңлата?

—Кайчандыр, бәлки, аңлаткан булгандыр,—диде хужа.—Минем әтием дә шул ук исемне йөрткән бит. Бабам да. Бәлки ул буыннан-буынга күчеп килгәндер.

Марат әлеге дәфтәрне миңа бирде. "Син яхшы гына тел белгече дә бит әле,—диде ул,—ач моның серен."

Инде, хөрмәтле укучым, әлеге дәфтәрнең кыскартылган һәм үз сүзләрем белән бирелгән эчтәлеген тәкъдим итәм.

1741 елның июнь аенда Русия Император флотының алты корабльдән торган эскадрасы капитан-командор Витус Беринг житәкчелегендә Охотск портыннан кузгалып, Камчаткага таба юл алды. Иң алда Беринг үзе утырган өч мачталы хәрби шлюп " Изге Петр" Охотск дингезен яра. Икенче булып "Изге Павел" дигән пакетбот, ә аңардан берничә кабельтов ара калдырып кечерәк кораблар бара.

Берингның бу сәяхәт максаты—Вест-Индия ярларына барып житү иде. Русия ике йөз елга якын вакыт эчендә Казан һәм башка татар ханлыкларын

яулап, үзенә көнчыгышка юл ачты, бөтен Ерак Көнчыгыш халыкларын басып алып, Тын океанга кадәр җәелде. Соңгы елларда шул ук Витус Беринг, Ерофей Хабаров, Василий Поярков, аннан соң Федот Попов, Семен Дежнев һәм бертуган Лаптевлар Камчатка, Сахалин тирәләренә борын тыктылар һәм андагы халыкларның җир-суларын картага төшереп, Русия биләмәләре, дип игълан иттеләр. Ә көньяктарак Русия Кытай җирләре өчен сугыш башлады, ләкин тешләре үтмичә, солых төзергә мәҗбүр булды.

Шушы хәлләрдән соң тагын берничә дистә ел үткәч, Беринг Якутск воеводасы Шуваловтан ярдәм алып, инде эшлекле урыс алыпсатарлары һәм аучылары тарафыннан үзләштерелә башлаган Камчатка, Алеут утрауларын узып, Америка дип атала башлаган илаһи зур җирнең төньяк-көнчыгыш ярларына таба юнәлде.

Охотск диңгезе бу көннәрдә тыныч булып, атна да үтмәде, Камчатка ярыматавының көньяк очлыгында төзелгән Камчатск төрмәсе (урыслар кайда барып урнашсалар да, башлап төрмә салалар иде) һәм шуның тирәсендә барлыкка килгән шәһәрчек белән диңгез порты күренде.

Камчатскта Беринг экспедиция өчен өстәмә рәвештә азык-төлек юнәтергә тиеш иде, ләкин тозлы балыктан башка берни дә эләкмәде. Аның каравы, юлда авырган матросларга алмашка аңа солдатлар бирделәр. "Документлар патшасы" актуариус Батиков командорга булачак диңгезчеләрнең кайбер шәхси кәгазьләрен дә бирде. "Сабуров Максим Николай улы,—диде ул соңгы солдатның кәгазен сонып.—Чукындырылган татарлардан,—дип әйтергә теләгән иде, ләкин нигәдер тынып калды.—Яхшы мушкетер,"—диде ул ахырда.

Эскадра Тын океан суларына килеп чыкты. Монда су һәм дулкыннар гына түгел, һава да икенчерәк кебек иде.

Беринг әле Камчатск портында чакта ук беренче рангтагы капитан Тизенгаузен һәм командор Чириков белән бергәләп, экспедициянең маршрутын төзеп куйды. Аларга башта төньяк-көнчыгышка сиксән биш градуслы румб буенча йөзәргә, ярты юлны үткәч, төньяккарак борылырга кирәк булачак иде. Үтәчәк ара биш мең мильдән артыграк булса да, эскадраның юлында инде өлешчә билгеле булган Алеут утраулары урнашканга күрә, Беринг һәм аның командасы үзләренең киләчәк язмышы өчен артык хафаланмадылар. Ләкин юкка.

Биш-алты тәүлектән соң, иртән, көн яктыра башлауга, уң яктанрак офык каралды. Бу диңгезчеләрне шундук хафага салды: очсыз-кырыйсыз океан киңлекләреннән давыл килә иде. Ике-өч сәгатьтән җил көчәеп, дулкыннар корабларны әле күккә чөя, әле су төбенә кадый башлады. Шторм шул кадәр көчле иде ки, яңа гына хәрби матрос булып киткән Максим Сабуров кына түгел, күпне күргән "диңгез бүреләре"дә белгән догаларын укый башладылар.

Дүрт-биш тәүлек дәвам иткән мәхшәрдән соң көн аязды, һәм Максим хезмәт иткән "Изге Павел"нең үтә кызганыч хәлдә икәне беленде: җилкәннәр теткәләнеп беткән, бизань-мачта бөтенләй сынган, фальшбортның эзе дә калмаган. Карый торгач, су мичкәләренең дә ярылып акканлыгы билгеле булды. Ә иң начары—төньяк тарафында күренгән бер корабтан башка, океан өстендә һичкем дә юк иде.

Чириков, төньякка таба искән җилдән файдаланып, теге корабка якыная башлады, һәм аның "Камчатка" исемле шхуна икәнлеге мәгълүм булды.

Ике капитан, кают-компаниядә озак кына утыргач, командаларны тезеп, төньяк-көнчыгышка таба хәрәкәт итәчәкләрен белдерделәр. Анда ике-өч йөз мильдән соң бер зур гына утрау очрарга тиеш икән, шунда хәл алырга өметләнеп корабларны төзәтергә агач бирделәр, төче суларын һәм азык-төлекләрен дә кызганмадылар.

—Монда утраулар күпме?—дип сорады командор авылның аксакалыннан.

—У-у-уй!—дип куйды авылның башлыгы һәм нидер бытылдап алды.

—Бу якта берәү генә—Атту. Ә теге якта,—дип көнчыгышка күрсәтте тылмач,—алар бихисап.

—Ә зур җир еракмы?

—Укимакны узгач та башлана,—диде аксакал.

—Ничек атала ул?

—Ничек атала?—дип аптырады карт.—Төрлечә. Анда авыллар күп.

Ике көннән соң кораблар юлга чыкты. Бу юлы Чириковның алдан билгеләнгән курс белән бармыйча, көньяккарак борылуы мәгълүм булды. Шулвакыт көтелмәгән хәл килеп чыкты: офыкта эскадрадан аерылып калган тагын бер кораб күренде. Бу—"Наварин" дигән шхуна иде. Кире утрауга кереп, аны да тәртипкә китерергә туры килде. Ниһаять, кораблар Вест-Индиянең, яки Американың җылырак сулы ярларына таба юнәлделәр.

Көннәрдән беркөнне Чириков, төче су һәм азык-төлек тулыландыру максаты белән Алеут утрауларының тагын берсенә туктарга әмер бирде. Командор бу эшне башкаруны ике шлюпкага төялгән унике матроска йөкләде. Үзләре белән берәр юньлерәк җирле кеше дә алып килергә кушты.

—Бу нинди утрау?—дип сорады ул алеуттан, үзенең боерыгы үтәлгәч.

—Белмим,—диде теге,—ишеткәнем юк.

—Хәзер инде утравыгызның исеме "Чириков" булыр,—диде командор һәм картасына нәрсәдер язып куйды.

—Тирикоф!—дип кабатлады алеут.

—Чириков, балда!

—Тирикоф, балта!

Командор ачуыннан төкереп куйды да тагын сораша башлады. Тегесе зур җирнең ярлары, андагы халыклар турында белгәнен сөйләп бирде.

Мәргәнне (документлары буенча Максим Сабуров иде ул) артта баручы корабка күчерделәр. Менә ничәнче көн инде, буш вакыты булды исә, бушпритның төбенә утырып, ул океанны күзәтә. Аның карашы офыкны айкый, ә күнеле еракта, Идел буенда иде.

Аның рәсми исеме Максим булса да, яшертен генә мулла чакыртып куштырган исеме Мәргән иде. Чөнки бабасының бабасы Сабирҗан көчләп чукындырылган булса да, ул үзе дә, балалары һәм оныклары да беркайчан да мөселман икәнлекләрен онытмаганнар. Мәҗбүри рәвештә чиркәүгә йөрсәләр дә, авылларындагы күпчелек керәшеннәр кебек, өйдә намаз укыганнар. Балаларын ике телдә укырга-язарга өйрәткәннәр.

Мәргәнне рекрутлыкка моннан биш ел элек алдылар. Башта аларны Тобольскига китерделәр. Анда яшь рекрутларны озак кына җафаладылар, аннан соң, ярты ел үткәч, чын солдат булдылар диптер инде, Русиянең күптән түгел генә сугышып алынган һәм колониягә әйләндерелгән Ерак көнчыгыштагы биләмәләрен сакларга алып киттеләр.

Мәргәннең ата-анасы, туганнары һәм үзе дә бу гомерлеккә аерылуны бик авыр кичерделәр. Дөрес, дүрт ел хезмәт иткәч, Русия императоры галиҗәнапләре гомерлек солдат хезмәтен егерме биш елга кадәр киметте киметүен. Ләкин Мәргән һәм аның иптәшләре мондый шартларда тагын егерме ел исән-сау хезмәт итеп, туган илгә кайта алуларына шикләнәләр иде.

Шундый уйлардан Мәргәннең күнеле бөтенләй төшенкелеккә бирелә торган булды, үзенең фаҗигалы гомере өчен йөрәге әрнеде. "Минем бу дөньяда яшәвемнең нинди мәгънәсе бар?—дип хәсрәтләнде ул һәрчак.—Йә туганнарымны күрмәячәкмен, йә гаилә корып, балалар үстерәлмәячәкмын! Миннән бу дөньяда нинди эз, нинди истәлек кала?"

Уйлана торгач, Мәргән көндәлек алып барырга карар кылды. Бәлки язмаларым туган җиремә кайтып җитәрләр, дип өметләнде ул, ә бәлки... Аннан-моннан кәгазь юнәтеп, бөтен баштан кичкәннәрен, өч-дүрт көнгә бер утырып булса да, шуңа теркәп бара башлады.

Чириковның кораблары бер айга якын вакыт эчендә тын океанның төньяк читен кисеп чыгып, июнь аенда серле яңа ярларга якынлаштылар. Бу җирләрнең көнчыгыш тарафларын ауропалыларның ике йөз илле еллар элек ачуын, аларның башта Вест-Индия, аннан соң Америка дип атала башлавын сәяхәтчеләр беләләр иде инде. Белү генә түгел, бу илаһи зур континентны биләүче ниндидер индеецлар дип аталган халык белән очрашу аларны дулкынландыра да, куркыта да иде. Нигә киләләр алар монда? Дус булыпмы, әллә дошманмы? Чириков һәм аның офицерлары моны беләләрдер, ләкин гади солдатка беркем берни аңлатмый шул.

Күпсанлы утраулар арасында беренче җирле кешеләр очрый башлады. Юан агачларны чокып, яисә каен тузыннан эшләнгән җиңелчә көймәләр—каеклардан диңгез камасы, балык һәм башка нәрсәләрне тотып көн күрүче Вест-Индия халкы якынаеп килүче корабларга кызыксыну катыш шомлану белән карыйлар иде.

Диңгезчеләр ярга өч кабельтов калгач, ләнкерләр төшерделәр. Шунда ук шлюпкалар эшкә җигелде, һәм унар-унбишәр кеше утырган өч зур көймә ярга таба юнәлде. Ярга җитәр-җитмәс шлюпкалардан сикерешеп төшеп, хәрби матрослар көймәләрен яр буендагы эре ташларга беркеттеләр. Бу төркемнең бурычы—яр буен һәм якын-тирәне тикшерү, разведкалау иде. Ике солдат ут ягып җибәрде, ә башкалары вак-вак төркемнәргә бүленеп, мушкет һәм башка коралларын әзер тотып, тирә-юньгә таралдылар. Ике-өч сәгатьтән соң алар учак янына кайттылар һәм әйләнә-тирә тыныч, дип белдерделәр.

Чириков бер офицерга, ярдәмчеләр алып, корабларны озаккарак урнаштыру өчен унайлырак урын әзерләргә кушты. Ерак та түгел яраклы бухта да табылды, һәм кораблар шунда күчерелде. Бөтен солдатлар,мәш килеп, кораблардагы әйберне ярга ташый башладылар. Ахырда экипаждан башка бөтенесе ярга күченделәр.

Колония башта куышларда гына яшәде, ләкин күз якынаюга дүрт-биш нык агач өй, лабаз, командор һәм колония хакимиятенең эш урыны, кеше ябар өчен махсус тәрәзәсез өй, кечкенә чиркәү салынды. Алар югары башы очланган, аскы ягы җиргә күмеп эшләнгән бүрәнәләрдән торган биек нык койма белән уратып алындылар. Бу фортка Новоархангельское дигән исем бирелде.

Колониянең шуннан соңгы тормышы өч юнәлештә барды: яңа җирләрне картага төшерү һәм аларны Русия милке дип игълан итү, җирле халык белән ике арадагы мөнәсәбәтләрне җайлау һәм, ниһаять, икътисади эшчәнлек җәелдерү.

Бу эшләрне башкару өчен утыз-кырыгар кешедән торган өч отряд булдырылды. Алардан башка аучы һәм балыкчылардан торган зур бер төркем төзелде. Алар даими рәвештә кыйммәтле диңгез һәм урман хайваннары, затлы балык тоттылар.

Элекке мушкетер Максим Сабуров капитан-лейтенант Паначев җитәкчелегендәге төркемгә эләкте. Алар яр буйлап көньякка хәрәкәт иттеләр, утрау һәм яр буйларын үзләштерделәр, картага төшерделәр, урындагы халыкны читкә куарга тырыштылар. Ләкин шулай да җирле теленкит кавеме белән низагка кермичәрәк эш иттеләр.

Әкренләп колониядәге тормыш җайга салынды, җирле теленкитлар меннәрчә ел яшәп тукланып торган урыннарыннан тауларга куыла

башладылар. Дингез бирә торган бөтен байлык алар кулыннан тартып алынып, корабларга төялә торды.

Чириков теленкитләр белән хәйлә һәм мәкергә нигезләнгән сәясәт алып барды. Жирле халыктан, аракыга алыштырып, җәнлек тиресе җыю оештырылды. Ялтыравыклы вак-төяк бәрабәренә куаннарнын башлыклары сатып алына башлады. Аларнын кайсылары үзләре теләп Русиягә буйсынабыз дигән кәгазьгә тамгаларын да бастылар. Әлбәттә, жирле гади халык бу эшләрдән хәбәрдар түгел иде. Ә шулай да бу кәгазьләрдә ин куәтле теленкит ыруы Чилкат куаны юлбашчысынын тамгасы юк иде әле. Бу Чириковны чамасыз борчый, ул төннәрен йокламыйча, әлеге ыруны көчсезләндерү, анын горур башлыгын үзенә буйсындыру планын корды.

Көннәрдән бер көнне, һәркем үз эше белән китеп, фортта сакчылар гына калгач, бер төркем теленкитләр каекларын күтәреп урманнан чыктылар да яр буена жыелдылар. Аннан сон тыныч кына сөйләнә-сөйләнә көймәләренә утырдылар һәм элек үзләре дингез камасы аулый торган урынга юнәлделәр. Яр буендарак йөргән бер урыс балыкчысы моны Чириковка житкерде. Командор офицерларга тиз генә якын-тирәдәге кешеләрне жыярга кушты. Озакламый мушкетерлар һәм сакчылардан торган илле-алтмыш кешелек отряд әзер булды. Алар көймәләргә төялделәр дә, коралларын әзер тотып, индеецларны эзләп киттеләр. Озак та үтмәде, ерактан, томан эченнән атышкан, кычкырышкан, боерыклар биргән тавышлар ишетелде. Ә тагын бераздан жирле аучыларга һөжүм иткән сугышчылар канәгать кыяфәт белән базага кайтып керделәр. Теленкитләр исә ярга чыкмады.

Мәргән ул көнне аягы авырту сәбәпле фортта калган иде. Аны факториянен көньяк почмагындагы манарасыман урынга сакка куйдылар. Шуна күрә дингездәге фажига анын күз алдында булып үтте. Әмма бу аны таң калдырмады: ничә ел патша хезмәтендә булып, мондый хәлне еш күрә иде. Нерчинскида да, Охотскида да, Камчаткада да урыслар шул ук бер сәясәтне алып бардылар: кеше жиренә сорамыйча килеп урнашу, аны патша жире дип белдерү, жирле халыкны үз ягына аудару, буйсындыру. Барып чыкмаса, кырып бетерү. Бу эшләргә Мәргән үзе шаһит булды, ирексездән үзе дә катнашты. "Боларны эшләргә кем безгә хокук биргән?"—дигән сорау анын анында күптән инде ныклап урын алган иде.

Ике көн үткәч, иртәнге аштан сон, Мәргәннәрнен төркеме колониянен эчке ягына тезелде. Ә койманын тышкы ягында калган солдатлар һәм аучылар урын алган иде. Фортта тиздән жирле халык һөжүм итә икән, дигән имеш-мимеш таралды. Ләкин бу хәбәр өлешчә генә дөрес булып чыкты: теленкитләр килделәр, ләкин...

Башта зур-зур берничә төркем колонияне чолгап алды. Бу хәл күпне күргән солдатларга да хафа салды, ләкин алар шундук тынычлана төштеләр: фортнын капкасына таба зур төркем теленкитләр сагы астында Чилкат куаны юлбашчысы килә иде. Төрле төстәге каурыйлар белән киемен бизәгән урта яшьләрдәге кеше иде бу.

Шул вакытта форт эчендә дә хәрәкәт сизелде: Чилкат юлбашчысына каршы капкага таба Чириков атлый, ә аны биш-алты офицер һәм дистә ярым кораллы мушкетер озата килә иде. Ике процессия капка янындагы мәйданчыкта очраштылар да тукталып калдылар. Беренче булып Чириков телгә килде:

—Бәлки, Бөек юлбашчы кунак өенә узар?—дип сорады ул ярым мыскыллы тавыш белән. Юлбашчыга озын төрөбкә тоттырдылар, һәм ул тыныч кына төтен суыра башлады. Чириков та тәмәке кабызды.

—Командор!—диде, ниһаять тегесе.—Минем халкымнан яшерен сүзләрем юк, монда гына сөйләшик.—Аннан сон тыныч, ләкин нык тавыш белән

дәвам итте.—Әйт! Ни өчен сез безнең утыз кешене юк иттегез? Балаларын ятим калдырдыгыз?

Чириков бу сорауны көтә иде булса кирәк, тынычлыгын һич тә җуймыйча җавап бирде:

—Бөек юлбашчы! Без бу турыда ишеттек һәм шул ук көнне тикшерү үткәрдек. Сезнең кешеләрегезне ситкәлеләр кырган. Алар бит сезнең ыругдашларыгыз, ләкин һәрдаим сезгә яманлыклар эшләп торалар. Ни өченме? Безнең белән дус булганыгыз өчен.

Утраулылар белән зур җирдәге теленкитләр электән үк тату яшәмәгәч юлбашчы икеләнә башлады, бу хәбәргә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Ә командор мыскыллы елмаеп, аңа карап тора бирде.

Озак кына дәшми торгач, юлбашчы болай диде:

—Соңгы вакытта безнең аралар бозылды. Бу турыда, командор, бергә сөйләшәсе бар әле. Аннан, ситкәлеләр турында нинди дәлилләрегез бар?

—Бар, бар!—диде Чириков кулын селтәп, һәм шундук бер төркем дингезче алар алдына килеп басты.—Менә! Сорагыз алардан,—диде командор.

Юлбашчы бераз дәшми торды да, кинәт борылып, капкага таба атлады. Җирле халык, коралларын әзер тоткан килеш, зур саклык белән аның артыннан китте.

Чириковның мәкерлелеге, кабәхәтлеге күпне күргән Мәргәнне дә таң калдырды.

“Инде хәзер,—дип уйлады солдат,—ике тугандаш кавем арасында канкоеш башланачак. Алар бер-берсен кырачаклар. Ә Чириков кебекләргә шул гына кирәк тә инде. Ни өчен эшләнә бу? Океанга кадәр никадәр җир сугышып алынды, күпме төрле халыклар юк ителде. Һаман да аз. Инде Америка җиренә килеп тыгылдык. Нигә кирәк урыска шул кадәр җир, су, кеше мөлкәте? Бер заман тамагына таш булып утырмасмы аның? Саклый ала алырмы ул яулап алган җирләрен? Бөтен байлыгы, көче, халкының гомере шуңа гына китеп тормасмы?

Кичкә таба каравылдан бушаган Мәргән яр буена төште. Бераздан аның янына ике креол килеп утырды. Икесе дә Алеут утрауларыннан бәхет эзләп килгән кешеләр иде болар. Аталары урыс булганга, икесе дә урыс телен беләләр иде. Утыра торгач, әле генә булып үткән хәлләр турында сүз чыкты. Креолларга ышанган Мәргән үзен газаплаган уйлар белән бүлеште, Чириков һәм аның ярдәмчеләренең сәясәтен хурлады. Балыкчы теленкитләрнең кем кулыннан һәлак булуын да сөйләде.

Күпмедер сөйләшкәч, тегеләрнең берсе каекка утырып көньякка китте, икенчесе фортка ашыкты. Ә Мәргән әле яр буенда озак утырды. Аның уйлары, меңнәрчә чакрымны үтеп, туган җиренә, яшьлегенә кайттылар, кардәшләре, дус-ишләре, ата-анасы янында йөрделәр. Нихәлдәләр икән мескенкәйләр, яшиләр микән әле якты дөньяда?

Мәргән гадәтенчә акрын гына җырлап җибәрде. Һәрвакыт—дозорда, каравылда торган чакта да, авыз эченнән генә, моңлы татар көйләрен җырлый торган булды ул, шулардан үзе өчен күңел тынычлыгы, сабырлык, рухи көч ала килде.

Үзенең сөйгән яры Нәстүген—Нәсимәсен дә искә төшерде ул. Ике яшь йөрәк, бер-берсен өзелеп сөеп, күзгә туйлар ясарга да вәгъдә итешкәннәр, инде ата-аналары да каршы килмиләр иде. Ләкин язмыш аларның бәхетенә киртә куйды: Нәсимәгә авыл бае, урыслар алдында куштанланып үзе чукынган Питрәй улы Микулайның күзе төште. Нәсимә аны яратмый гына түгел, җирәнә һәм чиркана иде. Аңа хатын булу түгел, хәтта үләргә дә әзер иде.

Башта Питрәй Мәргәннең һәм аның атасының өстенә яла ягып, аларны хөкем иттерергә тырышты. Ул аларны мөселманлыкта, чиркәүгә күз буяу

өчен генә йөрүдә гаепләде. Ләкин бу барып чыкмады. Әмма шул чакта авылга рекрутлар җибәрү йөкләмәсе килеп төште, һәм Питрәй, акча төртепме әллә башкачамы, Мәргәнне гомерлеккә хәрби хезмәткә озаттырды.

Саубуллашу киче җиткәч, егет белән кыз су буендагы карама төбендә очраштылар. Нәсимә үзенең өметсез киләчәге өчен елады, бәгыре телгәләнгән егет аны юатырга тырышты, сабыр итүен үтенде. Алар кызның әнисе эзләп килгәч кенә аерылыштылар...

Фортка кайтканда караңгы төшеп килә иде инде. Казармага килеп керү белән үк, аның артыннан, ишекне каерып ачып, өч кеше—фендрик Баранов һәм ана ияреп ике солдат килеп керде. "Сабуров! Сине Их Превосходство командорга чакыралар, тиз генә бул!"—дип рәсми телдә җикеренде фендрик, һәм аның ярдәмчеләре Мәргәнне җилтерәтеп урамга алып чыктылар.

Чириков Мәргәннән үзе сорау ала башлады. Башта ул ана озак кына сөзеп карап торды.

—Үзең әйтеп каласыңмы, әллә терелэй тиреңне туныйкмы?—дип шактый каты бәрелде ул тоткынга.

—Мин берни аңламыйм, Ваше Превосходство!—дип котылмакчы иде Мәргән.

—Ул аңламый, кара син аны ә!—дип җикеренүендә булды командор.—Ә кем креолларга туземецларның үлеме турында сөйләде? Кем серне ачты?

—Мин бары тик дөресен генә сөйләдем!..—дип акланырга тотынды Сабуров.

—Кем кушты сөйләргә? Теге икенче креол Ситкәдәгеләргә яисә мондагы маймылларга җиткерсә, башың бетте! Аннан соң!—дип кычкырынуын дәвам итте түрә.—Син нәрсә сызгалыйсың анда көн саен? Син укымышлымыни? Күрсәт әле язмаларыңны! Бу нинди язулар? Син төрек шпионы мәллә?—дип бәйләнә башлады, Мәргәннең гарәп хәрефле көндәлеген күргәч.—Димәк син безнең көн саен нәрсәләр эшләвебез турында яза барасың һәм оттоманнар өчен белдермә әзерлисең?!

Үз өстенә шундый куркынычлы яла яксалар да егет дәфтәрдәге язуларның нәрсә икәнен, үзенең һәм ата-аналарының кем булуын белдермәскә булды, дәшмәде.

—Яхшы!—диде Чириков янаулы тавыш белән.—Иртәгә, яктыргач, телен чишелер. Алып китегез!—дип боерды солдатларга, Мәргәннең дәфтәрен өстәл астына яшерә-яшерә.

Төнне Мәргән тоткыннарны ябу өчен махсус эшләнгән тәрәзәсез өйдә үткәрде. Башка вакытта бу зиндан төрле сәбәпләр аркасында ябылган теленкитләр белән тула торган булса да бүген буш иде. Егетнең күзенә йокы кермәде, чөнки язмышы, киләчәге шомлы томан эчендә иде кебек. Ниләр булыр, ничек котылыр ул нахак бәладән? Хәер, иблис кенә өметсез, дигәннәр бит, Аллаһе Тәгалә үзе карар, ул ничек кушкан, шулай булыр. Амин...

Иртәнгә таба, ял итүче солдатлар гына түгел, сакта торучылар да йокымсыраган чакта, тышта ниндидер тавышлар, атыш ишетелде. Урман ягында җирле халык чинап кычкыра, форт эчендә хәрбиләр акырыша башлады. Борынга янгын, төтен исе килеп бәрелде. Мәргән бүрәнә ерыгыннан тышны күзәтә башлады. Теленкитләр фортны чолгап алып, ерактан гына утлы уклар белән атып фортның коймаларын, эчтәге корылмаларын яндыралар, ә солдатлар аларга мушкетлардан, туплардан аталар.

Күп тә үтмәде, бөтен фортны янгын чорнап алды. Кальгәнең коймасы кайсыбер урында җимерелеп төште. Җирле халык форт эчендәге кешеләрне иркенләп кыра башлады. Утлы һәм утсыз уклар туктаусыз сызгырды. Солдатлар тегеләрнең күплеген, үзләренең җиңелә баруларын сизеп, океан ярына таба тартыла башладылар. Ләкин анда да котыла алмадылар, исән калганнарына бирелергә туры килде.

Шулвакыт бер төркем теленкитләр форт эчендәге ачыграк урынга Чириковны һәм аның исән калган офицерларын чыгардылар. Күптән түгел генә кикриге шиңгән әтәчтәй кайтып киткән юлбашчы, җиңүче кыяфәтендә командордан сорау ала башлады. Хәер, ул моны гаҗәп йомшак, ачусыз тавыш белән башкара иде.

—Командор!—дип башлады ул.—Син үзеңнең мәкерле һәм кабахәт эш иткәнлегеңне, безне кан кардәшләребез белән сугыштырырга теләгәнеңне таныйсыңмы?—Чириков дәшмәде.—Әйт әле!—дип сүзен дәвам итте тегесе.—Нигә килдегез сез монда? Без бит сезне дусларча кабул иттек, ә сез кан кою белән җавап бирдегез. Сезгә монда ни кирәк?

—Бу җирләр безнеке!—дип җавап бирде Чириков тәкәббер тавыш белән.—Рус кешесе аяк баскан бөтен җир Русиянеке. Бу элек тә шулай булды, киләчәктә дә үзгәрмәячәк.

—Чит ил җирләре, мөлкәте, байлыгы сезнең өчен кеше гомереннән югарыракмыни?—дип сорады юлбашчы.—Моның өчен сез үз халкыгызны да кызганмыйсызмыни?

—Халык?—дип елмайды Чириков масаюлы кыяфәт белән.—Халык тузан гына ул. Ул югары катлауның иминлеген, байлыгын тәэмин итү өчен генә кирәк. Бездә хатын-кыз күп, солдатлар кырыла, яңалары туа тора. Аннан соң, әгәр сугышта күп ганимәт алына икән, халыкның исән калган өлеше мохтаҗлыксыз яшәячәк.

—Сез бөтен халкыгызны эшләмичә, басып, сугышып алынган ганимәт исәбенә генә яшәргә өйрәттегезмени?—дип сорады исе киткән юлбашчы.

—Моның нәрсәсе начар?—дип куйды тегесе горур тавыш белән.—Әйдә безнең өчен басып алынган халыклар тир түксен.

—Әфәнде!—диде юлбашчы кырыс тавыш белән.—Сез рәхимсез кешеләр, өстәвенә кәпрәючән.—Һәм ул дәшмичә озак кына Чириковка карап уйланып алды, аннан соң сорау бирде:—Ә кайда синең безгә ярдәм иткән намуслы солдатың?

—Ә-ә-ә! Теге басурманны, төрек шымчысын әйтәсеңме? Ул юк инде!—дип көлде Чириков.—Ул юк...

Ләкин шул ук мизгелдә Мәргән ябылып яткан корылманың түбәсе ябып җимерелә башлады, һәм аннан кычкырган тавыш килде. Кабилә башлыгының ымлавы буенча берничә индеец шул якка йөгерделәр һәм сугыш балталары белән ишекне ватып, Мәргәнне азат иттеләр.

—Шулмы?—дип сорады башлык тылмач булып хезмәт итүче креолдан. Тегесе баш какты.

—Ах син хайван! Төрек танавы!—дип җикеренде Чириков, төкереген чәчеп.—Сине дар агачы көтә! Бөтен ыруың тамыры белән йолкынып юк ителәчәк...

—Командор!—диде кабилә башлыгы тыныч кына тавыш белән.—Без теленкитләр сезнең кебек сугыш яратучан халык түгелбез. Әмма сез безне кан коярга мәҗбүр иттегез. Шулай да мин сезне азат итәм. Корабларыгызга төялегез дә кайтып китегез, башка монда килеп күренмәгез! Тик башта безнең җирне талап җыйган малны ярга чыгарып куегыз!

Шуннан соң ул Мәргәнгә борылды:

—Ә син, мәрхәмәтле кеше, нинди карарга киләсең? Минем аңлавымча, иленә кайтырга ярамый. Монда каласың икән, сине берсе дә кыерсытмас, киресенчә, хөрмәтле кеше булырсың.

Мәргән бу сүзләргә тиз генә җавап бирә алмады. Чириков белән бер корабта бару—мөмкин булмаган гамәл икәне көн кебек ачык иде. Таш өстендә утырып, солдатларның кораблардан җәнлек тиреләре бушатуын, Чириковның азат ителүен һәм иптәшләренең җилкәннәр күтәреп кузгалып китүен күзәтте.

Әле кораблар кузгалып киткәч тә торып китә алмады. Әлбәттә, анын уйлары күнелсез, киләчәге өметсез иде. Нәрсә көтә аны монда? Хөрмәтле кеше булырсын, дип әйттеләр әйтүен, ләкин адәм баласына ул гына житми бит. Туган ил кирәк ана, ата-анасы, туганнары, яшьлек дуслары, сөйгән яры, ниһаять.

Мәргәнгә карата жирле халык чыннан да яхшы, дусларча мөнәсәбәттә булды. Анын бөтен эше дингез яры буенда йөрү һәм Чириковнын яныл өлгермәгән өеннән алып чыккан көндәлекне тутыру иде.

Бер-ике атна яр буенда таптангач, Мәргән ныклы бер карарга килде: ул ирекле кеше һәм туган ягына кайтырга тиеш. Зур һәм нык кына көймәгә утырып чыкса, Алеут архипелагы буйлап утрадан утрауга күчә-күчә, Командор утравына барып житәр төсле иде ул. Бу турыда ул таныш креолдан сорашты. Ә аннан Камчаткага да ерак калмый. Дингездә йөрү тәртибен белмәгән кешегә дүрт-биш мен миль араны үтүнен никадәр хәвефле икәнен анласа да үзе өчен бүтән чара күрмәде.

Көймәне теленкитләр башлыгыннан сорарга булды. Тегесе, бу уеннан кире кайтару өчен Мәргәнне озак кына үгетләгәннән сон көймә бирергә булды. Ул гына да түгел, Мәргәнгә ярдәмгә үзенен тәржемәче креолын да бирде, һәм бу хәл егетне бик нык сөендерде.

—Мин ана болай гына океанга чыгарга кинәш итмәс идем, әмма ул шундый карарга килгән икән, бар, Кадьякка чаклы озатып куй. Анда минем танышым кабилә башлыгы булып тора, ул сина кире кайтырга ярдәм итәр,—диде юлбашчы креолга.

Азык-төлек, су һәм башка кирәк-ярак нәрсәләр төялгән зур гына көймә (урыслар аларны "коч" дип атыйлар), дингез дулкыннарында чайкала-чайкала, көнбатыш тарафына юл алды. Ишкәкләр өскә алып куелган, чөнки яна кузгалган жил, тиз генә әмәлләп алынган жилкәнне күпертеп көймәне алга куа.

Мәргән белән Уан (креолнын исеме шулай иде) дуслашып та киттеләр. Бер-берсенә үзләренен үткән гомерләре турында сөйләделәр. "Мин үзем Кыскадан, Алеут утрауларынын көнбатышынннан,—дип анлатты Уан.—Әтием урыс булган. Ул Камчаткадан бирегә штормга эләгеп килеп чыккан. Әнием алеут кызы. Әтием жирле халык белән ызгыш вакытында һәлак булган. Әнием мине алып, континентка күчкән, ә теленкитләр башлыгы аны үзенә хатынлыкка алган. Урыс телен әнием өйрәтте, чөнки ул әтиемне бик яраткан."

—Синен туган утравын Кадьяктан еракмы, анда кайтырга уйламыйсынмы?—дип сорады Мәргән.

—Мин аннан бала чагымда ук киткәнмен, ул утрау мине тартмый,—дип кулын селтәде креол.

—Син теленкит юлбашчысы углы булгач, киләчәктә анын урынына кала аласындыр?—дип сорады Мәргән.

—Анын үз балалары бар, мин ана үги,—диде Уан.—Аннан сон, минем максат—Европаны күрү, шунда яшәү...

Өч-дүрт тәүлек үтеп, көн яктыруга Уан борчулы кыяфәт белән алга таба карап тора башлады.

—Ни бар, Уан?—дип сорады Мәргән.

—Күрәсенме офыктагы кара болытны?

—Һ—у—у—у! Әле ана кадәр ерак бит,—дип кулын селтәде тегесе.

—Алай түгел!—диде креол.—Ике сәгать тә үтмәс, шторм башланыр.

Уаннын хафалануы, әлбәттә, дөрескә чыкты: көн уртасы якынаюга океанда коточкыч шторм котыра иде инде. Бертуктаусыз янгыр коя, кап-кара болытларны яшен телгәли, кая карама тау-тау дулкыннар. Көймә әле биек дулкын сыртына эләгеп күккә чөелә, әле тирән упкынга төшеп киткән кебек дулкыннар арасына чума.

—Менә сиңа Тын океан!—дип кычкырды Мәргән иптәшенә.

Ике диңгезче бертуктаусыз көймәдәге суны түгәләр. Җилкән инде күптән теткәләнеп беткән, ишкәкләр һәм көймәдәге әйберләр юкка чыкканнар.

Ике мескен йә хәлдән таеп көймә төбенә капланалар, йә бераз хәл җыйгач, чиләкләр белән су түгәләр. Вакытның исәбе югалды. Көн белән төн кушылгандай булды.

—Кая таба алып бара безне океан?—дип сорады Мәргән иптәшеннән кычкырып.

—Тәгаен генә әйтүе кыен, алай да без хәрәкәт иткән якта һава яктырак кебек. Көньякка океан уртасына этәрә бугай безне давыл.

Океанның котырынуы дәвам итте. Көймәне туктаусыз дулкыннар каплый торды.

Су түгү ифрат күп көч таләп итә иде. Инде ничәнче көн стихия белән көрәшүче ике мескинәкнең көчләре бетә башлады. Алар бит авызларына валчык та капмый эшләделәр, чөнки азыкларын су алып китте. Бу коточкыч давыл тагын бер-ике сәгать кенә дәвам итсә дә, көймәгә су тулып, алар океан төбенә китәчәкләр.

—Уан! Бу мәхшәр ничә көн бара инде?

—Белмим Мәргән, биш-алты көндер инде.

—Гадәттә ул күпмегә сузыла?

—Атна-ун көн,—дип җавап бирде Уан сәер һәм тыныч тавыш белән.

—Бетәбезмени алайса?—дигән сорауга креол җавап бирмәде, нишдидер бөтен нәрсәгә карата битарафлык белдергән күзләре йомылды. Иптәше өстенә иелгән Мәргән дә онытыла баруын сизде. Аның үлем турында уйларлык һәм якты дөнья белән хушлашырлык та хәле калмаган иде. Ниһаять, ул да аңын җуйды.

Мәргән аңына килгәндә, алар икесе дә яр буендагы җылы ком өстендә яталар иде. Күктә якты кояш балкый, ә тирә-якта давыл ярга чыгарып ташлаган нәрсәләр аунап ята. Ниләр генә юк анда: тамыры белән йолкынган агачлар, мичкәләр, көймә калдыклары, тагын әллә ниләр.

Бераз исенә килгәч, Мәргән иптәшенә дәште:

—Әй, Уан, син тересеңме?

—Тере, Мәргән, тере.

—Без монда ничек килеп чыктык икән ә, Уан?

—Ходай Тәгалә чыгарган, башка кем булсын. Җирдә ризыгыбыз да, эшебез дә бетмәгән әле, димәк.

—Без кай җирдәбез икән?—дип сорады Мәргән,—диңгез ярындамы, әллә утраудамы? Кешеләрдән сорарга кирәк...

Ул арада яр буйлап килүче кешеләр күренде. Болар җирле халык иде ахрысы, әмма киемнәре, үзләрен тотулары һәм телләре ят, теленкитләрнекенә охшамаган иде. Алай да аларның берсе теленкит телен азрак белә булып чыкты. Уан аның белән озак кына сөйләшеп тә алды.

—Беләсеңме, без кайда?—дип сорады ул ахырда Мәргәнгә борылып.

—Кайда?

—Безне давыл ике мең миль көньякка, Өрегән җиренә китереп ташлаган.

—Тукта, тукта!—диде Мәргән.—Бу нәрсә, утраумы әллә ?..

—Юк, юк! Бу шул ук Америго җире.

—Америкадыр!

—Әйе, алай дип тә әйтәләр.

Ул арада индеецлар, кунакларның хәлен аңлап, ашап алырга тәкъдим иттеләр. Ризык какланган балык, казылык һәм икмәктән тора иде. Мәргән ачы камырдан пешерелгән ак, ләкин бик каты икмәкнең нинди ашлыктан икәнен сорады.

—Маистан һәм арпадан,—дип аңлатты ана Уан, тегеләр белән сөйләшеп алгач. Алар ашлыкны үзләре үстермиләр икән. Тау артындагы тигезлектә яшәүче шешеннәрдән балыкка алыштырып алалар.

—Ничек атала инде бу ризык?—дип сорады Мәргән.

—Әпи.

—Әпи? Бу бик кызык! Ә нинди тәмле!

Кинәттән ашап хәлләре беткән сәяхәтчеләр тагын комга сузылдылар. Мәргән шул тирәдә йөргән һиндеецларны күзәтеп ятты. Төсләре теленкитләрнекенә охшамаган иде боларның. Тегеләре Мәргән Якутскида яки Камчаткада күргән җирле халыкларга охшаган булсалар, болары үзгәрәк иде. Буйга да биегрәкләр, гәүдәләре дә төзрәк, йөзләре дә табак битле түгел, борын төпләре дә калку иде.

—Ничек, Уан! Телләре теленкитләрнекеннән нык аерыламы боларның?—дип сорады Мәргән җирле халык белән әңгәмә корып утырган иптәшеннән.

—Бу бөтенләй үзгә тел,—дип җавап бирде тегесе,—бу кавем пенути исемле икән. Ә пенутиләр үзләре берничә төрлегә бүленә. Болары үзләрен җимшәннәр дип атыйлар.

Җимшәннәр кунакларны авылларына алып киттеләр. Тауларга таба байтак вакыт атлагач, урман эчендә биек утыртма койма белән уратып алынган алачыклар күренде. Авыл утыз-кырык кечкенә өйчекләрдән тора, ләкин арада зурраклары да бар. Өйләрнең кайсылары дүрт почмаклы һәм озынча булса, кайсыберләре түгәрәк иде. Моржалары күренми, түтен өй түбәсендәге тишектән чыга. Кайсыбер алачыкларның ишеге дә түбәдә урнашкан.

Кунакларны кабиләнең башлыгы кабул итте. Өстенә каурыйлар белән бизәлгән киемнәрен кигәнче көтеп торырга туры килде. Озын төребкәсен тарта-тарта тәрҗемәчене тыңлый, ә күзләре килгән кешеләрне сынап карый.

—Нинди илдән килдек дип әйтә әле ул?—дип сорады башлык тылмачтан.

—Русиядән,—дип җавап бирде Уан.

—Русия? Ишеткәнем юк. Зур илме ул, көчлеме?

—Бик зур һәм бик көчле!—дип җавап бирде Мәргән.

—Испаниядән көчлерәкме?

—Көчлерәк булыр,—дип баш какты кунак.

—У-у-у! Димәк бу яктан Испания һәм Британия килә, арттан франклар, ә олы диңгездән Русия,—диде башлык уйланып алгач.—Ярый, инде сез нишләргә уйлыйсыз? ...Яхшы!—дип дәвам итте ул сүзен, кунаклардан аңлаешлы җавап ала алмагач.—Әлегә бездә яшәгез, аннан соң...

Мәргән белән Уанны бер буш алачыкта урнаштырдылар. Очлы түбәле бу түгәрәк куышсыман нәрсә "типи" дип атала иде. Арган һәм чиктән тыш йончыган сәяхәтчеләр шундук йокыга талдылар. Иртән алар үзләре өчен калдырылган ризыкны ашадылар да яр буена төшәргә булдылар, чөнки аулакта үзләренең язмышы һәм киләчәге турында уйлашырга, киңәшергә кирәк иде.

Ләкин көтелмәгән вакыйгалар әле дәвам итә булып чыкты: су буена килеп җитмәс борын ук, Уан диңгез ягына карап кычкырып җибәрде, чөнки нәкъ шушы турыга зур гына бер кораб якынлашып килә иде. Ул башта ярдан искән җилгә каршы уң галс белән барды, аннан соң сул галска күчте. Коры җиргә җитәргә биш-алты кабельтов калгач, туктады һәм ләнкер төшерде.

—Бу галера түгел,—дие Уан,—мин испан корабларын яхшы беләм. Алар Кадьякка кадәр килеп чыккалыйлар. Ә мондыйларны беренчеләй күрәм. Кара әле, Мәргән, үзләрен ничек тыныч һәм ваемсыз тоталар болар.

Озакламый кешеләр төялгән ике шлюпка корабтан ярга таба юнәлде. Көймәдәгеләрнең икесендә генә мушкет, калганнарында ишкәк иде.

—Алай да безгә саграк булырга кирәк,—диде Мәргән,—кем белгән аларның ниятен. Әйдә куаклар арасына, аннан да күренә бит.

Башта җирле халык корабтагылардан шүрли төште бугай: озак кына диңгез ярында беркем күренмәде. Ләкин бераз вакыт үткәч ыгы-зыгы башланды, башта бала-чага, аннан соң авыл халкы да яр буена төштеләр.

Килүчеләр көймәләрдән төрле нәрсә бушатып, кире корабка таба ашыктылар, ә бирелә калганнары тауарны яр буена тезә башладылар. Уан белән Мәргән, куаклар арасыннан чыгып, корабтан бушатылган әйберләрне карарга керештеләр. Ниләр генә юк иде монда: кием-салым, савыт-саба, төрле корал, җиләк-җимеш һәм ашамлыклар, исерткеч эчемлекләр, тоз...

Мәргән агач әрҗәләргә салынган яшелчәсыман нәрсә янында тукталды. Озынча яки йомры, кызгылт төстәге бүлбеләрне ул беренче тапкыр күрә иде.

—Моны Кадьякка көньяктан испаннар китереп сата торганнар иде,—диде Уан. Шуннан соң ул таныш тылмачны очратып сөйләшеп алды.—Бу урында үстермиләр икән, көньяктарак шешеннәр утырта, ләкин вак була. Аны "пәтәйтә" дип атыйлар икән.

Шунда гына басып торган сатучы боларның ни турыда сөйләшүен аңлап, пычак белән әлеге бүлбене кисеп алды да Мәргәнгә тоттырды. "Потато!"—диде ул шуннан соң һәм баш бармагын югары күтәрде. Мәргән сусыл саргылт кисәкне авызына капты, ләкин шунда ук кире төкерде. Сатучы кычкырып көлеп җибәрде.

—Аны пешереп ашыйлар бит,—дип аңлатты Уан көлә-көлә һәм тагын тылмач белән сөйләшеп алды. Ә сатучы әлеге ризыкның пешкәнен китереп чыгарды һәм Мәргәнгә тоттырды. Бу ят ярмалы ризык бик тәмле тоелды егеткә.

—Сезнең якта юкмыни соң мондый ризык?—дип сорады аңардан Уан. Тегесе башын чайкагач, дәвам итте:—Моны Европада да бик яратып бетермиләр икән. Алманнар хәтта шайтан җимеше "картойфель" дип атаганнар...

Ул арада кинәттән зураеп киткән бу базарда сату-алу, алмаштыру кыза барды. Җирле халык төрле яклардан урман һәм су җәнлеге тиреләре, какланган балык һәм башка тауар ташыды. Кайсыберләре зур-зур торсыкларга салып, чишмәләрдән су китерделәр, ә диңгезчеләр аны, мичкәләргә тутырып, корабка ташый бардылар.

Ауропалыларны барыннан да бигрәк алтын кызыксындыра иде. Ә якынтирәдә ул юк икән. Шуңа күрә таулардан килгән һиндеецларга алар аеруча игътибарлы булдылар. Җирле халыкның хыялы булган утлы коралны алар бары тик алтынга гына алмаштыралар иде.

Шулвакыт Мәргән кемнеңдер үзенә текәлеп карап торуын сизде. Тирәякка күз төшергәч, әлеге "пәтәйтә" сатып торган кешенең ниндидер хәрбигә (офицерга булса кирәк) Мәргәнгә карый-карый нидер сөйләвен күрде. Аларны, әлбәттә, Русия солдаты киеме гаҗәпкә калдырган иде булса кирәк. Мәргән теткәләнеп беткән мундирын күптән салып атмаганына да үкенеп куйды. Ә офицер бер солдатны ияртте дә аңа таба атлады. Мәргән башта качарга уйлаган иде дә ләкин бу уеннан кире кайтты. Теге аңа ниндидер телдә сорау бирде, ләкин җавап ала алмады. Шуннан соң ул Мәргәнне көймәләр янына алып китте. Шлюпкаларга тауар төяүчеләр янындагы өчдүрт офицер да аңарга кызыксынып карадылар, берничә телдә сораулар бирделәр. Мәргән күкрәгенә сукты да "Русия, рус"!—дип, кай яктан икәнен аңлатты. "Русия, рашен!"—диештеләр тегеләр исләре китеп. Өлкәнрәк офицер бер матросны тиз генә корабка җибәрде.

Ул арада базар бөтенләй кызган иде инде. Шул тирәдәрәк йөргән Мәргәнне тагын офицерлар янына чакырдылар. Әле генә корабтан килеп җиткән теге матрос та шунда иде инде. Өлкән офицер Мәргәнгә көймәгә утырырга кушты һәм аны корабка алып китте.

Корабка якынайгач, анын зурлыгына шаккатты Мәргән. Чириковнын унбиш-унсигез туплы корабы монардан күпкә калыша иде. "Алтмыш-житмешләп туп бар монда",—дип уйлады егет, тиз генә күз йөгертеп чыккач. Офицер да анын соклангыч күз карашын сизде ахры: "Фрегат!"—диде ул горур тавыш белән һәм баш бармагын өскә тырпайтты.

Мәргәнне каюткомпаниягә алып керделәр. Анда аларны ике кеше каршы алды. Берсе, яшьрәге, яхшы гына аңлаешлы урыс телендә сөйләшә булып чыкты.

—Капитан Роулингз,—диде ул олырак күршесенә күрсәтеп.—Ә мин кораб хуҗасы лорд Кеннингхэм. Сезне Русиядән, дип әйттеләр, бу чыннан да шулаймы?

—Нәкъ шулай, сэр!—дип, "сэр" сүзен ычкындырганын сизми дә калды Мәргән. Моны ул күпне күргән солдат һәм офицерлардан ишеткән мәзәкләр буенча белә иде.

—О-о! Сез офицермы?—дип сорады лорд.

—Юк, сэр! Мин солдат, мушкетер,—дип җавап бирде Мәргән.

—Менә ничек! Император армиясендә шундый мәгърифәтле солдатлар да бармыни?

Шуннан соң лорд Мәргәннең ничек бу якларга килеп чыгуы турында сораша башлады. Егет башта башыннан кичкәннәрнең барысын да сөйләп бирергә уйлаган иде дә, ләкин бу уеннан кире кайтты. "Кем белгән аларны?"—дип уйлады ул.

Шулай да күпмесендер дөресен сөйләргә туры килде. "Чириков экспедициясе белән килгән идем, шлюпкамны давыл алып китеп, монда китереп ташлады",—дип аңлатты ул.

Тегеләрне исә Чириков һәм анын командасы турындагы хәбәр бөтенләй шөбһәгә төшерде бугай. Алар озак кына үзара шаулашып алдылар. Ахырда лорд Мәргәнгә борылды да гафу үтенде, аннан соң экспедиция һәм анын эше турында сораша башлады. Теленкитләрнең Чириковны куып җибәргәнен белгәч, шактый куаныштылар. Лорд Аляска тирәсендә урыс кораблары йөрүен ишеткән икән, бәлки Чириков шунда төньякка барып чыккандыр,—диде ул.

Хуҗалар Мәргәнне кофе эчәргә чакырдылар. Ул, әлбәттә, боларның югары катлау кешеләре икәнен аңлый, бу аларның кием-салымнарыннан да, үз-үзләрен тотышларыннан да күренә. Өстәл артына утыргач та, ул ашыкмады, хуҗаларның хәрәкәтләренә, ашау-эчү тәртибенә игътибар итеп утырды, сиздермичә генә яхшы гадәтләрен үзләштерергә тырышты.

Лорд аңа төрле сораулар бирде, Русиядәге тормыш турында сорашты, ә Мәргәннең сүзләрен капитанга тәрҗемә итә барды.

—Минем Русиядә булганым бар,—диде ул ахырда.—Британия короле галиҗәнапләренең Петр патша, дөресрәге император заманындагы илчелегендә хезмәт иткән вакытымда. Ах ул еллар! Үзләре бер калын китапка сыймас иде... Ләкин мине сәясәт туйдырды. Океан-диңгезләр үзенә тартты... Минем үзем кораб бар бит. Әмма монысы—минем горурлыгым!.. Әйтегез әле?—диде ул көтмәгәндә.—Сез бит урыс түгел.

—Әйе, сэр!—дип җавап бирде Мәргән, бераз дәшми торгач.—Сез хаклы: мин татар кешесе. Мөселман. Ләкин безне көчләп чукындырганнар.

—Шулайдыр, дип уйлаган идем дә инде, Санкт-Петербург казематларында күпләр иде алар. Патшага каршы баш күтәргән өчен китереп япканнар, дип сөйлиләр иде. Шуннан соң лорд бу турыда капитанга да сөйләп алды.

—Уау!—диде тегесе Мәргәннең кем икәнен белгәч.—Тартар!

—Тартар түгел, татар!—дип төзәтте аны лорд һәм Мәргәнгә борылып.—Мин Русия тарихын аз гына беләм. Ул Рим империясенекенә охшаган.

—Рум тарихына, сэр?—дип кайтарып сорады Мәргән.

—Рум түгел. Рум дип мөселманнар Византия империясен атыйлар. Ә бу Рим империясе. Рум аның яртысы, соңрак Римнан бүленеп чыккан. Менә шушы римлылар да ике мең еллар элек Русия кебек бик күп илләрне һәм кавемнәрне басып алганнар. Әлбәттә, кол ителгән халыклар Римга каршы туктаусыз баш күтәрә торган булганнар. Римга һәрбер провинцияда күпсанлы легионнар тотарга туры килгән. Ә бушап калган төп Рим җирләрендә акрын-акрын чит илләрдән хәрби әсир итеп китерелгән кешеләр, коллар урнашкан. Алар төп халык белән кушыла барганнар. Икенчедән, провинцияләргә җибәрелгән легионерлар да акрынлап шундагы халыклар арасында эрегәннәр, күп кенә легионнарда җирле халык та хезмәт итә башлаган. Нәтиҗәдә Римда плебейларныкы гына түгел, патрицийларнын да табигате, үзаны үзгәргән. Аларда элекке римлыларга хас сугышчанлык, баскынчылык һәм патриотик хисләр кимегән, беткән, һәм империя җимерелгән. Аны бүтән халыклар басып алганнар.

—Озак яшәгәнме соң ул Рим империясе?—дип сорады Мәргән уйчан тавыш белән.

—Мең елга якын,—дип җавап бирде лорд.

—Ә Русия кайчан барлыкка килгән?

—Балтик буеннан килгән урысларның славян кабиләләрен берләштереп, якын-тирәдә яшәгән төркиләрне басып ала башлаганнан исәпләсәң, җиде йөз-сигез йөз еллап булыр. Ә хәзер үзегезнең тормышыгыз турында сөйләгез, бу безне бик кызыксындыра. Чириков экспедициясенә ничек килеп эләктегез?

Мәргән рекрутлыкка алынган чагыннан башлап, инде яшермичә башыннан үткәннәрне бәян итә башлады. Лорд аның сүзләрен капитанга тәрҗемә итә барды. Ахырда озак кына сүзсез утырдылар. Шуннан соң лорд теленкитләрнең ни белән сату итүләре турында белеште.

—Сары металл юкмы аларда?—дип сорады ул ахырда.

—Алтынмы? Юк дип әйтерлек. Ә менә төньяктарак яшәгән атапаскларда күп, дип сөйлиләр.

—Атапаскларда? Һ—м—м!.. Майкл (Инглизләр Мәргәннең исемен шулай үзгәрткәннәр иде)! Бу җирдәге төп халыкның хәле сезнең язмышыгызны хәтерләтә түгелме соң?

—Әлбәттә, сэр! Ничек кенә хәтерләтә әле,—дип җавап бирде Мәргән.

—Без Кеннингхэм әфәнде белән чит җирләрне, иркле халыкларны басып алуны хупламыйбыз,—диде капитан. Монда да күрәсез, сату итәргә генә килдек. Ә безнең туплар пиратлардан саклану өчен генә.

—Әйе, әйе!—дип, аның сүзләрен җөпләде лорд.—Инде иркенләп сату итәр урыннар да калмый башлады. Көньякта испанлылар майия, астык, йота һәм шешеннәрне кырып бетерә яздылар, ә исән калганнарын кол иттеләр. Көнчыгышта французлар чикәсәүләрне,ерикләрне кырып яталар, безнекеләр Атлантик океан ярындагы һиндлеләр җирендә инде унөч колония төзеделәр. Ул гына да түгел, тиздән бу тирәдә дә кызу көннәр башланачак бит: Британия королевасы флоты әле раштуага чаклы ук бу җирләрне империягә кушарга тиеш.

—Бу турыда җирле халыкка хәбәр итәргә ярыймы?—дип сорады Мәргән.

—Әлбәттә. Бу инде сер түгел. Икенчедән, бирердәге халык сугышчан түгел, житмәсә аз санлы. Туп һәм мушкетларга каршы алар нәрсә куя ала?

—Майкл!—диде ул бераз сүзсез утыргач.—Бәхәсләшә алам, сез Чириков экспедициясеннән юкка гына төшеп калмагансыздыр.

Мәргәннең бу ачык йөзле һәм үзенә карата күпмедер игелек күрсәтергә омтылган кешеләргә ялганлыйсы килмәде һәм Новоархангельскоеда булып үткән вакыйгалар турында энәсеннән-җебенә кадәр сөйләп бирде.

Лорд белән капитан рәхмәт йөзеннән аның кулын алып кыстылар.

—Сез намуслы кеше, Майкл!—диде лорд дулкынланган тавыш белән. Әйтегез, сезнең өчен без нинди яхшылык эшли алабыз?

—Минем туган җиремә кайтасым килә, сэр!—диде Мәргән өмет чаткылары янган күзләрен инглизләргә төбәп.

—Анда үзегезне нәрсә көткәнен аңлыйсызмы?

—Аңлыйм.

—Аңлыйсыз, ә шулай да кайтырга ашкынасыз! Әйтегез әле, Майкл! Бу сыйфат татарларга гына хасмы, әллә Русиянең башка халыкларына дамы?

—Нинди сыйфат, сэр?

—Туган җирне сөю. Үлем куркынычы астында да шунда кайтырга омтылу.

Мәргән дәшмәде.

—Ярый! Инде сезнең үтенечегез турында. Кызганычка каршы, без әле берничек тә Русиягә таба бара алмыйбыз. Европага да тиз генә кайтмабыз. Җитмәсә, без барасы җирләрдә урыс хәрби флоты булуы мөмкин... Менә нәрсә. Минем сезгә шулай да бер бүләк тапшырасым килә,—дип, инглизле Мәргәнгә зиннәтләп эшләнгән кечкенә мушкет тоттырды.—Пистолет!—диде ул елмаеп.

Мәргән ярга чыкканда караңгы төшкән иде инде. Яр буенда бер генә кеше—аны көтеп утыручы Уан гына күренде.

—Мин сине күрүемнән өмет өзә язган идем инде,—диде ул, иптәшенең котылуына сөенеп. Тегесе корабта булган хәлләр турында кыскача гына сөйләп бирде.

Ике дус иртән торып яр буена чыгуга, корабтан җилләр искән, ә кичә шаулап торган базарлы яр буенда чүп-чар арасында бала-чага гына казынып йөри иде.

—Уан!—диде Мәргән иптәшенә.—Безнең теге таныш тылмач кайда икән?

—Нигә ул сиңа?

—Кабилә башлыгын кисәтеп куярга кирәк. Озакламый бирегә Британия хәрби флоты киләчәк, дип әйттем бит кичә. Әле кыш җитмәс борын ук пенутиларның җирләре басып алынып, Британия колониясенә әйләндерелергә тиеш икән.

Тылмачны тапкач, алар Кара Болыт янына юнәлделәр. Кабилә башлыгының башка алачыклардан зурлыгы һәм чагыштырмача зиннәтлелеге белән аерылып торган өенә тиз генә кертмәделәр. Болар килеп кергәндә Кара Болыт, төрлечә бизәлгән киемен киеп, бик эре кыяфәттә түрдәге тәбәнәк урында утыра иде.

Мәргән аңарга инглизләрдән ишеткән хәбәр турында җиткерде. Башлык өчен бу яңалык түгел идеме, әллә башка сәбәптәнме, аның чыраенда бер үзгәреш тә сизелмәде.

—Ничек уйлый кунак,—дип сорады Мәргәннән түрә,—инглизләр дөресен сөйлиләрме?

—Дөресен дип уйлыйм.

—Ни өчен алай уйлый, хөрмәтле кеше?

—Алар миңа ышанычлы кеше булып күренделәр.

—Яхшы!—диде башлык һәм беренче мәртәбә Мәргәнгә сынаулы караш ташлады.—Без бу турыда Олы Түгәрәктә киңәшләшербез. Бүген үк бу турыда Зирәк Кондызга хәбәр итәрмен. Ул пенутиларның һәм җимшәннәрнең иң олы башлыгы. Кунаклар да ерак чыгып китмәсен: башлыкның бу турыда аларның үзеннән ишетергә теләве бар.

Ике көннән соң Мәргән белән Уанны кабилә башлыгы янына чакырдылар һәм атларга атландырып көнчыгышка, таулар ягына алып киттеләр. Кара Болыт үзе чуар атка атланган, ә аның сакчылары җәяү иделәр. Боларның утлы коралы аз иде, ахрысы, егермеләп һиндеецның бары икесендә генә

мушкет, калганнары ук-җәя, сөңге, балта ише нәрсәләр белән генә коралланганнар. Ә атлар исә бөтен кабиләгә биш-алты гына иде шикелле.

Таулар һәм урманнар арасындагы яшерен сукмаклар буйлап көне буе бара торгач, зур гына бер авылга килеп җиттеләр. Мондагы өйләр дә агачтан эшләнгән булып, яртылаш җиргә күмелгәннәр, ләкин арада җир өстенә чыгарып салынганнары да бар. Боларының ишекләре дә бар, ә тегеләренә түбәдәге тишек аша кереп йөриләр икән.

Зирәк Кондызның карамагында җиде кабилә башлыгы бар икән. Кинәшмәдә башта Кара Болытка сүз бирелде. Ул кыскача гына Мәргән белән Уан турында әйтеп китте. Аннан соң Мәргәнгә сөйләргә кушылды, һәм ул тагын бер мәртәбә инглизләр корабында ишеткән хәбәр турында бәян итте.

Шуннан соң һәр кабилә башлыгы сөйләп алды. Аларның күпчелеге Мәргәннең сүзләренә ышанмый гына түгел, аны ак тәнлеләрнең шымчысы, дип исәплиләр икән. Йомгаклауны Зирәк Кондыз үзе ясады һәм кунакларга ышануын белдерде. Ахырда әлегә урыннан кузгалмаска, ләкин сак булырга һәм коралларны әзер тотарга карар кылынды.

Бер атналап вакыт үткәч, диңгез буенда йөргәндә Мәргән белән Уан якынаеп килүче корабларны күрделәр. Аларның берсе корвет, ә икесе барк булып, мачталарында Британия флагы җилферди иде. Кораблар ярга мөмкин кадәр якынрак килделәр дә дөбер-шатыр ләнкер төшерделәр. Күперчекләрдәге шкиперлар озын-озын күзәтү торбаларын бушап калган яр буена, урман читләренә, ерактагы тауларга төбәделәр. Шуннан соң кораблардан эре-эре шлюпкалар—баркаслар төшерелде, аларга мушкетлар тоткан диңгез пехотачылары төялде. Корыга чыккан сугышчылар яр буена тезелә тордылар, ә баркаслар яңаларын ташыды.

Мәргән белән Уан урман эченәрәк кереп яшеренделәр. Агачлыктагы күзәтче җимшәннәр Кара Болытка хәбәр итәргә йөгерделәр ахрысы, юкка чыктылар.

Ул арада офицерлар солдатларны бишәр атлам ара куеп тезделәр дә сафларны урман ягына борып куеп, мылтыкларны корырга куштылар. Ә кораблар белән яр буе арасына да туктаусыз шлюпкалар йөреп торды. Алардан кечкенәрәк кыр туплары төшереп, тәгәрмәчләргә беркеттеләр. Берничә кешедән торган ике дозор урманга кереп югалды.

—Ничә сугышчы бар икән бу сафларда?—дип сорады Уан.

—Өч йөзләп булыр,—диде Мәргән,—корабтан һаман да төшәләр бит. Яңаларының да килүе мөмкин әле. Ничек уйлыйсың, Уан, бу хәлләр ничегрәк бетәр икән?

—Кискен башлауларына караганда, инглизләр эшне кызу тотарга җыена бугай. Күрәсеңме, җирле халык белән сөйләшүләр алып барырга бөтенләй уйламыйлар. Боларның тактикасы—көтелмәгәнлек һәм тәвәккәллек ахрысы.

—Һәм кансызлык,—дип өстәде Мәргән.—Бу миңа бик таныш тактика. Уан! Хәзер инде нишләргә безгә? Яр буенда калабызмы, әллә Кара Болытны барып кисәтеп куябызмы?

—Ул беләдер инде бу хәлләр турында. Аның яр буенда күзәтчеләре бар иде шикелле. Аннан соң, Мәргән, безгә инглизләргә бирелсәк яхшырак булмас иде микән? Без бит аларга берниндидә зарар китермәдек. Бәлки туган ягыңа кайтырга ярдәм итәрләр, ә миңа—Европага, ә?

—Итәрләр, тот капчыгыңны. Аларда безнең кайгы түгел хәзер. Хәрби әсирләр дип, Русия корабына тапшырсалар. Чириков теләгәнчә булып чыкмасмы?

—Ансы бар,—диде Уан. Житмәсә, болар турында без җимшәннәрне дә кисәтеп куйган идек бит әле. Инглизләр бу турыда белсәләр, баш тиреннән колак кагуың да ихтимал.

—Дөрес,—диде Мәргән,—башны балта астына салырга ашыкмыйк.

Тагын бераз кинәшләшкәч, ике дус җирле халык кына йөри торган сукмаклар белән авылга киттеләр, ләкин авыл буш иде.

Шулвакыт ерак та түгел ниндидер тавышлар ишетелде. Уан белән Мәргән авылны чолгап алган койма буендагы биек һәм куе үлән арасына качтылар. Шул ук мизгелдә капкадан авыл урамына өч-дүрт дистәгә якын инглиз яугирләре килеп керде. Алар ашыга-ашыга өйләргә таралдылар һәм эзләнә башладылар. Мәргән койма ерыгыннан тышкы якка карады һәм авылның гаскәриләр белән чолгап алынганын күрде.

Ул арада өйләрне таларга кергән хәрбиләр буш кул белән чыктылар һәм шаулаша-шаулаша авылның урта бер җиренә җыелдылар.

—Син боларның телен аңлыйсыңмы?—дип сорады Уан.

Мәргән башын чайкады.

Мәйданга офицер килеп җитүгә, кайдандыр берничә җимшәнне сөйрәп китереп, аның алдына ташладылар. Бер гаскәри су китереп, тегеләрнең өстенә аударды. Бер әсир кузгалып куйды һәм башын күтәрде. Аны култыгыннан тотып башлыкның алдына китерделәр. Бирелгән сорауларга җавап алмагач, офицер кыска мушкетын әсирнең мангаена терәп атып җибәрде. Моны күреп, әле генә аңына килгән җимшәннең теле чишелә башлады. Ул кулы белән каядыр күрсәтеп сөйләргә тотынды, ә тылмач тәрҗемә итә торды. Арада "Русия" дигән сүз дә колакка чалынып калды. Моны ишеткән офицерның каны кыза башлап, ул кычкырынырга, җикеренергә тотынды. "Рашен!", "Скальп!" дигән сүзләрне дә кыстыргалый иде ул. "Болар минем хакта сөйлиләр бугай!—дип уйлады Мәргән.—Ә менә "скальп" сүзен нигә кыстыралар? Ул бит баш тиресен аңлата."

—Һиндеецләр, ә хәзер ак чырайлылар да әсирләрнең баш тиресен тунап алалар, чәче белән бергә. Шушы скальплар аларга юк ителгән дошманнарның санын белдерә,—дип аңлатты Уан.

—Димәк алар минем баш тиресен алырга тырышачаклар?

—Шулай булырга охшый,—диде Уан,—ләкин синекен генә түгелдер, алар өчен без икебез дә "рашен" бит инде. Ахрысы, болар безнең җимшәннәрне кисәтеп куюыбызны белгәннәр, мондагы халыкны тапмагач, ачулары килеп, бездән үч алырга тырышачаклар.

—Әйе,—диде Мәргән,—монда калу безнең өчен үлем белән бер.

Ул арада инглизләр әсирләрне атып үтерделәр дә тәмәке тартырга тотындылар. Шулвакыт алар янына тагын бер җимшәнне китерделәр. "Бу бит Кара Болытның тылмачы",—дип пышылдады Уан. Әсирдән бераз сорау алып маташкач, тегене бер өйгә яптылар да, каравыл куеп, ашыгыч рәвештә каядыр киттеләр. Китми калган унбишләп гаскәри бер буш өйгә кереп китте, ә капка янында өч сакчы калды.

Кич җитте. Сакчылар ут яктылар.

—Безгә хәзер ычкынырга кирәк,—диде Уан.

—Тылмачны үзебез белән алырга кирәк,—дип, теге өйгә таба башы белән ымлады Мәргән.

Тагын бераз көткәч, юан гына таяклар тотып, арттан килеп, сакчыга һөҗүм иттеләр һәм аның мәлҗерәп төшкән гәүдәсен атлап чыгып, ишекне ачтылар. Моны һич тә көтмәгән әсир аптырап калды, ләкин аны тиз генә баулардан азат итеп, үзләре белән алдылар. Койма аша чыгу авыр булмады, чөнки тылмачның үзе белән йөрткән озын һәм нык бавы кием эченә яшерелгән булган икән.

—Син болар кулына ничек килеп эләктең?—дип сорадылар тылмачтан.

—Кара Болыт сезне эзләп табарга кушкан иде, менә шулай эләктем.

—Җимшәннәр кайда хәзер?

—Кабилә хәзер көнчыгышка таба хәрәкәт итә. Без аларны Зирәк Кондыз авылында куып җитәргә тиешбез,—дип җавап бирде тылмач.

—Әйт әле,—диде Мәргән хәйләкәр елмаеп,—әгәр безне инглизләр арасында күргән булсаң, син нишләргә тиеш идең?

—Миңа андый күрсәтмәләр бирелмәде,—дип җавап бирде тылмач тыныч кына.

Төн караңгы булуга карамастан, тылмач сукмакны таба һәм аларны алга алып бара бирде. Берничә сәгатьтән төн караңгылыгы кимеп, таулар күренә башлады. Шуларның көнбатыш итәгендә зур гына авыл урнашкан иде.

Авылга керү белән үк аларны Зирәк Кондызның өенә чакырдылар. Кыйсыбер кабилә башлыклары, теге вакыттагыча, аларга мыскыллап карадылар. Бары тик тылмач инглизләрнең Мәргән белән Уанны үтерергә теләүләре турында сөйләгәч кенә, ике аксыл чырайлыга сүз бирелде. Алар дошман турында бар белгәннәрен сөйләп бирделәр.

—Сез китергән хәбәрләр безгә инде мәгълүм,—диде Зирәк Кондыз.—Сезгә рәхмәт, теге вакытта кисәтеп куймаган булсагыз, Кара Болытның кешесе бәлки калмас та иде... Без инглизләрне монда каршыламаска булдык,—дип дәвам итте иң Олы кабилә башлыгы, чөнки бирedә сугышуы уңайсыз. Без аларга сез әле генә үткән тарлавыкта көтмәгәндә һөҗүм итәрбез. Гаиләләребезне бүген үк тау артындагы авылларга озата башлыйбыз, ә кичкә юлбасарларга "сый" әзерлибез.

—Авылны яндырасызмы?—дип сорады Мәргән.

—Хәзергә юк. Кирәк булса, без бу эшне кайчан да эшли алабыз.

Ике-өч сәгатьтән авыл бушап калды. Ә ук һәм җәя, сөңге һәм сугыш балталары—томагавклар белән коралланган ир-атлар тарлавык ягына юнәлде.

"Бу гына чирү җинә алыр микән инглизләрнең алаен?—дип уйлады Мәргән.—Кешеләр саны тигез булса да, тегеләрдә бит утлы корал!"

Җимшәннәр инглизләрне көтеп, төн буе таулар арасында яттылар, ләкин урман тын иде. Аның каравы, таң беленгән вакытта дозордагылар килеп дошманның якынлашуы турында хәбәр итте. Яктыруга юлбасарлар үзләре дә күренде. Тарлавык ягына алып бара торган юл буйлап башта дозор үтте, аның артыннан мушкетларын атарга әзер тоткан зур төркем атлый иде.

Сакта торучы җимшәннәр ике солдаттан торган дозорны якын ук китерделәр дә, кинәт өсләренә ташланып, пычаклар ярдәмендә юк иттеләр. "Их, иртә юк иттеләр бит дозорны! Отряд тарлавыкка кергәч кенә кирәк иде бит!"—дип уйлады Мәргән. Якында гына яткан Зирәк Кондыз да иреннәрен тешләп куйды.

Инглизләрнең отряд башлыгы дозор күренми башлагач, тавыш биреп, тегеләрне чакырды, ләкин җавап ала алмагач, ниндидер боерык бирде. Солдатлар урман эченәрәк кереп, бишәр адым ара калдырып тезелделәр дә тау ягына таба кузгалдылар.

Алдагы саф җимшәннәр яткан урынга килеп җиткәч, куаклар арасыннан уклар сызгырып чыкты. Берничә инглизле кычкырып җиргә ауды, калганнары җәһәт кенә җиргә яттылар да куакларга таба ата башладылар. Берничә җирдә яраланган һиндеецнең тавышы ишетелде.

Зирәк Кондыз кашларын җыерды, чөнки аның планы тормышка ашмаган: инглизләр тарлавыкка алдап кертелмәгән иде. Инде бу сугыш озакка сузылачак һәм корбаннар күп булачак. Һәр ике якның да үзенә күрә өстенлеге бар иде: җимшәннәр үз илендә, һәр куакны беләләр, яхшы аучылар; инглизләр—күпне күргән тәҗрибәле солдатлар, ә аларның утлы кораллары җирле халык өчен күк күкрәп яшен сугуга тигез.

Ул арада аста тавышлар ишетелде: позицияләргә яна дингез пехотачылары

якынлаша иде. Аларның бер төркеме, туктап та тормыйча, ун якка борылды, ә икенчесе—сулга.

Флангларга чыгалар, чолгап алырга чамалыйлар, дип уйлады Мәргән һәм юлбашчыга карады. Зирәк Кондыз бу вакытта кулын күтәреп артка селтәде. Бу чигенергә, яна позицияләргә күчәргә боерык иде.

—Кешеләрен саклап калырга тырыша,—дип хуплады Мәргән бу боерыкны.

Жимшәннәрнен алае кин үзәннен аргы ягындагы тауларга күчте һәм шундагы кыя ташлар артында яшеренде. Бу төштә инде инглизләр ачык жирдән һөжүм итәрләр, һәм аларны кыру жинелрәккә килергә тиеш иде. Әмма инглиз офицеры башлырак булып чыкты: башта ул тау башына каратып өч жинел туп урнаштырды. Аннан соң иң төз атышучы йөзләп мушкетерны шундый ук позициягә куйды. Калган солдатларга тау башына таба һөжүм итәргә кушылды. Өч йөзләп пехотачы, мылтыкларына багинетларын беркетеп, саф-саф булып, тауга үрмәли башладылар.

Тау башындагы жимшәннәр уклардан ата башлауга, аста ятучы солдатлар туплардан һәм мушкетлардан атып, тегеләрне ташлар артына качарга мәжбүр иттеләр. Һөжүм итүчеләр тау башына менеп житәр чакта гына өстәгеләр рәхәтләнеп уклардан ата алдылар, ләкин соң иде шул инде. Инглизләр байтак кына мәет калдырсалар да, тау башына менеп життеләр һәм кул сугышы башланды. Ләкин жимшәннәр ягыннан туктаусыз уклар, сөнгеләр һәм томагавклар очып, алар өстенлек ала башладылар. Тагын берничә мизгел—һәм инглизләр кире тау астына качачак. Ләкин шулвакыт еракта быргылар кычкырткан, барабаннар каккан тавыш ишетелде: орыш кырына тагын бер отряд солдат якынлаша иде.

Моны күргәч, инглизләрнең күңеле күтәрелеп китте. Алар кулындагы багинетлар да ныграк кадый, ядрәләре дә турырак оча башлады. Ә жимшәннәрнен аң төпкелендә жан саклап калу теләге урын ала башлады. Акрын-акрын тау артына таба чигенеп, урманга кереп югалдылар. Йөзләрчә чакрымга сузылган бу урманнарда жимшәннәрне тиз генә табу мөмкин булмаса да, аларның язмышы хәл ителгән иде инде.

Берничә көн үтте, ә Мәргән туктамыйча, көнчыгыш тарафына юл тота. Ул белә: артта, океан ягында ана үлем куркынычы яный, чөнки хәзер анда инглизләр хакимлек итә. Пенути халкының аларга каршы торырлык көче юк. Моны шул яктан ишетелгән туплар канонадасы буенча да аңларга була иде, ләкин инде алар да ишетелми. Кичерегез, жимшәннәр! Мин генә сезне коткара алмам инде.

Күпмедер атлагач, алдагы куаклар арасыннан таулар күренә башлады. Тагын ике тәүлек баргач, Мәргән болытларга кадәр күтәрелгән мәһабәт тауларның итәгендә иде инде. "Бу таулар артына инглизләр тиз генә килеп житмәсләр, мина шунда барырга кирәк",—дип уйлады ул.

Тагын бер тәүлек өскә үрмәләгәч, сыртка менеп житте һәм чалкан китә язды: көнчыгыш тарафында күз күреме жирдә, шәфәкъ кызыллыгына манчылып, берсеннән-берсе югарырак яна таулар күренә иде. Мәргән таң калды: мондый сихри матурлыкны беренче тапкыр күрергә туры килде егеткә. "Монардан да гүзәлрәк күренеш була микән дөньяда!"—дип уйлады ул.

Бераз ял итеп алгач, тагын кузгалырга булды. Юл кешесенен юлда булуы яхшы, дип юкка гына әйтмиләр шул.

Бу тауларны ике-өч көндә үтәргә теләгән булса да, ялгышты: иң биек тауның сыртына менеп житәр өчен ана сигез көн кирәк булды. Урыны-урыны бигрәк тә авыр. Авыллар очраса, урап үтәргә туры килде. "Их, Уан булса икән!"—дип юксынды ул кайдадыр сугыш кырында аерылып калган иптәшен.

Таунын теге як итәгенә төшәр өчен тагын берничә көн кирәк булды. Әле ярый кораллары бар: томагавк һәм җәяне җимшәннәрдән алган иде ул, ә пистолетыннан бер тапкыр да атып карамады, чөнки кирәге дә чыкмады. Нинди генә җәнлек яки кош очраса да, күп уйлап тормады, шундук угын очырды. Урманнарда төрле җимеш, үлән, кыргый арпа һәм солы белән тукланды. Тау елгаларында ук белән балык атып алды. Мондый һөнәрне ул әле Чириков командасында чакта теленкитләрдән үзләштергән иде.

Менә таш кыялы таулар да артта калды. Алда очсыз-кырыйсыз урман катыш далалар җәелеп ята. Соңгы үрне генә төшәсе дә...

Шулвакыт алда ниндидер тавышлар ишетелде. Меңнәрчә ат тояклары гүләвенә охшаган. Дөнья яңгыратып кешеләр кычкыруы да, барабансыман нәрсәләр дөбердәве дә кушыла иде. Тау итәгендәге киң алан өстендәге болыт эченнән килә иде ул гүләү. Кинәт шул тузан болыты эченнән күз күрмәгән, колак ишетмәгән хайваннар килеп чыктылар да тауга, Мәргән ягына ыргылдылар. Ин зур үгезләрдән дә дәүрәк бу мөгезле аждаһалар, алны-артны күрмичә, өскә таба омтылалар, ә йөзәрләгән кызгылт-көрән хайваннан торган бу көтүне таяклар һәм сөңгеләр тоткан атлы кешеләр куалый, бу корыч тояклы җеннәр өерен, як-якка җибәрмичә, таш кыяның читенә таба юнәлтәләр.

Менә алдагы дәү хайван кыя читенә килеп җитте, аның белән рәттән тагын берничәсе соңгы мизгелдә аякларын терәп тукталып калдылар. Ләкин аларның язмышы хәл ителгән иде инде: ашкынып килгән арткы үгезләр алдагыларны упкынга, тырпаеп торган очлы ташлар өстенә этеп төшерделәр. Ә анда аларны сөңгеләр тоткан аучылар көтә иде.

Җиде-сигез хайваннын башына җиткәч, көтүне арттан куалаудан туктадылар, һәм арткы хайваннар алдагыларын кысрыкламый башладылар. Ә бераздан бөтен өер кирегә чапты.

"Үзләренә кирәк кадәр генә үтерделәр,—дип уйлады Мәргән,—болар малны юкка әрәм итмиләр".

Әлеге вакыйга анын ниндидер яна кәсеп белән шөгыльләнүче көчле халык җиренә аяк басуын күрсәтте. Әмма, Мәргән турыдан-туры алар янына барырга базмады, башка юл табып, тау астына төшә башлады, ә бу сукмак исә егетне бөтенләй икенче якка, башка кабиләләр җиренә алып китте. Еракта күренгән урманлы далага килеп җиткәнче әле тагын байтак атларга туры килде.

Мондагы агачлар беренче караудa аңа таныш кебек тоелдылар. Әмма ныклабрак күз төшергәч, аларның үзгә икәне беленде. Менә өрәнге агачы. Ул бит Идел буенда да шундый ук. Ләкин нигә соң аның кабыгын кыйгачлап чапканнар һәм агачны "еларга" мәҗбүр иткәннәр. Өрәнгенең "яшенә" бармагын тидереп авызына капкач, Мәргән бу куе сыекчаның бик татлы икәнен тойды. "Бал-шикәр агачта үсә икән бит монда",—дип уйлады ул.

Куаклар арасыннан кечкенәрәк кенә бер елга күренде. Егет сакланыбрак кына елга ярына якынлашты һәм су чупылдаган тавыш ишетте. Карана торгач, утыз-кырык адым түбәндәрәк су коенучы шыр ялангач бер кеше күренде. Мәргән аның уналты-унҗиде яшьләрдәге сылу тәнле бер кыз бала икәнлеген күреп таң калды.

Егеткә теге ярга чыгарга кирәк иде. Шуңа күрә ул бил тиңентен суга кереп, елганы кичте һәм сулы киемен өстендә килеш кенә сыга-сыга, куаклар арасындарак туктады. Кыз егетне күрми иде. Ул арада чибәр ярга чыкты, озын чәчләрен сыгып алды да киенә башлады. Бизәкләнеп тегелгән ыштан һәм шундый ук кыска күлмәк киде, чәчләрен зәңгәр тасма белән бәйләп куйды, аңа ниндидер кошның матур чуар каурыен кыстырды, аягына йомшак күн башмаклар эләктерде.

Шулвакыт куаклар арасында ниндидер кыштырдау ишетелде. Шул ук мизгелдә теге як ярда таза гәүдәле, бите кара буяу белән сызгаланган бер

һиндеец күренде. Ул кызга күренмичә генә бирге як ярга чыкты да инде киенеп беткән чибәр янына атлады. Мәргән дә шулай ук яшеренеп кенә анын артыннан калмады. Яшь һөҗүмче җәһәт кенә кызга ташланды һәм аны биленнән сынар кулы белән эләктереп, теге як ярга чыга башлады. Кыз тавышланып, тыпырчынып караса да ычкына алмады. Шул мәлне юлбасар ачы сызгырып җибәрде, һәм анын каршысына ияр урынына ниндидер калын чүпрәк салынган аты килеп чыкты. Күз ачып йомганчы һиндеец кызны тоткан килеш атына сикереп менде. Бер секундтан сон юлбасар кызны алып качачак. Мәргән ирексездән "Тукта!"—дип кычкырды һәм тиз генә кечкенә мушкетын чыгарып атып җибәрде. Шул ук мизгелдә кыз урлаучы да озын нәзек саплы үткен балтасын чыгарып, егет ягына ыргытырга өлгерде, ә үзе пуля тиеп авып төште. Томагавк Мәргәннен йөзлек өстенә килеп кадалды.

Аягын угалап ынгырашып яткан егет бераз исенә-акылына килгәч, баягы кызны күрде: тегесе иелеп, аңа карап тора иде. Яр буенда һиндеецнен гәүдәсе ята, янында аты тора иде.

Кыз егетнен яралы аягына ымлап нәрсәләр әйтте, ләкин яралы баш какты: анламый, янәсе. Кыз куаклар арасына йөгерде һәм озак та үтми, ниндидер үлән яфраклары тотып, килеп житте. Аннан сон ул Мәргәннен тузып таркалырга житкән аяк киемен салдырды, ярага әлеге яфракларны япты, һәм букча кебек нәрсәсеннән чүпрәк кисәге алып, ярасын бәйләп куйды.

Шуннан сон кыз тагын нидер сорады, ләкин егет анламагач, үз күкрәгенә төртеп күрсәтте:

—Сар Каин!

—Нәрсә дисен?

Кыз елга буенда үскән агачларга күрсәтте:

—Сар Каин!

—Сары Каен?—диде егет аптырап.

—Һеэ! Һеэ!—дип кычкырып көлде чибәр.—Мен Сар Каин.

—Мин Мәргән!—диде егет күкрәгенә төртеп.

—Мәр Гән! Мәр Гән!—диде кыз учларын чәбәкли-чәбәкли.

—Әйе Мәргән.

—Мәр Гән!—диде тагын кыз анын исемен икегә бүлеп. Аннан сон җирдә яткан җәясен алып, нәрсәгәдер күзләгән булып кыланып, янадан егетнен исемен кабатлады.

Мәргәннен тагын исе китте. "Ул бит минем исемемне җәядән атучы, дип анлатты. Безненчә дә бит Мәргән төз атучы дигән сүз".

Шуннан сон Сары Каен тиз генә юлбасарнын атын алып килде дә атланырга кушты. "Теү екта чикәтаулар"!—диде ул шомланып.

Икесе бер атка атланып, егет белән кыз көнчыгыш тарафына чаптылар, ләкин ерак китә алмадылар: арттан тояклар шакылдавы, кемнәрнендер ачы итеп кычкыруы ишетелә башлады. Аргамакны унга борып, кыз елгыр гына сикереп төште дә Мәргәнгә төшәргә булышты. Егет аягы авыртуына тешен кысып, пистолетын чыгарды. Сары Каен исә җәясе белән укларын әзерләде.

Куа килүчеләр өчәү иде. Алар инде җан-фәрман чапмыйлар, атларын тыя төшеп, карана-карана гына киләләр.

Кыз ишарәләп уртадагысына күрсәтте, ә үзе алдагысына угын төбәп атып та җибәрде. Мәргән дә калышмады. Ике чикәтаулы берьюлы атларыннан мәтәлеп төштеләр, ә исән калганы яшен тизлегендә атыннан сикереп төште дә юкка чыкты, әмма шундук Мәргән алдында пәйда булды һәм балтасын очырды, ә аннан сон пычагын чыгарып, балтадан тайпылып калган егеткә ташланды. Бәхеткә каршы, кыз аткан ук чикәтаулынын тамагын тишеп чыкты, әмма анын үткен пычагы Мәргәннен ботын ярып өлгерде.

Сары Каен пычагын чыгарып мәетләрнен баш тиреләрен тунап алды.

Скальп салдыруны ул гаять оста һәм тиз башкара иде .

Егетнең тагын бер ярасын бәйләгәч, ике атка атланып юлга чыктылар. Иясез калган хайваннар арттан иярде. Чирек сәгатьләп баргач, ниндидер елганы кичтеләр.

—Сут!—диде аның исемен кыз.

—Сөт?—дип сорады Мәргән һәм суга карады: елга суы аксыл иде.

Ул арада кеше тавышлары ишетелде. Елганың теге як ярында агач таганнарга калын тукыма киерелеп ясалган чатырлар урнашкан иде.

Тыштагы шау-шуны ишетеп, уртадагы зуррак һәм зиннәтлерәк чатырдан урта яшьләрдәге бер кеше чыкты. Аның өстендә юлбашчы киеме, кулында бизәкле таяк иде.

Сары Каен аны күрүгә, "Әтинә-ә-ә-м! Әтинә!—дип кычкырып җибәрде һәм, тезләнеп, атасының аякларын кочты, ә үзе елый-елый нәрсәдер сөйләде. Күптән түгел генә чикәтаулар белән ана капландай сугышкан кыз атасын күрүгә нарасый балага әйләнгән иде. Тегесе кызын аягына бастырды һәм иркәләү катыш шелтә белдергән тавыш белән баласын юатты. Аннан соң кабилә башлыгы читтәрәк торган дүрт ят атны күреп, аларга сокланып карап торды, барып муеннарын сыйпады. Шуннан соң гына Мәргәнгә игътибар итте һәм кызына ниндидер сорау бирде. Тегесе дулкынланып атасына нидер сөйләде. Ә Мәргәннең бу вакытта хәле җиңел түгел иде. Җәрәхәтләр сызлап егетне бер эссегә, бер салкынга сала, вакыты-вакыты белән ул аңын да җуя яза иде. Ниһаять, ничә тәүлекләр буе ярымач һәм ялсыз хәрәкәтләнгән егет чыдамады: баскан урынында аңсыз егылды.

Аңына килгәндә үзенең бишек кебек нәрсәдә тирбәлүен сизде Мәргән. Аптырап баш калкытып караса, үзен дүрт һиндеецның агачларга челтәрсыман нәрсә тагып эшләнгән ятакка салып алып баруларын абайлады. "Кабилә көченә ахрысы",—дип уйлап өлгерде ул һәм тагын аңын югалтты.

Егет янадан исенә-акылына килгәндә, алар зур гына бер авылда иделәр. Тирә-якта агач өйләр генә түгел, хәтта кызыл балчыктан сугылган эре-эре яндырылган шакмаклардан салынганнары да бар иде. Авыл читендәрәк җиргә казып ясалган куышлар да күренә. Урамнарда кешеләр, мал-туар йөри.

Мәргәнне авыл уртасындагы иң зур йортка терәтеп эшләнгән, ян яклары чыбыклардан үрелгән, түбәсе ботак-яфрак белән ябылган бер алачыкка урнаштырдылар. Мондагы җиләс саф һава яралы авыру кеше өчен бик файдалы икән.

Егетнең үзен генә калдырмыйлар диярлек: ниндидер урта яшьләрдәге хатын (имче булса кирәк) яраларын өшкерә, дәвалый, көненә биш тапкыр ашарга китерә. Ә инде Мәргән өчен иң көтеп алына торганы—Сары Каеннын килүе. Хәер, кыз үзе дә озак көттерми, юк йомышын бар итеп, гел кергәләп йөри.

Мәргәнгә авыл халкы гына түгел, юлбашчы үзе дә хөрмәт күрсәтә, еш кына хәлен белеп китә, егетнең терелүен көтә иде.

Бу кавем сиу халыклары гаиләсеннән булып, дакота исемле кабилә иде. Аларның бөтенесе берничә дистә мең кеше булып, гүзәл һәм мул сулы Миссури буйларын билиләр. Шунсы начар, куаннар арасында бердәмлек юк, төрле юк-бар сәбәп аркасында ызгыш бара икән.

Кабиләнең төп шөгыле—терлекчелек, иген үстерү, сунарчылык һәм балык тоту.

Мәргән ике атнадан артык инде урында ята, яралары бетәшеп бетә алмый. Торырга аңа рөхсәт юк. Ялкыч. "Сары Каен килсә икән!"—дип уфтанып куйды егет, һәм шул ук мизгелдә кызның көлгән тавышын ишетте. Менә ул кояштай балкып үзе дә килеп керде. Аңа әле исем дә яулап өлгермәгән унбиш яшьлек энесе иярган. Тагын бер елдан аңа исем бирәчәкләр икән,

инде "Житез кугуар" дигән исем дә әзерләнгән, ләкин үсмер ул исемгә лаек икәнен ауда яки яуда исбат итәргә тиеш.

Бераздан кыз белән егет икәү генә калдылар һәм телсез кешеләрдәй берберенә карап утыра башладылар. Бу минутларда кыз егеткә бик якын һәм кадерле тоела иде. "Бу халыкта сөю турында әйтү гадәте бар микән? Яшьләр ничек итеп аңлашалар, кавышалар икән?"—дип уйлый иде егет еш кына, ә сорашырга кыенсына да, хәленнән дә килми иде, чөнки дакота телен үзләштерә башлаган гына иде әле...

Дакоталар теленен татарныкына якын булуы таң калдыра иде Мәргәнне. Аерым сүзләр бөтенләй таңгал килә. Икенчеләрен охшатып аңларга була. Калганнарының мәгънәсе сүз сөрешеннән беленә. Татарныкына охшаган телләр Себер җирләрендә дә очраштыргалады, ә шулай да туган яклардан меңнәрчә чакрым ераклыкта, җир читенен аргы як икълимнәрендә таныш сүзләр ишетү, күңелгә ятышлы итеп сөйләшкән кешеләрне күрү гаҗәеп хәл иде.

—Аягың сызлыймы?—дип сорады, ниһаять, Сары Каен.

—Юк,—диде егет,—рөхсәт булган булса, күптән инде йөреп киткән булыр идем.

—Ашыкма! Аба яхшырак белә. Син монда булганда безгә күрешеп торырга да уңай.

—Сары Каен!—диде егет уйчан һәм дулкынлану белдергән тавыш белән.

—Сары Каен тыңлый сине...

Ләкин боларга башлаган сүзләрен дәвам итәргә туры килмәде: алачыкка Олы Кыя үзе килеп керде һәм кызына чыгып торырга кушты. Яшьләрнең берберсенә битараф түгеллеген ата сизә иде, ахрысы, ләкин моны күрсәтми иде.

—Сары Каен кунакны безнеңчә сөйләшергә өйрәттеме инде?—дип башлады ул сүзен.

—Азмы-күпме өйрәндем. Безнең телләр охшаш бит.

—Сизелә,—диде Олы Кыя. Аннан соң кулындагы бизәкле таягының очы белән идән урынына тапталган кызгылт балчыкка ниләрдер сызгалый башлады. Карый торгач, Мәргән Миссуриның кушылдыгы булган Сөт елгасын, үзе үткән таш кыялы тауларны һәм, ниһаять, океанга коя торган Һумул елгасын таныды.

—Мәр Гән кайсы урында инглизләрне күрде?—дип сорады ул һәм таягын егеткә тоттырды. Җавап алгач, дәвам итте:—Олы Кыя ул җирләрдә булганы бар. Җимшәннәрнең башлыгын да белә. Ярый, Мәр Гән тагын ун мәртәбә кояш баеганчы ял итсен әле,—диде ул бераз утыргач,—аннан соң сөйләшербез. Ә Олы Кыя хәзер тирләмәгә керә, нигәдер тәне йончыды.

Мәргән ун көн ятып түзә алмады: дүрт-биш көннән соң торып алачыкны әйләнеп чыкты, бала-чага белән бергә таягына таянып елга буена төште. Анда малай-шалай ук белән балык атарга өйрәнәләр икән. Шулвакыт ниндидер чыр-чу ишетелде: кызлар ногыт борчагы җыеп кайталар икән. Буй җиткергән чибәрләр арасында Сары Каен да бар. Ул шундук йөгереп килеп житте һәм ягымлы шат тавыш белән егетне битәрли башлады. Сүз дә әйттермичә егетне дәвалану урынына кайтарды һәм ятагына салды.

—Сары Каен!—диде егет.—Син бит юлбашчы кызы, нигә башкалар белән бергә эшләп йөрисең? Әтиең кушамы?

—Кушмый. Сары Каенга анда күңелле. Тиздән маис җыя башлаячакбыз. Ансы инде авыррак эш. Ул чакта минем әтием үзе дә эшли. Әле быел пәтәйтә утыртып карадык. Үсеп ята бит. Балчыктагы бүлбеләре менә мондый булдылар инде!—дип, кыз баш бармагын күрсәтте.

—Сары Каен Мәр Гәнгә күчтәнәч китерде,—дип, кыз кечкенә бизәкле капчыгыннан беләк буе кадәрле маис чәкәне чыгарды.—Без аны утта кыздырдык, сыйланамы син?

—Пәтәйтә, мәис, тәмәтле—дип куйды Мәргән.—Беләсеңме, бездә бу нәрсәләр үсми бит.

—Үсми? Нигә үсми? Утырткан чакта безнең кебек оя саен бер уч черек тизәк саламы сез?

—Аңламадың, мин бу үсемлекләрне монда беренче мәртәбә күрдем,—диде егет аптыраган кызга.

—Ярый, Сары Каенга китәргә кирәк. Кичләтеп килеп җитәр. Үзегезнең яклар турында сөйләр син.

Кыз чыгып киткәч, егет тирән уйга батты. "Нишләргә соң миңа?—дип уйлады ул.—Үземнең хисләрем турында Сары Каенга белдерергәме, юкмы? Мин бит бу кызны Нәстүгем кебек күрәм. Нәсимәмне оныта барам түгелме соң мин? Сөюемне бу кызга күчердем түгелме? Әгәр мин моны аңа белдерсәм, ул да миңа карата шундый ук хисләр белән янып йөргән булса? Ул чакта бит өйләнергә, язмышымны шушы халык белән бәйләргә тиеш булам. Нишләргә соң миңа?

Шундый уйлар һаман да ешрак били иде Мәргәнне.

Берничә көннән соң егет янына тагын Олы Кыя килеп керде. Бераз тәмәкесен төтәткәч, ашыкмый гына сүз башлады:

—Мәр Гән сөйләсен, кайдан килде, кем була ул, ата-аналары кем? Монда ничек килеп эләкте? Барын да.

Мәргән озак кына уйланып торды да, авырлык белән генә сүзләр сайлый-сайлый, әлегә кадәр укучыга мәгълүм булган вакыйгалар турында бәян итте. Ниһаять, хикәятен тәмамлап тукталып калды. Алачыкта тынлык урнашты.

—Күпне күргән, Мәр Гән! Аның иле еракмы моннан? Көн ничә мәртәбә баеганчы барырга кирәк? Зур диңгезнең теге ягында бит?

—Әйе! Аны океан диләр. Без ул су аша корабта утыз мәртәбә көн баеганчы йөздек. Ә океанга кадәр җиде-сигез мең чакрым килергә кирәк,—дип аңлатты егет.—Җәяү атласаң, бер җәйдән икенчесенә кадәр барырга кирәк.

—Безгә ул яктан хәвеф-хәтәр яныймы?

—Яный,—дип уйлыйм,—диде Мәргән, озак кына фикерен тәгаенләп алгач. Аннан соң дәвам итте:

—Әгәр инглизләр китсәләр, барыбер урыслар йә испанлылар басып алачак бу җирләрне. Монда килеп җиткәнче, аларга каршы торырлык көчле кабиләләр күрмәдем мин. Ә көнчыгышта ничек?

—Анда да инглизләр,—диде Олы Кыя.—Көнтуыш яктагы олы дингез буйларына гына түгел, Андаман тауларына да килеп җиткәннәр. Ләкин аларга кадәр бик ерак әле, һәм анда каршы торырлык халыклар бар. Ә менә көнторышта эшләр күпкә хәтәррәк. Мәр Гән әле белми, безнең кардәшләребез майия һәм астыклар күп еллар элек моннан китеп, Юкатан дигән җиргә барып урнашканнар икән. Иллә дә гайрәтле кавемнәр булганнар алар. Ләкин испаннар аларны барыбер җиңә алганнар. Хәзер инде ул илбасарлар безнең тарафка таба хәрәкәт итәләр. Әлегә алар шешеннәр белән бәрелешә, ә бит кайчандыр безнең нәүбәт җитәчәк. Дөрес, шешеннәр тиз биреша торганнардан түгел... Мәр Гәннең кавеме ничек атала?—дип сорады ул бераз дәшми утыргач.

—Без "татар" дигән халык,—диде Мәргән.

—Кабилә башлыгының аты ничек?—дип сорашуын дәвам итте юлбашчы.

—Безнең үз башлыгыбыз юк, урыс падишаһы кулында яшибез.

Шуннан соң Мәргән кыскача итеп татарларның аяныч язмышы турында сөйләп алды.—Сезне дә шундыйрак язмыш көтә бугай,—диде ул ахырда.

—Ихтимал,—дип куйды башлык,—монда уйланырлык нәрсәләр бар.— Аннан соң ул байтак кына дәшми утырды.—Мәр Гәннең йәрәшкән кызы бармы?—дип сорады ул ахырда.

Мәргәнгә Нәсимәсе турында сөйләп бирергә туры килде.

—Анын белән кавышу насыйп түгелдер инде,—диде Олы Кыя.—Минем кызым килешәме?

—Мин аны Нәсимәм кебек күрәм.

—Мәр Гән каршы килмәсә, мин кызымны ана хатынлыкка бирәм.

—Ул үзе минем белән яшәргә ризамы соң?—дип сорады мондый кискен борылышны көтмәгән егет.

—Бездә болай хатын-кызның ризалыгын сорау гадәте юк, ләкин мин бердәнбер кызымны яратам һәм анын теләген исәпкә алам.

—Димәк ул риза?

—Шулай дип уйлыйм.

—Олы Кыя! Син кызыңны минем белән дөньяның теге ягына җибәрергә ризамы?

Башлык озак кына егеткә карап торды да елмаеп куйды.

Кабилә башлыгы чыгып киткәч, Мәргән әле озак уйланып утырды. Олы Кыяның тәкъдиме егетнен теләгенә туры килсә дә, бу бик капылт һәм тормышны төптән үзгәртә торган тәкъдим иде. Туган җире, ата-аналары, туганнары белән күрешүдән ваз кичеп, монда тамыр җәяргә тиеш була иде бит ул.

Ләкин Олы Кыяның Мәргән белән алыш-биреш итү уе тормышка аша алмады, чөнки вакыйгалар күпкә тизрәк һәм куркынычрак борылыш ясый башладылар: көнбатыштан, Кыялы таулар ягыннан инглизләр турында хәбәр алынды. Аларның чиргә инде чикәтаулылар җиренә якынлашкан икән. Дөрес, тау халкы, сунарчылар кавеме алай тиз генә биреша торганнардан түгел, ләкин аларның да океан артыннан килгән илбасарлар белән озак сугышу мөмкинлеге юк иде шикелле.

—Олы Кыя Мәргәнне өенә киңәшләшергә чакырды.

—Инглизләрнең сугышчылары күпме?—дип сорады ул сүзне озакка сузмыйча гына.

—Мин күргәне—биш йөзләп булыр,—дип җавап бирде Мәргән,—ләкин алар күпме кирәк шулкадәр кеше китерә ала,—дип уйлыйм мин.

—Чикәтаулардан соң безгә һөҗүм итәрләрме икән?—дип төпченде башлык.

—Итәрләр, ахры. Сезнең җәннәттәй җирләрегез аларны кызыктырмый калмас. Гомумән алар бөтен Америка җирләрен басып алырга тырыша булыр.

—Болай булса, без нишләргә тиешбез?

—Йә бирелеп аларга кол буласыз, йә берләшеп каршы торасыз. Өченче юл юк, дип уйлыйм мин. Безнең, татарларның хатасын кабатларга ярамый. Сезнең кавемдәшләрегез кемнәр?

—Бөтен һүкә-сиү халыклары,—дип санап китте Олы Кыя,—чирүкләр, һуклар, керикләр, мескәкләр, төтөннәр. Көнчыгыштарак тагын барлардыр әле.

—Аларның барысын да кем берләштерә ала?—дип, Мәргән Олы Кыяны уйга калдырды. Тегесе, ниһаять, башын чайкады:

—Бу җиңел эш түгел,—диде ул,—алай да берничә кабилә башлыгы белән сөйләшеп карарга була. Ерактагыларына вам-пум җибәрермен.

—Нәрсә ул вам-пум?

Олы Кыя нәзек баулардан эшләнгән төен һәм челтәрләрдән торган бер үрем китереп чыгарды.

—Менә шушы инде ул. Сары Каен өйрәтер әле бу челтәрләрне, төеннәрне укырга.

—Сездә утлы корал бармы?—дип сорады Мәргән.—Мушкетлар, туплар.

—Мушкетлар аз гына бар, туплар турында ишеткән дә юк.

—Ансыз аксыл чырайлыларга каршы торып булмаячак. Әйт әле, Олы Кыя, чикәтаулылар кемнәр алар? Ни өчен Сары Каенны урлап китәргә тиешләр иде?

—Бу беренче мәртәбә генә түгел. Аларның юлбашчысы Кара Козгын кызымны үзенә хатынлыкка сорый. Ләкин Сары Каен моны теләми. Дөрес, ул күнгән сүрәттә, ике кабилә арасындагы дошманлык юкка чыгар иде. Әмма мин кызымның теләген аяк астына салып таптый алмыйм.

—Син, Олы Кыя, яхшы ата һәм намуслы кеше,—диде Мәргән.—Чикәтаулар сезгә тел буенча якынмы?

—Бик якын. Без алар белән тылмачсыз сөйләшәбез,—диде башлык.—Тик шөгыльләр башка: без иген игәбез, мал тотабыз. Алар сунарчылар. Анда бездәге кебек тигез җирләр юк, таулар да урманнар гына.

—Безгә бөтен сиу халыкларын берләштермичә коллыктан котылу юк. Ә башларга кирәк чикәтаулылардан. Алар инглизләрнең нәрсә алып килгәннәрен беләләрдер инде. Әгәр дә мин чикәтаулылар белән килешә алсам?—диде Мәргән.

—Барып чыгарлык булса, тәвәкәлләргә кирәк,—дип җөпләде Олы Кыя,—ә мин башкаларның кылларын чиертеп карармын. Тик мин шунсыннан куркам: Мәр Гән бит аларның дүрт сугышчысын үтерде, үч алырга теләмәсләрме?

—Әлбәттә, монда уйланырлык урын бар. Әмма аларга да, безгә дә янаган бәла күпкә куркынычрак. Башы булса, Кара Козгын моны аңлар. Икенчедән, боларны кем аңарга миннән дә юньлерәк итеп аңлата алыр?

—Мәр Гән хаклы.

—Иң мөһиме—безгә утлы корал кирәк,—дип дәвам итте фикерен Мәргән,—ә ул инглизләрдә генә бар. Алар янына барыр өчен безгә чикәтаулылар җире аша үтәргә кирәк. Күрәсеңме, тагын шуларга барып төртеләбез.

—Мәр Гән инглизләрдән утлы корал алырга җыенамыни?—дип сорады Олы Кыя.

—Башка юл юк. Сатып алырга җитәрлек синең алтының юк. Кара Козгында да юктыр инде ул, шулай бит?

—Шулай!—дип җөпләде юлбашчы.—Булса да аз.

—Күрәсеңме? Бер генә юл кала: талап алырга. Бу эшкә иртәгә үк тотынырга кирәк. Үзең аңлыйсың, безнең вакыт бик аз кала. Тагын бер тәкъдимем бар,—диде Мәргән,—әгәр берничә кабиләне җыйный алсак, барысын бергә "Сиу халыклары берләшмәсе" дип атарга кирәк. Иң баш кешене юлбашчылар бергәләп сайларга тиешләр. Бу эш беркемне дә кимсетмәс.

—Яхшы,—диде Олы Кыя Мәргәнгә ихтирам белән карап,—юлбашчыларга шулай дип әйтермен, бу төпле фикер. Миннән нинди ярдәм кирәк?

—Өч-дүрт булдыклы егет... һәм синең углың,—диде Мәргән.

—Минем углым?! Минем берданбер углым!—Бу бит аны күрәләтә һәлакәткә дучар итү дигән сүз!—дип чыгырыннан чыкты Олы Кыя.

—Озакламый без барыбыз да шул хәлдә калачакбыз. Икенче яктан, уйла: синең угланың булмаса, Кара Козгын миңа ышанырмы? Аннан соң, углына барыбер исем яуларга кирәк бит...

—Ансы шулай,—диде чиктән тыш дулкынлануы йөзенә чыккан юлбашчы.—Алайса әзерлән. Таңнан юлга чыгарсыз. Егетләр әзер торыр. Атлар кирәк булырмы?

—Кирәк булса, табарбыз. Атларың болай да аз.

—Йә, хуш, егет! Уңышлар телим!

Таң атып, офык алсулана башлагач, төнне йокысыз үткәргән Мәргәннең алачыгына Сары Каен йөгереп керде. Анын хәсрәтле күзләреннән атылып чыгарга җиткән яшьләре мөлдерәп тора, дулкынланудан һәм тиз йөгерүдән сулышы тыгылып, калку күкрәге бер күтәрелә, бер төшә иде.

—Мәр Гән!—... диде ул көч-хәл белән.—Мәр Гән! Син ник миңа әйтмәдең?!... Кая барырга җыенасың? Мине ташлап китәсеңме?!.. Үзем белеп

килмәгән булсам, хушлашырга да жыенмый иденме?... Әле ярый энем...

Шундыйрак күз яшьләре аша әйтелгән сүзләр белән кыз тезләнде һәм егетнең аякларын кочып елый башлады. Үзе һаман үпкә сүзләре әйтте. Ләкин алар Мәргәннең бәгыренә кадалмыйлар, ә ниндидер жан канәгатләнүе бирәләр, егетнең хисләренә жавап булып янгырыйлар сыман иде.

—Сары Каен!—диде егет кызны аягына бастырып.—Елама!... Мин кайтырмын!.. Мин сине ташламам!.. Ышан мина!...

Шулвакыт аяк тавышлары ишетелде һәм алачыкка дүрт егет килеп керде. Болар Олы Кыянын иң булдыклы һәм ышанычлы яугирләре, ә иң яше—Сары Каеннын энесе иде.

Чикәтаулылар жиренә житкәнче, аларны олы гына тәжрибәле бер кеше озата килде. Чик булып хезмәт иткән елгага житкәч (шушы елга буенда Мәргән Сары Каенны коткарган иде), ул теге ярда калып ни буласын яшеренеп күзәтеп торды. Мәргән моны яфраклар селкенеп куюдан анлап алды. Ул гына да түгел, ботак-яфрак тагын берничә жирдә кыштырдап куйды.

Шул мәлне чикәтаулылар ягыннан да тавыш килде, һәм ике-өч минуттан дистәгә якын сугышчы дакоталарны чолгап алдылар, шаулаша-шаулаша коралсызландырдылар, барысын да агач кәүсәләренә бәйләп куйдылар. "Әгәр хәзер куаклар арасыннан безне коткарырга уйлап атсалар, бөтен ният бозылачак",—дип шомланды Мәргән. Ул арада чикәтаулыларнын өч-дүрте тиз генә үткен пычакларын чыгарып, әсирләрнен баш тиресен салдырып алырга жыенды, ләкин бу вакытта Мәргән телгә килде:

—Тимәгез безгә! Без Олы Кыядан Кара Козгынга сөйләшер өчен барабыз, без илчеләр булабыз. Менә Олы Кыянын вам—пумы.

Шушы сүзләрдән соң ачулары чырайларына чыккан чикәтаулылар башлыкларына буйсындылар, әсирләрне юлбашчы янына алып китәргә булдылар. Аяк-кулларын бәйләгән бауларның озын очын иярсыман нәрсәгә беркеттеләр дә, атларга атланып, юлга чыктылар.

Ат артына тагылган әсирләрне атлата-йөгертә ярты көн интектергәч, таулар арасындагы калын урман эчендә яшеренгән зур гына авылга килеп життеләр. Мондагы торакларның күбесе түгәрәк булып, өстән аска кадәр зур-зур калын күн кисәкләре белән капланганнар иде. "Бу бит теге эре үгезләр аулаган халык,—дип исенә төшерде Мәргән,—димәк алар өйләрен шул хайван тиресе белән каплаганнар".

Бераздан әсирләрнең икесен (Мәргән Олы Кыянын улын үзе белән алды) Кара Козгын янына китерделәр. Анын зур гына түгәрәк өе типи дип атала икән. Юлбашчы янына барып кергәч үк, шундагы бер яшь кенә кеше кычкырып жибәрде һәм тиз генә пычак чыгарып Мәргәнгә ташланды. Кара Козгын тегене каты тавыш белән туктатты һәм ни булганын сорады. Әлеге егет Мәргәннең үзен атып үтерә язганын сөйләде. Шунда гына Мәргән егетне таныды: ул Сары Каенны урлап китәргә теләгән чикәтаулы иде. "Исән калган бит мәлгунь!"—дип уфтанды Мәргән.

—Син ни өчен минем улымны үтерергә теләдең?—дип жикерде юлбашчы.—Монын өчен синең баш тирең туналачак, ә итең белән этләр тукланачак!

—Синең улың икәнен белгән булсам, атмаган булыр идем,—дип жавап бирде Мәргән.—Олы Кыяның кызын урларга килгәндә үзенең кемлеген белдермәде ич ул. Беләм, сез Олы Кыя белән дус түгелсез, ләкин һәлакәт якынаеп килгәндә, үзара дошманлыкны онытып торырга кирәк. Житмәсә сез бит әле ятлар да түгел, тугандаш кавемнәр.

—Син кем?—дип сорады юлбашчы тупас тавыш белән.—Аксыл чырайлымы? Әллә креолмы? Бәлки, инглизләрнең шымчысыдыр.

—Юк, Кара Козгын! Алар минем дә дошманнарым. Мин Олы Кыядан илче булып килдем. Анын уе—бөтен сиу халыкларын берләштерү. Ул әле

керикләр һәм башкалар янына китте, мине бирегә җибәрде. Аксыл чырайлыларның явызлыгы, мәкерлелеге, көче турында ишеткәнең бармы? Бөтен тугандаш кабиләләрне бергә җыйнап, утлы корал белән тәэмин ителгән, яхшылап өйрәтелгән чирү булдырсак кына илбасарларга каршы тора алачакбыз.

—Нигә миңа кем беләндер берләшергә!—диде Кара Козгын масаюлы тавыш белән.—Мин үзем инглизләрне кыйнаячакмын. Арт сабакларын укыта башладык та инде.

Мәргәнгә үзенең күргәннәре һәм дошманның кем булуы турында сөйләп бирергә туры килде.

—Аксыл чырайлыларның уе—бөтен Америка җирләрен бүлешеп алып, җирле халыкларны кол итү. Ышан миңа, алар ярты юлда туктап кала торганнардан түгелләр...

—Ә мин сиңа ышанмыйм!—дип кычкырды башлык.—Син үзең дә шуларга охшагансың, җитмәсә, минем күптәнге дошманнарым—дакоталар белән килдең. Иң начары—минем улымны үтерә язгансың. Ә иптәшең кем? Олы Кыяның көчегемени? Ансы шәп! Без аны әманәт итеп тотарбыз.

Шуннан соң ике әсирне "чокыл" дип аталган караңгы өйгә яптылар. Иптәшләре турында ул берни дә белә алмады.

Чокылда ачлы-туклы берничә тәүлек яткач, боларны янә Кара Козгын янына китерделәр. Юлбашчы караңгы чырай белән озын нәзек трөбкәсен төтәтеп утыра иде.

—Синең сүзләрең дөрес булырга охшый,—диде ул.—Без әлегә дошманны тоткарлап торабыз, ләкин диңгез ягыннан хәбәр алдык: өч корабтан тагын исәпсез-хисапсыз яугир төшерелеп ята икән. Син нишләр идең, минем урында булсаң?

—Иң элек утлы корал табарга тырышыр идем...

—Кайда бар, ди ул утлы корал?

—Инглизләрдә генә. Синең алтының бармы?

—Алтын юк!—дип кырт кисте Кара Козгын.—Шул бернигә ярамаган сары таш өчен никадәр корбаннар китерелгәнен ишеттек без дә. Безгә андый алланың кирәге юк! Ә коралны дошманнан сугышып алырга кирәк!

—Яхшы!—диде Мәргән.—Әле генә бер нәрсә уйладым...

Таң белән атларга атланган унбишләп кеше, Кара Козгын авылын калдырып, көнбатыш тарафына юнәлде. Аларның башлыгы—Мәргән һәм Кара Козгын улы Тау Бөркете иде.

Кечкенә чирү бик сакланып кына аучылар салган сукмаклар буйлап бара. Алга өч кеше җибәрелгән. Алар бер-берсен күреп атлыйлар. Соңгысыннан Мәргән күзен алмый. Ике мәртәбә кояш баеганчы баргач, шундый көтелмәгән хәл булды: алдан баручы егет кинәт кенә тукталды һәм иелеп нәрсәдер эзли башлады: чирү инглизләр эзенә юлыккан иде. Мәргән көнбатышка таба күрсәтте һәм:

—Менә шушы юл белән дошманның төп урнашкан җиренә чаклы барабыз, ләкин юл белән түгел, урман эченнән. Алар безнең эзләрне күрмәскә тиеш. Таптанмагыз монда!..

Күпмедер атлагач, тагын бер вакыйга булып алды: кинәт ботак-яфраклар кыштырап куйды, һәм мизгел эчендә боларны укларын атарга әзер тоткан һиндееңләр төркеме чолгап алды. Бу—җимшәннәр иде. Мәргәннең юлдашлары коралларын алырга да өлгермәделәр. Шул чакны куаклар арасыннан тавыш килде:

—Әй, Мәргән! Синме бу?

—Мин, Уан, Мин! Син кайда югалдың, дус?

Агачлыктан Уан һәм Зирәк Кондыз килеп чыктылар. Барысы өчен дә зур шатлык иде бу. Мәргән һәм Уан баштан үткәннәрен сөйләп алдылар. Ахырда

Мәргән үзләренең нинди эш буенча йөрүләрен әйтте. Бәлки, сез дә кушылырсыз, дип сорады ул.

—Әлбәттә!—диде Зирәк Кондыз.—Без нишләп читтә калыйк? Өстәвенә, син эзләгән урынны без беләбез: аксыл чырайлылар минем авылымны форт иттеләр бит. Өстәләп ныгыттылыр. Адмираллары да шунда урнашты. Арсенал да шунда. Дөрес, авыл тирәсендә шымчылар күп, ләкин безнең яшерен юлларыбыз бар, үтәрбез. Туздырыйк бергә козгын оясын...

Тагын өч тәүлектән соң фортка якынлаштылар, һәм тау башында тукталдылар. Авыл моннан уч төбендәге кебек ачык күренә иде. Шушында бәрелешнең бөтен ягы уйланылды.

Авылга яшерен генә ике төркемгә бүленеп керделәр. Өч-дүрт сакчыны шым гына юк итәргә туры килде. Берничә егет куаклар арасыннан барып, иң эре һәм иң бай биш-алты өйне берьюлы яндырып җибәрделәр. Авылда мәхшәр башланды. Офицерлар акырышуы, атышкан тавышлар, янгын чытырдавы—барысы бергә кушылды. Ә бу вакытта һиндеецләр яшеренеп кенә укларын очыралар һәм янгын сүндерегә маташкан гаскәриләрне кыралар иде. Ун минутлап үтүгә бар да хәл ителде: утыз-кырык солдат, мәетләрен калдырып, урманга качтылар. Авыл җирле халык кулында калды. Ләкин бу озакка түгел икәне барысына да аңлашыла иде.

Авыл тирәли сакчылар куеп, яндырылмый калдырылган арсенал янына килделәр һәм тәрәзәсез өй эчендә булган бөтен мушкетларны, дарыны һәм башка кирәк-яракны атларга төяделәр. Мылтыкларның ике йөзе Зирәк Кондызга тиде. Калган җиде-сигез йөзен Мәргән белән Тау Бөркете алдылар. Зирәк Кондыз авылны яндырырга боерык бирде.

Озак кына бергә баргач, җимшәннәр белән аерылырга туры килде. Зирәк Кондыз инглизләр белән туктаусыз сугышырга вәгъдә бирде. Уан аның белән калды. Алар Мәргән белән кочаклашып саубуллаштылар. Җимшәннәр Мәргән белән дүрт-биш егетләрен җибәрделәр: алар ике арада хәбәрче булырга тиешләр иде.

Дакоталар һәм чикәтаулар күтәренке күңел белән бардылар. Моның сәбәбе—уңышлы үткән һөҗүм һәм коралның кулга төшүе иде. Бигрәк тә Олы Кыяның улы шат иде. Эш шунда, егет бу орышта батырлык күрсәтте. Ул чакта дакота егете Мәргән һәм Тау Бөркете янындарак сугыша иде. Бер заман чикәтаулыга берьюлы биш-алты дошман сугышчысы ташланды. Аларның икесен Мәргән үз өстенә алды, берсенә Олы Кыя улы һөҗүм итте, ә икесе Тау Бөркетен чигендерә башладылар. Шул мәлне бер инглизле арттан килеп, чикәтаулының аркасына багинетын кадарга җыенды. Тау Бөркетен Олы Кыя улы коткарды. Дошманның берсен балтасы белән җәрәхәтләде, икенчесенә пычагын очырды.

—Рәхмәт!—диде чикәтаулы.—Исемең ничек?

—Минем исемем юк әле.

—Нинди исем әзерләнгән сиңа?—дип сорады Тау Бөркете.

—Житез Кугуар!—дип җавап бирде авызы ерылып киткән егет.

—Син Тау Бөркетен үлемнән коткардың, Житез Кугуар! Хәзер син ана туган буласың...

Чикәтаулар җиренә килеп җиткәч, инглизләрнең кысрыклавы йомшарганы мәгълүм булды. Бу, әлбәттә, әлеге Мәргән үткәргән операция белән бәйле иде. Чикәтаулар һәм дакоталар дошманга каршы бергәләп сугышырга сүз бирделәр. Мәргән үзләре белән бәйләнеш тотар өчен Тау Бөркетен алып китте. Кара Козгын аларга берничә дистә баш ат биреп җибәрде.

Берничә көннән соң Мәргәннең кечкенә чиреүе Олы Кыя биләмәләренә килеп җитте. Аларның исән-аман кайтып керүе, корал китерүе, юлбашчы улының исем яулавы барысы өчен дә олы сөенеч булды. Олы Кыя шушы

уңайдан бәйрәм үткәрергә карар бирде. Алдагы көндә андый бәйрәмнәр үткәреп булуыннан да шикләнә иде, ахрысы ул, кем белә дөнья хәлләрен?

Тантана иртә белән кояш чыккач та башланды. Зур мәйдан төрле кошлар, кыргый җәнлекләр булып киенгән кешеләр белән тулды. Алар ниндидер борынгы заманнардан башлап килгән, тирән фәлсәфи мәгънәгә ия булган биюләр, йола күренешләрен башкардылар, һәм бу күренешләр алар өчен бәйрәм генә түгел, үзләренең күпсанлы аллаларына табыну, аларның кичерүләрен үтенү, алда торган сынауларны уңышлы үтәүне сорау иде.

Менә җирле халыкның аллаларыннан берсе—Козгын Ата чыкты, һәм тагын дини-йола бию үткәрелде. Аңардан соң җәнлекләр һәм кошлар сыйфатындагы тагын берничә алла тиешле ихтирамны һәм табыну йолаларын кабул иттеләр. Инде барысы да иң Баш алланы көтәләр иде. Ниһаять, түгәрәк уртасына әкрен генә, мәңгелек яшәешне гәүдәләндерүче, төплелек һәм нигезлелек билгесе Әкәм-төкәм алла чыкты. Җыелган барча халык җиргә йөзтүбән ятып аны сәламләделәр. Иң Баш аллага төрле камнар, имчеләр, күз буучылар һәм башка теге дөнья белән бәйләнешле затлар ияргән иде. Инде бәйрәмнең барышы иң югары ноктасына җитте, гомуми тантана башланды. Мәйдандагы бөтен халык сихерләнгән кешеләрдәй, үзләре дә сизмәстән, төрле табигый булмаган хәрәкәтләр ясыйлар, ниндидер сәер тавыш белән кычкыралар.

Иртәнгә таба бәйрәмнең барышы ниндидер көчле рухка буйсынгандай бер төрле тәртипкә керә башлады. Әле күптән түгел генә аны томаланган кешеләрнең хәрәкәтләре мәгънәлерәк төсмер алды. Ул да булмады, ниндидер күзгә күренмәгән барабаннар халыкны үз артларыннан чакырып, тезеп, түгәрәк буйлап йөртә башладылар. Аяклар, куллар, хисләр, тойгылар һәм баштагы өзек-өзек булган фикерләр бер тәртипкә, котылгысыз зарурилыкка буйсындылар. Әгъзалар төзәйде, аяклар корычтай ныгыды, куллар корал эзли башлады, рухлар какшамас булды. Бу—сугыш биюе, туган илне соңгы сулышка кадәр сакларга әзер торучылар биюе иде.

Төне буе барган бу галәмәт Мәргән белән Сары Каенга гына кагылмады. Аларның хәзер үз алласы, үз кайгысы, үз бәхете бөтен нәрсәдән югарырак, өстенрәк иде. Алар әле атка менеп көнчыгыш тарафындагы очсыз-кырыйсыз прериягә чаптылар, әле көнбатышка, Кыялы тауларга, Сөт елгасына таба омтылдылар. Йөреп туйгач, икесе өчен билгеләнгән вакытлы алачыкта чыбыктан үрелеп, кызыл балчык белән сыланып ясалган мич янында җылындылар. Бүгенге төн—алар мәхәббәтенең тантана төне иде.

Дәфтәрнең соңгы битендәге язманы, Мәргәннең үз сүзләре белән җиткерәсем килә:

*"Ерактагы туганнарым! Атам-анам! Якташларым! Яшьли сөйгән ярым!*

*Сезне күрергә насыйп булырмы, белмим. Тәкъдирем шундый булып, кайта алмасам, кичерегез мине!*

*Зур вакыйгалар көтелә. Без һукә-сиу халыкларын берләштерә алдык. Зур яу төзедек. Ул чирүне атышырга, сугышырга өйрәтү эше миңа йөкләнде. Мин шушы халыкны дошманнардан саклауны үземнең бурычым итеп исәплим. Алар да безнең кавем кебек кара язмышка дучар ителмәсеннәр иде.*

*Бу көндәлегемне язудан туктыйм. Барып керерме ул туган ягыма, бер Алла гына белә.*

*Нәсимә, бәгырем! Аерылуыбызга бик күп еллар үтте, ләкин мин сине оныта алмыйм. Әмма кавышу безгә язмаган икән. Кичер мине, сине бәхетле итә алмадым!*

*Улыгыз, туганыгыз, якташыгыз Мәргән яки Максим Сабуров."*



# Равил Рахмани

## Хәтер

### I

Яр буйлары куак кына—
Оя-оя чатыр...
Дала иңләп илгә кайта
Шәҗәрәле Хәтер.

Сары-кызгылт яфраклары—
Безгә диган хаттыр...
Һәрберсе—йөрәк... җөйләрен
Ятлап укыр чактыр.

Тиздән барсы сибелешеп
Җиргә төшеп ятыр...
Җыерчыклы тарих сере—
Җәрәхәтле Хәтер...

Өсләренә яңгыр явар,
Кырау, чык чылатыр...
Фанилыкның гамьсезлеге
Сагыш-моң кузгатыр.

Тынып калыр аннан җиһан,
Кабат ак кар балкыр...
Язылмаган ал-ак кәгазь
Кемгә нәрсә әйтер?!.

Сулар акмый тормас җирдә,
Кайтыр язлар, кайтыр...
Бозны тишеп чыгар сабак—
Тамырларда Хәтер!

### II

Кардәш булып килеп таптың эзләп,
Йөрәгемә утлар аттың төзәп:
Биш йөз еллык хатаң, имеш... төзәт...
Бу кадәр дә ник син үҗәт, Хәтер!

Нәслең-тамрың, кыйлган эшең саный,
Көрше карттай кырыс,—таяк яный...
Алга чыга йөгереп, арттан калмый,—
Йөзең бик карт, холкың сабый, Хәтер!

Өзеп бәгъреңә, сызлап тора эчтә,
Телә җанны иртәсен дә, кич тә...
Юк, калдырмый урын башка хискә—
Уйдан үткен, моңнан нечкә Хәтер!

Эзәрлекләп күпме куып барыр?
Ничәвебез туктап уйга калыр?..
Уй төбендә, белмим, нәрсә табыр?..
Бу кадәр дә ник син авыр, Хәтер?!

Равил РАХМАНИ (1949) — *галим, тәнкыйтьче; балалар әдәбиятына багышланган хезмәтләр авторы. Шигырьләре журналыбызда беренче тапкыр басыла. Казанда яши.*

Кабыргага житә сыңар чаткы—
Балачактан картлыгыңа чаклы
Чолгый тәнне уты катлы- катлы...
Газабың да—татлы ялкын, Хәтер!

III

Югалтудан вакыт, диләр, дәва—
Фаҗигадән ерагая ара...
Буын арты буын ятып кала,
Хәтер үлми—Хәтер алдан чаба!

Карында ук сине килеп таба:
Нәсел өне күчә җаннан җанга...
Дәһшәт эзе төшә каннан-канга...
Юк, төзәлми—ачык тора яра.

Барган саен алда еллар кара,
Асыл затлар поскан кайсы кая...
Ил-Ватансыз үткән гомер зая—
Җәрәхәттән, сыкрап, Өмет тама.

## Татар юлы

Каралтмыйк та, тарайтмыйк та
Бабайлар кайткан юлны...
Диңгезләрдән диңгезләргә
Сузылган татар моңы.

Ярты тәүлек чыгып кояш,
Яңарта узган юлын;
Көн дә хәтергә уела
Тарих мең еллар буе—
Яктыра житмеш буын.

Заман арбасы ватылган...
Түгел Җир—сабан туе!
Җиһангирдан ятимлеккә
Ташлаган татар юлы.

Язмышына җибәрелгән
Сынауның хәтәр зуры:
Гайрәтле дә, гыйбрәтле дә
Җиһанда татар юлы.

Чәчелгән ярты дөньяга—
Тараткан кояш нуры.
Җан орлыгы чәчкә атса,
Ачылыр барыр юлы.

Җир—тарих җебе типчегән
Ямаулык белән тулы...
Шәрекъ-Гареб күлмәгенең
Җөе ул—татар юлы.

Еллар ябык заманда да
Кыйбласы һаман туры;
Изелүчедән кичерүчегә
Үзгәрә татар юлы.

Баш та имик, лаф та ормыйк,
Без җирдә—Алла колы!
Олы юлдан тар сукмакка
Төшмәсен татар юлы...

Әлмисактан бу көнгәчә
Сузылыр яшәү җыры.
Кара фал ачкан—ялгыша,—
Өзелмәс татар юлы!

## Йә бар ул, йә ул юк...

Яшьлек ул—чәчәге язмышның,
Соңыннан өлгерә җимеше...
Йозактай келт итеп ачыла булмышың—
Йә бар син, йәки юк син, Кеше!

Үстерә милләтең тиң күреп:
Җир сөреп, тир түгеп, дин биреп...
Һәм сынар үзенә хезмәттә иң элек:
Йә бар ул, йә юк ул Ир-егет!

Булсын дип сөюең канатлы,
Бәгъреңне, йә... азмы канаттың.
Чынбарлык яз белән, көз белән аңлатты:
Йә бар ул, йә юк ул Ярату!

Исемеңне күкләргә чөй, кабарт...
Җәй тавис койрыгың, башканы сүк-каралт;
Кабатла: менә мин—даһи! дип мең кабат—
Йә бар ул, йәки юк... ул Талант!

Сорамый Мәккәдә булганың,
Хөкемгә тартыла вөҗданың;
Үлчәнә ниятең, гамәлең, кылганың—
Йә бар ул, йә юк ул Иманың!

Бетәрме үгилек халәте,
Ник начар күренә әйбәтең?..
Атаң күк—якларга, биреп җан гайрәтең
Йә бар ул, йә юк ул Дәүләтең!

Һәр туган яңа көн тозаклы,
Һәр өмет учагың газаплы...
Кызарып баеган һәрбер кич азаккы:
Йә бар ул, йә юк ул Азатлык!

Камиллек үрнәге Табигать,
Ә тормыш—йә коллык, йә җиһад.
Син, Кеше, көрәштә үз бәяң хакын әйт:
Йә бар ул, йә юк ул Хакыйкать!

Исән ич аларның үз халкы—
Ник үсә чит телдә мең ятим?..
Чыгарыр хөкемен чал тарих—чын хәким:
Бармы ул, юкмы ул Милләтең!

## Кичке дога

И Тәңребез, аң бир безгә—
җәмгебезгә!
Еллар өзек... юллар төзик
Мәңгебезгә!

Ерак бабайлар рухына
тиң ит безне!
Күрик заман көзгесендә
милли йөзне!

Кара төндә, таңдай сызлып,
кайтсын хәтер.
Җаһиллеккә хак сүзне ул
әйтсә әйтер?!

Саркып керсен яшәү сүле
тамырлардан.
Утырмасын сыкрап милләт
камыллардай.

**Кыя-таудай күккә ашсын**
**милли тирәк.**
**Терек суы чишмәседәй**
**типсен йөрәк!**

**Дастанга тиң Ватан корыйк**
**өр-яңадан!**
**Килсен көннәр шатлык төяп**
**кәрван-кәрван.**

**Карап тормыйк шәҗәрәгә**
**кан калтырап.**
**Йөрмәсен моң дөнья буйлап**
**яфрак-яфрак!**

**Кайтсын дөньяны тарсынып**
**очкан кошлар...**
**Агартмыйк баш: бу милләт, дип,**
**кайда кышлар?**

**Җәеп, Тәңрем, галәм утын—**
**таңнар яса.**
**Без нур булып Сиңа кайтыр**
**җан лабаса!**

## Казан—бәхет капкасы

**Күк илчесе манаралар...**
**Мәңгелектән—азаны.**
**Туктала җан гомерлеккә:**
**Бу, дип,—минем Казаным!**

**Таң нурларына ачыла**
**Казан—Шәрекъ капкасы.**
**Чал тарихтан, кырыс хәтер,**
**Килеп тәрәз какмачы!**

**Нинди татлы бу яшәеш,**
**Тик ник кыска соң гомер?!**
**Дөньялыкта чәчрәп яныпп,**
**Мәңгелеккә син өлгер...**

**Ургып ача заман җиле...**
**Казан—Гареб капкасы.**
**Кузгал, милләт, чык—сүзең әйт,**
**Язмыш юрап ятмачы!**

**Җирең көтә изге гамәл,**
**Ай-кояшлы вазыйфаң;**
**Кешелеккә Хак сүзен илт,—**
**Нурга чумсын бар җиһан!**

**Сынала җан, ныклы иман...**
**Казан—Кыйбла капкасы.**
**Торма ишек төпләрендә,**
**Бәхет, түргә атлачы!**



Фәнзаман
Баттал

## САТИРИК ХИКӘЯЛӘР

### Күршем шәкертләре

Эшләре хутта күршем Саматның. Кая барса да үзе укытып чыгарган ир-егетләр, хатын-кызлар кин елмаеп каршы ала. Шуна күрә сөйләшүендә үк һавалык сизелеп тора. Тавышы бөереннән чыга.

Анын белән якыннан танышу бер ел элек—мин яна фатир алып, бер подъездга урнашкач булды.

Кәефем кырылып кибеттән кайтышым иде, баскыч төбендә очрады бу. Эскәмиядә утыра. Үз-үзеннән бик канәгать кенә сигарет пыскыта. Туктап исәнләштем тегенен белән, бишенче катка менгәнче бераз сулыш алу булыр, дип янына килеп утырдым. Чү! Нәрсә бу? Без тарта торган сигареттан төтен чыга, ә моныкыннан тәмле хуш ис тарала. Түзмәдем, игътибар иттем. Шундук сизеп алды, каһәр. Әкрен генә кесәсенә тыгылды, салмак кына ниндидер кара пачка чыгарды.

—Тартып җибәр, күрше. Ашыгу—шайтан фигыле, диләр бит, бераз ял итеп утыр.

Ул биргән сигаретка саклык белән генә күз салдым. Тел очын иреннәре буйлап шудырып алды да тәмле генә елмаеп куйды Самат һәм нурланып киткән карашын мина юнәлтте.

—Үземдә укып чыккан бер кыз горисплоком буфетында эшли. "Золотое руно"ны шул китереп тора.

Андый тәмәкене күргәнем бар иде барын. Гомер булгач, менә сигаретын да күрергә насыйп икән.

Кабызып бер-ике суыруыма, күршем буш кәрзинемә ым какты:

—Өйдән чыгып киткәндәге кебек үтә күренмәле синен бу кәрзинен, күрше.

Шул җитә калды, кибетләрдән ит таба алмау аркасында кителгән кәефем нерв кылларыма кабат ышкылып үтте.

—Һы, ит юк дисен, ә!—дип куйды күршем уйчан гына.—Пүчтәк сөйләмә син, күрше, совет влачына күләгә төшермә. Безнен илдә юк әйбер юк ул.

Аннары салмак кына урынынннан купты һәм торып басты.

—Күпме кирәк?

—Бер-ике кило булса да ярар иде дә бит...—дидем мин өметсез генә.

---

Фәнзаман БАТТАЛ (1939)—*сатирик язучы; «Сакалыңа ут капса...», «Сигезенче оҗмах», «Безнең сурәт» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

—Алгач-алгач биш-ун кило ал инде син аны... Әйдәле, минә бу ашханә складына кагылып чыгыйк.

Күрше йорт астында гына иде ул ашханә. Арт ишектән кердек. Килеп тә кердек, гаҗәп тә матур, гаҗәп тә сөйкемле бер кыз каршыбызга йөгереп килде.

—Ай, исәнмесез, Самат абый!—дип куанды сылукай.—Рәхим итегез!

Күршем ләззәтле итеп көлемсерәде, сизелер-сизелмәс кенә баш иде:

—Саумы, Зилә кызым. Бу юлы бигрәк тә күркәм күренәсең әле син.

Бер-ике минут гөрләштеләр, хәбәр алыштылар. Аннары Самат минем йомышка кайтты.

—Син, сеңлем, бу абыеңа биш-алты кило ит үлчәп бир инде. Кубрәге дә мишәйт итмәс.... Әйбәте булсын түлке.

Кызга, гүя, үз бәхетенә илткән юлны күрсәттеләр—канатланып коридор буйлап йөгереп китте дә бер бүлмәгә кереп югалды. Ул арада полиэтиленга әйбәтләп төрелгән бер күтәрәм итне китереп тә житкерде.

—Бик яхшы колбасный паштет бар, Самат абый,—диде ул, ярдәмгә яравына шатланып.—Кирәк булса, һинд чәе дә бирә алам.

Болары да минем файдага булды. Складтан чыккач, Самат кул гына селтәде:

—Мина кирәкми. Өемдә ике суыткыч, икесе дә жан теләгән ризык белән тулы, туганкай. Миндә укыган бер егет базада эшли бит. Үземә кирәк азык-төлекне шуннан төяп кайтам мин. Анда күркә ите белән кипкән балыкка хәтле бар. Складның озынлыгы да, валлаһи, бер чакрымга житәдер... Ул егетне дә күрсәтермен әле шушы арада. Зиләне дә, сабакташы буларак, бирегә шул урнаштырды бит.

Беркөнне миңа иртә таңда Пермьнән кунаклар килеп төште. Абый белән жиңги инде... Килгән хутларына бер ярты чыгарып утырттым. Үзем дә кунаклар хөрмәтенә күтәрдем. Аз булса да түбәтәй астын кыздырып жибәрде, ләгыйнь. Күкрәк сукканымны үзем дә сизми калдым. "Эшкә бармасам да сүз әйтүче булмас, без үзебез начальство,—дип жибәрдем.—Заводның агач цехы хужасы—үзем!"—дип ярып салдым. Тагын бер-ике мәртәбә тотып алгач, гади балта остасы икәнлегемә үзем дә ышанмый башладым. Икенче көнне махмыр башны таң тишеге ачылганда төзәттек. Тагын бер көн югалды. Бәйрәм бер булыр, ачы әйрән көн дә булыр, ди бит бабайлар. Миңа да прогулның ачысын тояр, начальниклар алдында хисап кылыр көн житте.

Шул хакта уйлап баскычтан төшеп барам, үз фатирының ишеген киң ачып күршем Самат чыгып килә. Сөйләшеп китттек. Кыен хәлемне аңлагач, күршем уйга калды.

—Дә-ә, дә!..—дип куйды ул өстән генә карап һәм шундук жанланып китте.—Кайгырма, Хәкимулла туган, минем элеккеге бер студент больницада скорый пумыш йөртә. Тиресеннән чыкса чыгар, әмма дә ләкин бер бюллетень таптырыр... Әйдәле, миңа кереп чыгыйк.

Кердек. Самат ипле генә итеп креслога чумды, телефон төрепкәсен күтәрде.

—Исәнме, чибәр сеңлем! Үсеп буламы? О-о, яхшы, яхшы! Галимжан дигән матур егетебез кайтса, Самат абыйсына шылтыратсын иде. Янәшәдә утыра дисенме? Бәрәкаллла! Каяле сөйләшик үзе белән... Йә, Галимжан энем, ни хәлләр! Молодец! Син искә төшсәң дә, сөенеп куям инде мин.

Аннары хәл-әхвәл белеште, гадәтенчә, күңелгә ятышлы итеп кенә кеткелдәп алды, төп йомышка тукталды. Килеште.

—Фамилиясеме? Гарипов. Ә исеме Хәкимулла. Әйе, көтәм. Китереп житкерсәң иде, энем.

Чирле чакта ашыгыч ярдәм машинасының бик озак килүенә зарланырга күнеккән бәндәләр бит инде без. Бә-әй!... Кешесенә карап гаҗәп тә тиз йөри икән ул, рәхмәт төшкере. Биш минут үткәндерме-юктырмы, чирләп

эшкә бармаганлыкны күрсәткән кәгазь кесәмә кереп тә ятты.

Саматтан белем алып чыккан бер егет кирпеч заводында мастер икән—анардан шәһәр читендәге бакчама йорт салу өчен арзан гына бәягә кирпеч алдык. Ләкин... Йа Хода, йортка идән җәя башлавыма, йортым янына бер мотоцикл килеп туктады. Мин аңыма килгәнче, рәхим итүенең сәбәбен дә әйтте.

—Контрольдән мин, Хәсәнов булам,—диде ул коры гына.—Кирпеч алганлыгыгызга кәгазегез бармы?

Тез буыным тотмый башлады. Кирпечен алуын алганбыз да бит, тиешле документын кайгыртмаганбыз, ангыра башлар. Өйдә бар, дигән булдым, үзем белән килмәгән, дидем. Иртәгә китерерсен, дип, үзе эшли торган оешманың юлын бик тәфсилләп өйрәтеп китте.

Йортка кайтып кердем дә, Саматның бусагасына егылдым. Кайгымны аңлагач, күршем ихлас күңелдән көлеп җибәрде.

—Хәсәнов дисең, ә? Контрольдән, димәк. Хәзер, Хәкимулла брат, авыл хуҗалыгы фәннәре буенча имтихан алам мин анардан.

Тагын шул ук хәл белешү. Техникум елларын искә төшерү. Аннары төп мәсьәләне хәл итү. Теге баштан сөйләшкән Хәсәновның тавышы трубкадан миңа да ишетелеп торды.

—Ә шулай да бер кәгазь юнәтегез инде ул күршегезгә, Самат абый,—диде ул бик эшлекле тавыш белән.—Шунсыз ярамас, милиция кешеләренә тап булуы бар.

Суга карап әйткән диярсең. Өч көн үттеме-юкмы, тәки милиция кулына эләктем. Юк-юк. Кирпеч мәсьәләсе буенча түгел. Бәла көтмәгән җирдән килеп чыкты. Хезмәт хакы алгач, берләшеп салган идек. Артыграк төяп ташлаганбыз. Исерек булсам да хәтердә, көч-хәл белән өйгә кайтып барышым. Шулчак яныма җәһәт кенә бер машина килеп туктады. Як-ягыма погонлы ике кеше килеп басты. Артык иркәләп тормадылар: гәүдәмнең күтәрә алган кадәресен—үзем, калганын алар күтәрде. "Ә" дигәнче машинага кертеп тә утырттылар. Айнып ук киттем, ахры, үз-үземне сүгәргә керештем: Эх, сабакы син, Хәкимулла, мин әйтәм, килеп каптың бит, сәрхуш. Монда инде Самат күршең юк, рәхим-шәфкать көтмә», дим. Баксаң, эчтән түгел, кычкырып битәрлим икән үземне. Машина, тәгәрмәченә таяк тыккандай, туктап калды. Погонлыларның берсе миңа сорау биреп куймасынмы?

—Туктале, брат, нинди Саматны сүгәсең син?!—диде катгый итеп.—Кайсы Самат ул?!

—Юк,—мин әйтәм,—үземне сүгәм, иптәш милиционер,—дим.—Күршем Самат кебек кешене сүгәргә түгел, аның кулын үбәргә кирәк,—дим.

Чокчына торгач, кайсы Самат турында мыгырдавымны тәки ачыклады бит! Аннары, күршемнең үзе кебек үк, тәмле, бик ләззәтле итеп елмаеп җибәрде.

—Машинага салганда сине катырак тоттык, брат,—диде бу милиционер, үкенгән сыман.—Син инде гафу ит һәм бу хакта Самат абыйга ычкындыра күрмә. Мин бит аның бывший шәкерте. Үпкәләве бар.

Машинаны кабат кабыздылар да кирегә бордылар. Киттек. Кабат туктады машина.

—Самат абыйның подъезды шушы,—диде күршемнең шәкерте.—Димәк, син дә шушында торасың. Әйдә, төш, кереп йокла! Саграк бул, берүк бәреләкүрмә. Самат абыйга сәлам житкер.

Егетләр, рәхимле генә саубуллашып, китеп бардылар. Мин закон кешеләренең сүзен изге саныйм. Шуңа күрә иң элек, алар әйткәнчә, кереп йокладым, ә икенче көнне Самат күршемә кердем. Билгеле, башта мең-мең рәхмәтләр укыдым:

—Эх, Самат, синең үзеңнән, шәкертләреңнән күргән игелекнең чуты юк. Шундый рәхимлеләр, кайда гына эшләмәсеннәр, сине ихтирам итәләр,— дидем мин.—Шулкадәр белемне, күңелләренә шулкадәр изгелекне кайсы гына уку йортында салып өлгерден соң үзләренә?—дидем.

Саматның күңеленә шул хәтле хуш килде бу сүзләрем—тәмам эреп китте. Үзе елмая, күзләре челт-челт йомылып тора, йөзе нурланганнан-нурлана бара.

Валлаһи дип әйтәм, оеп калды күршем. Бераздан гына, соң гына телгә килде, һәр сүзен бик тә тәмле, гаҗәп баллы әйберне суыргандай әйтеп бирде:

—Агрономнар алар, һәркайсы безнең техникумны, авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлады,—диде.

Һай, кайда гына эшләсәләр дә, иллә дә миһербанлы кешеләр икән бу агрономнар!

## Җәза

—Йә, житте, сүз куертудан фәтуа юк,—диде колхоз рәисе, нәрәткә җыелган ирләргә кырыс карашын ташлап.—Үлгән кешене җир өстендә калдырып булмый. Үзегезнең дә борыннарыгыз сизәдер. Үлүенә ике-өч көн үткән булырга тиеш... Көннәре дә җәһәннәм кебек кызу бит әле. Чир тарала башласа...

—Сиңа, читтән килгән кешегә барысы да ансат... Син аның кем икәнен белмисең. Авылның утыз ике кешесен аттырган, илледән артыгын төрмәгә тыктырган Рауза бит ул! Ятим калып, күпме бала-чага кырылмады тагын!..—дип сүз башлады гомере буе "Мал йөгертүче Хәмәй" дип йөртелгән ветврач карт.—Мин үзем дә, атам-анам булган килеш, дитдум малае булып үстем. Әгәренки дә шул мөртәтнең үләксәсен күмәргә барам икән, җәннәткә күчкән бөтен нәсел-нәсәбем каргап ятачак.

—Тормыш кеше гәүдәсен генә түгел, чучканыкын да күмдерә ул, Хәмәтдин агай,—дип зәһәр елмайды рәис. Ләкин күзләреннән кырыслык югалмады.

Халык гөжләшеп куйды. Барысының да уртак фикерен дуңгыз фермасында каравылчы булып йоклаучы Гыйлмулла әйтеп бирде:

—Һей,иптәш персидәтел... Мин күмгән чучкаларның чуты-хисабы юк. Хәзер куш менә мең дә беренче чучканы күмәргә, эһ тә итмичә күмеп бирәм. Пычрак булса да җан бит ул. Аны бөтен кеше дә күмә...

—Ә кешене?..

—Безнең әле бер кешене дә гүргә индерми калганыбыз юк, Аллага шөкер!—дип чәчрәп торды Кызрач Шәркәй.—Зиначы Шәмсияне дә, аны суеп үтергән малаен да күмдек. Түлке шунысын да бел, Радик энем, безнең авылда аның ишеләрне упши зыяратка күммиләр. Андыйларның урыны читтәрәк, Шайтан чокыры янындарак.

—Сизеп торам,—диде рәис, түгәрәк йөзендәге тирен сөлге хәтле кульяулык белән сыпыра-сыпыра,—бу мәетне дә шунда күммәкче буласыз. Барыгызның да теләге шундый икән, хуп мәйле, шунда күмегез, алайса. Мин бит сезнең гореф-гадәтне җимерергә килмәгән.

Беркемнең дә җеназага җыенмавын аңлап бетергәч, капыл гына урыныннан калыкты да колхоз рәисе, сулыш та алмыйча, боерык бирә башлады:

—Алайса, көндәлек нәрәтне тыңлагыз. Син, Гарифҗан абый, печәнчеләргә аш илтәсең . Сабир белән Әхмәдиша кибән куярга барыр. Шәмсулла, Сафа, Әхәт, Мансур Шайтан чокыры янында чокыр казырлар. Түләве—тариф буенча. Размеры икегә бер ярым булсын. Харис белән Әшрәфҗан ферма ишекләрен...

Ләкин ишек төбендәрәк утыручы берничә ир, дәррәү кузгалып, ыгы-зыгы тудырды.

—Юк-юк! Чокыр да, кабер дә казымыйбыз. Ник шунда колхоздан кудыртмыйсың...

—Күрше колхоздан чакыртыйммыни инде?! Ояты үзегезгә булыр ...

—Күршеләр дә казымаячак. Ул бәдбәхетнең зәхмәте аларга да күп тиде. Берәү дә килмәячәк!

—Һи, сезгә ялынып торганчы...

Хәтере калган хужа, барысына да кул селтәп, ишектән чыгып та китте, җитез "Рафик"ка кереп тә утырды . Шоферына бер генә сүз әйтте:

—Район үзәгенә!

* * *

Ул озак яшәде... Башкалар гыйбрәт алсыннар, ул күренгән яки искә төшкән саен гасыр михнәтләре хакында балаларына сөйләп торсыннар, дигәндер Ходай—аның гомерен сузды да сузды... Заманында агач аягының авыл урамы буйлап гөрселдәп үтүен ишетеп үскән балаларның да күбесе гүрдә инде. Кайберләре сугыштан кайтмады, шактые картаеп үлде, күбесе пенсиягә дә чыгып өлгермәде... Сабантуй тоткан өрлектәй ирләр үлде, бу һаман калды. Ул картаеп беткәндә әле мәктәп юлында гына йөргән авылдашларының чәчләре чаларды, йөзләрен җыерчыклар сарып бетерде, ә ул һаман яши бирде. Юлда каршы очраган чакларында урамның икенче ягына чыгарга ашыкты кешеләр: сәлам дә бирмәделәр, аныкын да алмаска тырыштылар. Ул күренүгә, сабыйлар, тыннары катып, өйләренә йөгерделәр. Чөнки туа-тумыштан каһәрле дә, шомлы да сүзләрне әти-әниләреннән, әби-бабаларыннан күп ишеттеләр:

—И, Ходаем, Чатан Рауза килә, урамга чыга күрмәгез, җене кагылыр!..

—Аның яныннан үткән кешегә зәхмәт кагылучан була, якын килмәгез.

—Күзенә карасаң, йоклаганда саташырсың, карашынны читкә борып үт! Эченнән генә булса да «әстагъфирулла!» дияргә онытма.

Авыл халкының инануынча, мондый кансыз бәндәне күптән инде каргыш сугарга тиеш иде. Ләкин, дистә еллар буе бөтен авыл белән каргап яшәсәләр дә, каһәр дә төшмәде сыман, чәнчелеп тә китмәде. Ходай аңа катырак җәза сайлады: Чатан Рауза үзе җәфалаган, кан-яшь койдырган, төрмә-сөрген юлларында йөрткән авылдашларының җирәнүле, нәфрәтле карашы астында яшәде дә яшәде... Туксанына җитәрәк, ул инде, кешедән бигрәк, маймыл сурәтенә керде. Яшьлегендә үк авызына сыймастай булып купайган теш казнасы, корышкан иреннәрен ертырдай булып, бөтен барлыгы белән алга калыкты. Тора-бара, башкалары да коелып беткәч, азау тешләре генә ыржаеп калды. Кайчандыр бөтен авылны дер селкетеп гөпелдәгән агач аягы, заманча итеп әйтсәк, протезы, хәзер инде үзе каләр йөкне хәтерләтә: урамнан үткәндә ул кырмыскага тагылган солыны хәтерләтә. Шулай булса да, һәр йорт яныннан үткәндә шыгырдавык тавышы белән сукранып куя:

—Барыгызны да аттырашы калган,ышбулышлар! Тамырыгызны корытып бетерә алмадым, контралар!

...Инде фани дөнья белән саубуллашкан картларның исән чакта сөйләгән хатирәләренә караганда, борынына егетләр исе керә башлаган елларда ук иштәш ахирәтләренә үчлек белән, кара көнчелек белән карый башлаган Рауза. Егет затлары ахирәтләрен почмак саен диярлек саклап торалар, назлымы, төртмәме сүзләр сибеп калалар, аулаграк урыннарда чәчбиләрнең билләренә кул салырга да күп сорамыйлар икән. Кайбер чытлыклары бит, муен тирәләренә иреннәрен дә тидергәлиләр имеш. Ә Раузаны саклап торучы да, аңа мәхәббәтле караш ташлаучы да юк... Күпәт авызда гына булмаган хикмәт. Кызның дорфа теле, яшьтәшләрен адым саен йә укытучыларга, йә ата-

аналарына әләкләп торуы егетләрнең бәгырен катырып бетергән. Башка кызлар кияүгә чыга тора, ә монын белән, күнел өчен генә булса да, капка төбендә сөйләшеп торучы да юк... Тегеләр сандугачтай матур, сыбызгыдай әче тавышлы балалар таба, ә моның хатын-кыз затыннан икәнен дә белмиләр сыман. Ә инде сыңар аяк хөкеменә дә калгач, әйтеп тә торасы юктыр, ир заты борылып та карамас булды.

Хәер, ашыкмыйк.

...Үз гомерендә ике ир күрде Рауза. Беренчесе район комсомолыннан вәкил булып килгән ач яңаклы, йөгерек күзле урыс егете иде. Күзләренең шул тиклем хәрәкәтчән булуын егет бер сулышта аңлатып бирде.

—Мин бит акларга каршы сугышып йөрдем. Уңнан да, сулдан да, алдан һәм арттан да атып кына торалар анда. Шуңа күрә баш та бөтерелеп кенә тора, күз дә барысын да шәйләп торырга күнегә.

Рауза җитәкләгән өч кешелек комсомол ячейкасының эшен тикшерү әлләни вакыт алмады: революция дошманнарына карата сизгерлекләре бармы—бар, продотрядның нәрсә икәнен беләләрме—беләләр, большевиклар эше өчен җаннарын бирергә әзерләрме—әзерләр. И вәссәлам!

Рауза шул ук төнне комсомолның бөек җиңүләре өчен аягын бирде. Районнан килгән җитәкчесе белән печәнлек сәндрәсендә тарткалашканда, астындагы такталарның шуышкалавын сизсә дә, нәфес кайнарлаткан шушы төндә исереп киткәндәй булды—сырты белән тойганын башы белән чамалап өлгерүдән гаҗиз иде. Бергәлекнең иң ләззәтле мизгелендә ике такта арасының киңәеп китүе булды, Рауза сәндрәдән абзар идәненә очты. Идән генә түгел иде шул аста!.. Атасы ташып куйган танадай зур ташлар өстенә килеп төшүгә үк, измәсез салынган стенага охшап торган кирпеч өеме уң аягына ишелеп ауды. Ләззәттән башланган чинавына илереп ыңгырашу килеп кушылды. Балтыр сөяге чәрдәкләнүдән Рауза гомерлеккә чатан калды ... Ә егет? Аңа, кем әйтмешли, чуртым да булмады—революцион сизгерлеге белән әлеге такталарның берсенә тотынып өлгерде һәм шул минутта ук авылдан чыгып тайды.

Кызларының атакайланып йөрүенә ачынып яшәүче диндар, йомшак күнелле әтисе белән әнисе, бу вакыйгадан соң кайгырышып тынычланганда, юкка гына :

—Бәлкем шушы фаҗигадан соң акылга утырыр, авылдашларның һәр гамәлен районга җиткереп торудан туктар,—дип өметләнделәр. Рауза тагын да үчләшеп, задурлашып китте. Район большевиклары ясатып биргән агач аягына күнегеп бетүгә үк, теге чактагыдан да тизрәк, тәвәккәлрәк җилдертә башлады. Ирләрнекедәй эре сөякле гәүдәсе белән башын тоташтырган кыска, юан муенын борып та тормас булды: дошманына таба һәрвакыт пләмә үгезе шикелле, хәзергечәрәк әйтсәк, танк сыман туп-туры элдертә. Каеннан ясалган аягын кигәч, күкрәге дә киңәеп киткәдәй булды, замана героена охшап калды.

Ни өчен аяксыз калуын авылдашларына да, район ЧКасына да аңлата белде: имеш, авылдан ерак түгел олы юлда ниндидер контраларны күзәтеп барган да бу, тегеләр Нарат Чокырына таба борылып кача башлагач, артларыннан ияргән һәм төнге караңгылыкта ярдан егылган. Ә андагы ташлар исә абзардагыларга караганда да эрерәк.

Шулай итеп, комсомолка Рауза район герое булып танылды һәм "контралар эзәрлекләгәндә кылган батырлыгын" гомере буе мәктәпләрдә үткәрелә торган очрашуларда сөйләп йөрде:

—Без Лилин-Ысталин партиясе өчен аяк-кулларны гына түгел, җаныбызны да кызганмадык,коммунистик байрак астында һәрвакыт алга бардык. Контрлар безнең авылда да хисапсыз иде. Алар икмәкләрен яшерделәр, кача-поса

малларын суеп ашадылар. Ә без эзләренә төшә тордык. Бервакыт, мәсәлән, бер кулакны раскулачить иткәч, үзен авылдан олактыргач, мунчасын семьясына биргән идек—яши торсыннар инде әйдә, дип. Күзәтеп йөрим, лыкма ризыклары юк боларның...

Сүзе шушы урынга җиткәч, Рауза теш казналарын киереп, серле генә елмаеп тора да, йодрыгы белән һаваны ярып алгач, капыл гына дәвам итә:

—...ләкин берсе дә ачтан үлми! Биш баланы бу хатын ничек асрый? Менә бит хикмәт нәрсәдә! Димәк ки, яшергән ипиләре булырга тиеш боларның! Допрос алам—әйтмиләр. Шуннан соң, мин боларның барысын да шул мунчаларына тутырам да,өсләреннән бикләп куям. Комсомоллардан чиратлы сак куям. Ике-өч көн үткәч, тагын допрос алам—әйтмиләр ысбулычлар. Кече балалары үлгәч кенә, калганнары ачтан әлсерәп беткәч кенә телләре чишелде контраларның . Баксаң, абзар артына өелгән тирес астына ике капчык он яшергән булганнар икән! Кызыл Армиягә, совет милициясенә ризык җитмәгән чакта авыз тутырып икмәк ашарга хаклары бар идеме аларның?! Юк иде,билгеле! Шуңа күрә дә нәселләрен ачлык белән корыттык. Чөнки алар халык дошманнары иделәр.

Әйе, "дошманнардан" нык чистартты авылны Рауза. Ул заманда яшәгән бер агайның, колхозга алынган атын күргән саен, күзләренә яшь килә икән. Җиң очы белән күзен сөртеп, сыкранып торганда Рауза күреп ала моны.

—Нигә балавыз сыгасың, Фәйзрахман?

Фәйзрахман, кайнар сулышын эчкә ала-ала, үксеп куя:

—Соң... Рауза, ничек еламыйсың... Мөлкәт буларак чурт сим инде, җан иясе буларак кызганыч бит... Бер ай эчендә бетәште бит малкай, колхозга кергәч... Авызын ачса, күте күренә бит...

—Ызначыт, колхоз ошшамый ссиңа, иптәш Ысталин зирәклеге белән төзелгән яңа тормышш ошшамый?

Шул төнне Фәйзрахман авылдан бөтенләйгә югала...

Бигрәк тә яшьлегендә күзе төшеп тә үзенә игътибар итмәгән, башкаларга өйләнгән егетләргә,шуларга кияүгә чыккан кызларга каныкты Рауза. Тегеләре дә, болары да олыгаеп бетте инде бетүен, әмма Раузаның нәфрәтле көнчелеге елдан-ел көчлерәк дөрләде, ачы ялгызлыгын шулардан күрде. Теге чактагы егетләрнең берсе—хәзер инде ир уртасы булып баручы Габделәхәт читәннән корыштырган һәм сыер тизәге белән сыланган сыер фермасы янында тәмәке төреп торганда Рауза килеп чыкты. Ниндидер сүз катты да иргә, тегенең кулындагы бөкләнгән гәҗиткә игътибар итте. Ертылган читеннән Сталин рәсемен шәйләде.

—Туктале, бир әле, Гапти гәҗитенне!.. Әй-е! Сөекле юлбашчыбыз иптәш Ысталинның партритына төреп тартасың икән бит син тәмәкене! Иптәш Ысталинны яндырып куаныч табасыңмыни?!

Габделәхәт куырылып килгәндәй булды да, уч төбедәй гәҗит бөкләмнәрен калтырана-калтырана сүтәргә кереште:

—Юк, Рауза, юк!... Валлаһи, юк! Менә, кара, аның сурәтенә тимәдем.

Рауза, тишәрдәй күзләре белән текәлеп, агулы елмайды:

—Алдама! Әнә, чите ертылган... Иптәш Ысталиннан үч алу юлын тапкансың син, контра!

—Кая, ул бит тырнак очы хәтле дә юк. Кәгазе шулай ертылды бит...

—Менә шулай була ул, Гапти. Берәр сазнателни кызга өйләнгән булсаң, мондый җинаятькә бармаган булыр идең син. Аңлаткан булыр иде. Коммунистик сизгерлегең булган булыр иде! Ә болай... һе-һе... саубуллашсак та ярыйдыр. Киттем әле мин.

Икенче көннән башлап Габделәхәт авылда күренмәде. Бөтенләйгә югалды. Хәбәре дә килмәде.

Язларның берсендә авылдан үтеп баручы таныш булмаган бер кеше капка төбендә утыручы ирләргә:

—Суканы бетердегезме әле?—дип эндәшкәч, җор телле Сафиулла:

—Безнең колхозда сукасы да, сабаны да калмады, барысы да бетте,—дип кычкырып калган. Кирәк бит,ходавәндә—нәкъ шул вакытта тыкрыктан Рауза килеп чыга. Гөрс-гөрс атлап килә дә, мыскыллы карашын төбәп,көйдереп тә ала тегене:

—Колхоз строеннан көләбезме,Сапый. Белеп кал, сабан-суканың бөтенләй кирәге булмаган җирләр дә бар безнең Сысысырда!

Ике-өч көн үтте микән, Сафиулланы ат менгән погонлылар алып китте. Өстән салкын яңгыр коя,ике ат арасында баручы Сафиулла, тая-тая, авылга борылып карый-карый, бөкерәеп атлый...

Ирләр китә, ләкин хатыннары кала. Алар, балаларын ачтан үтермәү хакына, кесәгәме,итәк астынамы бер-ике уч ашлык салып кайтырга мәҗбүр. Еш кына аларның каршына колхоз башлыгы Әхмәдиша чыгып баса, килеш-килбәтләрен, гәүдәләрен күзәтә: урлашмыйлармы, кабарып-бүлтәеп торган җирләре юкмы, янәсе. Кайберсенең кесәләренә дә суккалап ала. Аннары, моңсу гына карап тора да:

—Урлаша, эләгә күрмәгез инде,катыннар,закун бик тә каты бит,—дип куя.

Шундый чакларда еш кына Рауза килеп җитә. Ул иң әүвәл, нindидер кызыл значоклар тагылган күкрәген киереп, башлык алдына баса:

—Син, иптәш Хәйруллин, үзең караклар пособнигы. Урлашуларын юри сизмәмешкә салынасың. Кесәдә булмый ул хатын-кызның урлашканы,ыштан төбендә була.Шуннан эзләргә кирәк!

—Соң, Рауза...

—Иптәш Мотыйгуллина диген!

—Соң, иптәш Мотыйгуллина...—дип мыгырдана Әхмәдиша, гаепле кешедәй.—Ни бит... оят бит... Хатыннарның итәк асларына ирләре генә керергә тиеш бит. Анда да, мулла абзыйлар әйтмешли, "өммәти-өммәти, көндез тимә, төннә ти"... Кеше күргәндә үз ире тию дә хәләл түгел, ягъни...

Бу хәлне читтән генә бөтен авыл күзәтә, чаярак бала-чага бәхәс купкан җиргә якынлаша. Шуларны сырты белән сизеп торучы Рауза, сикереп китәргә әзер туп кебек, ешрак калкына башлый.

—Урлаша икән, бөтен җиренә дә тияргә ярый, иптәш Хәйруллин. Тимисең икән, персидәтел дип тормаслар, колхозны талаткан өчен үзенә дә бер чара табарлар. Карап тор, болай итәләр аны...

Ул, җәһәт кенә борылып, тилмерүле караш белән тезелеп торучы хатыннарның йөзләренә текәлә дә, тимер очлы агач аягы белән кайсыныңдыр аяк йөзенә китереп баса. Өнсез калган, авыртудан сулышсыз калган ана, аягын шудырып алмакчы була. Шуны гына көткәндәй, болай да иләмсез таза,тыгыз гәүдәле Рауза бөтен авырлыгын агач аягына күчерә һәм ияген тегенең чыраена терәргә маташкандай,теш арасыннан сыгып кына боерык бирә:

—Итәгеңне күтәр,корткыч! Күтәәәр!..

Сүзен тагын да үтемлерәк итү өчен, тимер коршаулы "аягын" бөтереп тә ала.

—Соң, Рауза,—дип өзгәләнә хатын,—кешеләр, ба-балалар карап тора бит.

—Күтәр диләр сиңа. Урлаган нигъмәтеңне күрсәт!

Теге мескеннең күлмәген күтәрә башлавы була, Рауза келәшәдәй каты бармаклары белән ыштан бөрмәсеннән элəктереп ала, корбанының аягын сытарлык итеп тагын бер мәртәбә басып куйгач, артка талпына. Шулвакыт җиргә йодрык хәтлерәк янчык килеп төшә. Әхмәдиша, кыенсынып, башын читкә бора.

Ләкин шундук Рауза тавышы сискәндерә:

—Син коммунист кеше, иптәш Хәйруллин, хакыйкатьнең күзенә туры кара.

—Хакыйкатькә туры карыйм да ул... Ну бит бөтен җиргә дә карау оят...

—Бу корткычларны аткарып бетерми торып, бернәрсәгә дә күз йомарга тиеш түгелбез. Кадерле партиябез шулай куша.

—Аткарган саен ятим балалар күбәя тора бит әле монда.

—Ничауа! Контрлардан барыбер юньле бала тумагандыр. Совет власы аларга да гуманлы—детдумнан урын бирер.

"Контрлардан" бушаган дистәләрчә йортларның берсе үзенә бирелгән атналардарак тагын бер ир белән кавышып алды ул. Анысы "халык дошманнары"ның чираттагысын—ире инде Рауза әләге белән аттырылган, алты бала белән калган Хәмдүнәне кулга алырга килгән чалыш авызлы, шадра йөзле милиционер иде. "Үзе дә әлләкем түгел, өйләнүе дә бик мөмкин", дип уйлаган иде Рауза, шуңа күрә аракыны да муллан эчертеп, бөтен шартын китереп сыйлаган иде. Бергә тормыш итү хакында кич буе тәмле генә ләчтит сатып утырган шадраның иртә таңда ук фикере үзгәрде. Кичке вәгъдәләрен исенә төшерүе булды Раузаның, погонлы нәмәрсәкәй авыз җыерды: авызының бер чите муен таба тартылды, икенчесе колак тарафына менеп китте. Идәнгә тама язган селәгәен фуражка түбәсе белән сөртеп алгач, шыркылдап җибәрде:

—Булмый. Төнлә аягың мишәйт итә.

—Сон... гарибе—гарип инде аның...

—Юк, сәламәте мишәйт итә,—диде дә милиционер аламасы, ишектән чыгып китте.Әгәр дә ул бу сүзләренең, икенче сүзгә әйләнеп, НКВД начальнигы өстәленә барып ятасын белсә, телен тешләгән булыр иде. Рауза доносының бер җөмләсе болай булды:"Безгә ашарга кайткан милиция Гайфулла Гарифҗановның халык дошманы икәнлегенә бер шигем дә калмады. Тормышның авыр яклары турында сүз чыккач, ул, Сталин үлмичә торып, тормыш рәтләнмәячәк, безгә Сталин мишәйт итә, диде..."

...Ул бик озак яшәде. Әйтерсең лә Ходай аңа үзе кылган бөтен гамәлләрнең гөнаһтан гына гыйбарәт булуын күрсәтеп бетерүне,үзенә бер төрле җәза бирүне мәкъбүл санады. Караватаcларын, мич артларын пычратып йөрүче песине, гадәттә, муенынан тотып, әледән-әле үз азаена борыны белән тыгалар. Рауза да картаймыш көнендә шундыйрак тормыш кичерде.

Бервакыт ул, район үзәгенә баргач, пьедесталеннән сугып төшерелгән Сталин һәйкәлен күрде: аяклары пьедестальгә эләгеп калган, йөзе белән пычракка капланган. Шуның өстеннән, бүрәнә өстеннән йөгереп йөргән кебек, балалар йөгерешеп уйный ...

Аннан соң ул, үзенең "данлы юл" үтүе турында күкрәк кагып сөйләгән чакларында, Ленин исемен генә кабатлый торган булды. Ләкин тагын шундый көн килде—телевизордан бик еш кына "даһи" һәйкәлләрен җимерүне күрсәтә башладылар.

Аяк астында аунап ятучы кызыл байракларны да күп күрде Рауза. Үзе җимерттергән мәчет урынына зифа манаралы яңа мәчет салынуның да шаһиты булды. Үч иткәндәй, аның үз йорты каршында иде мәчет. Әледән-әле әйтелеп торучы азан чирләп, тартышып ятучы бу карчыкка ясин булып тоела иде. Канлы елларның бөтен сәбәпчеләре дә, шушы ясинны тынлый-тынлый, үзе белән янәшә яталардыр, җан бирү газабын кичерәләрдер сыман...

Үләр алдыннан ул шаркылдап көлүче Сталинның өрәген күрде. Көлле-көлле дә юлбашчы, кинәт кара янып, тешләрен бик хәтәр ыржайтып, Раузага йодрык күрсәтте.

* * *

Район үзәгендә туып-үскән егет буларак, андагы тормышны, хәл-әхвәлне яхшы белә иде Радик. Ләкин бу юлы аның күз алдына көннәр буе сыра цистерналары янында, аракы сатыла торган кибет буйларында киләп салып, бер йотым аракыга яки сырага зар-интизар булып йөрүче сәрхүшләр генә килде. Менә кемнәргә таянырга кирәк бүген! Һәркайсына бер шешә тоттырсанмы!?. Теләсә нинди хәшәрәтне күмәчәкләр.

Унбиш чакрым асфальт сизелми дә калды.

—Әнә теге кибет янында туктат!..

Кергәч, кесәсеннән бер уч акча каезлап чыгарды да Радик, сатучыга сузды:

—Бер ящик аракы!

—Ниндиен? ”Московский”мы, “Мензелинский”мы, әллә?..—дип төче генә елмаеп килгән сатучы чәчбикәнен йөзенә дә карап тормастан:

—Ник шунда “Шайтанский” булмый...—дип тупас кына мыгырданды Радик. Ләкин шундук йомшарды.—Юньлерәген бир...

Шул ук вакытта тирә-ягына да күз салырга өлгерде Радик. Ә ан-да-а!.. биш-алты сәрхүш, сихерләнгән сыман, прилавкага менеп утырган тартманы күзләре белән ашый башлаганнар иде инде. Җәлт кенә шуларга борылды рәис:

—Туйганчы эчәсегез киләме?

Теге төркем калтырана-калтырана елмаешып куйды:

—Кәнишне...

—Алайса болай итәбез...—Ул карашы белән тегеләрне барлап алды.—Җир казый беләсезме?

—Кәнишне...

—Аракыны күтәрегез дә машинага төягез.

...Казыганда салмак селкенсәләр дә, күмгәндә җәһәт кыландылар шәһәр “егетләре”—балчыкны ишеп кенә тордылар—күңел кайтаргыч мәетне мөмкин кадәр тизрәк җир астында калдырып котыласылары, яшел чирәмгә сузылып ятып, бүген күргәннәре онытылганчы эчәргә ашыктылар.

Ә инде исерешеп беткәч, берсе кинәнеп куйды:

—Мондый мәетне күмү дә стоит, черт побери. Аракы—мүре! Син безне тагын чакыр, хозяин. Бишкуллап әзер!

Кулларына аз-маз акча да тоттыргач, калган аракылары-ниләре белән бергә тегеләрнең барысын да машинага төяп кайтыр юлларына аткаргач, яшь рәис, “табын”лы чокырдан чыгып,авылга тәпиләде.

“Һава сафланып китте бүген, бәлки яңгыр да явар әле”, дип уйлады, эңгер-меңгерле урам буйлап атлаганда...

## “Крутой” әби

Үз гомеремдә руль тотып караганым булмаса да, берсеннән-берсе затлырак машиналарда сәфәр кылганым бар. Әмма иң яраткан транспортым—трамвай!

Тек-тек-дык... тек-тек-дык...

Ул көнне дә трамвайда бара идем. Шундыен да аяз көн, Ходайның рәхмәте, хәтта күк гөмбәзе дә үтә күренмәле биниһая зур кыңгырау кебек чынлап торадыр сыман. Кояш нурлары трамвайның тәрәзәләреннән генә түгел, стеналарыннан да үтеп кергәндәй тоела.

Тек-тек-дык... тек-тек-дык...

И, рәхәт тә сон чажлап, ашкынып, томырылып жилдерткән трамвайда як-якны күзәтеп бару! Житмәсә, ни хикмәттер, пассажирлар да бармак белән генә санарлык. Якты, иркен, жиләс!..

Хозурланып барам шулай, чираттагы тукталышта алгы ишектән бик ыспай киенгән бер хатын кереп килә. Тартылып торган зәңгәрсу джинсы чалбардан, аллы-гөлле гажәп матур кофтадан бу. Беләгендә затлы сәгать. Баскычтан күтәрелгәндә карашы гел трамвай йөртүчедә монын. Яшь күренә, житез күренә!

Бәй, менеп баскач, алтын беләзекле кулы белән елтыр колгага тотынгач... вә һәм дә... йөзен болайга таба боргач, үземнең алдануымнан көлеп жибәрә яздым: каршымда ким дигәндә алтмыш яшьлек карчык күрдем. Житмешкә дә якын түгелме икән әле. Ләкин шундук нәтижә дә ясадым: үзен карап кына яши торган, килеш-килбәтеннән бик канәгать һәм... һавалы карчык бу!

Иң алдагы утыргычка ук утырмакчы булгандыр, ахры, карашын шунда— капчыклары, төенчекләре белән мәж килә-килә ике урынның берсендә утырып кайтучы һәм фәкыйрьлеге тышына, ягъни өс-башына ук чыккан ертык яулыклы әбигә күз төшерде. Шунын янындагы буш урынга утырыр инде бу ыспай дисәм, ул ниндидер әкәмәт хәл күргән сыман, авыз чите белән генә көлемсерәп тә, кызганып һәм жирәнеп тә дигәндәй, тишкәләнеп беткән пакетындагы кайбер шырды-бырдысын иләндәге сүсәреп беткән капчыгына иелә-иелә күчереп салучы "ертык яулыкны" текәлә-текәлә күзәтеп торды да, карашын кинәт кенә урамга күчерде.

Шул мизгелдә үк тегесе дә башын күтәрде һәм, карашы белән ыспай карчыкка кадалгандай, тораташ катты. Иреннәрен ялап куйды, шактый озак хәрәкәтсез торган керфексез күзләрен чет-чет йомгалап алды. Нәрсәдер әйтте дә сыман, ләкин тавышы чыкмады. Тамагын кыргалап алгач кына, анлашылырлык сүзләр әвәли алды:

—Бәй, син түгелме сон бу, Нажия?

Нажия булырга тиешлесе ишетмәде, дөресрәге, ишетмәмешкә салынып, биек йортларның өске катларын бик зур игътибар белән күздән үткәргәндәй, башын күтәреп бара бирде. Монысы кабат кыбырдады, авыз читләрен сыпыргалап алгач, тагын эндәште:

—Син бит бу, Нажия... Танымыйсынмы әллә, Мәгъфия бит мин.

—Нажия булсам сон!—дип кырт кисте тегесе, күз чите белән генә Мәгъфиягә тәкәббер карашын төшереп алгач.—Нажияләр бик күп алар Казанда. Мәгъфияләр дә хисапсыз!

—Сон... ни бит... мин бит... Без бит синең белән еллар буе бер упшыйда, бер бүлмәдә яшәдек.

Нажия дигәне һаман да урамга караган килеш кенә тагын кистерде:

—Упшыйлар онытылганга биш былтыр инде. Искә дә төшерәсем килми.

—Ә мин сине еш искә төшерәм... Ничегрәк яшәп ятасың сон, Нажия?

—Нэт прәблим!

—Финсиян күпме? Житәме сон?

—Нэт прәблим!

—Алай дисең дә син... Ашарга да житә торган түгел бит ул финсия дигән нәмәкәй. Кулга керүе була, агып чыгуы була. Бигрәк буш бит хәзерге акча. Сиңа да артыгын бирмиләрдер...

Нажиясе, хәтеренә бүтән сүз салынмаган автомат сыман, ирен очлары белән генә тагын шул ук сүзне кабатлады:

—Нэт прәблим!

Күреп утырам: бераз борылып, карашын трамвай эченә юнәлтсә дә, ыспай карчык "упшыйдашына" күз дә төшерми. Ләкин карашы минеке белән

очрашкан мизгелләрдә күзләре белән:"Күрәсеңме, без ничек эре сөйләшәбез. Булдырабыз бит ә?!" дия сыман. Мондыйрак җөмлә дә күренә сыман шул ук күзләрдә: "Сәбәбе бар, хикмәте бар болай сөйләшүнең!" Бәлки бөтенләй күренмидер, миңа гына шулай тоеладыр. Ничек кенә булмасын, бу тәкәббер әби эчемдә үскәннән-үсә барган кызыксынуымны һәр хәрәкәте, бертуктаусыз кабатланып торган сүзләре белән арттыра бара. Бөтен Рәсәй зар елаган, пошаманга төшкән һәм зарланып туймаган заманда бернинди проблемасыз әби бар микәнни бу Казанда? Мәгъфиясенең өзек-өзек сүзләреннән аңлашылганча, пенсиягә чыкканчы икесе дә кара эшче булган—яңа төзелгән йортларның ишек-тәрәзәләрен буяп яшәгәннәр... Инде килеп, яшь чакларында бер тулай торакның бер бүлмәсендә гомер иткән бу ике җанның берсе ни өчен шул кадәр каты бәгырьле? Кырык ел буе очрашмаганнар лабаса! Миңа калса, алар: "И, Нәҗиякәем, син түгелме соң бу?!", "И, Мәгъфиякәем, ни хәлләрдә яшәп ятасың? Сагынып беттем үзеңне!" дип кочаклашырга, бер-берсен сөя-сөя куанышырга тиешләр иде. "Нэт прәблим! Нэт прәблим!" имеш...

Юк инде, моның серенә төшенмәсәм, йокым йокы булмаячак минем—гадәтем шундый. Үз-үземә кистереп тә куйдым: "Проблемасыз әбинең ни өчен һавалануын аңламый калмаска, бу юлы, һич югы, яшәгән йортын булса да чамалап үтәргә!" Ачыкланмаган сорауларның башымда озак йөрүен яратмыйм мин.

...Ул арада Мәгъфия карчык сөйләнүен дәвам итте:

—Бик эре кыланма инде, Нәҗия. Син дә ир тапмадың, мин дә... Синең дә балаң юк, минеке дә. Беребезгә дә толыкманы белән акча тоттыручы кеше юк икәнен беләм бит инде мин...

Шуны гына көткәндәй, Нәҗиясе, тавык чираттагы җимен чукып алган тизлек белән, башын алга талпындырып куйды:

—Ә минеке баррр!

—Белмим тагы, мин үзем шапырына алмыйм,—диде мескенлеге сыртына ук чыккан Мәгъфия карчык, үзалдына мыгырданган кебек.—Тормыш авыр... Кием яңартырлык та хәлем юк...

—Ссиңа шул төссс!—дип ысылдады ахирәте, мыскыл белән.

Аның сүзенә куәт биргәндәй, туктаган трамваебызның ишеге дә ысылдап ачылды. Горький паркына җиткәнбез икән. Нәҗия ишеккә атлады. Үз тукталышыма әле бик ерак калган булса да, мин дә чыгу юлына ашыктым.

Менә җитез адымлы, төз гәүдәле Нәҗия карчык паркка элдертә, ике-өч кенә адым калышып, мин дә җилдертәм. Игътибарын җәлеп итү өчен, көлеп җибәргән булдым. Ул аптыраган кыяфәт белән борылып карый һәм... якты караш белән елмая. Йөзендә-күзендә тәкәбберлекнең, һавалыкның әсәре дә юк. Шуны гына көткән бу бәндәгез, кытыклангандай көлә-көлә, әйтә куя:

—Ну, маладис, апа, чын артист икәнсез! Тәки аптырашта калдырдыгыз теге карчыкны үз уеныгыз белән!

Мин инде, моның белән уртак тел табу өчен, шактый бормалы-сырмалы сүзләр уйлап куйган идем. Ләкин аларның кирәге бөтенләй чыкмады. Без күптәнге танышлар кебек сөйләшеп киттек.

—Әллә артистлык сәләтем дә бар сыман тоелдымы?—диде ул ихлас күңелдән көлеп.

—Тоелды. Әйбәт уйнадыгыз, апа. Тик соңгы сүзегез генә энәле булды. Кызгандым мескенне.

—Мин дә кызгандым-кызгануын... Ләкин кырык ел ниятләп йөргән ул сүзне әйтмичә түзә алмадым. Нык үпкәләтте ул мине, нык рәнҗетте теге заманда...

...Парктагы бихисап эскәмияләрнең берсенә утырып дәвам иттек сүзне.

Дөресрәге, ул сөйләде. Миңа әледән-әле җөпләп, сораулар биргәләп һәм баш каккалап кына утырырга калды.

—И Аллам, ул чакта безгә егерме тирәсе генә булган!.. Чыннан да, бер тулай торакта тордык без Мәгъфия белән, энем. Бер бүлмәдә! Алай гына да түгел, сердәшләр идек. Тату да идек. Кайсы егетне ничек каратырга икәнлеккә кадәр бәйнә-бәйнә киңәшә идек, үзебезчә хәйлә-планнар кора идек. Шул заманда, менә бүген сез арттан төшкән кебек, бер егет арттан иярде. Әндәшә теге, бер—алдыма, бер артыма төшә. Ошый бит бу, рәхмәт төшкере! Күзенә карау белән эреп китмәле. Ләкин, кызлар бит алар киреләнмәсә, ис китмәгәндәй кыланмаса, кыз да булмый инде. Безне Ходай шулай яраткан бит—үз бәясен югарырак күрсәтә торган итеп... Ничек кенә булмасын, таныштык, сөйләшеп тордык, озатып куйды, очрашырга булдык. Мәгъфия ул миңа караганда бик күпкә бай иде. Авылда әти-әнисе дә булгач, кызыгырлык киемнәре дә булып торды... Гөнаһ шомлыгыдыр инде, теге егет белән очрашуга Мәгъфиянең тавис канатыдай төрле төсләр белән балкып торган күлмәген киеп чыгасым килде. Берсүзсез бирде. Алай гына да түгел, “сиңа бигрәк тә килешә икән бу!” ди-ди, тирәмдә бөтерелеп тә йөрде әле.

Мин тулай торактан килеп чыккач, теге егет, бахыркаем, телсез калды. Хәзергедән дә авыррак, фәкыйрьрәк заманалар иде бит... Ике-өч атна йөрдек аның белән. Ике-өч мәртәбә, Мәгъфияне дә ияртеп, киногa бардык. Бер көнне егетем: ”Теге затлы күлмәгең гаҗәп матур иде. Үзеңнеке булмаган икән”, дип куймасынмы!.. Сулышым тукталып торды хәтта. Аңлашылды: Мәгъфия ахирәтем үзе әйткән. “Шул Нәҗиянең нәрсәсенә кызыктың инде? Аның теге күлмәге дә минеке иде бит”, дигән. Шуннан соң мин икенче бүлмәгә күчтем. Теге егет белән очрашырга да оялдым. Әйе, бер-ике рәт Мәгъфия белән күрдем мин аны... Тора-бара аның яныннан да юк булды егет...

Нәҗия карчык, моңаеп калгандай, бер-ике сулыш тынып торды да, көлеп җибәрде:

—Шулай, энем, мин дә, ул да ирсез үткәрдек гомеркәйләрне. Тәкъдир шулай булгандыр... Тик шулай да якын ахирәтемнең хыянәте, астан сүз йөртүе йөрәк җәрәхәте булып калды. Шулай да, кызгандым мин аны бүген. Йончыган, таушалган мескенкәем... Барам әле мин аңа, барам. Башыннан аягына кадәр киендереп кайтам. Бик күп булса, өч йөз долларым китәр...

Сөйләве моңлы-сагышлы булса да, шушы гап-гади әңгәмәдәшемнең әле ярты сәгать чамасы элек кенә “нэт, прәблим!” дип тәкърарлап торуы күз алдына килде дә, күңел кытыкланып куйды—шаяртып алуны кирәк таптым:

—Нет проблем, дисез инде алайса?

—Әйе, андый гына проблема юк,—диде карчык көлеп һәм “проблема”сын нәкъ китапча әйтеп.—Акчага аптыратмыйлар мине. Көчләп тутыралар шкафыма!

—Бай туганнарың бар, димәк?

—Беркемем дә юк. Ну, шулай да...

Сүзне дәвам итәргәме-юкмы, дигәндәй, аяк астында тыз-быз килүче кырмыскаларга карап утырды ул. Аннан соң гына кабат телгә килде:

—Не было бы счастья, да несчастье помогло, диләр бит әле. Шуның хаклыгына, рас килүенә инандым бит узган ел... Минем пенсиям Мәгъфиянекеннән дә аздыр әле. Белүемчә, ветеран дигән документы да бар аның. Бик авыр яшәдем мин, энем, пенсия көненә калгач, гарьләнеп яшәдем... Коммунизм булыр, киләчәктә бәхетле яшәрбез, ди-ди, кызыл грамытлар, вымпеллар бирә-бирә эшләттеләр бит без тинтәкләрне коммунистлар... Кая монда бәхет? Тоттырдылар!.. Вәгъдә иткән бәхетләрен үзләренә каерып алдылар да, безгә хәерчелек калдырып, бизнесмен булып,

офисларына качтылар. Хәтта фатир да бирмәделәр. Пенсиягә китәр алдыннан бер яшь кыз белән яшәп ята идем упшыйның унике квадрат метрлы бүлмәсендә. Пенсиягә озатканда пачутлы итеп җыелыш җыйган булдылар да: "Кырык ел буе безнең предприятиегә тугърылыклы хезмәт иткән һәм хезмәт батырлыклары күрсәткән өчен үзе яшәгән бүлмәне бирүзенә калдырырга!", дип карар укып, җыелыштан кул чаптырдылар. Гарьлегемнән гел елап яшәдем унөч ел буе... Шулай елап утырдым-утырдым да бер кичне, күңелем бушанмасмы, дип, танышларыма киттем... Чәй эчтек, сөйләштек, телевизор карадык шунда. Күңелдәге хәсрәт белән ятимлек барыбер эремәде. Ноябрьнең җилле-яңгырлы төн уртасы... Уйлана-уйлана кайтып барам: их, мәйтәм, минем пенсияне Ельцин яки Путинга бирергә иде дә, бүтән бер тиен дә кермәслек хәлгә куеп, шул акчага бер ай яшәтергә иде, дим... Юлы да тайгак, җиле дә аяктан егарлык—каһәр суккан төн бу. "Ни өчен яшәдем дә, ни өчен яшим?" кебегрәк уйларга тулып барам бит инде шулай... Зур күпер астыннан үтә торган юлга керүем булды, ажгырып килүче бер машинаның бәреп китүе булды! Бетон баганага килеп сыландым, ишшу җитмәсә. Аннан соң, кадерсез урам эте кебек, асфальтка мәтәлдем. Шунысы гаҗәп, үлүем шушы икән, дип кайгырмыйм гына бит әкәмәт! Котылам икән бу каһәрле дөньядан, дип сөенеп ятам шул чак...

Карчык, бераз сытылып, күз яшен сөртеп алды. Әлеге куркыныч мизгелне тулаем хәтере аша үткәрүе булгандыр, сүзе шактый өзелеп торды.

—...Ә теге машина илле адымлап үтте микән, юлны чажлатып, туктап калды да, арты белән чигенеп, минем янга кабат килде. Шундук ишекләре ачылып китте, дүрт ишегеннән әзмәвердәй дүрт ир чәчрәп чыкты. Барысы да минем өскә килеп иелде. Җаным чыгып барганын сизсәм дә, күреп ятам—барысы да яшьләр, һәркайсы күн курткадан, йөзләре кавындай түгәрәк, авызларыннан—коньяк, киемнәреннән ресторан исе аңкый..

—Әби, хәлең ничек? Исәнме син?

Мин ыңгырашам.

—Хәзер, әби, машинага салабыз да сине, больницага тапшырабыз,—диләр.

Шулчак акылыма җиңеллек килде микән, әллә бу тормышның газапларыннан туюымның, бу җәмгыяттә кадерсез, артык кеше булуымны тоюның каһәрле авазы тышка бәреп чыгу булды микән, бар көчемә җан ачысы белән кычкырып җибәрүемне үзем дә сизми калдым:

—Таегыз моннан, сабакылар, төрмәдә черисегез килмәсә! Минем барыбер яшисем юк... Үтем шартлаган, кабыргаларым сынып беткән...

Тегеләр һаман мышкылдыйлар, "болай ташлап китү ярамый бит инде", дия-дия, күтәрергә маташалар.

Шулчак, ни хикмәттер, күз яшемә буылып, кабат үкерәм тегеләргә:

—Ычкыныгыз, пока не поздно! Убирайтесь! Әләгәсез!

Кинәт күңел нечкәреп китте, тамак төпләрем кызышты, хәлсезләнеп киттем. Шулай да, елый-елый, үз сүземне куәтләдем:

—Милиция килүен көтәсезмени, оланнар, харап буласыз бит...

Болар дәррәү машинага тулдылар. Кузгалып китәләр дигәндә генә, берсе кабат сикереп төште:

—Әби, һич югы исемеңне, адресыңны әйт инде син...

Хәтерем югалмаган икән әле—әйттем. Әйттем дә, кабат кычкырдым:

—Таегыз, оланнар, таегыз!.. Соң булуы бар...

Машина күздән югалуга минем дә аңым югалды. Бүлнистә айныдым. Ниндидер уколлар кадыйлар, гәүдәмне бинт белән урыйлар, авызыма дару агызалар...

Бер-ике көннән аңладым: ике кабыргам чатнаган, аякларым каймыккан, кулым каерылган. Үзем ятам, үзем исән калганыма үкенәм. Әнә бит, башка

авырулар янына туганнары, дуслары, танышлары килә. Тумбочкаларына тәмле, баллы ризыклар, ширбәтләр тутыралар. Минем янга эт тә килми. Күңел елый, ятимлегем, кадерсезлегем елый...

Өч көн үттеме икән, дүртме... Бер мәлне палатага матур итеп киенгән, җилкәләренә ак халатлар да бөркәгән бер төркем чибәр кыз килеп керә. Әкият диярсең! Бер-бер артлы тезелешеп керә болар. Башларында чигүле калфак, өсләрендә камзуллар, тагын әллә ниләр... Һәркайсының кулында бизәкле подноcлар, подносларда—виноградлар, кайнар бәлеш, кызган тавык, гөбәдия, алма-әфлисуннар, тәмле сулар, минсинайтим! Кергәне-бере минем карават янына тезелә, һәркайсы баш ия.

—Нажия апа, якын туганнарыгыз кучтәнәчләр җибәрде. Алар сезне бик яраталар, түземсезлек белән терелүегезне көтәләр. Менә, күңелсез булмасын өчен, бәләкәй телевизор да җибәрделәр... Бу чәчәк бәйләме Нажия апабызның күз алдында торсын, хуш исе белән терелтсен, диделәр оланнарың... Ни кирәк, әйтсен генә, барысын да табабыз, дип торалар затлы егетләрең...

Шундый матур итеп чөкердәшә бу сылу да, ягымлы да кызыйлар—оҗмах фәрештәләре диярсең. Ә мин юләр, туганнарымның, оланнарымның күп икәнлегенә үзем дә ышанып ятам. Китергән әйберләре палата почмагындагы ындырдай өстәлгә аслы-өсле итеп өйгәч кенә сыйды. Авырулардан кем нәрсә тели—шуны ашый. "Пажалыста, пажалыста!" дип кенә ятам. Рәхәтләнде үзем кебек ятимнәр деликатеслар ашап.

Икенче көнне түбәтәйләре, камзуллары асылташ белән чигелгән өч егет килде. Муеныма алтын чылбырлы алтын ай тактылар, төрек осталары теккән үтә затлы халат кидерделәр, бүлнис биргән алама, сасы тәпечкәләр урынына патшабикәләр генә кия торган башмаклар куйдылар, одеял хәтле махровый җаймә калдырдылар. Ә берсе, җилкәсенә чүпрәк метр асканы, билләремне, буйларымны, җилкәләремне үлчәргә кереште. Үлчи дә яза, үлчи дә яза... Һәркайсының сүзе бер: "Оланнарыгыз шулай кушты", диләр.

Әнә шундый күп хөрмәтләр күрә торгач, өч атна вакыт сизелми дә үтеп китте. Соңгы көнне тагын ике кыз килеп керде. Кулларында зур төргәкләр.

—Улларыгыз сезне һәйбәтләп киендерергә куштылар, апа. Ярты сәгатьтән үзләре дә килеп җитәчәкләр. Кичә үк белешеп куйганнар, сезне бүген чыгаралар икән,—дип, дөньяда нинди затлы кием бар, шуларга төреп тә куйдылар мине.

Ул арада берсе тиз генә чыгып керде:

—Оланнарың килеп җиттеләр, апа! Урамга рәхим ит!

Мин атлыйм. Затлы туныммнан сөя-сөя, артымнан әлеге гүзәлләр атлый. Чыксам, шаклар каттым: таныш "оланнарым" бик тә озын ап-ак машина янына тезелешеп басканнар. Һәркайсы иң бәхетле кешедәй киң итеп елмая, һәркайсының кулында бер кочак аллы-гөлле чәчәкләр! Берьюлы кочаклап алдылар, һәркайсы битемне, кулларымны үбә! Аннары, күтәреп диярлек, әлеге "Линкольн" дигән машинаның иң алгы урынына утырттылар да:

—Хәзер инде, кадерле апабыз, фатирыңа кайтабыз,—диештеләр.

Машинаның бөтенләй икенче тарафка баруын шәйләдем дә, теге караңгы төндәге кебек кычкырып җибәрдем:

—Ул якка түгел, оланнар!

Барысы да дәррәү көлештеләр җаныкайларым.

—Теләсәң, иске адресыңа да кайтырсың, апа. Бүгенгә без сайлаган фатирда кун әле син. Бәлки, ошап куйса, шунда яшәрсең.

Алар китергән квартирга кергәч, исем-акылым китте: бар икән бу фани дөньяда да җәннәттә яшәүчеләр. Упшыйдагы бүлмә дигәнем моның бәдрәфеннән дә таррак, шыксызрак икән бит! Евроремонт дигән сүзне ишеткәләгәнем бар иде, бу фатир шул икән... Затлы җиһазлар белән тулы

бүлмәләрне күрсәткәләп йөрттеләр дә, сәгатьләренә күз салдылар... Кайдадыр кемнәр беләндер очрашасылары, сөйләшәселәре бар икән.

Чыгып китәр алдыннан, яшькә зуррак күренгәне бер пачка акча сузды:

—Хәзергә шуны тота тор, тагын китереп торырбыз,—диде.

Бәй, 100 саннары һәркайсына төшерелгән-төшерелүен бу акчаларның, ләкин, нәрсә бу, безнең пычрак көрән йөзлекләргә охшамаган болар—барысы да ямь-яшел! Әллә мыскыл итәләр инде чукынчыклар?!

—Ничауа, Нажия апа, җаена төшенерсең,—диештеләр-көлештеләр дә, тыпырдашып баскычтан төшеп тә киттеләр. Берсе, ялт кына борылып:

—Гаеп итмә, кадерле апабыз, без озак тора алмыйбыз—бизнес чакыра!—дип өстәргә өлгерде.

... Нажия карчык сөйләвеннән шып туктады. Нәрсәгәдер сокланган сыман үзалдына елмаеп утырды. Аннан соң гына сүзен дәвам итте:

—Бик тә сәер икән бу замана яшьләре: партия белән комсомол да мәҗбүр итми, агит-үгет тә көтмиләр—үзләре ашыгалар. Килеп керәләр дә фатирыма, акчамы шунда, берәр затлы нәрсәме китерәләр дә, кыска-кыска гына сөйләшеп, җылы сүзләр әйтеп, чыгып та таялар. Әйтерсең лә алар барасы юлга акча түшәп куйганнар! Шулай да, алтмыш сигез яшем тулган көнне озак утырдылар фатирымда. Матур-матур тостлар әйттеләр:

—Нажия апа,—диде берсе,—без биргән акчаларны җәлләп торма, җаның теләгәнчә туздыр. Һәрвакыт "Нет проблем!" дип яшәрлек булсын. Син крутой булсын өчен без барысын да эшләрбез. Чөнки... и у нас нет никаких проблем! Чөнки без күктән—күкәй, таудан тавык көтеп ятмыйбыз—көн-төн эшлибез, уйлыйбыз, утка төшкәндәй чабабыз. Без бер сине генә оҗмахтай тормышта яшәтә алабыз... Курыкма, апа, крутой бул!

—Миңа күп кирәкми, оланнар. Акчагызны исраф кылмагыз...—дип сүз башлаган идем дә, икенчесе, җәт кенә торып, авызымны япты:

—И, апа-апа!.. Әгәр син безне милиция, прокурорлар, судьялар хөкеменә калдырган булсаң, әллә нинди кодекслар, статьялар, "бандит" дигән ярлыклар белән пычранып беткән булыр идек. Һәр көне, сәгате кадерле бизнес урынына айлар буе суд юлын таптыйсы кешеләр идек бит. Сүз дә юк, сине үтереп әләккән булсак та, котыла идек. Ләкин без аларга сиңа биргәннән ун тапкыр күбрәк түгәр идек акчаны. Аларның нәфесенә чама юк! Ә син безне чиста калдырдың. Инде хәзер... атаклы композитор белән танылган шагыйрьдән яздырган, йолдыз дип йөртелүче җырчыдан җырлаткан бүләгебезне тыңла!..

Шулай дию булды, үзләре бүләккә дип алып килгән музыкаль үзәкнең төймәсенә басты. Ә аннан!...—Нажия карчык, тынсыз калгандай, кулларын җәеп, бер мәл хәрәкәтсез утырды, бәхеттән балкыган күзләрен кояшка төбәде, шуннан соң гына чытлык кызлар тавышы белән көләргә кереште.—Ә аннан, минсиңайтим, "Нажия апа, мең яшә!" дигән җыр яңгырый башлады. Мәгънәсенә карасаң, мин изге дә, миһербанлы да, саклаучы һәм яклаучы да икәнмен!.. Барлык сүзләре дә истә калмаган әле... Берничә мәртәбә кабатлана торган кушымтасы болай:

Милицияләр, бандитлар
Безгә төбәп аталар.
Без үлмәбез, исән булса
Нажиядәй апалар.

...Трамвайда иреннәрен бөрештереп кенә "нэт прәблим!" дип барганда Нажия карчыкның авызы, кем әйтмешли, уймактай гына булып тоелган иде. Юк икән, ихлас күңелдән сөенеп тә, сокланып та көлгәндә нык ерыла икән бу авыз. Сөйләвенә караганда, машина биргәнче, "крутойлар" белән

танышканчы, өч кенә теше калган булган. Ә хәзер, авызы ерылган саен, тыгыз итеп тезелгән алтын тешләре уттай балкып куя. Ошбу паркны кояш түгел, шушы тешләр яктыртадыр сыман тоела, хәтта.

Ул сәгатенә карап куйды:

—Бүген җомга бит әле безнең... Кабат бер сәгатьтән аларның хезмәтчесе мина чишмә суы китереп китәргә тиеш. Кран суы—агу ул, апа, республикадагы иң саф суны гына эчертеп торачакбыз сина, дигәннәр иде, өзми-куймый көмештәй су ташытып торалар.

—Ә!.. Алайса, хезмәтче дә тоталар икән!? Андыйларга элек эксплуататорлар дип мөһер сугалар иде бит,—дигән булып, сүз кыстырдым.

—Хезмәтчеләре дә иномаркада гына йөри аларның. Кияү егетләре кебек. Бик төгәлләр, барысы да игътибарлы, ягымлы... Әле шул туган көнемне үткәргәндә әлеге оланнар мина да: “Нажия апа, кулына чүпрәк тә тотма, бер-ике хезмәтче ялла”, дигәннәр иде. Тузан да сөртмичә, идән дә юмыйча яшәсәң, аяк өсте череп бетәрсең, юләр!.. Әле менә монда утырганда уйлап куйдым: шул Мәгъфияне алып кайтырга микән әллә, дип. Ул мескен дә минем кебек үк туалеттай бүлмәдә калды бит, социализм җимерелеп төшүгә. Яшәрбез әле чөкердәшеп, яшьлек юләрлекләрен искә төшереп. Квартирым болын хәтле булса да, бер үземә бик күнелсез инде хәзер... Картайдык бит инде, картайдык. Яшьләр крутойлансын әнә! Безгә килешми ул эреләнү, энем...

...Парктан чыгып, тукталышка җиткәч, җинел машина туктатты Нажия карчык. Шофер ишек ачты. Әмма, аны күрмәгәндәй, тагын бер машинага кул күтәрде. Икесе дә бер-бер артлы баскач һәм һәркайсының хуҗасына йөзәр сум биргәч, мина борылды:

—Икесенең берсенә утырыгыз. Паркта яшәмисездер дип беләм. Анда керүегез минем белән кызыксынудан булды бит.—Ул ике бармагы белән пиджак якамнан тотты да тагын бер мәртәбә кеткелләде:

—Яза калсагыз, шыттырмагыз. Дөрес әйберләрне уку кызыграк. Бер генә сүзне үзгәртегез—минем исемемне. Крутойларым рекламаларның артыгын яратмыйлар.

Каушаудан сискәнеп куюымны үзем дә шәйләдем. Мин тотлыккан мизгелдә ул шуклык белән бармак янады:

—Беләм мин сезне, бик беләм! Телевизордан да, гәҗит-журнал битләреннән дә күп күргән бар. Очраклы кешегә сөйләп утыра бу ачык авызлы дивана карчык, дип уйлаган идегезме әллә? Алай ук беркатлы түгел без, энем!

Мин утырган машина йортым янына тугыз минут кайтты. Шоферына рәхмәт әйтеп төшкәч кенә, үткән гомеремнең әнә шул тугыз минутын хатын-кыз исәбенә яшәгәнлегемне абайлап алдым...

## Беренче татарның галәмгә сәяхәте

Ниһаять, татар халкын кырык елга якын уйландырган, кимсетеп һәм өметләндереп килгән мәсьәләгә нокта куелды!

Хәер, вакыйга гадәттән тыш куанычлы, биниһая дулкынландыргыч булса да, сүзне тәртибе белән сөйләү мәслихәттер...

—Хөрмәтле иртә, хәерле милләттәшләр, туганнар, якташлар! Тынлагыз, тынлагыз, ишетми калдык, димәгез! Якын көннәрдә серлелеге белән ерак бабаларыбызны да уйландырган, шөбһәләндергән галәмгә дөньяда беренче мәртәбә татар космонавты очачак! Ишетүебезчә, Россия президенты ризалык

биреп өлгергән инде. Указга да кул куйган. Кем очарга тиешлеген генә ачыклыйсы калган... Бу вакыйганы Россиянең Татарстан мөстәкыйльлеген тануы дип аңларга кирәк...

Радиодан хәбәр әйтелеп беткәч, гимнны рәттән ике мәртәбә уйнаттылар да, тыңкыш тавышлы халык артистын җырлатырга керештеләр. Әмма халыкны, гадәттәгечә, тегесе дә, монысы да кызыксындырмый иде инде. Һәр баш миенә хәбәрнең үзе генә сеңеп калган иде:

—Кайсыдыр түрәнең малае очадыр әле. Безнең кебекләргә тәтемәс ул...

—Татарстан суверен икән, ни өчен чит ил президенты рөхсәте белән оча? Мондагысы ни хаҗәтемә кирәк? Әрәмтамаклар җыеп ятаргамы?

—Ике хөкүмәт ашатып яткач, каян калсын ул безгә хезмәт хакы...

Икенче бер халык булса, "ур-ра" кычкырыр иде. Һәрвакыт көнче, берберсенә хөсет татар бу юлы да үзе булып калды. Аның уйлавынча, илдәге халык кебек үк, президентлар да ач-ялангач яшәргә тиеш. Нәкъ менә башкалардан тәмлерәк ашау, баерак яшәү өчен кырыкмаса-кырык алдаулар, хәйләмәкерләр белән сайланырга тырышалар бит инде алар.

Озак та үтмәде, хәбәрнең яңасы килде: Минзәләдә яшәп ятучы кырык бер яшьлек Саттар Гаттаров очачак икән!

Шуны гына көткән кебек, Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, Чистай, Әлки һәм башка бик күп шәһәрләрнең, районнарның татарлары митинг мәйданнарына ыргылдылар.

—Ни өчен Әлмәттән түгел?! Долой Минзәлә!

—Чистай татарлары цыпцыкмыни?! Мишәрләргә запретмыни?! Минзәләдән алган хатыннарыгызны аерыгыз!

—Без монда газ сулап, селте эчеп яшибез... Алай да сан юк. Түбән Камадан бер кешенең булса да саф һава сулап кайтырга хакы юк микәнни? Яшергән бомбаларыгызны алыгыз да, алга! Космонавты-ние белән Минзәләне күккә очырабыз!

Ә башкала барысыннан да горуррак фикер йөртте:

—Казан халкы фән өлкәсендә Минзәлә кешеләреннән өстен булды...

—Моның нindидер яшерен хикмәте булырга тиеш, җәмәгать!.. Минзәлә башлыгы Мәскәү президентына ришвәт биргәндер...

Мондый коткыдан соң митингнын койрыгына ут капкандай була:

—Минзәлә башлыгын—отставкага!

—Отс-тав-ка! Отс-тав-ка! Отс-тав-ка!!!

Казандагы галимнәрнең саны Чыңгыз гаскәреннән ишлерәк булуга карамастан, гап-гади чынбарлыкны аңларлык бер генә акыл иясе дә табылмады. Хикмәт шунда, мондый "Отс-тав-ка!»ларга карап кына әле бер генә түрәне дә эштән чыгарганнары булмады.

Инде дә Минзәлә башлыгына килсәк, теге яңалыктан бөтенләй хәбәрдар булмаган хәлдә, Бикбау басуларындагы урак эшләрен тикшереп йөри иде. Булачак космонавт исә, бу сәгатьләрдә, "шанцевый инструментын"—шомарып беткән саплы каен себеркесен кочаклап, канауда йоклап ята иде.

Аны йортлар идарәсе управы торгызып утыртты:

—Тор тизрәк, хурлыкка калдырасың! Космоска очасың, кос-мос-ка!

Ләкин Саттар, иләс-миләс күзләрен бер генә ачты да, дөньягызны күрәсем килми, дигәндәй, мыгырдана-мыгырдана, кабат ауды:

—Әйе, космаска кирәк, космаска... Шуна күрә космадым да мин... Косканым да юк... Юк минем косканым, юк... Булачак та түгел...

—Галәм, димен мин сина, га-ләм!

—Каләм дә кирәкми, сәлам дә кирәкми... Аракы кирәк!

Гомер буе айнымас булса да, шушы Саттар йортлар идарәсендә генә түгел, бөтен Минзәләдә сөекле шәхес иде. Ул таң тишегеннән үк бер-ике шәхси

йортның ишегалдын себереп чыга. Хуҗалар ана туйганчы аракы эчертәләр. Шуннан соң ару-талу белмәс Саттар, яхшы заправкалы машина кебек, шәһәр урамнарын себереп китә. Чөнки як-ягына баш күтәреп карамый, аяк астын гына күрә. Ә инде үз участогын эшенең беренче сәгатендә үк себереп бетергән була... Егерме кешелек эшли Саттар!

Управның бер стакан аракы юнәтеп салдыруы булды, Саттар айнып китте. Айнып та китте, себерә дә башлады. Җитәкчесе аны көч-хәл белән туктатты.

—Ашыкма, диләр сиңа! Торып тор! Космоска җибәрәбез сине, командировкага!

—Ярар, барып кайтырмын... Хәзер үк түгелдер бит...

—Күрше авылга димим мин сиңа, космоска, димен!

—Соң, аңладым бит инде, аңладым. Гагарин очкан космоскадыр... Анда чәчбикәләр дә очты бугай бит инде. Син кушкач, барам инде, барам!

—Мин кушмыйм! Россия президенты куша!

—Алайса бармыйм!—дип киреләнде дә куйды Саттар.—Теләсә кем кушканга йөгеримме? Ахмак түгел лә мин...

—Гагарин белән икегез беренчеләр булачаксыз икән...

—Нинди беренче?!—Саттар, күзен акайтып, ярсый башлады.—Анда бармаган урыс та, чуаш та калмады инде. Берничә парны бала ясарга да менгереп төшерделәр ул космоска...

—Аңла әле: Гагарин—беренче, ә син мең дә беренче! "Беренче" дигән сүзе бар!

—Ну, ярый... себереп чыгыйм да Минзәләне...

Ләкин ике-өч мәртәбә дә селтәнергә өлгермәде, себеркесе өстенә машина килеп менде. Каршында Саттарның күзенә алты булып күренгән өч милиционер басып тора иде.

—Ташла себеркенне, киттек. Космос экспертлары килеп җитте анда. Сине көтәләр.

—Сезнең космосыгыз хакына җандай күргән себеркемне ташларгамы?! Анысы булмас!..

Себеркесен буш утын сараена кертеп куеп, аның ишегенә ике йозак салгач кына, милицияләр уртасына кереп утырды Саттар.

Минзәләгә махсус самолет белән килеп җиткән экспертлар төркеме милиция начальнигы бүлмәсендә түгәрәкләнеп утыра иде инде.

—"РСФСРның атказанган урам себерүчесе" дигән мактаулы исемне алган татар Саттар Гаттаров син буласыңмы?

—Мин. Ну и што?..—диде Саттар, урысларның сөйләшү культурасына охшатырга тырышып.—А вам какое дело?

—Есть важное дело,—диде экспертлар башлыгы.—Космосны себереп, чистартып төшәргә кирәк.

—Тузаны, чүбе күбәйгәнмени?

—Әйе, тузан да, чүп тә җитәрлек анда... Ишеткәнең бардыр, соңгы кырык ел эчендә космоска меңнәрчә спутниклар, кораблар, станцияләр җибәрдек. Инде алар күгәреп, череп беттеләр. Шуңа күрә бөтен дөнья президентлары безнең президентка протест белдергәннәр, әгәр дә үз чүбегезне үзегез себереп алмасагыз, Милләтләр Оешмасыннан да, Европа Советыннан да куабыз, дигәннәр. Шулай итсәләр, чит илләрдән товар керү туктаячак, хезмәт сөючән бөек урыс халкы ачлыктан, ялангачлыктан кырылып бетәчәк...

—Себереп төшсәм, миңа да берәр файда булачакмы соң? Моңа хәтле йә генерал, йә герой иттеләр...

Эксперт, биш бармагын җәеп, учын өстәлгә ябыштырды:

—Һичшиксез, булачак! Президент бу хакта тантаналы рәвештә үзе вәгъдә

бирде. Эшенне җиренә житкереп төшсән, бер айлык минималь хезмәт хакы сина! (Ә үзе күнеленнән сүгенеп куйды: "Карале син бу яптырмалахайны! Татар башы белән исән каласы, кабат җирдә йөрисе килә! Юк инде, анысы тәтемәс, чарасын табарбыз! Җирдә бер татар булса да кимрәк булыр, ичмасам.)

—Бәлкем, ефрейтор да итәрбез сине...

Саттар, сикереп диярлек, урыныннан калыкты:

—Минималь хезмәт хакы икән, киттек алайса, вакыт сатып тормыйк.

Галәм белгечләре ыгы-зыгы килеп алдылар:

—Алай ашыгу килешми.

—Төрле ягын кайгыртасы бар...

—Җаваплы эш ул... Әйтик, мәсәлән, ашарыңа нинди ризыклар тутырыйк корабка? Консервлармы яки ипи, шоколад кебек нәрсәләрме?..

Һәр әйтелгән ризык исемен ишеткән саен, башын як-якка селкергә кереште Саттар:

—Юк, юк! Мин экологик яктан шикле ризыклар кабул итмим. Мин бары тик Минзәлә аракысы белән хушланам.

—Закускага нәрсә? Кабымлыкка, дибез...

—Ике стакан аракыдан соң бер стакан аракы кабып куярга яратам. Корабка бер мичкә аракы куйсагыз, бүтән берни дә кирәкми.

"Әйбәт, бик әйбәт. Димәк, "Мир" станциясендәге бәдрәф пычранмас, чиста торыр. Хәер, ул станция болай да җимерек бәдрәф хәленә калып бетте бугай инде", дип нәтиҗә ясады баш эксперт. Ә үзе мәсьәләнең икенче ягын кайгырта башлады:

—Яхшы, яхшы... Себеркең янамы? Тагын ничәне ясатыйк?

—Бер дә борчылмагыз, татар каенынnan бәйләнгән ул. Космостан соң бөтен Җир шарын себереп чыксаң да тузарлык түгел.

—Тәк-тәк... Сиңа космик станциядән чыгып эшләргә туры киләчәк бит. Шулай булгач, корычтан нечкә трос ясатырбыз. Себергәндә бил каешыңа бәйләрсең. Анысы станциядән ычкынып китмәү, аерылып калмау өчен кирәк. Тагын... тагын... Әһе! Бөтен чүпләрне, ягъни спутникларны, корабларны, ракеталарны тутырып бару өчен дә шундый ук тростан җәтмә бәйләтербез...

Айный башлаган Саттар, кулларын селти-селти, ризасызлык белдерде:

—Бернинди трос та кирәкми! Мин үзебезнең сукырлар җәмгыятендә сүс бау иштерәм. Җәтмәсен дә шул баудан бәйләттерәм. Алар миңа бушлай эшләячәкләр. Үзем дә аларның ишегалдын себергән өчен бер тиен дә алганым юк... Мин Россиядә эшләнгән әйберләрнең сыйфатына ышанмыйм. Алар һәр әйберне "ну его..., итак сойдет" дип кенә ясыйлар.

Шулай да Мәскәүдән килгәннәрнең берсе, күңелендәге агуын тышка чыгармаска тырышып, сорау бирде:

—Минзәлә кешеләре аракыны күп эчәләрме соң?

—Безнең уртак законыбыз бар: эшләгәндә—эчмибез, эчмәгәндә—эшлибез!

...Икенче көнне шәһәргә сәер хәбәр таралды. Кунакханәгә урнашкан экспертларның икесе акылдан шашкан, имеш. Төне буе әлеге уртак законның очына чыгарга маташып караганнар.

—«Эшләгәндә эчмибез»,—диде бит ул. Димәк, тәртипле халык яши монда.

—Ә син ул законның икенче яртысына игътибар ит!—дип каршы төшкән икенчесе.—Эчмәгәндә генә эшлиләр булып чыга түгелме соң?! Бәлки алар гел эчеп кенә яталардыр, бөтенләй эшләмиләрдер...

—Минемчә, төп хикмәт җөмләнең беренче яртысында. Эшләгәндә эчмиләр икән, димәк, эшлиләр булып чыга.

—Ә мин әйтәм, эчкечеләр законы бу! Эчә торгач, эш өчен вакытлары да калмыйдыр...

Шулай итеп, бер үк сүзләрне кабатлый-кабатлый, һәркайсы үз хаклыгын исбатлый-исбатлый, сугыша башлаганнар, бу законнын Мебиус тасмасы кебек үк очсыз, ахырсыз икәнлеген шәйли алмаганнар. Ниһаять, башларындагы кайбер шөрепләре ычкынып китеп, шәрә килеш, Минзәлә урамына чыгып йөгергәннәр. Берсе "эшләгәндә—эчмибез", икенчесе "эчмәгәндә—эшлибез", ди-ди, такмаклый-такмаклый йөгереп баралар икән.

* * *

Космоска старт алдыннан Гагарин "поехали!" дип кычкырган. Ә Саттарның тыны да чыкмады: корабка килеп керүгә үк кранлы мичкәгә чылбыр белән бәйләнгән әлүмин кружканы күздәй итеп аракы белән тутырды, аны төбенә кадәр эчеп бетергәч, себеркесенә ураглан ике чакрымлы сүс бауга башын салып, йокыга китте. Старт кнопкасына басарга тиешле академик, корабның сыңар иллюминаторына ничәмә-ничә мәртәбә тилмереп күз салса да, "смирно" басып торган себеркедән һәм ана кигереп куелган куян бүректән гайре нәрсә күрмәде. Артыннан ут көлтәсе ургытып, Жир шарын дер селкетеп, кораб чиксезлеккә ыргылды...

Кабат бер сәгатьтән бөтен дөнья астрономнарының, галәм белгечләренең карашы йолдызларга, дөресрәге, шул йолдызлар арасында йөзә башлаган Россия корабына төбәлгән иде. Миллион мәртәбә якынайта торган телескоплардан караганда Саттар утырган кораб абзар артындагы сыман якын. Хәтта иллюминатор тәрәзәсенә очлы тимер белән сыдырып язылган өч һәм биш хәрефле сүзләр дә уч төбендәгедәй ачык күренә. Кораб тапшырачак сигнал-тавышларны тоту өчен әзерләп куелган куәтле рацияләр дә, кем әйтмешли, колакларын торгызган: кораб эчендә чебен очкан тавыш та ишетеләчәк!

Ниһаять, старт бирелгәннән соң сигез сәгать үтүгә, гырлаган, мыгырданган тавышлар килә башлады, аннары зур авызлы, кыска көпшәле туптан аткан сыманрак берничә гөпелдәү яңгырады, бераздан чыпырдап сыеклык аккан тавыш ишетелде. Монысын инде бөтен дөнья аңлады: Саттар, йокыдан торып, баш төзәтү хәстәрен күрә!..

Цивилизацияле илләрдә шушы тавышларның язмасын эфирга чыгаргач, шаркылдап көлүдән планета тетрәп торды. Ләкин көлүне курку, шомланып калу алыштырды—кинәт кенә Ай тотылгандай булды, дөньяга дөм караңгылык иңде, көндезге унда шәһәр урамнарында утлар кабызылды, күпләр, саташып китеп, йокларга яттылар. Бары тик телескопларыннан бер мизгелгә дә аерылмаган астрономнар өчен генә бу караңгылыкның сере якты иде—үзе утырган корабны "Мир" станциясенә тоташтырып өлгергән Саттар, ачык космоска чыккан һәм себеркесе белән "ут өертә" башлаган иде. Әнә, скафандрының мунча плафонына охшаган пыяла башлыгы эчендә ачулы карашы елтырый, калын кара кашлары бер жыерылып, бер тирбәлеп куя, ә үзе, Минзәлә урамнарын иңләп баргандагы дәрт һәм кодрәт белән бәбәй итәктәй киң себеркесен селтәп-селтәп жибәрә—галәм киңлекләренә кара тузан күтәрелә. Мона кадәр тыныч кына Жир шары тирәсендә әйләнеп йөргән спутниклар, эт, куян, маймыл, селедка скелетлары төрле якка чәчрәп-чәчрәп оча. Шулай да татар космонавтының кәефсезлеге дә сизелеп тора: үз шәһәрен тавышсыз-тынсыз жыештырып яшәгән Саттар селтәнгән саен диярлек сүгенеп жибәрә:

—Һый, яптырррмалахайларррр, космоссс, имешшш!.. Пычрата белгәч, жыештыра да беләләр аны, ашаган табагына төкергән дуңгызлар. Эх, сезне!.. Космоска беренче булып менгәннәр, имеш. Иң элек тәһарәт алырга өйрәнергә иде, гүрегездә чучка үкергере нәмәрсәләр!..

Очып килүче лифчик белән арыш капчыгыдай киң ыштанны әлеге жәтмәгә ташлаганда йөзенә жирәнү галәмәте чыкты:

—Ач-ялангач йөрмәдең, ир рәхәте дә күрмәдең, ялгызлыкта җаның чыккыры! Карале син аны, космоска менеп, ыштан чәчеп йөргән бит, йөзе кара булгыры!..

Скафандр эченә тегелгән микрофоннан җирдәге махсус радиостанцияләргә шул ук мизгелдә барып җитүче тавышны галәм белгечләрен аптыраштта калдырды. Янәсе: "Ниндидер информацияләр сөйли бу, әмма аңлау мөмкин түгел". Дөньяның төрле почмакларыннан Казанга телеграммалар ява: "SOS! Тиз генә татарча һәм инглизчә белүче тәрҗемәчеләр җибәрегез! Һәр җөмлә өчен минималь хезмәт хакыгызны түлибез".

Ә инде Россиянең космос үзәгеннән таләпләр, куркытулар агыла Саттарның колагына:

—Чо ты там калякаешь, гололобый?! Говори по-человечески! Иначе, там подохнешь, учти!

"Выжжжт!.. вызжжжт!.." ишетелеп торган себерке тавышына кушылып, Саттарның тавышы яңгырый:

—Нәрсә, безнең телне өйрәнергә запрет бар идеме әллә?! Безнең мигә ике тел дә сыя, сезнекенә сыймыймыни? Миңгерәүләр ыштули?! Миңа үз телемдә генә эндәшмисез икән, җавап бирдем булмаячак. Мин—татар космонавты!..

Дистәдән артык спутникны гектарлы җәтмә төбенә аткаргач, Саттар сабыйларча көлеп җибәрде, үзе дә сизмәстән, исендә калган шигырьне укып куйды: "Микикики! Микикики! Капчыктагы бүре башы бит уники!.." Эчендә сөенеч кебегрәк нәрсә дә кытыкланып куйды. Ярый әле, иренмәгәнмен, дүрт классны бетерергә түземлек тапканмын. Өченчедән соң ук ташлаган булсам мәктәпне, бу шигырьне белми калган булыр идем, дип, нәтиҗә ясарга да өлгерде. Ә себеркесе бер мизгелгә дә туктамый, галәмне инләп-буйлап тузан пырхылдата, шул тузан Җир белән Кояш арасына эленгән кара юрган сыман бик озак таралмый тора. Хикмәт икән монда—җил юк икән!..

Хәлдән таеп станциягә кайтып кергәч, себеркесен әледән-әле ватылуы белән үзенә кадәр очкан космонавтларның теңкәсенә тигән кәмпүтергә сөяде дә, телогрейкасын шул кәмпүтернең монитор экранына элеп куйды. Үзенә төбәлгән фотоаппарат кебек нәрсәнең объективына куян бүреген кигерде. Минут та үтмәгәндер, стенадагы репродуктордан тавыш яңгырады. Монысы татарча иде инде! Ниндидер кыз эндәшә:

—Саттар әфәнде, мондагылар зарланалар, нишләгәне күренми башлады, диләр. Бүрегегезне телекамерадан алсагыз иде...

—Барысын да күрми торсыннар әле, сеңелем. Космонавтның... теге... ни... тышка чыгып утырган чагы, дип әйт. Татарларда бөтен нәрсәне дә күрсәтеп бетерергә ярамый, шәригать кушмый, диң... Тамак та ялгап аласы бар әле...

Шунын хаклыгына шик калдырмаска теләгәндәй, Саттар мичкә кранын ачты, тагын бер кружка аракы агызды һәм, бөтен дөньяга ишеттереп, готголдатып эчеп җибәрде:

—Әх, идрит-кудрит, шәп тә инде Минзәлә аракысы!..

* * *

Ярый, Саттар галәмдә оча торсын, ә бу кыйссаның авторы Җиргә төшсен, мондагы хәлләргә күз-колак булсын...

Саттарның галәмгә очуына өч атнадан артык вакыт үткәч, дөньядагы аракы заводларының хуҗалары—күп миллиардлар туплаган капиталистлар баш вата башлаган: кешене шул гомер буена бер лыкма ризыксыз яшәтә, тәүлегенә унбиш-уналты сәгать эшләтә ала торган Минзәлә аракысының хикмәте нәрсәдә? Бары тик үзләре генә белә торган матдәләр кушалармы әллә? Шулай булгач, янәсе, ни өчен бу көнгә кадәр информация кермәгән? Бәлки алар файдалана торган су бик тә үзенчәлекледер? Бик ашыгыч рәвештә

бу аракының рецептын сатып алырга кирәк, алай барып чыкмый икән, шпионнар җибәрү дә гөнаһ булмас. Инде дә!.. Әйе, әйе, инде дә серенә берничек тә кереп булмаса, ике дә уйлап тормастан, шартлатырга туры килер. Чөнки кайдадыр мондый конкурент бар икән, беттек, бөлдек дигән сүз...

Ике йөз илдәге меңнәрчә аракы заводларыннан теге яки бу хәйлә белән шпионнар килеп төшкәч, унбиш мең кешелек Минзәләнең халкы бер атна эчендә чирек миллионга җитте. Башта кунакханәдәге бүлмәләрнең җидесенә дә сәндерәләр ясаттылар, тора-бара аскы катлардагы тулай торaклардан студентларны куып чыгарып, андагы бүлмәләрне дә кунакханәгә куштылар. Кайберләрендә люкс шарты да тудырмакчы булдылар әле... Ә монда гади номерны люкска әйләндерүнең мәшәкате зур түгел: өстәлдәге сырлы стаканны рюмкага алыштырдыңмы, теләсә кайсы бүлмә люкс була да куя! Аннан соң инде рәхим ит—бәяне ике мәртәбә артыграк түлә!.. Мондый чакта линиягә тоташмаган телефон, җимерек унитаз, янган телевизор, бүлкәләре ватылган тәрәзәләр, обойлары салынып төшкән стеналар исәпкә керми.

Алданрак килеп өлгергән шпионнар үзләрен бик бәхетле тойдылар: ни дисәң дә түбәдән яңгыр үтми! Шул бүлмәләр өчен конкуренция көчәйгән саен, Минзәләнең зирәк хакимияте кунакханәдә яшәүне тәүлекләп, сәгатьләп кенә түгел, минутлап санау тәртибен кертте. Торасың килә икән, минутына йөз долларны чыгар да сал—вәссәлам! Фатирларга урнашкан илчеләр һәм шпионнар өчен дә бәянең иге-чиге күренми башлады. Иртән бер бәя булса, кичкә таба биш-алты мәртәбә арта тора. Түләрлек хәлең юк икән—әнә барыр юлың, алдыңнан артың хәерлерәк, капиталист абзый! Чит илдән килгән халыкның бер өлеше хәйләле юл сайламакчы булды: кыр-болыннарда, урманнарда төн үткәрүне мәслихәт санады. Ләкин боларның да эзенә тиз төштеләр. Минзәлә җирендә йоклыйсың килә икән, буржуй иптәш, һәр квадрат метр өчен бер пачка долларыңны чыгарып сөйләш! Рубльләреңне шәһәр чүплегенә чыгарып түк. Шулай итмисең икән, районны чүпләвең, пычратуың өчен башың штрафтан чыкмас.

Шулай итеп, Саттарның галәм себерергә китүенә ике ай дигәндә, песи төчкереге хәтле хезмәт хакларын да айлар буе ала алмыйча җәфа чиккән Минзәлә халкының һәркайсы капиталистка әйләнде. Урамнарга чыкмалы да түгел: рәт-рәт булып баручы "Мерседес"лар, "Джип"лар һәм "Линкольн"нарның чуты-хисабы юк. Хәтта мона кадәр бәдрәфтәй алачыкларда, куышларда торып интеккән алкашлар да икешәр-өчәр катлы коттеджлар сала башладылар. Долларлар ташкынын кая куярга белмәгән хакимият башлыгы Мәскәүнекеннән дә зуррак, затлырак Кремль проектына заказ бирде. Тиз арада Минзәлә елгасының яр читләренә мәрмәрдән тротуарлар салуны кирәк таптылар. Аэропортны янартып, Вашингтон, Париж, Рио-де-Жанейро, Токио, Багдад шәһәрләренә очу өчен дистәләрчә "Боинг" самолетлары сатып алдылар. Әллә нинди президентлар, корольләр явып кына тора хәзер Минзәләгә! Шуларның барысына да почетлы каравыл оештырмый булмый бит әле... Почетлы икән, димәк, милиционерлар да затлы күренергә тиеш! Һәркайсына алтын погоннар тактылар, кичәге сержантлар, лейтенантлар, ким дигәндә, майор яки полковник булды, генераллар взводы төзелде, милиция начальнигы, район хакимияте башлыгының махсус указы белән, милиция маршалы дәрәҗәсенә күтәрелде.

Шуннан соң кайбер күңелсезлекләр дә туа башлады Минзәлә районы башкаласында. Икенче көнне үк милиция башлыгына Мәскәүнең Эчке Эшләр Министры шылтырата: янәсе, хәлләрең ничек, полковник? Ә мондагы тавыш горур яңгырый:

—Сортыңны белеп сөйләш, генерал! Маршал белән сөйләшкәнеңне оныт-

ма! Миңа шылтыратканчы тәһарәт алдыңмы, смирно бастыңмы?

Тегесенең башка сүз әйтерлек чарасы калмый—авызы кибә һәм, коты алынып, трубканы куя. Әмма шул атнада ук аракы заводы директоры эзсез югалып тора. Моны милиция киемендәге ниндидер бандитлар, Мияш урманына алып китеп, өч тәүлек буе җәзалаганнар:

—Чит ил магнатлары белеп өлгергәнче, аракыңның рецептын безгә бир! Мәскәү файдасына сатачакбыз. Ату, сез монда баеп ятканда, Россия дөнья дәүләтләреннән вак-төяк акча теләнеп сансызлана. Рецепт безнең кулга керми икән, матри, кояш белән саубуллашырга туры килмәгәе!

Әллә сер итеп саклана торган рецепт бөтенләй булмаган, әллә директор гадәттән тыш чыдамлык күрсәткән, гел бер сүзне кабатлап торган:

—Юк андый нәрсә, юк! Юк!! Юк!!!

Итәк астыннан гына йөргән хәбәрләргә караганда, аны Американың ЦРУы коткарган. Мәскәү генералы, егермеләп милиционеры юк ителсә дә, артын кыскан—бу вакыйгада катнашу фактын яшерү өчен, шым булуны мәгъкуль күргән: "Ул бандитлар безнеке түгел, безнекеләр Чечняда", дип акланган.

Иллә дә мәгәр бу хәл Минзәлә кешеләрен сизгерлеккә дә өйрәтте: аракы заводы директорына, генераль директор статусы биреп, аңа бер полк тән сакчысы билгеләделәр.

Яшерен лабораторияләрдә чит ил агентлары, Минзәләгә һәм аракы заводына килә торган суның составын тикшергәч, телсез калганнар: бу су микроблардан, бактерияләрдән һәм вируслардан гына тора икән, дигән нәтиҗәгә килгәннәр һәм, яшерен шифр белән Америкага телеграмма җибәргәннәр: "Безнең фикеребезчә өтер Минзәлә аракысының туклыклы булуы өтер кешеләрдә хезмәт сәләтен саклавы нәкъ менә шул бихисап паразитлар аркасында булырга тиеш нокта Алар сыек ит формасына керәләр өтер кеше организмын туклыклы матдәләр белән тәэмин итеп торалар".

Форсатны кулдан ычкындырмаска күнеккән чит ил магнатларыннан бихисап үтенечләр ява башлый. Һәркайсы Ык суының сатылуына, махсус килешүләр төзүгә өмет баглый. Алардан җибәрелгән вәкилләр, үз илләренең Ык суыннан өлешсез калуыннан котлары очып, Минзәлә башлыгына яңа тәкъдим кертәләр:

—Суны аукционда сату сезгә дә, безгә дә файдалы булачак. Шушы ысул белән халыкара гаделлек принципларын санга суксагыз, бөтен илләр Татарстан суверенлыгын бердәм танырга әзер торалар. Инде дә телисез икән, Минзәлә республикасы игълан итегез. Аны да, халыкара хокукый дәүләт итеп, Берләшкән Милләтләр Оешмасы составына кертүне хуплаячакбыз. Тарихыгыз да моның өчен унай шартларны күрсәтеп тора. Сездә, мәсәлән, элекке заманда "Минзәлә иле" исемле гәҗит чыккан. Димәк, Минзәлә дигән дәүләт тә булган!

Беренче аукционга нибары бер кубометр су куелды. Чүкеч белән сугып, башлангыч бәясен әйттеләр:

—Илле доллар!

Чит ил эшмәкәрләре үз бәяләрен кычкырырга ашыктылар:

—Алтмыш!

—Без туксанга алабыз!

—Йөз!

—Йөз егерме!..

Бәя дүрт йөз долларда туктап калды. "Ничауа, монысы да ярый,—дип нәтиҗә ясады хакимият әһелләре.—Миллион кубометр гына сатсак та, җан башына кимендә ун мең доллар өстәләчәк". Ләкин сәүдә әлеге миллион кубометрны сатуга ук туктап калды. Чөнки дөнья галимнәре яңа версия күтәреп чыктылар: "Хикмәт суда түгел! Андагыдан да күбрәк паразитлар

тупланган су чыганаклары Африканың кыргый кабиләләре яши торган якларда да табылган. Хикмәт Минзәләнен ашлыгында булырга тиеш!»

Су белән авызлары пешкән дөнья вәкилләре бу юлы сагаебрак эш иттеләр. Минзәләлеләр күпме генә: "Ашлык бит ул су гына түгел! Арышы да, бодае да мангай тире түгеп үстерелә аның!»—дип авыз суы корытмасыннар, әллә ни файда чыкмады: районлагы бөтен ашлыкны җыеп, тоннасын нибары ун мең доллардан җибәрергә мәҗбүр булдылар. Сатылган йөз мең тонна урынына Актаныш, Сарман, Мөслим якларыннан яна ашлык кайтарттылар. Алардагы ашлык 66 мәртәбә арзанрак булганлыктан, район казнасы зур отыш ясады, әмма яңа мәшәкать туды. Банк директорының әйтүенә караганда, тупланган долларларны куярга урын калмаган. Гаражлар, утын сарайлары шыгрым тулган яшел валюта белән, ишегалдына да берничә чүмәлә өеп, брезент белән капларга мәҗбүр булганнар. Шуңа күрә, бик тә экстерн рәвештә, яна банк төзергә кирәк икән!

Сәвит чорындагы гадәт буенча өмә оештырып, Минзәлә халкы банктагы долларларны ашлык кабул итү пунктының складларына ташыды. Өмәдә катнашкан ун мең кешенең фидакарьләрчә эшләве нәтиҗәсендә, егерме мең тонна долларны әлеге складларга күчерү өчен ике көн вакыт житте. Ә инде иске банкны Саттарга бау ишкән, җәтмә үргән сукырлар җәмгыятенә касса итеп бирделәр.

• • •

Космос тизлек ярата.

Космоста һәр нәрсә бездәгедән йөз мәртәбә кызурак хәрәкәт итә.

Менә шуңа күрә космос турында язучылар да каләмнәрен тизрәк уйнатырга, битләп-битләп язардай вакыйгаларны да бер-ике җөмләгә сыйдырып куярга, кайбер хәлләрне, әле генә күргәнегезчә, санап кына, әйтеп кенә үтәргә мәҗбүрләр. Язу өстәлең артында йокымсырап утырасың икән, потың бер тиен—сонга калдың дигән сүз.

Менә мин дә, Минзәләдәге хәлләр белән мавыгып китеп, галәмдәге Саттардан аерылып тордым. Обсерваториягә бу юлы да атнадан артык вакыт үткәч кенә бардым. Ә ан-да-а-а!..

Ә анда, ягъни галәмдә, урыс әйтмешли, кошмар! Бер очы—"Мир" станциясенең койрыгына, икенче очы бил каешына бәйләнгән бауны йә беләгенә урый-урый, йә сүтә-сүтә, әлеге гектарлы җәтмәгә космостагы үтилләрне—берсеннән-берсе зуррак, иләмсезрәк спутникларны, корабларны, ракеталарны сөйрәп китерә тора Саттар. Мондый чакларда ул кабартылган каз куыгын яки футбол тубын япа-ялгыз тартып баручы кырмысканы хәтерләтә. Еш кына болай да итә: кайсыдыр ракетага менеп атлана да, себеркесен ишкәктәй тотып, әле бер, әле икенче якка күчерә-күчерә, галәм океанын ишә башлый. Кайчак җырлап та җибәрә:

Менәмен дә утырамын
"Восток"ның билләренә.
Көн дә тормый кайтыр идем
Сөекле илләремә.
Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Гандали.
Туган илдә дөнья матур—
Бер минуты әллә ни.

Әйтеп торуның да кирәге юктыр, Саттарның галәмдәге эшләре белән таныштырган мизгелләрдә, Россия телевидениесе аны телсез итеп күрсәтә—

тавышын ишеттерми һәм, бер караганда, дөрес тә эшли. Мәсәлән, аның жырындагы Гандәли—Саттар эшли торган йортлар идарәсендә подъездлар юып йөрүче хатын. Үзе генә ишетсә бик шат булыр иде дә бит галәмнән килгән жырга!.. Әмма иренең дә ишетүе, Саттар белән Гандәли арасындагы яшерен хәлләрне белүе мөмкин. Чөнки Минзәлә ирләре дә, Жир йөзендәге бөтен ирләр кебек үк, чит хатыннар янына йөрергә яратсалар да, үз хатыннарының бүтән мыекбайлар куенында ятуын күз алдына да китерергә теләмиләр.

Билгеле инде, Россия телевидениесендә ул серләрне белмиләр, жырның хикмәтен дә аңламыйлар, "татарин опять что-то каля-маля кричит" дип кенә көләләр. Аларның төп максаты бер генә: урыс илен татар жыры, татар сүзе сасытмасын!..

Әлеге дә баягы, Саттарның урысчалатып, кырык катлы итеп сүгенәчәген дә истән чыгармыйлар космос белән тоташкан урыслар. Менә бу юлы да, жырын түгәрәкләп бетермәстән, бөтен галәм тетрәрлек итеп сүгенә башлады космонавт. Ник дигәндә, каршысына адашкан ракеталарның чираттагысы килеп чыкты.

—Һу, иманыгызны!.. Халыклары эттән ач, беттән ялангач заманда галәмгә тимер-томыр ыргытып, байлык туздырып уйнаганнар бит, уйнаштан туган нәрсәләр! "Восток", имеш, "Восход", имеш!.. Кояшыгыз батты бит инде, абзыкайлар! Монысы нинди "Союз" тагын?! Һә-һә, анысы да жимерелде ләбаса "Мир"лар ясый-ясый сугышып яшәгән гомерләрегездә. Ач кешеләрегезнең тамагын туйдырырга кирәк иде башта. Авызларын ачсалар, үпкәләре күренә бит инде!..

Биленә кыстырылган шешәсен алып, мөшкәсеннән генә берничә мәртәбә күз яшедәй үтә күренмәле сыеклык йоткач, шаркылдап көлде дә тутык ашап бетергән "Восток"ка әле яңа гына килеп житкән черек "Восход"ны себеркесе белән тартып китерде. Аны койрыкка тагып куюы булды, икесен дә жәтмәгә таба юнәлтте.

Укучы ничек уйлый торгандыр, мин үзем аның сүгенүләрен дә, жырлап, сөйләнеп йөрүләрен дә гаепләмим. Аның күңелен аңлау өчен, үзеңнең дә иксез-чиксез галәмдә япа-ялгыз йөреп каравың кирәктер...

* * *

...Минзәлә заводы аракысының бәясе космик тизлек белән арта башлагач, мондагы төзелешләрнең колачы адәм ышанмаслык төс алды. Кремль инде әзер диярлек. Аның ишегалдында тугыз гөмбәзле, ике йөз метр биеклектәге чиркәүне алтын белән тышлау эшләре дә төгәлләнеп бара. Татарларның да хәтере калмасын дип, авылларның берсеннән мунча бурасы сатып алып кайттылар. Анысын мәчет итмәкчеләр. Инде өстенә куелачак калай манарасы да әзер икән. Кремль капкасын чыктыңмы, үз күзләреңә үзең ышанмыйсың: түбәләре болытка тигән биек йортлар, банк биналары, патша сараедай рестораннар, менәр-менәр бүлмәле кунакханәләр тезелеп тора. Хәтта гасыр башында ярминкәгә килеп йөргән чит ил сәүдәгәрләре өчен эшләп торган Камали бардагы урынына, заманча итеп, өр-яңа "кети-мети" йорты да салырга онытмаганнар. Элекке ике катлы бина урынына йөз дә ике катлы итеп салынган бу бинаны да алтынга төргәннәр, Мәскәү якларыннан бер эшелон кыз алып кайтып, "изге эшкә" жиккәннәр. Ак, кызыл, кара мәрмәр жәйгән киң проспектларны шампунь белән юа торган техника кайтарткannar. Әйтергә онытып торам икән, хәтта унбиш ел буе ремонтка ябылган Минзәлә дәүләт драма театрын да, төзәтеп бетереп, кабат ачу тантанасы үткәргәннәр... Казанга барып кайтучылар, Казан турында сүз чыккан саен, борын жыерып, чырайларын чыталар. Янәсе: искә төшереп торма әле шул иске бәдрәфне...

Татарстанның яңа президенты да Актаныш ягыннан икән. Ул, Минзәлә белән вәкаләтләр бүлешеп, башкаланы Казаннан Минзәләгә күчерү өметенә кергән, диләр. Шул максатта бөтен аппаратын ике яклы Шартнамә төзергә утырткан.

"Минзәлә кешесе!" дигән сүз һәркайда горур яңгырый. Әфтәрититләренең чамасы юк. Кайсы гына калага барып чыксалар да:

—Мин Саттар Гаттаров шәһәреннән!—дип кенә жиффәрәләр. Шул сүзне әйтүләре була, оркестрлар уйный башлый, ачылмас ишекләр ачыла, табыннар әзерләнә. Хәтта Минзәләнең бетле күзле бичлары һәм бомжлары да Чаллы, Түбән Кама мэрларының түрендә, күкрәк киереп, коньяк, ром, виски чөмерә...

Шәһәргә читтән килеп, архитектор булып эшли башлаган бер адәм өр-яңа фикер күтәреп чыккан—шәһәр уртасына Саттар Гаттаров һәйкәлен салырга кирәк, дип, шундагы гәҗиткә дә язып өлгергән. "Ул һәйкәлне төзү өчен шәһәребезгә Саттар Гаттаров аркасында кергән байлыкның миллионнан бер өлеше дә китмәячәк", дип исбатлаган. Бу мәкалә үз ягында туып-үскән олы шәхесләрен хөрмәт итә белмәүче Минзәлә халкында нәфрәт тудырган. Барысы да митингка чыгып, әлеге архитекторны шәһәрдән кудыру актына кул куйганнар. Бары тик хакимият башлыгының Минзәлә кешесе булмавы аркасында гына үз сүзләрен гамәлгә ашыра алмаганнар. Башлык бу мәсьәләне хәл итү өчен тагын да арзанлырак, җинелрәк вариант тапкан—иске хакимият бинасы каршында торучы Ленин һәйкәлен үзгәртеп төзергә әмер биргән.

Архитекторлар һәм сынчылар ул әмерне көнендә үк гамәлгә ашырып куйдылар: Ленинның алга сузылган кулын өскә—галәм юнәлешенә каерып күтәрделәр дә, икенче кулына цементтан коелган себерке тоттырдылар. Әлбәттә инде, Ленинның башын салдырып алып, өр-яңа баш та ялгадылар. Карашын күккә төбәгән Саттар Гаттаровны Минзәләнең бөтен алкашлары да танырлык булды. Алар, космонавтның постаменты тирәсенә бушаган шешәләр китереп куеп, хөрмәт белдерделар. Тик шунысы, баш төзәтерлек акча таба алмагач, үзләре үк җыеп алып, савыт-саба ларегына илтеп тапшырдылар.

* * *

Саттар станциягә караңгы төшкәч кенә кайтып керде. Аягын сөйрәрлек тә хәле калмаган иде. Телогрейкасын җәйде дә идәнгә ауды. Хәтта "хәләл ризыгын" да яткан көе генә чөмерде. "Бетә, Аллага шөкер, эш бетә!" дип сөенде ул, үзалдына елмаеп. Шунда ук шомланып та куя: "Аракы да бетеп бара..."

Галәмдәге иске-москы хәзер корабка тагылган иске җәтмәдә инде!

Бары тик орбита буйлап әйләнүче меңнәрчә шешәләр генә калды. Юри ахырга калдырды ул аларны: кадерен белеп, тәмен белеп җыю өчен! Их, менә шуларны аерым капчыкларга тутырып, Минзәләгә алып кайтсаң иде дә, шешәдәш дуслар белән илтеп тапшырсаң иде! Күпме аракы тиячәк бит аларга! Мүре! Урысча әйтсәк, море! Ну, сөенер иде дуслар! Ул аракы беткәнче кулда гына йөртерләр иде Саттарны. Гандәли тозлы кыяр белән селедка ярата башлаган иде Саттар белән кавыша башлагач, аңа да күчтәнәчлек калыр әле, бәлкем...

Шул ягы үзәккә үтә бу галәмдә—тән кычыта, «Мир»да дистә еллар буе җыелып яткан бетләр, кандалалар сөягенә төшеп кимерәләр. Мунча кирәк аңа хәзер, мунча!.. Хәер, кан эчүче бу паразитлар хәлсезләнә башладылар соңгы вакытта. Саттарның канын эчкәнгәдер, стенада алпан-тилпән йөриләр. Алар бит, кан эчәбез дип алданалар, чынлыкта спирт эчәләр. Саттар кайтып киткәч, махмырдан кырылып бетүләре дә бик мөмкин. Шундый нәрсә ул

Минзәлә аракысы: эчкәндә каннарың да яңарып киткәндәй була, әмма, эченә керми торса, жан тәслим кылгандай интегәсең...

...Ерәп кенә китәм дигәндә, тәрәзә шакыдылар—иллюминатор пыяласын! Куркудан коты ботына төшкән Саттар күзләрен чытырдатып йомды. Катырак, шомлырак итеп тагын берничә мәртәбә төйделәр иллюминаторны. Әллә шайтаннар да менеп житә микән бу космос дигәннәренә?! Галлюцинация башлануы түгелдер бит, Ходаем!..

Йомылган күзләрен куллары белән дә каплаган иде Саттар, әмма станция эчендәге көчле яктылыкны барыбер шәйләде. Алай-болай ут чыкмагандыр бит?!

Күзен ачуы булды, тыштан шаку аралаш тавыш яңгырады:

—Саттар! Саттар!! Саттар, дим!!! Уян тизрәк, бетәсең! Сине харап итмәкчеләр!

Саф татарча эндәшәләр бит әле, житмәсә! Тиз генә торып караса, ни күрсен, иллюминаторның теге ягында... түбәтәйле бер егет карап тора! Шундый көләч, шундый матур, мыегы медучилище директорыныкына охшаган. Ә үзе, аякларын салындырып, бик тә дәү тәлинкә читенә утырган.

Ләкин көләчлеге шундук югалды егетнең—Саттарны күреп алуга ук житдиләнеп китте.

—Айны, кардәш, тиз бул, монда чык! Жирдәге башлыкларың кислородны ябачаклар. Сине үтермәкчеләр!..

Чүт кенә скафандрсыз чыгып йөгермәде космонавт. Ләкин, акылына килеп, кия башлады. Шулвакыт станция эчендә нәрсәләрдер чыжларга, сызгырырга тотынды: әйтерсең лә, ниндидер машина камерасын кабарттылар-кабарттылар да, тиз генә ниппель, колпачок дигән нәмәстәләрен тыгып куйдылар.

Ләкин Саттар бер мизгелгә генә булса да алданрак өлгерде скафандрын кияргә. Ә скафандр эчендәге баллонда ярты сәгатьлек чамасы кислород бар иде әле.

...Станциядән башын тыгуга ук аны кемнәрдер күтәреп алдылар. Ике-өч мәртәбә дә сулыш алырга өлгермәгәндер, үзен шундый рәхәт, шундыен да пөхтә бүлмәдә күрде. Һавасы, гүя, Ык буеныкы. Эссе көндә тал күләгәсендә утырган сыман...

Ә каршысында, ошбу егеттән кала, тагын өч татар утыра. Барысы да сизелер-сизелмәс елмаялар, күренеп тора, карашлары белән Саттарны барлыйлар. Чал төшкән түгәрәк сакаллысы, алдындагы чынаяктан сөтле чәй кебегрәк нәрсә йотып куйды да, ак сөлгене иреннәренә тигереп алгач, рәхимле генә көлеп куйды:

—Аллага шөкер, милләттәшебез исән калды. Шунын хакына, Аллаһы Тәгаләнең кодрәтле вә рәхим-шәфкатьле булуы хакына дога кылыр вакыт та житкәндер, балалар.

Алар дога кылганда Саттар да кушучы белән битен каплап утырган булды. Бу очракта да тамагыңны киереп, катлы-катлы сүгенеп кенә жибәрәсе булса, ул боларның барысыннан да уздырыр иде. Әмма нурлы, тыныч карашларыннан ук аңлашыла—болар, мөгаен, Россиядә әйтелә торган күп сүзләрне белмиләрдер. Кулланмыйлардыр...

Дога кылынып беткәч, битләр сыпырылгач, Чал Сакал әкрен генә сүз башлады:

—Синең хакта сорашып тормыйбыз, кардәш. Без, Жирдәге һәр татарның тормышын, язмышын белгән кебек, синекен дә беләбез. Синең галәмгә очачагың турында Жирдән хәбәрләр яңгырый башлауга ук, һәр хәрәкәтеңне, һәр гамәлеңне күзәтеп тордык. Сездәге космик үзәкнең яшерен тыннары да безгә килеп тора, дип әйтүнең кирәге дә юктыр. Чөнки без андагы һәр кешенең тавышын гына түгел, үе белән ниятен дә тыңлый алабыз. Менә

бүген шул космик үзәк дигән мәкерле йортта синең хакта кыска гына сөйләшеп алдылар. "Әгәр бу татар шушы зур эшләреннән соң Жиргә төшсә, аңа кадәр очкан урысларның эше бер тиенлек тә булып күренмәячәк, аны үтерик", диештеләр. Ә инде син җыйган чүп-чарны кайсыдыр кафердән төшертмәкчеләр... Шуннан соң без тиз генә юлга чыгарга булдык...

Тын гына утырган Саттар Чал Сакалның сүзен бүлдерми кала алмады:

—Сез үзегез кайсы районнан буласыз соң... абзый кеше, дисәм, аерма зур түгелдер... (Бүлмәдәгеләр, Чал Сакал сизмәгәе дигәндәй, сәер генә елмаешып куйдылар.)

—Аерма зур, бик тә зур, улым. Йөз мәртәбәдән артык. Минем улларым туганда да сезнең бик ерак бабаларыгыз әле монда—Натсратат планетасында яшәп яталар иде. Төшереп өлгермәгән идек әле аларны. Әйе... "район" дигәненә дә җавап булды бугай—без моннан, сезнең сәгать белән исәпләгәндә, ярты сәгатьлек юл үтә торган планетадан. Син монда менгән ара безнеке ннән миллиард мәртәбә кыскарак... Хәер, аз гына сабыр...

Ул ниндидер төймәгә басты. Шундук: "Мәскәү сөйли. Соңгы хәбәрләр тапшырабыз", дигән аваз килде дә, музыка шыңгырдый башлады. Гаҗәпләнүе хәттин ашкан Саттар шул арада сорау бирми түзмәде:

—Кайчаннан бирле татарча сөйли башлаган бу Мәскәү?!

Чал Сакал да хәбәрләр башланганчы җавап бирәп өлгерде:

—Без барлык телләрне дә тәрҗемә рәвешендә кабул итәбез.

Мәскәүнең беренче хәбәре үк, Минзәлә кешеләречә әйтсәк, аяктан еккыч иде:

"Бүген галәмнән күңелсез хәбәр алынды—галәмсәфәр Саттар Гаттаров фаҗигале төстә үлде. Ләкин бу көтелмәгән үк хәл түгел иде. Инде дөньяның хәл-хәбәр чараларыннан мәгълүм булганча, ул корабка бик күп аракы тутырткан иде. Шунлыктан, бер файдалы эш тә кыра алмыйча, елга якын эчеп ятты. Табибларның әйтүенә караганда, йөрәге тотып, баш миенә кан савып үлгән. Бу җәһәттән Илбашның катгый белдерүе дә мәгълүм булды. Ул: "Татарлар эчкече, ялкау һәм табигый яктан зәгыйфь булганлыктан, киләчәктә мондый хатаны кабатламаячакбыз", дигән. Гаттар Саттаров ел буе эшли алмаган эшне урыс галәмсәфәре Иван Вольфович Шнайдер бер атнада башкарып чыгарга вәгъдә бирә. Ул галәмдәге барлык чүп-чарны җыеп, Минзәлә читенә алып төшәргә дип тора. Ошбу чүпләрдә радиация нормадан миллион мәртәбә артыграк булганлыктан, Минзәлә халкын Соловкига күчерү каралган. Иван Вольфович китәчәк корабка бер атнадан старт биреләчәк".

Инде айнып беткән Саттарның каны кабарганын, бу хәбәрне ярсулы нәфрәт белән тынлаганын әйтеп торуның кирәге бар микән? Ул: "Оятсызлар! Мин үлмәдем, мин монда!" дип сикереп тормакчы иде дә, Чал Сакалның салмак, тынычландыргыч соравын ишетте:

—"Радиация" дигәнен генә аңламадым. Анысы нәрсә икән тагын?..

—Агу ул!—диде Саттар һәм сүгенеп куймакчы иде, кайда, кемнәрдә булуын абайлап, телен тешләде.

Шулчак Чал Сакал егетләрнең берсенә боерык биреп өлгерде:

—Габделәхәт углым, Мәскәүдәге гөнаһсыз бәндәләргә агудан саклану әфсенен җиткер. Ә син...—Ул икенче ягында утыручы иргә борылды.—Ә син, Габделхәмит кияү, Саттар тутырган җәтмәне Мәскәүдәге Кремль ишегалдына төшереп өй. Үз нәҗесләрен үзләре иснәсеннәр! Акылга утыра башлаулары хәерле булыр. Күп түздек—җитте! Ә без ошбу кораб белән Саттар оланны Минзәләсенә илтеп куярбыз.

Ике ир-егетнең коридор сыманрак уемтыкка кереп югалуы булды, Чал Сакал каршында утырган улына әйтеп куйды:

—Киттек, Габделбәр углым. Абыең белән җизнәңә хәбәр җиткер. Утыз

сулыштан соң монда булсыннар. Сиңа да сүзем бар Саттар олан: агулы илдә яшәп, агу эчеп йөрмә. Татар халкының тәгаме түгел ул. Бүтән милләт өлешенә кермә—үзләре ризыклансын ул эчемлек белән.

Авыр сулап алды да Чал Сакал, өстәп куйды:

—Без сезнең авыр тормышыгызны аңлыйбыз. Кирәк тапсак, бер сулышта дөньягызны ямьли алабыз. Ләкин үзегезнең акыл туплавыгызны телибез. Бабаларыгыздан башлап бердәм булмавыгыз харап итә сезне. Шуңа күрә без, сезне чыныктыру, гыйбрәт алдыру, сынау өчен, урыс дигән кавемне дә уйлап таптык. Чөнки без теге заманда үз планетабызда гөнаһ кылган татарларны төшергән идек Жиргә... Ярый, сау бул. Без сине онытып бетермәбез...

"Әле юл озын, бик озак сөйләшеп кайтырбыз", дип өметләнгән иде Саттар. Баксаң, ул авызын ачып өлгергәнче дәү тәлинкәнең ишеге ачылып китте.

—Синең туган илең шушы. Аны бәхетле итәргә тырыш!

Саттарның баш өстендә генә җил сызгырып алгандай булды һәм ул кычкырып җибәрә язды: як-ягында яшел алан, ә алдында биниһая зур ят шәһәр иде.

—Абзыкаем, ялгыш чит шәһәргә төшергәнсез бит! Кайтырга бер тиен акчам да юк минем!—дип кычкырмакчы иде ул. Әмма ике-өч чакрымда гына Дамбы күперен күргәч, шым булды. Балачактан ук күзгә, күңелгә газиз булып сеңгән күпер иде бу!

—Үлгән кешегә без нинди акча бирик?!—дип, аңа вәгъдә ителгән минималь хезмәт хакын бирмәделәр.

Ул үзе:

—Менә бит мин! Исән бит! Таныйсыз бит!—дип, шактый "бит"ләрне тәкрарлап караса да, бер тиен дә бирмичә кире бордылар. Артыннан:

—Әйе, таныйбыз, исән икәнеңне дә күрәбез. Ләкин сине Мәскәү тиклем Мәскәү үлдегә санаган икән, без аның сүзеннән уза алмыйбыз,—дип калдылар.

Аны бөтен шәһәрдә бер кеше генә санга сукты, хәлен аңлады. Ул—йортлар идарәсе башлыгы Исмай Галләметдинов иде. Саттарны күпме генә иске эшенә алырга тырышса да, файда чыкмады. Шәһәр башындагы түрәләр, кырт кисеп, Исмайның тетмәсен теттеләр:

—Башың бармы синең?! Шушындый гүзәл шәһәрне себертергә шундый шыксыз бәндәне урамда йөртикме?! Хәерче бит ул, бердәнбер хәерче! Аңлыйсыңмы шуны! Безнең күркәм шәһәребезнең юлларын бары тик сылу кызлар чистартып торачак!

...Бер эш тә тапмагач, Саттар атна буе урман-кырларда, болыннарда каңгырап, елап йөрде, йөрде дә, шәһәргә кайтып, үзенә салынган һәйкәл төбенә хәер сорашырга утырды...



Луиза
Янсуар

# СӨЮ КАДӘР СӨЮ—МИРАСЫБЫЗ...

## Без җан өргән учак

*Везде огонь я древний разжигала...*
Габриэла Мистраль

1

Син—имәннәр, таулар нәселеннән,—
Күкрәгеңә оя корган давыл...
Таҗларымны йомар мизгелемдә
Иң назлы җил булып миңа... кагыл!

Без, Тынлыкның татлы төшен бүлеп,
Утлы дулкын булып кабынырбыз.
Иң борынгы изге бу Ялкынга
Мәҗүси көч белән табынырбыз.

Мин—үләннәр, гөлләр нәселеннән,—
Табигатьнең тәүге Моң иленнән.
... Өстебезгә йолдыз-шәлен ябып,
Фатихасын биреп... Төн иелгән...

2

Кушылып ак минем елгаларга,
Минем таулар аша үрел Күккә!
Гашыйкларның җаны риза бары
Ике иңне бер итәрдәй йөккә...

Йөрәгеңнең купкан тамырларын
Сыендырыр туфрак булса җаным...
Өермәдәй күмел ул туфракка,—
Күк суларын эчкән—яшьнәр чагым.

Мин берьюлы ике гомер чиген
Бер офыкта төйнәр кояш гүя.
...Иреннәрең, кагылып учларыма:
«Өннәремнән мине... уят!»—дия.

Луиза ЯНСУАР (1981)—*шагыйрә; «Күзен ача умырзая», «Мин күкләргә кайтам», «Болан кызы» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

**3**

**Тамырларым сулкылдап җир яра,—**
**Эзләреңнән... сине эзләп бара.**
**Дөнья—салкын. Җилләр шундый уйчан.**
**Тын тауларны күксел болыт сара.**

**Шифа бирер яңгырларны көтәм,**
**Төннең кара толымнарын сүтәм.**
**Хыялларга син хыянәт итсәң,**
**Җирдә инде таңнар тумас бүтән.**

**Кояш көлмәс, ай да йөзмәс башка,**
**Әверелер гөлләр тораташка.**
**... Тамырларым сулкылдап җир яра...**
**Бер хәбәр бир, офыкларга аш та!**

**4**

**Бер-беребезне барыбер калдык саклап**
**Хыянәт һәм нәфрәт болытыннан.**
**Син төннәрдә инде җуелмассың,**
**Мин комнарга күмелеп онытылмам.**

**Дөрләрбез бер Өмет учагында,**
**Мәңге уяу җилләр өнен тыңлап.**
**...Җаннар җанга орынып, кушылганда...—**
**Ходай үзе бага Җиргә, сынап...**

**5**

**Учларында—туфрак исе,**
**Яшәү тыны—мәңге сулмас.**
**Җирдә тынар бар вакытлар,**
**Без кавышкан мизгел узмас.**

**Башакларны үтәм сыйпап,**
**Тургайларга дәшәм, көйләп.**
**Алар безнең җырны җырлар,**
**Сүнгәндә дә кояш—көйрәп.**

**Орлык сибәм кара җиргә,—**
**Гөлләр шытса, Сөю үлмәс.**
**... Сүнәр, бәлки, бар ялкыннар,**
**Без җан өргән учак сүнмәс!**

**6**

**Алышынып еллар, алышынып чорлар...**
**Ә беркөн без икәү төшенербез кинәт:**
**Нинди төшләр күреп изри кырда үлән,**
**Нинди нурлар үпкәч, пешә таңда җиләк.**

**Ул мизгелдә инде бүтән булыр көйләр.**
**Үзгәрербез без дә... Сибелербез җилгә...**
**Һәм аңларбыз: үлем—бары күчеш кенә,**
**Яңа гөлләр шытып үссен өчен Җирдә...**

### 7

Төннең чиксез киңлекләре аша
Без бер йолдызларга үреләбез.
Һәм, онытып җисми кануннарны,
Бер-беребезгә иңеп тереләбез!

... Шау агымын тыеп, туктый Вакыт,
Күк томырыла Җирнең куенына.
Бу тетрәүле мизгел онытылмас,—
Калыр туфрак, җилләр тоемында...

Ә без, онытып хискә җәза барын,
Бер үк утка һаман үреләбез.
Төннең йолдыз-киңлекләре аша
Мәңгелеккә иңеп тереләбез!

## Кыйсса

Җанга каккан бу давыл да үтәр кебек...
Күзләремнән, балкып, Кояш үбәр кебек ...
Ак көннәрем, ут-төннәрем хакын Язмыш
Аккош төсле җырлар белән түләр кебек...

Кемдер китәр-кайтыр, кемдер көтәр кебек...
Берәү беркөн үз ярына җитәр кебек...
Күзләреңә багып, бәлки, кыйсса сөйлим?!
Әмма йөрәк... Үлемне дә җиңәр кебек!

## Җавап

Чакырасың мине үз дөньяңа,—
Анда таңнар алсу җилкән ди.
Ымсына да, тыя хисен йөрәк,—
Мине Төннәр, Төннәр җибәрми.

«Күмәрмен лә,—дисең, гөлгә генә...»
Юк, өзелгән гөлләр кирәкми!
Аек кала күңел бар сихердән,—
Мине Җырлар, Җырлар җибәрми.

Чакырасың... Тик ят офыкларда
Җаным кояш булып тибәлми.
Өметләрне... өзәм тамырыннан,—
Мине Язмыш, Язмыш җибәрми!

## Гомер

Үләннәрдә иртәнге чык тибри...
Инеш аръягында атлар йөри...
Дөньяларның иркен, киң чагы.

Ят офыклар дәшә кочагына...
Тынгы тапмый кошлар оча гына...
Җанның күк болытка тиң чагы.

Хыял—юрга, тоягы җир тоймый...
Һаваларда ефәк тоҗым уйный...
Җәйнең төскә, хискә мул чагы.

Утлы ялын сирпеп шәфәкъ бии...
Уйлар били җанны, гамьнәр били.
Сүнеп ята Гомер учагы.

## Сусау

Сусавымны басмый ут та, су да,
Саф чишмәләр, җилләр, туфрак—берни!
Йөрәк, ахры, дымга җирсеп түгел,
Офыкларга канат төбәп иңри.

Тып-тын чишмәләрне калдырам да,
Давылларга тамырланам, түзми.
Йөрәк, ахры, сүзләр, күзләр аша
Тәү бишеген, соң ватанын эзли...

***

Юлларыңа юлдаш итеп җилне ал,
Ә мин, туфрак кочып, җиргә иңәрмен.
Чишмәләрнең татып кайнар сулышын,
Язмыш түгел, Үлемне дә җиңәрмен.

Юлларыңа юлдаш итеп Төнне ал,
Ай-йолдызлар, балкып, дога укырлар.
... Ялларына урап безнең моңнарны,
Күкрәп торыр гомер кичкән тупыллар...

Калдыр, калдыр мине генә!.. Ятларга
Терек суы булсын җырым-сулышым.
Мең ләззәтне, мең газапны кичәр җан,
Калдырганчы давыл теткән куышын...

## Көрәзә

Күз алдында—тарих шәүләләре...
Кисәтәме Язмыш, әллә сыный?
Казан күген ярган кошлар өнен
Йөрәк хәбәр көткән чаңдай тыңлый.

Өем-өем хәрабәләр аша
Иңрәрме бер безнең хыяллар да?!
Моңнар исән булсын... Сакла, Вакыт,
Һәм җиткер тик җаны уяуларга!

Анда да бер телгә килер ташлар,—
Ком-мүк кенә каплый алмас Сүзне,
Һәм кемнәрдер... танып өнебездән,
«Тере Хәтер» диеп атар безне!

***

Учларыма ява август йолдызлары...
Болын түрләрендә сагышлана гөлләр.
Гөлләр керфегенә яткан кырау төсле
Күңел бакчасына иңә көзге өннәр.

Учларымда бии август йолдызлары...
Без соң Җир катында, Күк каршында кемнәр?!
Аяз күзе белән бага төпсез Киңлек...
Юк, юатмый җанны, тик сагайта төннәр.

Нинди чиксезлекләр җилкендерә, дәшеп,
Нинди богауларны өзәр була куллар?
Тыпырчына учта бәхет йолдызлары,
Ә табанны өтә җир тузаны. . . юллар. . .

## Уңыш

Күкрәп торган буразналар көтә мине
Җирдә түгел, югарыда—Күк җанында.
Орлык итеп тере йолдыз чәчәрменме
Чиксезлекнең атар-атмас бер таңында?!

Ә Җиргә соң... Җиргә яшь-яшь карлар иңәр,
Саф сулышы белән гөнаһ утын тыеп...
Мин иңәрмен кабат тере бишегемә,
Жанга насыйп соң уңышны урып-җыеп!..

***

Кемнәр ымсынып бу юлга?!
Өзелгән гөл таҗы—кулда,
Энҗе яшь керфегемдә.
Ә йөрәк—төпсез коедай,—
Түрендә тибри йолдыз, ай...
Җуймам нур-бөртеген дә!

Төннәрдән куыш үрермен,
Телемем меңгә бүлермен,
Сыйлап һәр ачны, тукны.

Кем юрар килер көнемне?
Җил генә тыңлар өнемне,
Тоймый атылган укны...

Ә җанның тере учагын
Актарыр, айкар да Вакыт,
Сибәр бер көлен илгә.
... Коелган гомер чыклары,
Онытылмас Моңның чыңнары,
Шул—Яшәү хакым җирдә!

## Сөю кадәр сөю...

«Комны ярып гөлләр үсмәс,—дисең,—
Канаты юк тоймас кош җанын...»
Ә мин әкият төсле төшләремне
Син очрагач... чынга юрадым.

Ә мин «Бәхет» дигән могҗизага
Ничәнче кат (!)... кабат ышандым.
... Син—учына атлар, чүл, җил исе
Сеңгән җайдаккамы охшадың?!..

Толымнарым бизи талир тәңкә,
Яшь тал сыман зифа буйларым...
Инеш суларына кушылып агып,
Кәрван Юлын иңли уйларым...

Ком йөрәген бакча итәр җаным,
Җырым булыр—ризык-тәгамең!
...Сөю кадәр Сөю—мирасыбыз:
Тиңсез Кыйссаның без дәвамы..

*2005—2006*

## Габдулла Шәрәфи

# ТӘФТИЛӘҮ

Сугышның әле һаман кыза, дөрли барган чагы. Ә шулай да хәзер безнең өчен буран аркан. Жил каршы чаклар инде узган, фашистларны куабыз. Бүген менә немецлар ташлап чыккан белорус авылына кердек. Авыл өстен сөрем каплаган. Ут кабынган йортлар, каралтылар тирәсендә солдатлар кайнаша. Түбәләрен куптарып ташлаганнар да, такталарына туфрак сибеп, соңгы ялкыннарын бастырып киләләр...

Мин үзем шофер. Әле янарак кына дивизия командиры генерал Ильясовны йөртә башладым. Аның белән без якташлар. Ләкин ул хәзер монда юк. «Хатының хәл эчендә» дигән телеграмма алгач, ике-өч көнгә дип Казанга очкан иде. Шуңа күрә аның адъютанты лейтенант Айвазян белән икәү генә йөрибез. Бүген исә никтер ул да утырмады, иртәдән бирле машинада берүзем.

Авыл артындагы күпергә машиналар бөялгән. Безнең колонна да туктап калды. Мин янгын сүндереп маташучы солдатларны күзәтеп утырам. Шул чагында әллә кайдан гына Айвазян килеп чыкты да:

—Кабыз машинаңны, тиз бул!—дип, яныма кереп утырды.

Килгән юлыбыздан кире кайтып, авылны чыккач кына:

—Генерал кайткан, ул хәзер армия штабында, безне чакыра,—диде.

Олы юлны танклар эштән чыгарып бетерсә дә, аның белән янәшә генә жинел машиналар салып өлгергән яңа юл ярыйсы ук җайлы, зарланырлык түгел. Шулай байтак киткәч, лейтенант:

—Карабрак бар, озакламый юл аерылачак,—дип кисәтте. Һәм чыннан да, күп тә үтми, юл тармакланып өчкә аерылды. Без, сул яктагысыннан китеп, вак урманга кердек. Әмма ул озакка бармады, агачлар һаман биегәя, урман куера, карангылана башлады. Анда-санда сулы казылмалар, чокырлар очрый, юл өстенә чыгып торган юан-юан тамырларга юлыгабыз. Алар, көпчәкләр килеп эләккән саен, машинаны әле бер, әле икенче якка янтайтып сикертәләр.

Бара торгач итәкләрен киң җәеп утырган чыршылар, биек-биек каеннар, алар тирәсенә сырышып үскән вак куаклар белән уратылган хәтсез иркен аланлыкка килеп чыктык. Алан читләренә, чатлап-чутлап тормыйча, жинел кулдан гына әмәлләгән землянкалар тезелеп киткән. Элек партизаннар лагере булган, ахрысы, землянка түбәләрен, керү хутларын үлән, куак баскан. Шуңа күрә, якын ук килмичә, аларны күрерлек тә түгел.

Туктау белән, янибызга яшь кенә бер сержант килеп житте. Лейтенант машинадан чыгуга, сержант аңа честь бирел:

—Иптәш лейтенант, зур землянкага узыгыз, анда сезне көтәләр,—диде.

Алар китүгә, машинаны читкәрәк илтеп туктаттым да әле монда килешли генә көйсезләнә башлаган моторны карарга тотындым...

Мавыгып китеп, вакыт үткәнен сизми дә калганмын. Күрәм, генерал белән лейтенант, штабтан чыгып, минем янга ук якынлашып киләләр. Болай да чандыр гәүдәле, какча йөзле генерал тагын да юкарып, ябыгып киткән төсле тоелды. Аяк атлаулары да ничектер миңа ят, үзгәрәк сизелә...

Кайтырга чыктык. Генерал минем белән янәшә генә алда утыра, ә

адъютанты—аның артында. Шулай бер чама киткәннән соң лейтенант:

—Бая рәтләп сорашыр ара да булмады, хәлләрегез ничек соң, иптәш генерал?—диде.

—Хәлләр, хәлләр...

—Шулай өметсез үкмени?

Үз уйларына бирелеп баруы булгандырмы, генерал кайтарып бер сүз дә әйтмәде.

Бераз баргач, адъютант тагын сорап куйды:

—Кызыгыз ничек соң, иптәш генерал, кайта алмагандыр инде?

—Ничек кайтсын... Күрәсең ич... Ул да солдат бит, врачларга эш күп...

Тагын тынып калдылар. Менә урманны чыгарга да күп калмады, юл да бераз рәтләнә төште. Ә машинада әле һаман тынлык... һәм менә генерал,—әйтерсең сүзе өзелмәгән, әйтерсең лә безгә ишеттерми күңеленнән кем беләндер серләшеп барган да, хәзер инде кычкырыбрак сөйләшсән дә ярый дигәндәй,—керешсез-нисез ялгап китте:

—Аерылышып торган чаклар да күп булды... Ничектер шунда, бер-беребезнең хәлен сизеп, ерактан да белеп тора идек шикелле. Борчылып, хафаланып йөргән чакларың булса көт тә тор, я телефонга чакырта, яисә: «Син исән-саумы, җаным бик уйный», дигән телеграммасы килеп төшә иде. Үземә дә шулай... Телеграмма аласы көнне күңел шомланып, йөрәк сыкрый башлаган иде, хатынга нидер булган төсле...

—Шулай була ди бит ул, иптәш генерал, күрәсең, бик килешкәнсез, бәхетле сез икегез дә. Сезнең белән мин күптән бит инде... Күренә ич ул. Сизгер шул, акыллы, дөнья бәясе кеше булса кирәк Галия Идрисовна...

Лейтенантның бу сүзләреннән соң мин коелып индем. «Галия Идрисовна» диде түгелме соң?! Кулымнан рульне ычкындыра яздым. Күрәсең, төсем качкан булгандыр, икесе дә башларын мина таба борып сагаеп калдылар. Әмма машина элеккечә баруында булгач, тынычланып:

—Син нәрсә, әллә йоклаган идеңме?—дип көлемсерәгәндәй иттеләр.

—Юк, йокламадым. Сез Галия Идрисовна дидегез бугай, иптәш лейтенант, дөресме?

—Әйе. Ник?

—Фамилиясе Рахманова түгелдер ич, иптәш генерал?

—Шулай, Рахманова.

—Минем укытучым бит ул!

Генерал мина текәлеп карап торгач, башын чайкап куйды. Ләкин бер сүз дә дәшмәде. Бераз барганнан соң гына, баягы сүзен дәвам иткәндәй, лейтенантка таба борыла төшеп:

—Ике аягы да яраланган иде бит аның,—диде.

—Ничек алай, иптәш генерал, кайчан?

—Гражданнар сугышында. Татар бригадасында идек без. Төркстанны азат итешеп йөргән чаклар. Мин—рота командиры, ә ул шәфкать туташы иде...

—Анысын белми идем шул, сөйләгәнегез булмады...

Генерал белән адъютантның әнә шулай сабыр да, шактый ук моңсу да бу әңгәмәләренә колак салып дәшми-тынмый барам. Ә күз алдымнан хәзер Галия Идрисовна китми.

Галия Идрисовна... Ул безгә дүрт ел буе рус телен укыткан иде. Үзе татар булса да, шул дүрт ел эчендә без аның авызыннан татарча дүрт кенә сүз дә ишетмәдек. Башта гадәт буенча үзенә «апа» дип дәшә идек. Рөхсәт итмәде. Рус телендә «апа» дип эндәшмиләр, мина Галия Идрисовна дип дәшегез, диде. Соныннан инде күнектек,ияләштек, тора-бара хәтта аның татар кешесе булуына да шикләнә башладык. Кайсыдыр шунда: «Аның фамилиясе генә безнеке, үзе ул марҗа, татарча бернәрсә дә белми икән»,—дип, безне тәмам ышандыра язды. Шунын шаукымына бирелеп, ахрысы, усал димме, тәрбиясез дипме әйтим, аның атлаган саен шыгырдап куя торган протезлы аягына ишарә ясап: «Шауламагыз, шыгырдавыклы аяк кереп килә»,—дип ша-

макайланучылар да булгалады. Бәлки, шуңадыр да, ара-тирә укытучыбыз үзенең татарча белгәнлеген сиздерердәй нәрсәләр дә эшләп куя иде. Беркөнне шулай, дәрескә кергәч, җыйнак кына, ыспай гына сары портфелен өстәлгә куеп, гадәттәгечә класска бер күз йөртеп чыкты да, һәрвакыттагыча тыныч кына, ашыкмыйча гына дәрес аңлаткандай русча сөйләп китте:

—Бүген мәктәпкә килгәндә, бер күңелсез хәлгә тап булдым. Белмим, безнең мәктәп укучысы иде микән, ерактан танып бетерә алмадым, урам буйлап бөкрәеп барган агай артыннан, аны үчекләп, үзе дә бөкрәйгән булып кыланып килүче бер малайны күрдем...

Укытучының шул сүзләреннән соң, партага сугып:

—Беләм мин аны, Галия Идрисовна! Ишәм әле мин аны кайтканда!—дигән тавыш ишетелде.

Арткы партада утыручы олы гына гәүдәле, җәенке битле, зур гына авызлы—шуның өчен үзен «бәлеш» дип йөртәләр—Гаптери иде бу.

—Ярамый, дуслар, ярамый, сугышу да начар гадәт... Кешенең гариплегеннән көлгән, аны кимсеткән адәмнәр һичкемгә карата сизгер дә, миһербанлы да була алмыйлар. Моны онытмаска тырышыгыз...

Уйлар, уйлар... Әле без җилдерткән юлның үзе кебек бормалана-бормалана, бер вакыйгадан икенче вакыйгага сикерә-сикерә агалар да агалар, балачакның көенечле дә, сөенечле дә бер хатирәсе булып күңелгә сенеп калган әллә нийләр искә төшә...

Авторучка дигән нәрсәне без беренче тапкыр классташыбыз Хәкимҗан кулында күрдек. Бүгенгедәй хәтердә, дәрес бетәргә звонок булу белән: «Малайлар, бернәрсә күрсәтәм, килегез»,—дип, Хәкимҗан, кара такта янына атылып чыкты. Без, дәррәү кубып, аның янына йөгерештек. Хәкимҗан, сул кулы белән чиста дәфтәр битен тактага куеп, уң кулындагы ниндидер әкәмәт бер ручка белән сызгалый башлады. Үзе нәрсәдер сырлый, үзе сөйләнә:

—Абый Мәскәүдән алып кайтты. Бер тапкыр кара тутырасың да ай буе язасың,—ди.

Белмим, бер тутырган карасы ай буе язарга җиткәндерме, ә менә минем шул каһәр суккан ручка аркасында башыма төшкән аянычлы бер хәлне бүгенгәчә оныта алганым юк.

Эш болай булды. Арткы партада утырган Гаптери, әлеге хикмәтне карарга дип, иң соңыннан килеп җитте һәм, такта янына ук узарга теләп, аны-моны карамыйча, дуамалланып, малайларны араларга тотынды. Башта беребезне, аннан соң, иптәшләр җилкәсенә үрелеп, аяк очларыма гына басып торган җиремнән мине этеп җибәрде. Иптәшем бер якка атылды, ә мин безнең бу кылануларга һич тә игътибар итмичә өстәл янында журналга нидер язып маташкан Галия Идрисовнага килеп бәрелдем. Бәрелүем булды, укытучыбыз, кулына каләмен тоткан килеш, гөрс итеп идәнгә ауды. Бу хәлдән барыбыз да югалып калдык. Тик беркавымнан соң гына исебезгә килеп, тавыш-тынсыз әле һаман да идәндә яткан Галия Идрисовнаны торгызырга омтылдык. Ләкин ул беребезгә дә кагылырга рөхсәт итмәде, бары тик яткан җиреннән:

—Их, малайлар, әйттем ич мин сезгә... Барыгыз, укытучылардан кемне булса да чакырыгыз,—дип, авыр сулап куйды...

Шул көннән соң Галия Идрисовна байтак вакыт мәктәпкә килмәде. Класста ниндидер шомлы бер тынлык урнашты. Тәнәфескә чыккач та шаярулар, үрле-кырлы чабышулар бетте, басынкыланып калдык. Әйтә иде бит югыйсә: «Чүгез, чү, малайлар, миңа бәрелә күрмәгез»,—дип, һаман кисәтә иде. Ә без менә тыңлап бетерә алмаганбыз.

Башкалар ничек кичергәннәрдер, укытучыбызны рәнҗетүдән туган әлеге хисләр миңа бер генә минут та тынгылык бирмәде. Әйтерсең лә йөрәкне кемдер йомарлап тоткан да аны туктаусыз кисә, җәзалый, вөҗданыма тукынып, җанымны айкый иде төсле...

Әмма узасы көннәр узды. Галия Идрисовна да, терелеп, янадан мәктәпкә килде. Өстән авыр йөк төшкән кебек җиңеләеп, күңелләр язылып киткәндәй

булды. Укытучыбыз да, гүя берни булмаган, портфелен өстәлгә куеп, таягын элеккечә үк урындык артына элеп, тыныч кына сөйләп китте:

—Шактый күрешмичә тордык, дуслар, ул арада күп нәрсә үткәнсез, хәзер диктант язып карыйк...

Диктантны ничек язганмындыр, хәтерләмим. Аның каравы шуннан соң булган бер вакыйга әле менә бүген дә күз алдымда. Соңгы дәрес иде бу. Диктант язылып бетте. Дәфтәрләрне укытучы өстәленә илтеп өйдек тә, классташлар таралыша башладылар. Ә мин үз урыныма барып, букчамны алырга дип иелгән җиремнән күтәрелә алмыйча, үзем дә сизмәстән, парта өстенә капланып елап җибәрдем. Укытучыбыз килмәгән шул атна-ун көн эчендә сызланып, мөлдерәмә тулып йөргән күңел, ахрысы инде түзмәде, кайнар яшькә әверелеп, тыйлыга алмыйча ташырга тотынды...

Галия Идрисовнаның:

—Ни булды, Хәлим, ник елыйсың!—дип чәчемнән сыйпавына башымны күтәрсәм, класста инде берәү дә юк иде.

—Белмим... Сез килдегез менә... Мин еккан идем ич...

—Юк, Хәлим, юк, син гаепле түгел, мин үпкәләмим, борчылма. Сөрт күзләреңне, әйдә, миңа дәфтәрләрне күтәрешеп кайтырсың...

Күл урамы буйлап хәтсез генә баргач, кызыл кирпечтән салынган йортның икенче катына күтәрелдек. Өендә кеше юк иде, ахрысы, портфеленнән ачкыч чыгарып, Галия Идрисовна ишекне үзе ачты. Иркен генә алгы бүлмәгә кердек. Укытучы портфелен стенадагы чөйгә элде дә, чишенеп тә тормастан, түрдәге ишеккә юнәлде. Ә мин кочагымдагы дәфтәрләрне ишек төбендә торган әрҗә сыман бер нәрсә өстенә (аяк киемнәре өчен булса кирәк) куеп китәргә җыендым. Шул чагында Галия Идрисовна ишек ачасы җиреннән:

—Китмә әле, Хәлим, сиңа йомышым бар, чишенә тор, чәй генә куям,—дип мине туктатып калды.

Китсәм дә вай, калсам да вай кебегрәк бер хәлдә уңайсызланып таптана торгач, ниһаять, чишендем. Ул арада кухня ягыннан Галия Идрисовна да чыгып, ян бүлмәгә уздык. Бүлмә бик чиста, иркен иде. Керү уңаенда ук стенага терәп пианино куелган. Аның өстендә утыртмалы бәләкәй генә рамнан калын чәч толымын күкрәгенә салып төшкән яшүсмер кыз рәсеме көлеп тора. Каршы як стенада—челтәрле пәрдәләр элгән зур-зур ике тәрәзә. Уң як стенада—тоташтан китап киштәләре. Киштәләрне аерып, тотып торган бүлемтә кырыена скрипка эленгән. Авылдан әле янарак кына килеп, көн яктысы да юньләп төшми торган юеш подвалда яшәп ятучы мин, сала малае, бу чисталык, бу пөхтәлек уртасында тәмам югалып, каушап калдым. Минем хәлне сизепме, әллә инде чыннан да шулай кирәк булдымы, Галия Идрисовна:

—Йомышым шул иде, Хәлим, үземә бик авыр, әнә теге югарыгы киштәдән күрән тышлы китапны алып бирче,—дип, миңа киштәләр янында торган җыйнак кына бер баскычны күрсәтте дә үзе кухняга чыгып китте.

Мин киштәгә үрмәләп китап белән булашкан арада, эмальле ак чәйнек күтәреп, Галия Идрисовна да кереп җитте. Чәйнеген өстәлгә куеп:

—Син карый тор, кара башкаларын да,—дип, үзе кабат бүлмәдән чыкты. Ул шулай кухня белән бүлмә арасында байтак чуалды. Мин исә, бүтән китапларга орынырга кыймыйча, Галия Идрисовна сораган китапны актаргалап, баскыч өстендә генә утырдым. Йомышымны үтәү белән үк капылт кына чыгып китүе дә хәзер, ничектер, уңайсыз иде. Менә Галия Идрисовна мине искә төшереп, рәхмәтме-нәрсә әйтер дә, шуннан соң җае чыгар, кузгалырмын дип һаман көттем. Ә ул мин бөтенләй уйламаган нәрсә әйтеп ташлады:

—Әйдә, төш кунакчаңнан, чәй эчәбез,—диде.

Эчсәм дә эчтем мин бу чәйне, эчмәсәм дә эчтем. Ризыкка үрелү турында инде уйлаган да юк, башны күтәрергә дә оялам.

—Ярамый болай, әйдә, аша, эч,—дип, Галия Идрисовна чынаягымны һәм кабарып пешкән эре-эре күзәнәкле ап-ак күмәч телемнәре өелгән тәлинкәне

алдыма ук этәреп куйды. Чәемне тәлинкәгә агызып, кечкенә генә бер телем алдым һәм шуның белән вакытны авыштырырга чамаладым. Ләкин укытучым минем бу беркатлы хәйләмне бик тиз сизде. Дәшми-тынмый гына торып, кухнядан түгәрәк күмәчнең калган чиреген алып керде дә:

—Кечкенә чагымда мин үзем шулай ашарга ярата идем, син дә шулайдыр әле,—дип, каерып бер сынык кисте һәм, аңа калын итеп май ягып, өстенә шикәр комы сибеп алдыма куйды...

Китәр алдыннан гына Галия Идрисовна сорап куйды:

—Әниең ни хәлдә соң?

—Әни авырый...

—Ишеткән идем шул, шуна соравым.

—Үләр инде ул...

Укытучы ничектер сискәнеп киткәндәй булды һәм, миңа карап, озак кына дәшми торды. Шуннан соң яныма килеп җилкәмнән кысты да:

—Син аны каян беләсең?—диде.

—Күрше апалар сөйләшкәндә ишеттем. Доктор шулай дигән.

—Ялгыш ишеткәнсеңдер син, Хәлим, доктор алай димәс.

—Каты авырый ич... һаман йөткерә...

—Борчылма, менә күрерсең, терелер әле... Үзеңнән башка тагын кемнәрең бар соң?

—Абыйлар, апалар бар. Җидәү без.

—Алай... Ишле икәнсез шул. Әмма син борчылма, терелер әниегез, терелер...

Галия Идрисовна мине озата чыкты. Киез итегемнең берсен кигән арада икенчесен күтәреп карады да башын чайкап куйды. Кайсы абыйдан, ничәнче ападан калган итек булгандыр, кыска балтырыннан кар кереп йөдәткәч, әти аны икенче бер иске киез итек кунычын кисеп үстереп биргән иде. Хәзер ул төрле-төрле булып күзгә бәрелеп тора. Житмәсә, олтаны да бераз сүтелеп, авызын ача башлаган. Укытучы аны кире идәнгә куйды да ишек төбендә торган баягы әрҗә астыннан бер пар ак киез итек чыгарды.

—Минем кызым үсте инде, бу аныкы. Олтаны бераз юкарган юкаруын, әтиең астына салып бирер,—дип миңа сузды.—Ал, ал, оялма, аның берние дә юк, барыбер тик ята...

Укытучы биргән җинелчә ак киез итекне култык астыма кыстырдым да, үземнең иске, тупас, баладан балага күчеп килгән, шуна карамастан, «тузу»ны һич белмәгән бу фабричный авыр итектән котылачагыма куана-куана, өйгә кайтып киттем...

...Менә урманны да чыктык. Инде тизлекне арттырсаң да ярый. Ләкин генерал, кулы белән генә ишарәләп, миңа юлдан читкәрәк керергә кушты. Ул кушканча борылып кердем дә машинаны туктаттым. Генерал, машинадан төшеп, кульяулыгы белән мангай тирен сөртә-сөртә, киселгән агач төбенә барып утырды. Кайдандыр еракттан ара-тирә туплар гөрселдәве ишетелә. Ә монда тып-тын. Сәер тынлык, авыр тынлык иде бу. Аннан ничек тә котыласы, качасы килә. Һәм менә лейтенант арткы утыргыч астындагы ящиктан футляры белән скрипка чыгарды да машинадан төшеп генерал янына атлады.

—Иптәш генерал, уйнасагыз икән теге безнең көйне!

Генерал, башын күтәреп, аптыраган бер кыяфәт белән адъютантына карап куйды. Әмма каршы килмәде. Скрипканы иңсәсенә куеп, кыллар тоткычын бора-бора, смычогы белән сызгалый-сызгалый беравык маташкач, салмак кына уйный башлады.

Шул чагында генералның өендә булган вакытларым, пианино өстеннән елмаеп торган яшь кенә кыз рәсеме, китап киштәләре, кызыл тасма белән бәйләп эленгән скрипка кабат күз алдыма килеп басты. Күз карасыдай саклап машинамда йөрткән, кайгы килсә дә, шатлык килсә дә хуҗасының иңсәсенә куна торган бу сайрар кош теге чакта Галия Идрисовна янына баргач мин күргән шул скрипка булыр дип кем уйлаган!

Дивизия командирының скрипка уйнавын минем әле беренче күрүем. Айвазян «безнең көйне» дигәч, генерал йә украин, яисә рус көен уйнар дип көткән идем. Ә ул чын безнеңчә татар көен сыздырырга тотынды. Скрипка элек кайдандыр ерактан ишетелгән төсле тоныкк кына, сабыр гына моңланып торды да, авазы һаман көчәя, кыюлана барып, инде безнең тирәгә генә сыеша алмыйча, урман кырыйларына ук таралды. Генерал салмак кына чайкала-чайкала уйный да уйный. Әйтерсең лә ул, урман буйларын урап, тагын да көчәеп кайткан музыка дулкыннарыннан шулай чайкала иде. Лейтенант белән без, үлән өстенә кырын яткан килеш, әсәрләнеп тыңлыйбыз. Мин мин инде, менә бу әрмән егетенең дә шулай йотылып, дөньясын онытып тыңлавы миңа сәеррәк тоелды, генералга ихтирам йөзеннән генә түгелме икән дип шикләнгән идем. Әмма аның бер ноктага төбәлгән дымлы күзләре дә, авызына капкан үлән сабагын тешли-тешли ара-тирә көрсенеп куюы да кичерешләренең ихлас күңелдән, хак икәнлеген күрсәтә иде.

Генерал көйнең соңгы буынын бераз дулкынландыра төшеп сузып торды да кинәт кенә өзде. Аннары:

—Житте, егетләр, хәзер вакыты да, урыны да бу түгел,—дип, скрипканы лейтенантка сузды.

Айвазян, скрипканы алып, машинага таба китте. Ләкин берничә адым атлау белән борылып:

—Ә шулай да, иптәш генерал, нинди моң, ә!! Бу кадәрле дә сагыш!.. Әмма якты моң. Тирән сагыш, ләкин төпсез түгел. Яратам да соң шушы көйне. Безнең «Карлыгач» көе бит бу, әрмәнчә «Цицернак»,—дип куйды.

—Нишләп сезнең көй булсын, иптәш лейтенант, безнең көй ич бу, татар көе... «Тәфтиләү» бит,—дим. Үзем, генерал да шуны раслар, дип аңа карыйм. Ә ул:

—Барыбер түгелмени, менә өчебезгә дә житте бит әле,—дип көлә...

Без тагын кузгалдык. Генерал белән Айвазян ара-тирә генә сүз катышып кайталар. Мин исә алар сүзенә инде рәтләп колак та салмыйм, «Тәфтиләү» канатларына утырып, күңелем белән туган-үскән якларга очтым. Бер кузгалган күңел, бер яңарган хәтер һаман да шул мәктәп елларына кайта, Галия Идрисовнага барып тоташа.

Мең тугыз йөз дә кырыгынчы ел иде. Без унынчы классны тәмамладык. Шул уңайдан мәктәптә чыгарылыш кичәсе булды. Үзебезне укыткан барлык укытучылар, ата-аналар жыелды, баларак чагыбызда шаярып теңкәләренә тигән, инде үсә төшкәч, элек кылган эшләребез өчен үзләре алдында оялып, әмма күңелдән хөрмәт итеп йөргән хезмәткәрләрне чакырдык. Имтиханнар арасында тыгызга килсә дә, ничектер вакытын табып, ныклап әзерләнгән идек без бу кичәгә. Кемдер нәрсәдер уйнарга, кемдер нидер сөйләргә яисә жырларга тиеш иде. Кыскасы, утызга якын кешедән берәү дә өлешсез калмады. Атлаган саен берәр хикмәт чыгарырга торган, ләкин әлегедәй концерт-фәлән эше нәрсәләргә бик авыр кубучан Гаптери булып Гаптери дә читтә кала алмады. «Миннән чуртым да чыкмый, жәмәгать, хет суегыз», дип тузгыгач, без аңа концерт алып баруны йөкләгән идек. Үзенең урынлы-урынсыз әйтеп ташлаган ярым-йорты сүзләре белән репетиция вакытында ук эчебезне катырып бетергән Гаптери, тамашачылар алдына чыга башлагач, тәмам каушап, бичарадан ни чара дигәндәй, коеп куйган шамакайга әйләнде дә куйды. Концерт инде тәмамланып килә иде. Шул чагында беренче рәттә утырган өлкән яшьтәге биология укытучысы Хәсән абый, чираттагы номерын игълан итәргә чыккан Гаптерине сәхнә кырыена чакырып, колагына нидер әйтте. Гаптери кинәт кенә тураеп артка чигенде дә Хәсән абыйга карап катып калды. Тегесе: «Шулай диярсең, шулай», дип кул изәгәч, егетебез сәхнә артында менә-менә чыгам дип чиратын көтеп торучыны игълан итәргә онытып:

—Ни, жәмәгать!.. Түгел лә, иптәшләр! Хәсән абый сызгырам, ди, нишлибез инде, ә!—диде.

Зал егылып көләргә тотынды. Ә Хәсән абый белән Гаптери сәхнә кырыена килә-китә сөйләшүләр алып баралар. Ул да түгел, аларга Галия Идрисовна да килеп кушылды...

Халык бераз тыйлыга төшеп, зал тынычлана башлагач, тирләп-пешкән Гаптери, бу юлы инде русчалатып:

—Ә Галия Идрисовна шигырьләр укыячак,—дип белдерде.

Зал тагын гөжли башлады һәм арадан кемдер:

—Ничек, икесе берьюлымы?—дип кычкырды.

—Түгелдер инде... Белмим тагын, сорыйм әле,—дип Гаптери кабат укытучылар янына барып килде. Аннары:

—Берьюлы икән шул,—диде.

Шуннан соң Хәсән абый белән Галия Идрисовна сәхнәгә күтәрелделәр. Икесе дә ап-ак чәчле, икесе дә кәкре башлы таякларын тотканнар. Янәшә бастылар да, үзләренең бу ниятләре мәзәк сыман бер нәрсәгә әйләнүдән уңайсызлана төшеп, ахрысы, әле һаман да тынычланып бетә алмаган залга карап елмаешалар.

Ниһаять, зал тынды һәм сәхнәдән моңлы гына итеп «Карурман» көен сызгырган тавыш ишетелә башлады. Озак та үтми, аңа:

—Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл—Кырлай, диләр,—дип Галия Идрисовна кушылып китте...

Элек Хәсән абыйның шулай сәнгатьчә, нәфис итеп сызгыра белүенә шаккатсак, хәзер инде менә ничә еллар буена авызыннан татарча бер сүз ишетмәгән Галия Идрисовнаның һич уйламаганда «Шүрәле»не сөйләп китүенә хәйран калдык.

«Карурман» шулай көйләнә, «Шүрәле» сөйләнә торды, һәм менә Галия Идрисовна «Бервакыт чут-чут итеп сайрый ходайның кошлары», дигән урыннарга җитәрәк, Хәсән абый көйне сизелер-сизелмәс кенә бүлде дә нәкъ сандугачка охшатып сайрарга кереште, аннары кәккүк тавышы чыгарды, кабат сандугачка әверелеп тынып-тынып сайрады да тагын сызгыруга күчте, сабан туйларын хәтерләтеп, авыл көен көйли башлады...

Шул рәвешчә «Шүрәле» сөйләнеп бетте. Ә без, ишеткәннәр тәэсиреннән айный алмыйча, кул чабуны да онытып утырабыз. Ходай үзенә болай да сыйлап биргән авызын бөтен колачына ерып сәхнә артыннан Гаптери атылып чыккач кына исебезгә килеп, кул чабарга тотындык...

Уйларымнан бүленеп генералга карап алдым. Менә шулай янәшә генә утырып йөрсәк тә, үзенең буй җитмәслек дәрәҗәсе белән моңарчы миннән барыбер ерак, арабызда күзгә күренми торган бер киртә бар шикелле тоела иде. Хәзер исә әйтерсең лә шул киртәне икебез өчен дә бик кадерле булган башка берәү әкренләп сүтә бара кебек. Шул чагында мин тирән уйга баткан бу кешегә карата күңелемдә ниндидер олы, тирән хисләр баш калкытып килүен тойдым. Һәм, үзем дә сизмәстән, беренче тапкыр татарча:

—Иптәш генерал, сугыш бетеп, Галия апа янына икәүләп кайтып керсәк, ә?!—дип куйдым.

Генерал да миңа карап, шулай ук татарча:

—Кайтуын кайтырбыз да, Галия апаң юк шул инде, туган!—диде...

Аннан бирле бик күп еллар узды. Бу ике кешенең мөлаем образлары, туган ягыбызның тыйнак та, күркәм дә табигатен хәтерләтеп, ботак-толымнары белән төнбоеклы күл өстенә иелгән пар тирәкләр кебек җаныма рәхәтлек биреп, яшьлегемнең моңсу да, якты да бер хатирәсе булып, күңелем түрендә һаман саклана. Әле һаман да.

*1971.*

## Искәрмә

Ватан сугышы, шартлы рәвештә дип әйтик, шул чор кешеләрен икегә аерып куйды шикелле. Моның шаукымы әдәбиятта да үзенчә бер чагылыш тапты. Әйтик, «1941 елгылар» дигән гыйбарә әйләнешкә кереп китте — ягъни сугыш башланасы елны туган балалар. Шулар арасыннан татар әдәбиятында инде күптән үз урынын тапкан шагыйрьләрдән Рәшит Әхмәтҗан, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим исемнәрен атап китү дә җитә.

Ә сугышка кадәр үк туган үсмерләр, абый-әтиләре фронтка китеп баргач та тылдагы бөтен авырлыкны үз җилкәсенә алган, ут эченә ашкынып торган буынны кая куясың? Олы йөрәкле, тыйнак солдат дустыбыз, язучы Габдулла Шәрәфи — әнә шундыйлар җөмләсеннән иде. Ул барыннан да элек прозаик, повесть һәм хикәяләр остасы буларак танылды.

Без аның 1971 елда язылган «Тәфтиләү» исемле хикәясе белән танышып киттек. Игътибар иткәнсездер: сюжеты кызыклы, мавыктыргыч итеп, чын әдәби осталык белән үрелгән. Вакыйгалар арасында күренеп-күренеп китә торган геройлар югалмый, нәкъ кирәкле урында кабат калкып чыга, бер-берсенең сыйфатларын ачу-баетуга хезмәт итәләр. Артык озын булмаган бу хикәядә әллә ничаклы вакыйгалар (сугыш, мәктәп тормышы, скрипка кыйссасы) һәм байтак кына геройлар (фронтовик генерал, аның адъютанты, хатыны, шофер солдат) ничектер гаять табигый булып ныклы бер үзәккә төйнәлә, реаль шәхесләр рәвешендә күз алдына килеп баса. Әсәрнең тәрбияви-эстетик әһәмияте шунда ки, ул дуслык һәм гуманизм идеясе белән сугарылган.

Әрмән егетенең йотылып, дөньясын онытып татар көе «Тәфтиләү»не тыңлавын кара син!.. Яисә мәктәпнең чыгарылыш кичәсендә биология укытучысы Хәсәннең «Карурман» көен сызгырып көйләвен, рус теле укытучысы Галия Идрисовнаның Тукай «Шүрәле»сен саф татарча сөйләп бирүе дисеңме... Ирексездән: «Вәт ичмасам күңелләрне эретерлек милли хикәя бу!» — дип авыз тутырып әйтәсе килә башлый.

Габдулла Шәрәфи 1926 елның 29 июлендә Татарстанның Биектау (элекке Дөбъяз) районы Кече Битаман авылында туган. Казанга күченеп килгәч, җиденче сыйныфка кадәр укый, әдәби түгәрәккә йөри. Тукайга ияреп язган «Батыр егет» исемле өйрәнчек әкият-поэмасы 1941 елда «Яшь ленинчы» газетасында басылып чыга.

Әдәбиятка ныклап торып аяк басканчы аңа дөньяның әчесен-төчесен шактый татырга, күпне кичергә туры килә. Ватан сугышы башлану сәбәпле, укуын өзеп, төрле авыр эшләрдә хезмәт биографиясен башлап җибәрә. Аннары инде — җиде елга сузылган солдат хезмәте. Ул совет гаскәрләре составында Монголия далаларын, атаклы Гоби чүлен, Хинган тауларын кичә. («Сусыз дәрья» исемле повестенда нәкъ менә совет гаскәрләренең япон самурайларына каршы сугышчан походы гыйбрәтле, реаль вакыйгалар аша бәян ителә). Солдат шинелен салгач, озак еллар электромонтажчы булып эшли, читтән торып Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый, аннары «Совет Татарстаны» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә бүлек мөдире булып эшли. 1967 елдан башлап «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналында җаваплы сәркатип, соңрак редактор урынбасары вазифаларын башкара.

Габдулла Шәрәфи — дистәгә якын китап авторы. Ул 1997 елны Казанда вафат булды. Быел аның тууына 80 ел. Әлеге «Тәфтиләү» хикәясе һәм шуның уңаеннан бирелгән искәрмә язучының исталеген, иҗатын яд итү булсын дигән теләктә калабыз.

**Рашат НИЗАМИ**



Лилия
Сәгыйдуллина

# ҖИРДӘ—ЧӘЧӘК ЙОЛДЫЗЛЫГЫ

## Палас сугам...

**Көннәр сүттем, төннәр сүттем**
**Мәңгелек йомгагыннан:**
**Берөзлексез палас суктым**
**Гомерем елларыннан...**

**Буталды да, өзелде дә**
**Кайчак мизгел җепләрем.**
**Тешне кыстым, яшьне йоттым—**
**Стан ташлап китмәдем.**

**Бүген паласым бизәге—**
**Күзнең явын алырлык.**
**Паласы тузып бетсә дә,**
**Сурәте—сакланырлык.**

**Ул сурәт каян килгәндер?**
**Кем калдырган һөнәрен?**
**Палас-бирнә әзерлик, дип,**
**Туганбызмы өйрәнеп?**

**Без әллә тик тукучымы**
**Җирдә җиһан келәмен?**
**Күккә карыйм... Аннан эзлим**
**Үз паласым үрнәген.**

## Тарих

**Хәрабәләр... Хәрабәләр...**
**Хәбәр алар... Хәтер алар...**
**Хәтәрсезгә—хәер алар:**
**Хәттат* алар—хат язалар...**
**Хәерсезгә—хәтәр алар:**
**Хак алалар, хак салалар...**
**Хаксызларга—харап алар:**
**Хәрабәләр, хәрабәләр...**

***

**Илле илсез,**
**Телле телсез**
**Без бу җирдә.**

**Атлы атсыз,**
**Хаклы хаксыз**
**Без бу илдә.**

**Барлы-юклы**
**Без бу җирдә...**

**Бармы, юкмы**
**Без бу илдә?**

---

Хәттат — кульязмачы

Лилия СӘГЫЙДУЛЛИНА—*галимә; «Абага чәчәге», «Мизгелләр йолдызлыгы» исемле китаплар авторы. Уфада яши.*

***

Кеше туа бу дөньяга—
Куллары йодрыкка җыелган...
Кеше кичә бу дөньядан—
Куллары канаттай җәелгән.

## Безнең юл

Орлык күмдем кара җиргә.
Орлык күмдем, яшәсен, дип:
Тизрәк үлеп таркалсын да
Тормыш булып яшәрсен, дип.

Бакчаларым—шау гөл, чәчәк!
Үлемнәрдән—чәчәк туган:
Күккә баккан һәрбер тажы,
Тамырлары—сутка тулган.

Җирдә—чәчәк йолдызлыгы.
Җирдән хәтта кояш көнли!
...Орлык булып үләчәген
Бу йолдызлык әле белми.

***

Мин кайчандыр ат булмадым микән?
Атлар күрсәм, йөрәк ашкына.
Авызлыклап куйган тоткын җаным
Тулпарланып ала чак кына.

Мин кайчандыр ат булмадым микән?
Бәйгеләрдә килдем ничәнче?
Кеше күтәрмәсне тартмадыммы,
Камытымның бавын өзгәнче?

Мин кайчандыр ат булмадым микән?
Бүген дә бит йөгән-камытлы...
Язмыш тәртәсендә юксынамын
Канатлы ат булган вакытны.

Мин кайчандыр ат булмадым микән?..

***

Төшләрем—
Төнге тормышка,
Үзгә булмышка
Салган күперләр.
Күпме җаннар үтте аннан?
Күпме үтерләр?!

***

Тыныч күлгә
Кыя таудан
Күтәрмәслек
Зур таш очты
Һәм күл—йотты.

Тын күңелгә
Синең җаннан
Тик бер тамчы
Сөю тамды—
Туфан купты...



# Рифат Сәлахов

## Идел ага...

Идел ага. Хәрабәләр...
Дала калган Болгардан.
Шәһре Болгар ут кичкәндә
Гасырларда югалган.

Болгар, Биләр—ныклы богау—
Вакыт белән чорналган.
Ташларга сеңгән тавышлар
Килә ерак чорлардан.

Бөек җырлар, шан авазлар
Ничек калсын кабердә.
Болар җансыз ташлар түгел,
Кабер түгел, хәтер лә!

Еллар-чорлардан сызылган
Югалту яралары,
Чаң нигезенә салынган
Хәтер манаралары.

Югалтканын эзли татар,
Ерак чорларга кайтып.
Уян, кыпчак, уян, болгар,
Уяныргa мең вакыт!

## Кайда син, Таң кызы?

*Кайда син, беренче мәхәббәт, Таң кызы?*
Әхмәт Рәшит

Кара төн...
Кинәттән алсу таң яктысы
Энҗедәй таралып җиһанга сибелә.
Кайда син,
Төш Зөһрә йолдыздан, Таң кызы,
Юк, күктә түгел лә, күңелдә син генә.

Төшемә керәсең—йокымны бүләсең,
Таң аткан чагында саташып уянам.
Сөйкемлем, чибәрем, хыялда йөрмә син,
Хур кызы—Таң кызы, син кайсы дөньядан?

«Кил монда, йолдызга мен!»—диеп дәшәсең,
Мин җирдән аерылып китәлми интегәм.
Шәрабка тутырып күңелем касәсен,
Төшемнән айнымыйм мин, кайда син бер генәм?!

Ерактан чакырып хәбәрләр юллама,
Моңайган болытта ай йөзә ялгызы.

---

Рифат СӘЛАХОВ(1987)—*Казан дәүләт университеты студенты; шигырьләре көндәлек матбугатта күренә килде. Журналыбызда беренче тапкыр басыла.*

Маягым—мәхәббәт—хәтердә гел яна,
Кулымда чәчәкләр...
Кайда син, Таң кызы?

Бар галәм караңгы—кыйбламны югалттым,
Юлларны аермыйм, дөрес соң кайсысы?
Юлыма яз чәчеп хуш исләр тараттың,
Дөньяны яктыртып кил инде, Таң кызы!!!

## Ак болыт

Ак болыт—яктылык,
Җиргә нур тарата.
Бу болыт юыртып,
Чабамы пар атта?
Әллә соң...
Диңгезгә батканмы
Ак кораб?
Ак болыт,
Югалма,
Нур тарат!

## Каләм-чакматаш

Кулларымда нәни каләм—чакма ташы,
Салкын җилләр исеп сүнә шәм.
Берьялгызым аяз күккә карап,
Мин йолдызлар белән сөйләшәм.

Әй йолдызлар, әйдә җырлыйк әле,
Әйдә биик әле бергәләп.
Бөтен хисләремне шигырь итеп
Мин таратам сезгә, бүлгәләп.

Утсыз чакма ташы күккә гашыйк,
Әнә күктә йолдыз атыла.
...Шигырь ага җиргә йолдыз булып,
Ә алдымда кәгазь ак кына.

***

Әйт әле син, миңа сине
Кабат яратыргамы,
Инде сүрелгән сагышны
Кабат яңартыргамы?..
Соңгы сорау: яраттыңмы,
Әллә яратасыңмы?

Каян белдең бүген сиңа
Яңадан барасымны!



Рафаэль
Хәким

# ТАТАР РУХЫ

(ТӨРКИ-ТАТАР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ
МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА)

*"Төрки бәкләр халкы, моны ишетегез! Төрки халкының берләшеп, ил тотачагын биредә чукып яздым, ялгышлар аркасында бүлгәләнеп үләчәгегезне тагын монда чокып яздым, әйтергә теләгән сүзләремне мәңгелек ташка чокып яздым...*

*Күлтәгин истәлеге. Кече язма.*

## "Каһәр суккан" сораулар

(кереш сүз урынына)

Тарих—кеше рухының әверелешләре, вакыйгалар барышын билгеләүче бөек идеяләрнең үсеше ул. Рух юкка чыга икән, тормыш та әкренләп туктала, дәүләтләр җимерелә, халыклар юкка чыга, алар турында бары тик хатирәләр генә торып кала. Материя—аның тересе дә, үлесе дә—идея аркасында гына мәгънәгә ия.

Бөтен сугышларның, сәүдәнең, шәһәрләр салынуның, дәүләтләр төзелүнең һәм аларның таркалу-җимерелүенең, матди һәм матди булмаган һәйкәлләрнең артында тарихны хәрәкәткә китерүче нәрсә—халык рухы тора. Бөек шәхесләр, җиңүләр һәм җиңелүләр, бөек һәйкәлләр турында сөйләгәндә чынлыкта без рух әверелешләрен—ягъни вакыйгалар барышына мәгънә бирүче бердәнбер нәрсәне тасвирлыйбыз. Кеше фикеренең үзгәрешләре чылбыры күрсәтелмәгән булса, дөнья картинасы юкка чыга, ул инде бары археология табылдыклары җыелмасы, өзек-төтек хатирәләр һәм әдәби истәлекләр генә булып кала.

Сүнгән рух халыкның дөнья аренасыннан юкка чыгуына бәрабәр. Аның исеме елъязмаларда һәм топонимикада кала, әмма рухы башка халык, бүтән культура эчендә эреп, бүтән рәвешкә керә, көчлерәк ихтыяр тарафыннан йотыла.

Идеянең иясе гаять зур тарихи вакыйгаларны хәрәкәткә китерүче була ала. Атасының казанышларын дәвам итеп гаять зур империя төзегән Александр Македонский әнә шундый булган. Мөхәммәт Пәйгамбәрнең туган нәселе—корәйшитләр дә башта яңа динне кабул итмәгәннәр. Чыңгыз ханның дөньяны яулап алуының берничнди дә икътисадый яки хәрби алшартлары булмаган, бары тик рух көче, үз максатына ирешергә көчле омтылыш кына булган. 1916 елга кадәр большевиклар дигәнең—беркем дә белмәгән фикердәшләр түгәрәге генә иде.

Рафаэль ХӘКИМ (1947)—*сәясәтче; федерализм, этник мөнәсәбәтләр турындагы хезмәтләр авторы. Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. Казанда яши.*

Хакимияткә көчле омтылыш нәтиҗәсендә Коммунистик Интернационал оештыра алганнар. Дөнья бу кешеләрне көткән, һәм алар зур-зур массаларны хәрәкәткә китергәннәр.

Без барыбыз да объектив законнар буенча хәрәкәтләнгән сыман тоелган гомум тарих агымының бер өлеше. Әмма көчле ихтыяр агымның юнәлешен үзгәртә дә ала. Көтү үзенең башлыгы артыннан чапканда, якыннан карасак, без аерым атларның тояклары уйнаклавын, мускуллары киерелүен, аларның көтүдән калышмаска теләп алга ыргылганын күрәбез. Кош очышы биеклегеннән карасаң исә, күз алдында, алдан башлыгы чаба торган тоташ бер ташкын ачыла, көтү башлыгы бу ташкынны уңга да, сулга да бора яки барысын да упкынга юнәлтә ала. Безгә бөтен нәрсәне дә бу дөньяның көчле яки бай кешеләре хәл итә кебек тоела, чынлыкта исә бар да актив кешеләргә бәйле, вакыйгалар барышын шулар билгели, чөнки алар күңелендә үзгәрешләргә ашкыну бар, нәкъ менә шундый кешеләргә язмыш үз тамгасын сала да. Энтузиастлар тырышлыгына башкалар ярдәме дә кушылса, күмәк узаң революция кичерә. XX гасыр Ленины кебек, Чыңгыз хан да урта гасырларда дөнья картинасын үзгәрткән.

Кеше өч үлчәм кысаларында фикер йөртә: пространство, вакыт, материя. Хәрәкәт материянең эчке табигатенә хас үзенчәлек итеп фикерләнә. Әмма тормыш—материя түгел, материя тышчасына төрелгән рух ул. Кешелекнең яшәеш мәгънәсе рух үсешеннән гыйбарәт. Икътисад, техника, технология, машиналар һәм кораллар—рух торышын күрсәтүче тышкы билгеләр генә ул. Рух хәрәкәтен берниндн акчалар да алдан билгели алмый—бу дөньяда бөтен нәрсәне дә сатып яки сатып алып булмый. Әмма рух әверелешләре материянең галәмдә һәм вакытта үсешен билгели.

Рух әверелешләре шаккаттыргыч. Алар табигать үзгәрешләре кебек үк серле. Мәсәлән, ваемсыз күбәләк бирән кортны тудыра, корт исә, тут агачы кимереп, ефәк җепле кузы ясый. Бу әверелеш бигрәк тә шунысы белән гаҗәп: меңнәрчә еллар буена ымсындыргыч байлык символына әйләнеп, ефәк Европа һәм Азия тарихының үзәгендә булып чыга. Ефәк күп халыкларның язмышын кискен төстә үзгәртә. "Бөек Ефәк юлын" кулга төшерү өчен сугыш арты сугышлар кабына, күпме дәрт-дәрман, көч сарыф ителә, ефәк сәүдәсенә ия булырга омтылып күпме дәүләтләр баеый яки юкка чыга.

* * *

*"Гамәлләрне күзәт һәм уңайлы форсат көт, тиешле вакыт җиткәч, аннан файдалана бел, сабырлыкны акыл белән куш; тут агачының яфрагы шул рәвешчә ефәккә әйләнә".*

Ибн Гарәпшаһ. XV гасыр.

Тарих—әверелешләр чылбыры ул.

Халыклар үз йөзләрен һәм исемнәрен үзгәртәләр, тулы бер мәмләкәтләр юкка чыга, алар урынында яңалары барлыкка килә. Күчмә халык шәһәрләр сала башлый, ә шәһәр кешеләре "казак"лар булып китеп яшәү рәвешләрен үзгәртәләр. Кайчандыр коточкыч юлбасарлар булган викинглар белемле һәм тыныч скандинавия кешеләренә әвереләләр. Таркалып баручы Руська исә Чыңгыз хан рухы кереп оялый һәм Мәскәүдән, орлыктан шытып чыккан сыман, иләмсез олы ил үсеп чыга.

Заманча узаң—территориаль, утрак фикер йөртү ул. Татар тарихын без Татарстанда эзлибез һәм Киев Русенда—нәкъ менә руслар, ә Борынгы Римда—латинлылар яшәгәнлегендә шигебез юк. Чынлыкта исә күпчелек халыклар һәрвакыт күченеп, бер-берсе белән аралашып яшәгәннәр. Бер генә халыкның да мәңгегә үзенә беркетелгән биләмәсе булмаган.

Киев башта Куяба исемле хәзәр шәһәре булган, анда славяннардан тыш төркиләр дә: хәзәрләр, төрекләр, каракалпаклар (черные клобуки) да, берендейлар да яшәгән. Соңрак викинглар килеп кенәзлек иткәннәр. Аннан соң башка төрки кабиләләр—печенеглар, кыпчаклар, татар-монголлар, шулай ук литвалылар һәм поляклар пәйда була. Культура катламнарының шушы катнашмасын-

нан рус рухы ясалган. Анда славян белән төрки кушылып болгатылган.[1]

Татарларның борынгы бабалары (төрки телле һуннар) Азия төпкелләреннән Көнбатышка таба хәрәкәт иткәннәр һәм безнең эрага кадәр 155-158 елларда Идел-Урал төбәгенә килеп утырганнар. Руслар Идел елгасы буена күп соңрак— мең елдан соң гына килеп чыкканнар. Болар бар да күченеп йөргән һәм бер-берсе белән аралашкан: йә ниндидер симбиозга берләшкәннәр, йә параллель культуралар тудырганнар, йә бер-берсенә каршы сугышканнар.

X гасырда һуннарның көнбатыш тармакларының берсе—болгарлар бер үк вакытта Дунайда һәм Иделдә мөстәкыйль дәүләтләр төзи. Кубрат ханның бер улы—Аспарух—славяннарны, икенче улы Идел буенда төркиләрне һәм фин-угырларны берләштерә. Дунайда христиан Болгарстаны һәм Урта Иделдә мөселман Болгарстаны барлыкка килә. С. М. Соловьев болай дип яза: "Борынгы заманнарда, рус славян кешесе Ока елгасы буенда христиан чиркәүләре төзи башлаганчы, бу җирләргә Европа гражданлыгы хакына килеп урнашканчы ук, болгар кешесе Идел һәм Чулман буйларында Коръән тыңлаган. Биредә Төньяк-Көнчыгыш Европада беренче мәртәбә христианлык басурманлык белән бәрелешә. Бу бәрелеш зарури була, чөнки тиздән яңа Русь Югары Идел өлкәсендә төпләнә һәм славян колониясе бу елганың түбәнге агымына үтә, яңа, Төньяк-Көнчыгыш Русьның беренче кенәзләре—Юрий Долгорукий, Андрей Боголюбский, Всеволод III, Юрий II болгарларга каршы сугыш алып баралар һәм, үз биләмәләренең чикләрен Идел буенда Ока тамагына кадәр җиткереп, аларны Түбән Новгород белән беркетеп куялар".[2] "Бөек рус елгасы" Волгадан алдарак бөек татар Иделе аккан. Төрки-татарлардан аермалы буларак, руслар Көнбатыштан Көнчыгышка таба Татар бугазынача барганнар, аннары хәтта Аляскага җиткәннәр.

Төрки-татарлар элек-электән бик зур территория биләгәннәр, шуңа күрә этник тамырларыбызны бер үк вакытта Кытайның төньягыннан да һәм Дунай буйларыннан да эзләвебез табигый ул. Территориаль фикер йөртү культура әверелешләренең бөтен колачын һәм тирәнлеген күзалларга комачаулый. Тарихны аңлар өчен күчмә халыкныкы кебек экстерриториаль карашлы булу кирәк.

Без тарихны гади итеп аңлатып бирүләрен телибез. Еш кына мондый сорау ишетәсең: "Татарлар болгарлармы, әллә монголлармы?" Юк, алар—татарлар. Һәм мондый җавап әлеге сорауга бернинди дә ачыклык кертми кебек. Әмма башкача җавап бирсәң дә берни аныкланмый. "Татарлар" этнонимы үз тормышы белән яшәгән, ә халык төрки һәм төрки булмаган культуралардан үзенә күп нәрсә сеңдергән. Һуннар—төркиләр—болгарлар—татар-монголлар—хәзерге заман татарлары,—этногенез формуласы менә шундый. Татар этногенезында ике куәтле агым—һун-төрки һәм төрки-татар бергә кушылган. II гасырда Европага ыргылып кергән һун-төрки дулкыны үзеннән соң Идел һәм Дунай буйларында болгар дәүләтчелеге калдырган, ә төрки-татар агымы күп санлы төрки кабиләләрне төрки-татар халкына әверелдереп, болгар һәм кыпчак тирәлегендә тамыр җәйгән. Халыкның физик яшәешенә яки этноним язмышындагы үзгәрешләргә һәрвакытта да туры килми торган рух үсешеннән мөһимрәк нәрсә булырга мөмкин соң? Татар рухының сүрелү сәбәбен аңлау мөһим. Ни өчен Казанны алырга Явыз Иван белән бергәләп Шаһ Гали җитәкчелегендәге татарлар да барган? Шуннан соң татарлар Россия эчендә югалып калганнар. Үз дөньялары белән яши биргәннәр алар, әмма кешелек өчен, тарих өчен—инде юкка чыкканнар. Татар рухын кабат тергезү мөмкинме? Үз заманында һуннар, Алтай таулары аша, сугыша-сугыша Идел буена бәреп кергән һуннар әнә зәгыйфь кабилә булганнар һәм тарихтан 200 елга юкка чыкканнар, әмма соңрак, угырлар белән кушылып, бөтен Европаны дер селкеткән дәһшәтле һуннарга әверелгәннәр. Аларның рухы яңарган. Бәлки татар рухы тулысы белән русларга

---

[1] Владимир Кулаков болай дип яза: "Без борынгы рус халкы бары тик славяннардан гына торган дип әйтә алмыйбыз. Рус кенәзләренең Византия белән төзегән беренче шартнамәләрендәге (941-944 еллар) исемлекләрне карасак, анда славян исемнәре биштән бер өлешкә дә җыелмый. Игорь кенәз боярлары арасында прусслар да, скандинавлар да, төркиләр дә, балтлар да, угыр-финнар да булган" // "Известия", 31 января, 2004 г.

[2] С. М. Соловьев. Сочинения. Книга III. – М., Мысль, 1989, с. 461-462.

күчкәндер? Россиянең дәүләтчелеге генә түгел, русларның культурасы да башлыча Мәскәүгә хезмәт итәргә киткән татарлар энергиясе ярдәмендә формалашкан бит.

Татарлар бөтен дөньяны буйсындырырга тырышканнар һәм үзләре буйсындырылганнар. Алар Чыңгыз хан идеяләрен Мәскәүгә мирас итеп тапшырганнар, Мәскәү исә дәүләт экспансиясен православие-Византия мессиячелеге белән бәйләгән һәм шушы җирлектә рус идеясе барлыкка килгән. Әүвәл ошбу идея "Мәскәү—өченче Рим" дип тәгъбир ителсә, соңрак «Мәскәү—Коммунистик Интернационал башкаласы» рәвешенә керде. Алда тагынниләр көтә микән?

Россия тарихында XIX гасыр—дөнья проблемаларына киеренке рәвештә җаваплар эзләү вакыты иде. Алманнар һәм французлар кимәле белән чагыштырырлык фикер югарылыгы, атаклы исемнәр, әдәбиятта, шигърияттә, музыкада һәм сәнгатьтә күренекле әсәрләр... XIX-XX гасырларда дөнья культурасы рус культурасы йогынтысын тоеп үсә.

Славянофиллар һәм мәгърипчеләр арасындагы идея бәхәсе дөньяга Пушкинны, Аксаковны, Чаадаевны, Достоевскийны, Толстойны бирде. Бүген исә мәгърипчеләр һәм көнбатышка каршылар мәйдан тота. Юрий Афанасьев, Геннадий Бурбулис, Гавриил Попов, Александр Собчак, Егор Гайдар—әлеге лидерлар Мәскәүдәге күп санлы митинглар, гыйльми җыелышлар аркасында үсеп чыктылар һәм сәясәт күгендә кометалар көтүе сыман ялтырап алдылар, алар артыннан якты, ләкин кыска вакытлы эз калды. Кемнәрдер теләк теләргә өлгерде, ә кемнәрдер—юк. Бу төркем әле исән, аларның чырайлары телеэкраннарда күренгәләп ала. Әмма алар үзләре инде тарихка күчтеләр. Алар яклаган карашларны искә төшерүе дә кыен хәзер. Алар онытылды. Алар демократиянең Россиягә яраклы һәм аңлаешлы кыйммәтләрен үстерә алмадылар. Лев Аннинский билгеләп үткәнчә, "ул либералларга Россия кызык түгел!" [3] Көнбатыштагыны күчер дә утырт—алардан соң бары шундый тойгы гына калды.

1988 елда "Иного не дано" дигән атаклы мәкаләләр җыентыгы нәшер ителде. Бу китапны бөтен кеше кырылып укыды, ул "Үзгәртеп кору" дәверенең идея байрагы булды. Ун елдан соң әлеге җыентык авторлары тәэсир уртаклаштылар. [4] "Җыентык чыккан елны бу авторлар чын-чынлап фикер хакимнәре иде,—дип искә төшерә Юрий Афанасьев.—Шуңа күрә бу китапның иҗтимагый фикергә йогынтысы үтә көчле булды. Хәзерге вакытта андый фикер хакимнәре юк. Бу нормаль хәл дип уйлыйм. Зыялылар арасындагы таркаулык, фикер үсешендә якты маяклар булмау—нормаль күренеш. Димәк, тормыш җайлана, димәк, кеше үз язмышын үзе хәл итәргә сәләтле, ул үзенә нәрсә бирелгәнен һәм бирелмәгәнен үзе аңлый". Моның белән килешү авыр. Җәмгыятьтә "фикер хакимнәре" булмау нормаль хәл түгел. Лев Толстой яки Федор Достоевский булу начармыни? Григорий Водолазов сүзләрендә дөреслек күбрәк: "Без, гадәттәгечә, кабат уңышсызлыкка дучар булдык. Иҗтимагый һәм демократик энтузиазмны җилгә очырдык". Үзгәртеп кору идеологлары совет җәмгыятен бары тик тәнкыйть кенә иттеләр, үзләре үзенчәлекле юллар тәкъдим итә алмадылар. "Демократияне, көнбатыш модельләренә нигезләнеп, гомум тигезлек һәм чәчәк ату дип тонык күзаллаулар бар иде, әлбәттә,—дип раслый Андрей Нуйкин,—ләкин көрәшче-реформаторларның күпчелеге безнең уникаль ситуациядә бу модельләргә ничек якынаерга икәнлеге турында уйларга да теләмәде". Һәм, өметсезләнеп, өстәп куя: "Шушы еллар буена безнең профессиональ икътисадчылар, идеологлар, политологлар, психологлар, культурологлар өере кайда булган соң?" Әйе, "үзгәртеп кору" бик күп тәнкыйтьчеләр тудырды.

Тормыш "Иное", ягъни башка юллар да барлыгын раслады. Рухи остазлар "каһәр суккан" сорауларга җавап бирмәсә, "фикер хакимнәре" булмаса, башка көчләр барлыкка килә: милләтчеләр, сепаратистлар, шовинистлар, экстремистлар, фашистлар.

"Россия фашист дәүләте булачакмы?" дигән сорауга Александр Севастьянов болай дип кырт кисә: "Әйе, булачак. Һичшиксез. Котылгысыз рәвештә.

---

[3] Храмом – по библиотеке.– "Родина".– №2.1998.

[4] "Известия", 18 июня 1998 г.

Мәҗбүри". "Фашизм—милли капитал диктатурасы,—дип дәвам итә ул.—Ким дә түгел, артык та түгел, нәкъ шулай. Менә нәрсә турында уйларга кирәк. Милли капитал диктатурасы... Нәкъ менә шушы нәрсә Россиягә ашарга ипи, суларга һава кирәк булган кебек зарур. Бүгенге кебек интернациональ түгел, ә нәкъ менә милли! Милли капитал ныгып бергә туплангач, безнең сәнәгатьчеләр, сәүдәгәрләр һәм финансчылар үз илендә ялчы түгел, хуҗа булырга кирәклеген һәм мөмкинлеген ахырынача аңлап алгач, мондый диктатура хәзерге вәзгыятькә җавап рәвешендә һичшиксез барлыкка киләчәк".[5] Ул моны 1995 елда язган. Бүген скинхедлар инде бөтен ил буйлап атлый. Россиядә фашизм тәгълиматтан чынбарлыкка күчте.

Россия тарих чатында тоткарланып калды. Ул империя традицияләреннән дә китеп бетә алмый, шул ук вакытта демократик дәүләт тә була алмый. Күпләргә азрак кына артка чигенеп куярга, нәрсәләрнедер аз-маз Көнбатыштан, аз-маз Көнчыгыштан алырга һәм ниндидер идеаль империя төзергә мөмкин сыман тоела. "Яңа империя, ягъни көчле милли идеяле яңа үтә милли дәүләт фашистик яки коммунистик мутациягә һәм либераль "таркау склероз"га альтернатива булырга мөмкин һәм тиеш тә,—"Милли манифест" авторлары әнә шулай дип яза.—Аның үзәгенә совет заманының уңай традицияләрен дә үз эченә алган Россия үсеше традицияләре һәм рус фәлсәфи фикере казанышлары, аерым алганда, Вернадский эшләгән, кешелекнең ноосфера аша үзара тәэсире концепциясе белән берләштерелгән иң яңа, хәтта үтә яңа көнбатыш идеяләре салынырга тиеш. Ул дәүләттә XXI гасырның динамизмы һәм безнең илнең бөек рухияте, демократия кыйммәтләре һәм милли мәнфәгатьләр, базар икътисады механизмнары һәм милли идея үзара ярашырга тиеш. Болар барысы да ни Көнбатышта, ни Көнчыгышта эзләп-эзләп тә табылмый торган ниндидер абсолют яңа бер нәрсәгә әверелер".[6] Тәгәл анализны изге ниятләр белән алмаштыру—фикер йөртүнең инде таныш стиле бу. Проблема исә нинди "үтә яңа идеяләр" алырга кирәклеген тәгәл әйтүдән гыйбарәт. Демократик кыйммәтләрне һәм базар икътисады механизмнарын алырга өндәү кирәкми. Алар безнең тормышта бар инде, әмма алар начар. Хикмәт империяне яхшыртуда түгел, ә бәлки аны бөтенләйгә җирләп куюда. Россия—үзенчәлекле ил. Ләкин дөнья тенденцияләренә каршы барырлык дәрәҗәдә үк түгел. Россияне акыл белән аңлар, аршын белән үлчәр һәм исәп-хисап нигезендә идарә итәр вакыт җитте.

Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында яки алар өстендә тору түгел, икесенең берсен сайлап алыр чак җитте. Киев Русе Көнбатыш түгел, ул чорда көнбатыш төшенчәсе әле булмаган, ә көнчыгыш инде булган. Николай Бердяев: "Барлык бөек диннәр һәм культуралар бишеге—Көнчыгыш".—дип язган.[7] Соңыннан Көнбатыш формалашты, ә Көнчыгыш күптөрлегә әйләнде, көнчыгышлар күбәйде: Көньяк-Көнчыгыш Азия, Урта Азия, Гарәп дөньясы, Якын Көнчыгыш—һәм алар барысы да төрле-төрле. Россияне Көнчыгыш-Көнбатыш кебек урталык патшалыгы итеп шәрехләргә ярамый. Андый цивилизация юк. Чаадаев сүзләрендә хаклык күбрәк, мөгаен, ул бервакыт болай дип әйткән: "Без Көнбатышныкы да, Көнчыгышныкы да түгел, бездә ни тегесенең, ни монысының традицияләре юк. Без вакыттан читтә торган шикелле, безгә адәм кавеменең бөтендөнья тәрбиясе кагылмаган". Ул Россиянең дөнья культурасына керткән өлешен бик кырыс бәяли: "Без дөньяда ялгыз, без дөньяга бер нәрсә дә бирмәдек, аны бернигә дә өйрәтмәдек, кешелек идеяләре массасына без бер генә идея дә кертмәдек, кеше акылы прогрессына берни белән дә ярдәм итмәдек, ул прогресстан безгә кергән нәрсәләрне исә бозып бетердек". Чаадаев әлеге юлларны язганда әле Толстой да, Достоевский да, Чехов та, Бердяев та булмаган. Әмма, бүгенге тормышны текәлебрәк күзәтсәң, аның сүзләре искә төшә. Көнбатышның барлык алдынгы идеяләре Россия җирлегендә үзенең капма-каршысына әйләнә дә куя. Демократия монда күбрәк анархиягә охшый, хокукый тәртип исә авторитаризмны хәтерләтә. Хосусыйлаштыру дигәннәре халыкны талау булып

[5] А.Севастьянов. Национал-капитализм. – М.,1995. С. 12.

[6] Национальный манифест. – М., 1999, с. 93-94.

[7] Н.Бердяев. Философия свободы. – М.С. 2002, 320.

чыкты, фермерчылык авыл хуҗалыгын һәлакәткә китерде, җирле үзидарә, гомумән, берни дә түгел. Теләсә кайсы яхшы идея Россия шартларында бозылапычратыла. Ни өчен шулай соң бу? Ихтимал, әлеге сорауга җавап шул ук Чаадаев сүзләрендәдер: "Россия турында сөйләгәндә аны башка дәүләтләр кебек үк дәүләт дип күзаллыйлар, чынлыкта исә бу һич тә алай түгел. Россия—үзе аерым бер дөнья, ул бары тик бердәнбер генә кешенең ихтыярына, рөхсәтенә, фантазиясенә күндәм. Әлеге кешенең исеме Петрмы, Иванмы, хикмәт анда түгел, һәр очракта да бу—башбаштаклык һәм законсызлык гәүдәләнеше. Кешелек яшәешенең барлык законнарына капма-каршы рәвештә, Россия бер генә юнәлештә—күрше халыкларны буйсындыру юнәлешендә генә бара. Шул сәбәпле аны башка халыклар мәнфәгатьләрендә генә түгел, үз мәнфәгатьләрендә дә бөтен юлларга кучәргә мәҗбүр итү файдалы булыр иде".[8] Башбаштаклык—Россияне аңлау өчен кирәкле төп сүз шушы.

Рус фикере үсешендә нигилизм өстенлек алган чор булган. Нигилизм бөтендөнья кыйммәтләрен кире кага, бөтен нәрсәгә дә шөбһәчел карый, ул атеизмны тудыра, әмма анда хакыйкать эзләү чаткылары да күп була. Бүген аны рус психологиясенә хас нәрсәгә—кимсетелгән һәм изелгәннәргә карата мәхәббәткә һич тә исе китмичә, ярлыларны ахмаклар дип атый торган цинизм алмаштырды. "Акыллы икәнсең, нигә болай ярлы соң син?" Теләсә нинди юллар белән җыелган акча егетлек билгесенә әйләнде. Кайчандыр карьерадан, матди байлыклардан баш тартып халык арасына аның культуралылыгын арттырырга тормыш хәлен яхшыртырга киткән рус кешеләре булган. Бүген аларны акылдан язган дип санарлар иде. Хәзер үз халкыңны теләсә нинди—законлымы ул, яки законсызмы—юллар белән талау гадәти хәл булып санала. Һәм болар барысы да базар дип, демократия һәм либераллык дип атала. Ирек төшенчәсен кеше фантазиясе булдыра алган иң оятсыз кимәлдә шәрехләделәр.

Россиядә азмы-күпме йогынтылы либераль идеология беркайчан да булмаган. Ирек-хөрлек турында күбрәк анархистлар сөйләп килгән. Баш күтәрү—Россиягә һәрчак хас нәрсә һәм ирекне бирелә күбесенчә анархия дип аңлаганнар. Үзенә кадәрге мәдәниятне җимерә торган рус революцияләренең үзенчәлеге дә нәкъ менә шуннан килеп чыга. Европадагы буржуаз революцияләр яңа мөнәсәбәтләр тудырып, элеккеге культураны саклап, алга таба адым ясатканнар. 1917 елгы рус революция исә алга да, артка да илтмәгән, илне бөтенләй башка үлчәмгә күчергән дә куйган. Идеологик яктан бу анархия күренеше булып чагылган. Бакунин һәм кенәз Кропоткин үзләренең дәүләтсез коммунизм идеяләре белән дөньяны дер селкеткәннәр. Алар дәүләтне—җәмгыятьнең төп дошманы дип, бюрократчылыкны исә шәхес дошманы дип санаганнар. Бакунин язуынча, түрә канәфиләренә фәрештәләрне утырткан хәлдә дә, тиздән аларның канатлары урынына иблис мөгезләре үсеп чыгачак. Бакунин дәүләтне Алла идеясенә бәйләде, ә Алла идеясен кешелек акылыннан, гаделлектән һәм ирекtән баш тарту дип бәяләде. "Әгәр дә Алла бар икән, кеше—кол". Янәсе, Алла үч алучан, барлык диннәр дә рәхимсез. Алла—дәүләтнең залим формаларын аклау. Үзенең бер хезмәтендә ул, Христос чын-чынлап була калса, аны үтерү ярар иде, дигән. Бу—куркыныч фикерләр, ләкин анархистлар күп кенә очракта күрәзәче булып чыктылар бит. Бакунин фараз кылуынча, әгәр дә берәр халык үз илендә марксизмны гамәлгә ашырырга тырышып карый икән, бу дөнья тарихында иң куркыныч тиранлык булачак. Сүз уңаеннан, коммунистлар да Алладан баш тарттылар, тик шуңа да карамастан, явыз дәүләт төзеделәр. Бүген анархия идеяләре ни белән алмашынды соң? Башбаштаклык белән. Югарыда да башбаштаклык, түбәндә дә башбаштаклык. Анархизм Бакунин белән Кропоткин аңындагы башбаштаклык булмаган, ул җәмгыятьне түрәләрдән башка оештыру, ягъни чын коммунизм булган. Кеше шул рәвешчә генә ирекле була ала дип санаганнар алар.

1993 елда, Россия Президентының Парламент белән капма-каршылыгы шартларында, Ельцин Парламентны аттырды, ә халык исә моңа әлләни ризасызлык белдермәде. Юкса чып-чын башбаштаклык иде бит бу. Президент Явыз Иван

[8] Петр Чаадаев. "L UNIVERS". 15 января. 1854.// "Стратегия России". №10, 2004, с. 64.

яки император Петр I кебек эш итте—"без үз холопларыбызны яратырга да ирекле, җәзалап үтерергә дә ирекле". Әмма иң куркынычы шунда ки, халык моңа түзеп калды, чөнки аның психологиясе империя тарафыннан салынган, ягъни бу—башбаштаклыкка түзә һәм аны аклый торган коллык психологиясе. Телевизор караучылар Ак йортка ату күренешен ниндидер бер сәяси тамаша караган кебек кухняда чәй эчә-эчә күзәтте. Моннан соң әле күп вакыт та узмады, әмма бүген бу вакыйганы шунда һәлак булган кешеләрнең туганнары һәм якыннары гына хәтерли инде. Теләктәшлек тә юк, ризасызлык белдерү дә юк.

Рус философы К.Леонтьев раславынча, үзәкләштерелгән көчле хакимиятле рус дәүләтчелеге татар һәм немец элементлары ярдәмендә булдырылган. Аның фикеренчә, рус халкы һәм гомумән славяннар анархиядән башка берни дә кора алмаган булырлар иде. Шулай да, руслар, әле Петр I чакырып китергән немецларга чаклы һәм немец хатыны Екатерина II гә кадәр үк территорияләрне колонияләргә әйләндерү белән мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнгәннәр, гәрчә татарлар таптаган юл белән барсалар да. Шул рәвешчә, анархизм өчен генә түгел, империя өчен дә руслар үзләре җаваплы. Шулай да, Россиядә империя идеясенең мөгаен Чыңгыз хан мирасы булганлыгын танырга кирәк. Әлбәттә, бөек Чыңгыз хан башбаштаклыкка юл куймаган, ул үз законнарын—"Бөек Яса" ны кертсән, ә ханнар хакимияте дүрт бәк һәм корылтай системасы белән чикләнгән булган. Әмма хан ихтыярын закон дип игълан итү, ә корылтайны (соборны) җыймау әллә ни кыен түгел, һәм Петр шулай эшләгән дә.

Достоевскийның даһилыгы дөньяны көч кулланып берләштерүне кире кагуда. Ул авторитар христианлыкны да, авторитар социализмны да бер үк дәрәҗәдә кабул итмәгән. Югары гармониягә көч кулланып ирешү мөмкин түгел. Иван Карамазов болай ди: " Югары гармониядән тулысынча баш тартам. Ул җәберләнгән бердәнбер баланың бер тамчы күз яшенә дә тормый". Бернинди изге максатка да кешене кимсетү исәбенә ирешелергә тиеш түгел. Кеше корбаннарын бернинди сәясәт тә аклый алмый. Әмма XX гасырда барысы да киресенчә булып чыкты. Достоевский күпкә алдан, фашизм барлыкка килгәнче үк, аның психологиясен аңлаган. "Бөек Инквизитор"да мондый юллар бар: "Гомуми табыну аркасында алар бер-берсен кылыч белән үтергәннәр. Алар аллалар барлыкка китереп, бер берсен: "Аллаларыгызны ташлагыз һәм безнең аллаларга табыныгыз, югыйсә үзегезгә дә, аллаларыгызга да үлем киләчәк!"—дип өндәгәннәр. Дөнья беткәнче, хәтта дөньяда аллалар юкка чыккач та шулай булачак: потларга баш ияччәкләр... Сиңа әйтәмен, адәм баласының үзе белән туган ирегән тизрәк илтеп бирер өчен кемне дә булса эзләп табудан да зуррак гаме юк. Әмма кешеләрнең ирегенә аларның намусын тынычландырган кеше генә ия була". Фашизм кеше ирегенең киңәюенә, кешедә чиктән тыш җаваплылык барлыкка килүгә җавап булды, кеше, ул җаваплылыктан качып, вөждан тынычлыгын хакимияткә буйсынуда тапты. Ул мәгънәлелек кыяфәте тудыручы һәм тәртип кертүче теләсә нинди идеологияне, теләсә нинди сәяси төзелмәләрне һәм символларны кабул итәргә әзер. Ирекле булу хисе кешене бөтереп ала һәм ул ирекнән качып диктатура канаты астына да керергә әзер. Бу феноменны Эрих Фромм "ирекнән качу" дип атаган. Бу—кешенең эчке фаҗигасе, ул ирекә омтылышның үз эченә үк салынып куелган. Инде Аристотель үк күреп алган: кешеләрнең күбесе—табигатьләре буенча коллар, әгәр дә аларның чылбырларын салдырсаң, алар үз гамәлләренең киң мөмкинлекләрен үз кулларына ала алмыйлар, аларның үз гамәлләре өчен җаваплылыкны үз өсләренә алыр өчен әхлакый көчләре юк, шуңа күрә алар ул җаваплылыкны кемгәдер йөкләргә омтылалар. Гитлер Германиясе һәм Сталин СССРы Аристотель һәм Достоевский фаразларының дөреслеген раслады.

Кеше һәм дәүләт проблемалары, дин белгечләре бәхәсләре, сугышчан атеизм, халыкчылык (народничество), монархизм һәм социализм, террор, анархизм һәм эстетланучы символизм... XIX гасырда рус фикриятендә темалар искиткеч күп төрле һәм аларның һәрберсендә бөек исемнәр калкып чыга. Ә менә XX гасыр уртасында—кинәт өзеклек һәм XXI гасырда—кызганыч бытылдау. Бүген үткән заманның бөек әсәрләре белән рәттән куярлык нәрсә юк. Солженицын—

күренекле язучы, ләкин Бердяев һәм Трубецкой, Чехов яки Шолохов янәшәсендә ул бары тик күләгә генә. Солженицын үзенең Россияне коткару хакындагы фикерләре белән хәтта ачуны да китерми, ул—кызыксыз. Кызыксыз! Аның бар пафосы абстракт өндәүләргә кайтып кала: "Хәзерге дәүләткә түгел, Ватанга хезмәт итәргә. Ватан—безне барлыкка китерүче. Ул—өстенрәк, үзгәреп торучы төрле конституцияләрдән югарырак. Россиянең хәзерге күп кырлы тормышы ничек кенә төшенке булмасын—безнең әле нығырга һәм үзебезнең 1100 еллык җуелмас үткәнебезгә лаеклы булырга вакытыбыз бар. Ул—безгә кадәрге һәм бездән соңгы дистәләгән буыннар казанышы".[9] Россиялеләрнең хәзерге һәм киләчәк буыннарына тарихи юлламалыкка дәгъва кылучы әлеге үгетнәсихәтләрдә нинди дә булса фикер бәян итәргә тырышу да юк хәтта.

Детектив—Пушкинны һәм Тургеневны, "сабынлы опералар" Чеховны һәм Островскийны алмаштырды, вак "попса" Мусоргскийның бөек музыкасына алмашка килде. Дәүләтчелек үсеше даирәсендә идеяләр бөтенләй юк. Либералчылыктан—"хакимият вертикаленә", ялган федерализмнан—ялган империягә ташлану бара. Фәндә исә үткән еллардагы темалар уйнатып бетерелә. Нобель премиясенең Россиядәге яңа лауреатлары—безнең көннәргәчә яшәгән карт совет галимнәре. Рус рухы сүнгәнгә охшап тора. Моның нинди куркынычы бар икән?

Болар барысы да—"каһәр суккан" сораулар. Татар рухы да сүнгән, рус рухы да сүнгән... Тирә-якта барысы да бөек Россиянең яңаруы турында сөйләп торганда мондый сораулар кую отышлы түгел, әлбәттә. Әмма дәүләт бөек булса да, инде үткән заманда калган мәдәният турындагы истәлекләр белән генә яши алмый лабаса. Халык киләчәкне тарихи үрнәкләр буенча гына төзи алмый.

XX гасыр ахырында Россиянең хәлләре мөшкел иде. Дәүләт шигрин күне сыман кечерәя башлады. Иң элек Польша белән Финляндия аерылып чыкты. СССРны таратканнан соң "Зур Россия" таркалды. Хәзер Украина һәм аның белән бергә Кырым һәм Кара диңгез китте. Көньяк өлеш Оренбург далаларына якынайды. Балтыйк буе берничә дәүләт арасында калды. Россия Петр чорына кадәрге чикләргә кире кайтты. Россия составында руслар кабат татарлар белән йөзгә-йөз калдылар һәм Мәскәү каршына "Казан мәсьәләсе" кабат килеп басты. XVI гасырдан башлап Россия идеологиясе "Казан мәсьәләсен" хәл итү зарурлыгына нигезләнде, өстәвенә күбесенчә—көч кулланып. "Мәскәү патшалыгы үсешенең табигый өлеше булып "Казан мәсьәләсен" хәл итү, ягъни көнчыгышта илнең мөһим үзәкләренә янау сәләтенә ия булган соңгы куркыныч каршылыкны бетерү һәм русларга чиксез булып тоелган көнчыгыш пространствосы: далаларга, тайгага, тундрага, океаннарга бәреп керү тора",—дип яза В. Цымбурский.[10] Россиянең тарихында һәм сәясәтендә Казан белән Мәскәү арасында мөнәсәбәтләр аерым, билгеле бер дәрәҗәдә символик мәгънәгә ия. Россияне Киевтан башка күзаллау мөмкин, әмма Казаннан башка күз алдына китереп булмый. Мондый тезис бары тик беренче карашка гына парадокс кебек күренә.

Киев рәсми идеология буенча Россия дәүләтчелегенең башлангычы булып санала, ә хәзер исә ул—чит ил. Әгәр Киев—"рус шәһәрләренең анасы"—бөйсез дәүләт башкаласы икән, хәзерге заман Россиясе тамырларын Киев Русеннан эзләү ни дәрәҗәдә мөмкин соң? Бу Россия тарихын рәсми шәрехләүнең ялгыш икәнен күрсәтә түгелме? Инде шулай да Киев Русе чынлап та хәзерге заман Россиясенең башлангычы икән, ул вакытта Россия дәүләтенең Украинадан башка дәүләтчелек феноменын ничек аңлатып була? Бу очракта "Дәүләтнең табигый чикләрен" (В. О. Ключевский атамасы) билгеләүче генетик тамырлар кайда? Дәүләтнең тарихи белемнәре үзләрен мөстәкыйль милләт дип игълан итеп, җиңел генә яңа дәүләт ясый ала икән, бу дәүләт тагын да кечерәймәсме? Әгәр дә Киев—Россия түгел икән, Казан үзен шулай дип игълан итәргә тагын да хаклырак лабаса.

Тарих җиңелчә шәрехләүне яратмый. Чөнки бу бик күп дәгъваларны аклау

[9] А.Солженицын. Россия в обвале. – М., Русский путь, 1998, с. 204.

[10] Иное. Россия как субъект. – М., 1995, с. 212.

булып чыга. "Россия Федерациясе Президентының Федераль җыенга милли куркынычсызлык буенча юлламасы" мондый юллар белән башлана: "Тарих күзлегеннән караганда, Россия—Борынгы Русь, Мәскәү патшалыгы, Россия империясе варисы, СССР дәвамчысы".[11] Моннан чыгып дәүләтнең мөһим мәнфәгатьләре турында тирән нәтиҗәләр ясарга һәм эчке генә түгел, тышкы сәясәтне дә төзергә мөмкин. Бүген Россиянең килеп чыгышын Киевтан башка бәян итү җиңел түгел—бик күп нәрсәне кабат язарга туры киләчәк. Күпләргә илнең яңа чикләре эчендә үсеш юллары эзләүгә караганда Украина һәм Белоруссия белән кабат берләшү җиңелрәк тоела.

Тарихи үзаң—иҗтимагый кыйммәтләрне бер җепкә беркетүче элемент. Күп очракта Россия халыклары русларга караганда борынгырак тарихка ия. Бүген һәрбер халык үз тарихын мөстәкыйль яза. Ә бөтен ил тарихын нидән башларга соң? Төрки, Хәзәр, Авар каганатларыннан, "Дәште Кыпчак"тан (Кыпчак далалары), Болгар патшалыгыннан һәм башка борынгы халыклар тормышыннан икән, димәк, Россияне полиэтник дәүләт дип танырга кирәк? Яисә, рус булмаган халыкларның яшәешен төшереп калдырып, Россия тарихын чиста рус тарихы дип шәрехләргәме? Бу—гыйльми мәсьәлә булудан бигрәк сәяси мәсьәлә. Ул җәмгыятьнең асылына кагыла һәм халыкның үз-үзен ничек атавына бәйле. Чынлап та, Россия язмышы өчен кем җаваплы? Русларны? Россиялеләрме? Күпмилләтле халыкмы? Территорияләр кушылмасымы? Әгәр дә дәреслекләр татар тарихын объектив бәян итмәсә, татар халкы илнең кыйммәтләре системасыннан читтә калачак.

Казан белән Мәскәү арасындагы мөнәсәбәт хәзергәчә үзенең фундаменталь әһәмиятен саклый. Бу күчәр нык булганда, илнең киләчәген күзалларга мөмкин. Әгәр дә ул күчәр бушайса, үзәктән куучы көчләр барлыкка киләчәк. Әлбәттә, сәяси күзлектән караганда Россия һәм Татарстан—капма-каршы куела алмаслык күренешләр, аларның "авырлык категориясе"төрлечә. Россия гасырлар буена Европа һәм дөнья сәясәтендә төп рольне уйнап килә. Аның җитәкчеләре телеэкраннардан төшми, газеталар көн саен аның эчке һәм тышкы сәясәте турында яза, дистәләгән халыкара үзәк, Россиянең алга таба ни кыласын фаразларга тырышып, аны һәръяклап тикшерү белән мәшгуль.

Татарстан исә—бөтенләй башка мәсьәлә. Күпчелек кеше өчен ул гасырлар төпкелендә югалып калган. Европа үзаңына ул Чыңгыз хан, "Тартария"нең иксез-чиксез кыргый киңлекләре, татар-монгол явы, Азия эчендә яшәгән күчмә халыклар турындагы ниндидер тонык күзаллауларга бәйле рәвештә кереп калган. Республика турында бары тик тарих белгечләре, этнографлар, Татарстанга килеп киткән журналистлар гына яздылар, болары да, нигездә, Казан белән Мәскәү арасында мөнәсәбәтләр кискенләшкән чорларга туры килә.

Россия иксез-чиксез территория биләп тора, Татарстан исә—зур булмаган республика, аның халкы да бик күп түгел. Рус мәдәните бөтен дөньяга билгеле, татар мәдәниятен хәтта Россиядә дә белмиләр. Чынлап та, Россия белән Татарстан төрле "көч категориясендә", аларны чагыштыру да кыен. Гаять зур Россия белән халкы 4 миллионнан кимрәк, өстәвенә катнаш халыклы, илнең эчендә урнашкан кечкенә территорияле Татарстан арасында җитди бәхәс туу мөмкинлеге күпләргә хәтта көлке сыман. Нинди бәхәс була алсын инде биредә! "Мәскәүдән Татарстан күренми. Күренми!" Аны губерна итәргә кирәк һәм вәссәлам! Әмма зирәк сәясәтчеләр Татарстанга башкача карыйлар, алар Давид һәм Голиаф турындагы Библия риваятен яхшы хәтерлиләр һәм тота-каба нәтиҗә ясарга ашыкмыйлар.

Россия белән Татарстан кабат тарих чатында. Мөмкинлекләр тигез түгел, әмма бу—замана тудырган вәзгыять.

Сүздә генә бөек булган, уйлап чыгарылган Россия түгел, чын Россия алга таба нишләр? Татарларның урыны кайда булыр? Алар бит хәзер юклыктан чыктылар һәм яңадан сәяси факторга әйләнделәр. Вәзгыять шул рәвешле үзгәрер дип кем уйлаган? Хәзер Россия язмышы өчен руслар гына түгел, татарлар да

[11] Послание по национальной безопасности Президента Российской Федерации Федеральному собранию. – 1996, с. 3.

җавап бирергә тиеш була. Моңарчы андый бурыч куелмаган иде. Моңарчы культураны, телне тергезергә, үз хокукларыбыз өчен көрәшергә, империянең астыртын ниятләренә каршы торырга, Татарстанны ныгытырга кирәк иде, хәер, боларны бүген дә дәвам итәргә кирәк, әмма шул ук вакытта Россия дәүләтчелегенең татарлар язмышы белән ярашу мәсьәләсе дә бар. Россия зәгыйфь булган хәлдә, татарларның иминлеген күз алдына китерү дә кыен. Татар халкы киләчәге өчен Татарстан берүзе генә җавап бирә алмый, чөнки татарлар бөтен Россия буйлап яши, ахыр чиктә, кемнәргәдер бу сүзләр ошамаса да, Россия территориясе—элеккеге Төрки каганаты, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары, Зур һәм Нугай Урдасы биләмәләре. Бирегә бары тик Кырым ханлыгы гына җитми.

Русларны һәм татарларны күп нәрсә берләштерә: тарих, антропология, психология. Лев Гумилев раславынча, руслар һәм татарлар—бердәм этнос, бары тик берәүләр православие, икенчеләре ислам юлыннан киткән. Ләкин аермалыклар да күп: дәүләткә, җәмгыяткә, гаиләгә, җиргә, хезмәткә мөнәсәбәттә.

Рус кешеләре һәрвакыт мәхәббәтне һәм хакыйкатьне гаделлектән өстенрәк күргәннәр: Закон буенча түгел, намус кушканча яшәргә, "Царство Небесное" һәм "Град Грядущий"ны эзләргә. Татар традицияләрендә исә тугры юл—законнарны һәм кагыйдәләрне үтәү, һәм, әлбәттә, гаделлек буенча яшәү. Гадел исеменең татарлар арасында популяр булуы да шуннан килә. Казандагы урта гасырлар шагыйре Мөхәммәдьяр болай дип язган:

*Бер сәгать гадел кыйлмак яхшырак*
*Кем гыйбадәт алтмыш елдин азрак.*

Татар тарихында дәүләт проблемалары килеп чыгу гаделлектән тайпылу дип аңлатылган, гаделлек төрки каганатлары чорыннан ук идарә итүнең иң мөһим шарты булып саналган.

Төрки хакимиятенең парадигмасы мондый булган: Бодун-Әл-Тора ("Халык-Дәүләт-Закон"). Русларның күпчелеге дәүләтне яратмый, хакимиятне ихтирам итми. Татарлар—дәүләтчеләр. Хәтта үзләрен изгән, кимсеткән, хокукларын чикләгән рус дәүләтен дә татарлар руслардан ныграк ихтирам иткәннәр. Татарларга элек-электән үк бунтарьлык хас түгел, Пугачев һәм башка восстаниеләрдә катнашулары көчләп христианлаштыруга каршы ризасызлык белдерү булган. Татарлар җир эшкәртүне, торак төзү-төзекләндерүне өстенрәк күргәннәр. Бездәге "нигез" төшенчәсе үз җиреңдәге йорт мәгънәсеннән күпкә тирәнрәк. Бу—ата-бабалар культы, үз тамырларың, чишмә башы турында истәлек. Татар кешесе белән очрашып танышсаң, хәтта бер шәһәрдә, бер урамда яшәсәң дә, шунда ук бер-береңнең туган җире турында сораша башлыйсың. Һәм, Казанда туып гомер буе Казанда яшәсәң дә, килеп чыгышың буенча Казан артыннан, Күлле-Киме авылыннан булуың турында сөйләп бирергә тиешсең. Моңа җавап итеп әңгәмәдәшеңнең ата-бабалары кайдан булганлыгын ишетәсең. Татарлар үз туган җирләренә, үз тамырларына нык бәйләнгән. Бу әдәплелек кенә түгел, бу—тулы бер фәлсәфә.

Русларда мосафирлык психологиясе өстенлек итә, алар хәрәкәтчән, үзләре яшәгән авыллардан яки шәһәрләрдән җиңел күчеп китәләр, яңа урыннарга да җиңел җайлашалар. Бу даими рәвештә күнегергә, җайлашырга кирәк булган яңа җирләрнең бик күп булуыннан килә, күрәсең.

Бүгенге глобальләшү чоры бик күп тотрыклы күзаллауларны җимерде, бөтен дөньяга уртак кыйммәтләрне һәм уртак психологияне көчләп тага башлады. Дөньяны экстерриториаль рәвештә кабул итү һәм хәрәкәтчәнлек өстенлекле фактор булып бара. Америкалы, европалы яки кытайлы өчен эшчәнлек киңлеге—бөтен дөнья. Алар үзләрен номадлар—урта гасырлардагы күчмә халыклар кебек тота башладылар, чөнки базар—уртак, акчалар бөтен дөнья буйлап тулысынча ирекле рәвештә йөри, яшәү урынына бәйләнгәнлек юк, ә үзара аралашу чаралары, ерак араларны якынайтып, бөтен дөньяга юл ачтылар. Планета бердәм киңлеккә әверелде. Глобальләшү бар кешеләрне дә төрле илләрнең

мәнфәгатьләре белән яшәргә, төрле континентлардагы фаҗигаләрне бергәләп кичерергә, космонавтларның уңышлы очышларына бергәләп шатланырга, Айның һәм Марсның ландшафтларын игътибар белән күзәтеп барырга мәҗбүр итеп, фикер йөртү рәвешен үзгәртә. Сәясәт, икътисад һәм культура әверелешләре бара. Инде мәңгегә тарихта калган күчмә халык культурасы кире кайткан кебек тоела—Чыңгыз ханның һич югалмас рухы—экспансия рухы кабат яңара, әмма бу юлы ул англо-саксларга күчә.

Рус акыл ияләренең иң күренеклесе Николай Бердяев болай дип язган: "Халыклар тормышында тотрыклы яшәп килергә мөмкин ике миф бар. Аларның берсе—килеп чыгыш турында, икенчесе—ахыргы көн турындагы миф. Русларда ахыргы көн турындагы миф—эсхаталогик әкият өстенлек итә".[12] Ә татарларда-исә ни килеп чыгыш турында, ни ахыргы көн турында мифлар юк. Татар тарихының башы турында төрле уйдырмалар барлыкка килгән үзе, иң яхшы очракта аны татарлар килеп чыгышының чикле-территориаль "болгар" концепциясенә кайтарып калдыралар, тискәре очракта—Алтын Урда һәм татар ханлыклары чорларына яла ягып, аларны кыргыйлар дип атыйлар. Киләчәк турында миф исә милләтләрнең кушылуы "теориясенә" кайтарып калдырыла, анда татарларга "табигый рәвештә" юкка чыга баручы халык язмышы билгеләнә. Әмма мең еллар сакланган рух эзсез югала алмый. Ул яңаруны көтә, ул яңа биеклекләргә омтыла, ул яңа әверелешләргә әзерләнә, ул кискен үзгәрешләр көтеп үзенә тартып тора. Яңа меңьеллык яңа геройлар таләп итә. Татарлар заман чакыруына ничек җавап бирерләр икән?

Хәер, сораулар җитеп торыр, җаваплар эзлик.

> *"Күпсанлы килеш алар бер берсе белән дошман булмыйча бердәм булсалар, кытайлар һәм башкалар арасыннан бүтән халыклар һәм гомумән, беркем дә аларга каршы тора алмас иде. Әмма шулай да, араларында дошманлык һәм ызгыш-талаш хакимлек итүгә дә карамастан, алар бик борынгы заманнардан ук күп вакыт кабиләләрнең һәм өлкәләрнең иң зур өлешен буйсындыручылар һәм хакимлек итүчеләр булганнар, үзләренең бөеклекләре, куәтләре һәм башкалар ихтирамын казанулары белән аерылып торганнар. Аларның гадәттән тыш бөеклеге һәм югары абруе аркасында башка төрки кавемнәр, төркемнәре һәм исемнәре төрле-төрле булуга карамастан, дөньяга шулар исеме белән билгеле булганнар һәм барысы да татарлар дип аталганнар".*
>
> Рәшидеддин. "Җәмит әт- тәварих".

## "Рәхимсезлек"

Дөнья үзаңында татарлардан яшерен бер курку калган, ул куркуны Батый ханның Европага басып керүе тудырган. Аңа татар-монголларның рәхимсезлегә турындагы әкиятләр чәпәлгән. Алдан ук туган ялгыш фикер "кыргый татарлар" һәм беркем күрмәгән-белмәгән куркыныч "Тартария" турында легендалар китереп чыгарган. Папа Иннокентий IV 1234 елда, татарлар "Иблис илчеләре һәм Тартарус ялчылары" дип язган, аларга каршы тәре походы игълан иткән. Шул заманнардан алып татарларны цивилизациягә каршы кую гадәткә кергән. Әле соңгы елларга кадәр Европаның католик храмнары вәгазьләрендә Алладан тәмуг кисәүләре—татарлардан коткаруны сорыйлар иде. Бөтен бер халык уртаклык исемгә—"татарщина"га әверелде. Бу әкиятне Лев Гумилев "кара легенда" дип атады.

Татарларның урынлы-урынсыз искә алына торган "рәхимсезлеге" үз дәвере кысаларыннан чыкмаган һәм һәрвакыт Чыңгыз ханның "Бөек Яса—Ясак" (законнар кодексы) белән чикләнгән. Урта Азиягә поход вакытында Чыңгыз ханның кияве темник Тогучар үзенә каршылык күрсәткән бер шәһәрнең халкын рәхимсез җәберләгән. Чыңгыз хан, бу турыда ишетеп, чыгырыннан чыккан һәм бары тик бераз тынычлангач кына киявенең үлем җәзасын гади сугышчы

[12] Н.Бердяев. Русская идея. – М., 2002, с. 4.

дәрәҗәсенә төшерүгә алмаштырган. "Яса" бөек хан ихтыярына буйсынучы шәһәрләрнең, халыкларның, илләрнең куркынычсызлыгын тәэмин иткән. Ул башбаштаклыкка юл куймаган. Шунысын да әйтергә кирәк, ул урынсыз мәрхәмәт өчен дә җәза биргән.

Рәхимсезлек татар-монгол яуларының принцибы да, аларга хас сыйфат та булмаган һәм чыңгызчылар тарафыннан хупланмаган да. Чыңгыз ханның уллары Җучи һәм Үгәдәй игелекләре һәм сабырлыклары белән аерылып торганнар, Чагатай исә таләпчән, эшне төгәл башкаручан һәм хәтта кырыс булган, шуңа күрә "Ясаны саклаучы" вазыйфасы (прокурор эшенә охшаш гамәл) аңа йөкләнгән. Елъязма мәгълүматлары буенча, Батый хан, үз сугышчыларына карата таләпчән булса да, Урта Азия кампаниясендәге чамадан тыш рәхимсезлекне гаепләп чыккан.

Каршылык күрсәткән шәһәрләрнең халыклары, балалар һәм хатын-кызлардан, рәссамнардан, һөнәрчеләрдән һәм, гомумән, ниндидер гыйлемгә ия кешеләрдән тыш, гадәти кыйнауга дучар ителгән. Баш күтәргән шәһәрләргә һәм өлкәләргә карата аяусыз террор кулланылган, аеруча гаскәрләр тылында, чөнки татар-монголлар, аз санлы булу сәбәпле, кальгалэрдә гарнизоннар тота алмаганнар. Бу хәрби зарурлык булган.

Террор—барлык заманнарда да сугыш алып баруның бер ысулы. Викинглар походлары турында укыганда, мәсәлән, аларның чиксез-чамасыз талауларыннан котың алына, елъязмачылар алар хакында "бүреләр кебек котырыналар" дип язып калдырганнар. Андерс Стринңгольм викингларның Англиягә походы турында болай дип яза: "Алар терлекләрне алып киттеләр, чиктән тыш кансызлык күрсәтеп таладылар, үтерделәр, руханиларны да, монахларны да, монах хатыннарны да бервакытта да аямадылар".[13] Викингларның Франциягә, Италиягә, Сицилиягә һәм башка илләргә һөҗүмнәрен дә ул шулай тасвирлый. Викинглар үз походларына сагаларда дан җырлаганнар. Аларның берсе, Рагнар Лодброк исемлесе, үләр алдыннан мондый җыр җырлый: "Без илле бер сугышта кылыч белән кеше кырдык. Кешеләр арасында миннән дә данлырак король бар микән? Мин яшьтән үк кан койдым һәм шушындый үлем теләдем. Один илчеләре валькирияләр миңа дәшәләр, мине чакыралар; мин мактаулы урында аллалар белән сыйланырга китәм. Минем гомерем бетеп бара, әмма мин елмаеп үләм". Ул юлбасар буларак тотылган һәм үтерелгән, шул ук вакытта ул елмаеп үзенең рәхимсезлеге турында җыр җырлый.

Татарлар Муса Җәлил җитәкчелегендә Моабит төрмәсендә (моны үзе күреп торган патер Юрытко әйтүенчә) елмаеп үлгәннәр. Әмма алар елмаюының мәгънәсе булган. Совет әсирләре арасында бары тик татарлар гына үз ватандашларына атмаганнар—әсирлектә оештырылган бер генә татар полкы да фашистлар ягында сугышмаган. Муса Җәлил болай дип язган:

*Ил онытмас, бирсәң каныңны*
*Ватан өчен изге көрәшкә.*
*Хаин каны тама чиләккә.*
*Батыр каны тама йөрәккә.*

*Батыр үлә, үлмәс ат алып,*
*Батырлыклар белән макталып,*
*Исемең калысын, үзең үлсәң дә*
*Тарихларда укып ятларлык.*

("Батырлык турында" дигән шигырьдән)

Бу инде бөтенләй бүтән төрле сага...

"Бөек" викинг Сокке Халогаландка, зур булмаган Ульфей утравына килгән. "Биредә,—дип әйткән ул иптәшләренә,—без шәп табыш алачакбыз, чөнки монда бай кеше яши; аның йортына кылыч һәм ут белән һөҗүм итәрбез; бөтен хуҗа-

[13] Андрес Стриннгольм. Походы викингов. – М., 2003, с.27.

лык безгә булыр, ә йортларны һәм кешеләрне яндырып үтерербез". Һөҗүмгә дучар ителгән Ульфей кешесе викинглар юлбашчысыннан, ни өчен болай җәберлисез, дип сораган. "Без, викинглар, берәрсенең җанын яки мөлкәтен алырга теләсәк, ни өчен дип сорамыйбыз",—дип җавап биргән ул.[14] Викингларның талаулары турында йөзләгән, меңләгән җыр чыгарылган. Алар беркемне дә аямыйлар, монастырьлар, храмнардан башлап барысын да тоташ бөлдерәләр, алар мәкерлегенең чиге юк, ләкин без шведлар, норвегияләр һәм даниялеләр хакында башка батырлыкларына карап фикер йөртәбез. Нигә соң татарлар турында ялган мифларга карап фикер йөртәләр?!

Сугышлар гына түгел, революцияләр дә террорсыз гына узмаган. Якобинчылар диктатурасы үтә рәхимсез була, гильотина бер дә туктап тормый. Дәүләт терроры идеясе үзе үк Робеспьер режимы тарафыннан тудырылган. Ул, Дантонны җәзалап үтереп, революциянең тигезлек һәм гаделлек идеалларына ышанычны кабергә сала. Моның белән Россиядәге Гражданнар сугышы һәм 1937 елгы репрессияләр генә тиңләшә ала, шуңа да карамастан, француз революциясен "Бөек" дип атыйлар.

Октябрь революциясе вакытындагы "кызыл террор" миллионлаган кешенең гомерен өзә, колачы ягыннан ул татар-монгол яуларының Евразиянең барлык почмакларында өч йөз ел эчендәге корбаннары санынна да бик күп мәртәбәләр артык. Гильотинаны да татарлар түгел, мәгърифәтле французлар уйлап тапкан, Бухенвальд мичләрен дә немецның "явыз даһие" уйлап чыгарган. Ә Хиросимага атом бомбасын мәгърифәтле америкалылар ташлады. Әмма без бу халыкларга аларның башка казанышларына карап бәя бирәбез, алар уйлап тапкан әйберләрнең асылы—варварларча, кулланулы иезуитларча булып, цивилизация казанышларын халыкларны кыру өчен кулланылсалар да, без аларны кыргый дип атамыйбыз. Мәдәнилек белән кыргыйлык чиге каян үтә соң алай булгач?

Урта гасырлар, гомумән, гуманлы дәвер булмаган. Тынычлык сөю уңай сыйфат булып саналмаган. Тәре походлары, Европаны ялан чүлгә әйләндергән 30 еллык сугыш афәте, коточкыч рәхимсез инквизиция! Ә конквистадорларның Көньяк Америкага, инклар, ацтеклар һәм майялар алтынын кулга төшерү өчен башлаган походлары гына ни тора! Алардан соң бөтен-бөтен илләр һәм цивилизацияләр юкка чыккан. Казанны басып алу яки татарларны христианлаштыру вакытындагы рәхимсезлекнең иге-чиге булмаган. Мәгънәсезлеге, нигезсезлеге, чиксезлеге ягыннан Явыз Иванның рәхимсезлегенә бәрәү дә тиңләшә алмас, мөгаен. В. О. Ключевский Новгород шәһәрен күздә тотып язганча, Явыз Иван "Берни дә тикшереп тормыйча, шикләнү нигезендә генә, тик кенә-болай гына борынгы зур шәһәрне бөтен бер өлкәсе белән бергә кансыз, оятсыз рәвештә тар-мар итте, татарлар бервакытта да бер генә рус шәһәрен дә болай иттермәгәннәр".[15] Нәтиҗәдә Бөек Новгородта 6000 хуҗалыктан бары тик 1000 хуҗалык кына торып кала. Мәскәүдә Явыз Иван тәмам азып китә һәм чып-чын террорга күчә. "Патша җәбере, сөргеннәр, шикле кешеләрне җәзалап үтерүләр,—дип яза С. Ф. Платонов,—опричникларның "сатлыклар"га карата көч кулланулары, оргияләр вакытында үз кешеләрен рәхимсез газаплаучы Явыз Иванның чиктән тыш азгынлыгы—болар барысы да Мәскәүнең тиран алдында дер калтырап торуына һәм колларча басынкылыгына китергән".[16] Петр I нең походларын да тыныч походлар дип атап булмый. Атаклы генерал Ермолов та Алтын Урда заманнарыннан ук Мәскәүнең тугры аркадашы булган нугай халкын, хәрби яктан максатка ярашлы дигән булып, тоташ суеп чыккан. Тарихчылар моны искә алырга яратмыйлар анысы.

Тарих—рәхимсез сугышларның һәм кансыз режимнарның тоташ бер чылбыры. Александр Македонский каршылык күрсәткәннәре өчен күп шәһәрләрне тулысынча юкка чыгарган, Цезарь да Галлиядә рәхимсезлек буенча Македонскийдан калышмаган. Мәгърифәтле чорда яшәсә дә, Наполеонны да фәрештә дип атау кыен. Америкалылар бөтен бер кыйтганың дистәләгән халыкларын

[14] Шунда ук, 317.

[15] В.О.Ключевский. Сочинения. Т.II. – М., 1988,с. 180.

[16] С.Ф.Платонов. Полный курс лекций по русской истории. – М., 2004, с. 207.

кырып бетергәннәр, ә соңыннан боларның барысын да горур индеецлар һәм кыю ковбойлар турындагы романнарда һәм фильмнарда тасвирлап чыкканнар. Бүген төрле кыйтгалардагы балалар Чингачгук һәм кешенең баш тиресен салдыручылар булып уйныйлар. Тарихның хурлыклы сәхифәләре һәм сәер бер романтика. Европа романтикасы—мәхәббәт маҗараларын, Америка романтикасы колониаль сәясәтне данлый. Тарих бөҗраларының шушы чылбырында татарлар үз урыннарын алганнар һәм рәхимсезлек белән түгел, бөтенләй башка сыйфатлары белән аерылып торганнар, әмма болары бары тик белгечләргә генә мәгълүм шул.

Карл Маркс рус халкының җаны татар-монголлар тарафыннан "изелгән, бозылган һәм корытылган" дип саный, ләкин фактлар башка нәрсә турында сөйли: руслар шушы "золым"нан соң бөек дәүләт төзиләр. Моны "бозылган һәм корытылган" җан белән эшләп буламы? П. Н. Савицкий сүзләрендә дөреслек күбрәк: "Чыңгыз, аның гаскәриләре һәм дәвамчылары күп рәхимсезлекләр кылганнар. Шулай да, күчмә халыкларның экспансия рухы Европа колониализмына караганда сабыррак та, кешелеклерәк тә булган дип расларга җөрьәт итәм. Моңа меңләгән генә түгел, миллионлаган дәлил бар. Америкада испанлылар ниләр генә кыланмаган! Ә португалиялеләр! Ә Ост- һәм Вест-Индиядә инглизләр! Африканы талау, гасырлар буе кара тәнле коллар белән сәүдә итү үзе генә дә ни тора! Алтын Урдада сабырлык рухы "Үзбәк патша басурманлашкач" та сакланып калган. Монгол державасы эчендә яңа Русь барлыкка килгән. Кешелекнең киләчәк язмышы тулысынча шуның белән билгеләнгән һәм билгеләнә түгелме икән?"[17]

Урта гасырларда кеше гомеренең бәясе хәрби максатка ярашлылыктан түбәнрәк булган. Хәтта XX гасырда да әле ошбу принципны дошманнарга гына түгел, үз кешеләренә карата да киң кулланганнар. II Бөтендөнья сугышы вакытында маршал Жуков Кенигсбергны алганда, бернинди хәрби максаттан да чыгып түгел, бары тик Сталинга бүләк ясар өчен генә уннарча мең иң яхшы совет солдатын шәһәр диварлары астына күмеп калдырган. Чыңгыз хан исә камалыштагы ныгытмаларны штурмлауга иң яхшы сугышчыларны түгел, әсирләрне куган. Әйе, кешелекле гамәл булмаган бу, әмма фашист концлагерьларының беренче үрнәкләре булып, Россия җәмгыятенең иң югары катламының уртак кабеpенә әйләнгән Сталин лагерьлары моннан нәрсәсе белән кешелеклерәк соң? Чыңгыз хан әле ул үзенең дә, дошманнарының да сугышчыларын, чиркәү кешеләрен, һөнәрчеләрне саклаган. Аның гаскәрендә һәм дәүләт хезмәтендә элеккеге әсирләр—гыйлем кешеләре, кәсеп ияләре күптин-күп булган.

Тарих бервакытта да кешелеклелектән газапланмаган. Каршылык күрсәтмәгән яисә чит биләмәләр яуламаган халык тарихтан төшеп кенә калган.

Россиядә хәзергәчә татарларны кешеләрне утта кыздыручылар итеп тасвирлаган китапларны бик теләп бастыралар. Моның булуы мөмкин түгел, чөнки бу "Яса" законнарына каршы килгән, ә Монгол империясендә тәртип бик каты булган—законнарны бозган өчен аяусыз җәза, күбесенчә үлем җәзасы биргәннәр. Чынлыкта исә варварчылык тәре йөртүчеләргә хас булган ул, аларның тәртибе бернинди нормалар белән дә чикләнмәгән. Ач рыцарьлар учакларда балаларны кыздырып, кеше ашаучылык белән шөгыльләнгәннәр. 1099 елда алар Иерусалимда бер генә тере җан да калдырмаганнар, хәтта имчәк балаларын да үтереп бетергәннәр. Тәре йөртүчеләр яһүдиләрне һәм мөселманнарны гына түгел, үз христианнарын да, тыныч халыкны да үтергәннәр. Сатухыянәт тә алар өчен гадәти хәл булган: "1260 елда, монгол-христианнар Фәләстыйнга, "Ходай Табутын" мөселманнардан азат итәргә баргач, андагы тамплиерлар (христиан изге ядкәрләрен яклаучы тәре йөртүчеләр ордены) мәмлүкләрне[18] арыган монголларның тылына үткәргәннәр, ә мәмлүкләр сириялеләр һәм әрмән христианнарын үтерә башлаганнар. Тамплиерлар аларны яклап маташмаганнар. Алар башта Кипрга качканнар, соңыннан Европага ук кайтып

[17] Лев Гумилев. Черная легенда. – М., 2003, с. 95.

[18] Мәмлүкләр – кыпчак коллар, Мисырда гвардиячеләр булып хезмәт иткәннәр, соңыннан хакимиятне яулап алып үз династияләренә нигез салганнар.

киткәннәр. Европада шау-шу купкач, тамплиерлар бөтен гаепне монголлар өстенә өйгәннәр һәм җәмгыять каршында акланганнар. Вакытлар узгач шушы ялган орлыклары либераль тарих белеме җирлегендә шытып, XVIII гасырда көчле үсентеләр биргән, ул вакытта Европа Россиянең көчәюенә Монгол олысын тергезү дип караган. Шулай итеп, сатлык тамплиерларның җиңел кулыннан Европа тарих белеме татарларны, монголларны һәм русларны каралта башлаган, шушы "кыргый азиатлар"га цивилизацияле һәм тәкъва Көнбатышны каршы куйган. Шул рәвешчә "кара легенда" башта Көнбатыш Европада, аннан соң бездә—Россиядә тамыр җәйгән, чөнки чынбарлык һәрвакыт әкияткә караганда авыррак кабул ителә".[19] Ә хәзерге заман татарлары шушы ялгыны күтәрергә мәҗбүр, чөнки безнең тарих турында, нигездә, Европа һәм рус авторлары язган, алар исә объектив мәгълүмат эзләп интекмәгән, аларның каләмен алдан ук ялгыш караш йөрткән. Катып калган стереотиплар хәзергәчә телдән телгә күчә, һәм аларны абруйлы кешеләр авызыннан ишетү аеруча гарьләндерә. Чыңгыз Айтматов үз интервьюларының берсендә, Монголиядә Чыңгыз ханны милли каһарманнары кебек ихтирам итүләренә гаҗәпләнеп: "Монголиянең иҗтимагый үзаңы үз-үзен аңлауның һәм тәүбә итүнең әхлакый арафы аша узып үзгәрсен өчен дистәләрчә, йөзләрчә ел кирәк",—дип әйтә.[20] Миңа исә китапларны һәм матбугатны татар-монголлар турында ялган белән тутыруны дәвам итүче тарихчыларның тәүбәгә килүен таләп итү дөресрәк булыр кебек тоела. Монголлар ни сәбәпле тәүбә итәргә тиеш соң әле? Урта гасырларның шундый булганы өченме? Чыңгыз хан үз заманына тәңгәл ул. Чыңгыз Айтматов тагын болай ди: "Ул чакта да культураның иң түбән баскычында торган әлифбасыз халыктан чыккан Чыңгыз ханның бернинди белеме булмаган. Табигый ки, аның идеяләр даирәсе бик чикле. Аныкы дип саналучы гыйбарәләр һич тә акыл һәм фикер иясенең фәлсәфи карашлары түгел, ә бәлкиҗәза бирүче законнар җыелмасы гына, һәм аяусыз изү һәм юкка чыгару юлы белән ханнар хакимиятен ныгытуга юнәлтелгән, аларда киң дәүләти фикер йөртү, бигрәк тә халык бәхете идеясен аңлау билгеләре юк". Чыңгыз хан, чыннан да, укымышсыз булган, ләкин Мөхәммәт Пәйгамбәр дә белемле булмаган, алар икесе дә башкалардан өйрәнгәннәр. Чыңгыз ханда дәүләти фикерләү билгеләре юк дию дөрес түгел. Кешелек тарихында Чыңгыз хан империясеннән дә зуррак дәүләт оешмаган, мондый дәүләт төзү өчен даһиларча фикерләү зарур.

Тарихчылар үз хезмәтләрендәге каршылыкларны кайвакыт үзләре дә күрмиләр. Мәскәүнең "Вече" нәшрияты "100 диктаторов" дигән китап чыгарган, анда шундый юллар бар: "Урта Азиянең иң зур шәһәрләреннән халкы монгол гаскәрләренә батырларча каршылык күрсәткән соңгы шәһәр—Мерв. Ул 1221 елда яулап алынган. Дүрт тәүлек эчендә кешеләр үз шәһәрләрен ташлап чыгарга тиеш булганнар. Монголлар алар арасыннан кол итү өчен 400 һөнәрчене һәм бераз балаларны аерып алганнар. Калганнар җәзалап үтерелгән, моның өчен аларны хәрби частьләргә бүлеп биргәннәр: камалышта катнашучы һәрбер сугышчы үз кылычы белән 300 дән алып 400 гә кадәр кешене суярга тиеш булган! Ун меңнәрчә крестьян монголлар оештырган шушы зур кан коештан котылып калырга теләп, шәһәр читендәге тау куышларына качкан. Ибн әл- Әсир 700 000 кеше үтерелүе турында әйтә, шул ук вакытта Җүвәйни, бу санны арттырып, Изатдин Нассаба исемле нindидер бер кешенең башка берничә кеше белән шәһәрдә үтерелгән кешеләрне санын-саный унөч көн һәм унөч төн үткәргәнлеген хәбәр итә. Тау куышларында, авылларда һәм башка буш җирләрдә үтерелгәннәрне исәпкә алмыйча, мәетләре табылган кешеләр генә дә 1,3 миллионнан артып киткән". Бу юлларны укыгач чәчләр үрә тора, күңел татар-монголларга карата нәфрәт хисе белән тулып таша. Ибн әл-Әсир хикәятенең дәвамын укыгач, бигрәк тә: "Аннан соң монголлар шәһәргә ут төрттеләр, Синҗар солтанның төрбәсен яндырып, акча эзләп каберен актардылар. Алар бу эшне өч көн дәвам иттеләр, дүртенче көнне ул шәһәрдә яшәүче бөтен кешене үтерергә боерды һәм әйтте: "Алар безгә каршы баш күтәргән иделәр". Барысын да үтер-

[19] Лев Гумилев. Черная легенда..., с. 275.
[20] Реквием улетающей стаи. – М., 2003, с. 83.

деләр. Ул мәетләрне санарга кушты һәм алар 700 мең булып чыкты. Әйе, без Аллаһныкы һәм аңа кире кайтачакбыз! Мөселманнарга менә ни булды ул көнне".[21] Ләкин хикмәт шунда ки, урта гасырларда 700 мең кеше яши торган андый зур шәһәрләр булмаган, ул заманнарда 50 мең кеше яшәгән шәһәр дә бик зур булып саналган. Мәсәлән, XIII гасырда Бөек Новгород халкы ундүрт меңнән бераз гына артык булган.[22] Әмма иң кызыгы шунда—бер елдан соң Мерв шәһәре яңадан баш күтәрә һәм аны, кабат һөҗүм итеп, яулап алырга туры килә. Һәм, ниһаять, ике елдан соң шушы ук шәһәр татар-монголларга каршы 10 мең кешелек отряд оештыра, димәк, анда берәүне дә үтермәгәннәр, чөнки ун меңлек гаскәрне 40 мең-50 мең (урта гасырлар шәһәре өчен мөмкин булган иң зур сан) халкы булган шәһәр генә җыя ала. 700 мең яки 1,3 миллион корбан "кяфер татарлар"ны куралмаган мөселман авторының фантазиясе генә булып чыга. Шул ук елъязмачы тагын болай дип тә яза: "Алар шәһәрдә үзләре күргән бар нәрсәне җимергәнче, яндырганчы, талаганчы торалар, үзләренә кирәкмәгәнне яндыралар. Ефәкне җыеп тау итеп өяләр дә, ут төртәләр, шул рәвешчә алар башка әйберләрне дә юк иттеләр".[23] Ефәкне яндыруларына караганда, моның киресенә—татарларның шәһәрне алтыннан да кыйммәтрәк булган ефәк табу өчен талаулары на ышану җиңелрәк. Ефәк хакына сугышлар барган, дәүләтләр үзара берлекләр төзегән, дипломатлар һәм сәүдәгәрләр ефәкне алып кайту юлларын эзләгәннәр. Татар-монголларда ефәк уклардан саклану өчен һәм гигиена чарасы буларак кулланылган. Үз тормышларын саклаучы һәм муллык китерүче ефәкне яндырырга аларның кулы күтәрелмәс иде.

Хәзерге заман тарихчылары татар-монголларның аз санлы гаскәрләренең кытайларның, азиатларның, гарәпләрнең, иранлыларның зур армияләрен тармар итүләренә, нык уйланылган җиңүләренә сокланалар, тик шул ук вакытта аларны варварлар дип атыйлар, башка сыймаслык саннар атап, аларның коточкыч явызлыкларын тасвирлыйлар һәм күзгә ташланып торган каршылыкларны күрмиләр. Генерал М. И. Иванин Урта Азиянең имештер миллионлаган кешесе үтерелүен әйтә, ә соңыннан, гаҗәпләнеп, үзе үк өстәп куя: "Хива оазисында гомумән ике миллион кеше яшәве шикле, әлбәттә, ә көнчыгыш язучылары исәбенә караганда, бер Ургенчта гына да 2 400 мең кеше үтерелгән!"[24] Шуңа да карамастан, ул, Чыңгыз ханның хәрби стратегиясенең һәм тактикасының, халыкара дипломатиясенең асылына төшенмичә, шушындый уйдырмаларны җентекләп тасвирлавын дәвам итә. Ул татар-монголларныкына караганда берничә тапкыр күбрәк булган хәрби көч җыеп та "варварлар" тарафыннан тар—мар ителгән Кытай империясенең, Хәрәзем солтаны Мөхәммәтнең, рус кенәзләренең йомшаклыгына гына гаҗәпләнә. Ә "варварлар" исә ныгытылган шәһәрләрне яулап алалар, [25] Бөек Кытай Стенасын серле рәвештә урап үтәләр, берничә дистә мең сугышчы аз көч белән бөтен Кытай халкын кыйный, анда ул заманда кимендә 60-80 миллион кеше исәпләнгән. Алар моны ничек булдыра алганнар соң? Аларның күпләп үтерү кораллары да, крематорийлары да булма-

---

[21] Золотая Орда в источниках. Том первый. – М., 2003, с. 29.

[22] Илья Стулов. Александр Невский – герой. Но тевтоны – не псы-рыцари // "Известия", 10 апреля, 2004, с. 9.

[23] Золотая Орда в источниках..., с. 21.

[24] М.И.Иванин. О военном искусстве и завоеваниях монголо-татар и среднеазиатских народов при Чингисхане и Тамерлане. – М., Санкт-Петербург, 2003с. 98.

[25] М.И.Иванин культуралы кытайларның хәленә кереп болай дип яза: "Алар бик үҗәтләнеп оборона тотканнар. Корал йөртергә сәләтле булган барлык ир-атлар шәһәрне саклаганнар; ирләр киеменә киенгән хатын-кызлар сугышчыларга агач һәм таш китереп торганнар; ныгытма башлыгы картларны һәм балаларны үтереп, алардан май эретергә әмер бирә, ул майны саламга буяп, камалыш тотучыларны яндыру өчен кулланганнар; ныгытма өч ай буе азык-төлексез яши, гарнизон ашар өчен иярләр, итекләр, тузган литаврлар пешерә; ниһаять, картларны, балаларны, әсирләрне, яралыларны ашарга рөхсәт бирелә; кеше һәм хайван сөякләреннән камыр ясап, аңа яшел тәмләткечләр салып җиңелгән отрядларның сугышчыларын ашаганнар. Ниһаять, гиннар императоры, өметсезлеккә бирелеп асылынып үлгән; шәһәр 1234 елда һөҗүм белән яулап алынган һәм аның белән бергә гиннар империясе дә җимерелгән". ( Шунда ук, 121 нче бит). Шунысы кызыклы, цивилизацияле кытайлар балаларын майга әйләндергәч, шәһәрне кем өчен саклаганнар икән?

ган ләбаса. Шул ук вакытта кытайларның туплары һәм ракеталары "варварлар"ның атлы гаскәренә каршы ни өчендер "аз нәтиҗәле" булып чыккан. Шушындый рәхимсез сугыштан соң Кытайның атаклы киңәшчесе, фәйләсуф, шагыйрь һәм астролог Элюй Чу-цай ни сәбәпле Чыңгыз ханга хезмәткә күчкән һәм 20 ел буена канцлер булып тугры хезмәт иткән соң? Аның 1236 елгы канунга ярашлы рәвештә кытай халкына, соңрак рус халкына да салымнарны бераз йомшартуын[26] татар-монголлар аңлап кабул итәләр, чөнки алар мондый система икътисадны тизрәк тергезергә ярдәм итә дип санаганнар. Бу аларга нигә кирәк булган соң? Алар бит варварлар, җимерүчеләр, бөтен кешене рәттән кыйнап-үтереп йөрүчеләр.

Чыганаклардагы саннарны китерүчеләрнең күбесе дошман ягыннан булган. Гәрчә басып алучыларга карата нәфрәтләре аңлашылса да, алардан объектив фикер көтеп булмый. Басып алучыларны кем яратсын? Ләкин тарих турында язучылар елъязмачылар язганга тәнкыйди карарга тиеш бит.

Юк, елъязмачыларның барысы да ялганчы түгел. Татар дәүләтләрендә озак яшәп, телне һәм культураны белгәннәре еш кына сокланып язган. Гарәп тарихчыларына Биркә ханның һәм Үзбәк ханның ислам тарафдарлары булуы йогынты ясаган, күрәсең, моңа бәйле рәвештә аларның Алтын Урдага мөнәсәбәте кискен үзгәргән. Мисыр солтанының сәркатибе Әлмәлик-Әннәсар Ибне Фадлаллах әл-Омари да, үзеннән алда килүчеләрдән аермалы буларак, Алтын Урда татарларын мактап телгә алган: "Бу илләрнең төркиләре, намуслылык, кыюлык, ялганнан качу, буй-сыннарының камиллеге, матурлыгы һәм холыкларының яхшылыгы буенча төрки кабиләләрнең иң яхшыларыннан берсе".[27]

Нигаҗәп, рус тарихы евроцентризм эталоннары буенча язылган, юкса Европа тарихчылары русларны кичәге татарлар дип исәпләсәләр дә. "Русларның холкы, бу ярымварвар кавемнең барлык дәгъваларына карамастан, бик рәхимсез һәм әле бик озак рәхимсез булып калачак,—дип язган Астольф де Костин.— Чөнки бары тик йөз ел элек кенә алар чып-чын татарлар булганнар, цивилизациянең әлеге сәнәктән көрәк булган вәкилләренең күпчелеге Европача көяз ялтыравык астында аю тиресен саклый—алар бары тик аның йонлы ягын эчкә каратып кына кигәннәр. Аз-маз тырнаштырып карасаң, аларның йоннары кабарып чыга һәм тырпая".[28] Европадагы татарга каршы традиция Россиядә дәвам иттерелә, өстәвенә русофобия төсмере белән. "Мәгърипчелек" ошбу юнәлешнең чагылышы була да инде. Валерий Захаров язганча, "Мәскәү Русен куралмаган беренче рус русофобы—Петр I. Руслыктан баш тарту шушы күчә торган чирне йоктырган дворяннар арасында bon ton а (яхшы тон) билгесе булып саналган. Дворян русофобиясенә каршы күтәрелгән славянофиллар авазы руска ачу тотучыларның шау-шуында күмелеп калган; славянофилларның ретроградлар дип даннарын саталар, соңрак Достоевский белән Лесковка да шундый репутация ябыштырыла."[29] Ялган исә гадәти бер карашка, бәягә, димәк ки, үзүзеңне тотышның стереотибын ясаучы факторга әйләнә.

Европа тарихчылары, аларга ияреп рус тарихчылары да, сәясәтчеләр кушуы буенча, үз ялгышларын моңа катнашы булмаган кешеләргә китереп чәпәү максаты белән, кыргый татарлар турында төрле-төрле әкиятләр тараттылар. Алар моны европача, җиренә җиткереп эшләделәр. Өстәвенә төрле елъязмалардан теләсә нинди өзекләр җыярга мөмкин, чөнки төрле кешеләрнең карашлары да төрле-төрле һәм урта гасырлар вакыйгаларын шәрехләүдә аларның үз мәнфәгатьләре чагыла. Берәр-нинди халыкка карата тоташ нәфрәт тәрбияләү буенча моннан да рәхимсезрәк экспериментны[30] табуы кыен. Әмма бу хәл татар

---

[26] Салымны монголлардан һәм мөселманнардан алган кебек җан башыннан түгел, йорт башыннан алганнар.

[27] Золотая Орда в источниках..., с. 103.

[28] СМ.: Россия первой половины XX в. Глазами иностранцев.–Л., 1991, с. 536-537.

[29] В.Захаров. Извращение великорусской истории. // "Молодая гвардия", 1992, № 9, с. 166.

[30] Хәзерге вакытта көнбатыш масса-күләм мәгълүмат чараларында исламофобия шушы ук ысулларны кулланып таратыла. Ислам һәм радикализм, ислам һәм террорчылык, ислам һәм кыргыйлык дөньяви үзаңда синонимнарга әйләнделәр.

рухын сындыра алмады, гәрчә татарлар арасында "яхшырак", исеме "матуррак" яңгырашлы башка халык булып язылучылар табылса да.

Россия тарихчылары үзләренең рәсми тарихларын әкият белән тутырып кына калмадылар, татарлар өчен дә татарлар килеп чыгышының "болгар теориясе"н уйлап таптылар. Әлеге теория Төрки каганаты һәм Алтын Урда чорларын сызып ташлый. Алар үзләренекен генә түгел, татарларның да чын тарихын юкка чыгарырга маташтылар. Татарлар арасында үз исеменнән җиңел генә баш тартучы галимнәр аз булмады. Кызганыч ки, борынгы төрки тарихын бар нечкәлекләре белән аңлаучы Садри Максуди кебек күренекле акыл ияләре дә татарларны монголларга тәңгәлләштерде, монголларны—варварлар, ә Идел буе татарларын Чулман болгарлары дип атады. Этногенез проблемаларын шулай җиңел генә хәл итеп булса икән!

Нигаҗәп, Садри Максудиның фикеренә аның игелекле максаты—төркиләр тарихының абруен күтәрү нияте тәэсир иткән. Ул болай дип язган: "Төркиләрнең бер өлешен "татарлар" дип күзаллау һәм моннан килеп чыккан аяныч вакыйгалар татар-монгол хакимлегенең тискәре нәтиҗәләреннән берсе булып тора. Шунысын да билгеләп үтик, хәзерге вакытта "татарлар" дип аталучы халыклар тарихи яктан да, тел җәһәтеннән дә—чын төркиләр".[31] Гомумән, язмыш җилләре Төркиягә ташлаган һәм андагы җәмгыятьтә югары урыннарга ирешкән татарлар һәрвакыт иң актив "төркичеләр"[32] булып чыкканнар. Бик шәп сәясәтче һәм публицист Йосыф Акчура "төркичелек" теориясенә нигез салган, Садри Максуди әлеге концепциянең хокукый нигезен булдырган, Зәки Вәлиди исә, йомшак кына итеп әйткәндә, үзенең башкорт "мәгънәсезлекләренә" дә карамастан, ахыр чиктә, төрки-татар тарихы турында, Рәшит Арат төрек теленең реформасы хакында язганнар һәм алар барысы да бер идеягә—төркиләрнең халык буларак дәрәҗәсен күтәрү идеясенә хезмәт иткәннәр. Бу аңлаешлы хәл. Госман империясеннән Төркия республикасына күчү башка төрле тәңгәллекне таләп иткән: империячел госманлык урынына милли төреклек соралган, димәк, төрекләрдә милли хисләрне көчәйтергә кирәк булган. Язмыш ирониясе шундый ки: аларның барысын да бүген күренекле татар (әмма болгар түгел) галимнәре һәм сәясәтчеләре буларак искә алалар.[33]

Садри Максуди монголларны цивилизациягә, мәдәнилеккә ирешмәгән халык дип бәяләгән, әмма төркиләр үз тарихларын әһәмиятлерәк итү өчен башка халыкларны кимсетүгә мохтаҗ түгелләр. Варвар дип атап Чыңгыз ханның ролен кечерәйтү ихтыяҗы юк. Чынлап та, ул төрки традицияләр, төрки сугышчылар һәм киңәшчеләр аркасында күтәрелгән. Ләкин ул бит моны булдыра алган. Ул үзеннән культуралырак, оешканрак, сугыш алып баруның меңьеллык традицияләренә ия булган төркиләрне җиңгән. Чыңгыз хан төркиләр тәҗрибәсен өлләни баетмаган, әмма күп нәрсәне, аеруча хәрби өлкәдә, камиллеккә җиткергән.

Монголларның һәм татарларның тарихын бер-берсеннән аеруы кыен. Телләренең һәм мәдәниятләренең төрлелеге күзгә ташланып торса да, урта гасырлар тарихы аларны уртак язмыш белән бәйләгән. Кайбер тарихчылар, татарларның горурлыгын аярга тырышып, "монгол изүе" яисә "төрки-монгол явы" турында язалар, ләкин тарих мондый төзәтмәләргә мохтаҗ түгел. "Татар-монголлар" атамасының, ошаса да, ошамаса да, яшәргә хакы бар. Безнең язмыш уртак, аннан качып булмый. Татар һәм монгол тарихын аерым-аерым өйрәнү концепциясен аклар өчен, Казан Кремлендә күмелгән, Чыңгыз нәселеннән булган ханнарыбызның каберләрен ачып, җәсәдләрен Монголиягә илтеп куйыйкмы инде хәзер? Ахыр чиктә бу—искиткеч тарих, аның белән горурланырга мөмкин. Вакытлар узар, бу тарихны Евразиянең күп халыклары дәгъвалый башлар әле.

*Дәвамы киләсе саннарда*

[31] Садри Максуди Арсал. Тюркская история и право. – Казань, 2005, с. 300.

# БУЫННАР ЧЫЛБЫРЫ ӨЗЕЛМӘС...

*(Рәмис Аймәтнең "Айның арьягында", Марат Закирның "Кояшлы төн" исемле шигырь китаплары чыгу уңаеннан уйлану)*

Шагыйрьләребезнең күптән түгел генә чыккан шигырь китапларының исемнәре—«Айның арьягында», «Кояшлы төн»—күңелне күпмедер дәрәҗәдә сискәндерә... Уйланып куясың: ни өчен чагыштырмача яшьрәк шагыйрьләребез үзләренең шигъри реалияләрен аерым бер мизгелдә төн темасында тапканнар икән? Каян килеп чыккан чынбарлыкны, яшәешне мондый кимәлдә кабул итү?..




Бер карасаң, яшьрәк шагыйрьләрнең китапларына исем сайлаганда Төн чынлыгына игътибар итүләре бик үк гаҗәп тә түгелдер, мөгаен: ул бит кеше яшәешенең аерылгысыз бер өлеше! Кешенең тереклек итүе яртылаш Төн "кочагында" уза. Шуның өстенә бу вакытта яшәеш үзенчәлеклерәк дәвам итә... Шагыйрьләр—чынбарлык серләрен нечкәләп танып-белергә омтылган җаннар—вакыты белән ай-йолдызлы, вакыты белән куе болытлы да булган Төн дөньясын сурәтләүдән баш тарта аламы соң?!

Шулай да, ни өчен «Кояшлы төн»? Ни өчен «Айның арьягында»? Кем белә, бәлки, монда яшьрәк шагыйрьләребез чынбарлыкны үзенчәлеклерәк аңлауларын белдереп узалардыр... Бәлки, алар яшәешнең төнге сәгатьләренә, күк җисеменең беркайчан да күренмәгән арьягына игътибар итеп, җиһанның аңлашылып бетмәгән халәтләренә, серләренә дә игътибар күрсәтергә омтылалардыр... Кем белә, бәлки, алар безгә ошбу хәятның парадоксаль булуы, логикага буйсынмавы турында да искә төшерергә телиләрдер... Бәлки, алар Күк һәм Җир арасында Хакыйкатькә үз юлларын табарга ашкыналардыр...




Җиһанга үз сүзен әйтергә омтылган яшьрәк шагыйрьләребез буыны дигәннән... Әдәбиятыбызда буыннар чылбыры турында шактый әйтелгән, сөйләнелгән инде. Һәм күбрәк мондый бүленеш меңъеллык язмышы булган шигъриятебезгә карыйдыр. Гомумән, шигъриятне буыннар чылбыры күзлегеннән карап өйрәнүгә инде күнегеп тә беттек сыман. Кайбер вакыт шушындый үзенчәлекле "алым"нан башка шигъриятне күзәтеп, өйрәнеп, аңлап та барып булмас иде төсле тоела. Аның уңай бер ягы, сыйфаты: бу туктамас Вакыт агышында һәр буынның үз тавышын тотып, «аерып» алырга ярдәм итә ала ул...

Ә нәрсә күзәтәбез без бүген шигъри кырларыбызда? Шигъриятебездә тормыш үзе «үрә килгән» буыннар чылбыры исән-иминме соң? Билгеле, әдәбиятка, шигърияткә килүчеләрнең, шуна дәгъва белдерүчеләрнең беркайчан да туктап, бетеп

торганы булмады. Әмма, мәсәлән, Зәйдуллалар буыныннан соң шигърияткә көчле талантлар килмәде дигән фикерләр дә булмады түгел. Кайчакта әле аларны (сонрак күренүчеләрне) "калдык-постык" дип кимсетеберәк тә яздылар. Бу сүзләрдә дөреслек бар идеме?! Уйланырга була...

Сүз дә юк: Рәмис Аймәт, Марат Закирлар буыны Равил Фәйзуллиннар буыны да, Ркаил Зәйдуллалар буыны да түгел, охшамаган, болар—үзгәрәк, башкачарак... Аларның төп сыйфатларының берсе: алар әдәбиятка чынлап торып сонрак килделәр. Күбесе (Рәмис Аймәт, Марат Закир, Танчулпан...) тәүге китапларын утыз яшьне узгач чыгарды. Шул ук вакытта беренче китабын («Мин—шигырьдән», 1992) иртәрәк чыгарган бик тә сәләтле шагыйрь Рөстәм Сүлти, мәсәлән, татар шигъриятендә соңгы вакытта бик аз күренә, ул татарнын үзгә бер «Рембосы"дай Аурупага "китеп югалды». Шулай ук беренче шигырьләр китабын («Хисләренне жилгә чәчмә», 1994) иртәрәк чыгарган Жәмилә Әхтәмова да икенче китабын («Мин китәрмен синнән...», 2002 ) 8 елдан соң гына укучыларга тәкъдим итте.

Әмма, бәхеткә, вакыт-вакыт мәрхәмәтле була алган тормышыбызда чыгармалар һәрвакыт кала икән. Шуларның берсе—Уфада яшәүче Марат Кәбировтыр. Ул инде күп кенә китапларын (шигырьдә, прозада) дөньяга чыгарырга өлгерде, үзенең ижади потенциалын иртәрәк чынга ашыра алды, үзен чын мәгънәсендә үзенчәлекле язучы һәм прозаик (мона өстәп ул әле драматург та) итеп танытты... Рәмис Аймәт, Марат Закир, Марат Кәбиров, Рөстәм Сүлти, Жәмилә Әхтәмова, Танчулпан, Рәис Апуш, Фәрит Гази һ.б... Бер-берсенә охшамаган шагыйрьләр, шагыйрьпрозаиклар... Ни өчен алар әдәбиятка соңарыбрак килделәр икән?

Бу фактны, гамәлне төрлечә шәрехләргә булыр иде. Әмма әлеге буынның әдәбиятка соңарыбрак килүенең сәбәпләренең берсе, бәлки, иң мөһиме дип, Вакыт алып килгән кырыс заман реалияләрен атарга кирәктер?..

Үткән XX гасырның 80 еллар ахыры—90 еллар башында, Марат Закирлар буыны армиядән-хәрби хезмәттән кайтып югары уку йортларында укый башлаган дәвердә, СССР киңлекләрендә күпләр әле нindирәк нәтиҗәләргә китерәсен (кемнәр өчендер үтә фажигале...) уйлап та карамаган, бик күп халыкның чагыштырмача тыныч тормышын «себереп түгәчәк» шактый кискен үзгәрешләр башланып китте. Хәбәрдарлык, демократия, шәхес иреге, милли үзбилгеләнү кебек кыйммәтләр хакына башланып киткән үзгәрешләр ахыр чиктә безне кыргый капитализм, әхлакны танымаган жәмгыять атмосферасына, криминаль һәм сексуаль революцияләр төненә илтеп ташлар дип кем уйлаган ул чагында—хәтта һава үзе дә өмет белән тулган, аңкыган вакытларда... (М.Горбачев чорында шактый гына кимегән суицид—үз-үзенне үтерү күренеше—Ельцин хакимияткә килгәннән соң "пик" дәрәҗәсенә житте...)

Нәрсә хас иде соң бу «яна урыслар», «яна» казна караклары, яна «текәләр», яна «һөнәр» ияләре—киллерлар (жан кыючылар), фахишәләр хыялланган "кыргый капитализм" дигәннәренә? «Акча бар мәсьәләне дә чишә ала», «Бар көч—акчада», «Кем көчле—шул хаклы», «Көчлегә—капитал, көчсезгә—«социаль», «Үз проблемаң үзенә булсын!» һ.б.ш. принципларның вакханалиясе.... Кемдер әйтергә мөмкин: демократик жәмгыятькә таба булган юлда шундый кимчелек-чыгарылмалардан башка булмый инде ул дип. Әмма ашыкмыйк: изге максатлар хакына начар ысуллар кулланcаң, максатыбыз да начарга әвереләчәк!

Аннары Ичкериядә башланып киткән сугыш та табигый хис—милли Азатлыкка булган ихлас алгысуларга—кара шәүлә булып ятты...

Бик кыскача әйткәндә, Марат Закирлар буыны әдәбиятка килгәндә менә шундый искиткеч катлаулы чор иде. Моны күрми калу мөмкин түгел иде. Искә төшерсәк: күренекле тәнкыйтьчебез Мансур Вәли-Баржылы Рөстәм Сүлтинең беренче китабына 1993 елны язган «Яктырта да яшен, яндыра да...» дигән рецензиясендә бу яшь шагыйрьне «сәяси гарасатлар һәм экономик кризислар чоры шагыйре» дип тә атап китә.

Кайда инде мондый чорда шагыйрьгә дөнья белән гармоник мөнәсәбәткә керү!.. Хәтта олырак яшьтәге татар шагыйрьләре дә жәмгыятьнең тиз арада деградацияләнүен күреп беразга югалып калдылар, хәтта алар көнелендә дә диссонанс тумый

калмады кебек... Оптимистик романтизм тарафдары Рәдиф Гаташ болай язды ул елларда:

*Заман дигәнем, син—кемнәр заманы?*
*Мәхәббәткә, сафлыкка көн калмады...*

Әйе, үткән XX гасыр ахырында аңарчы чагыштырмача булган социаль, сәяси стабильлек «юылып алынды» һәм җәмгыятьтә кеше күңелен имгәтүче кырыс реалияләр туды...

Сүз дә юк, боларның барысы яшь буынга да, кулына каләм алган буынга да, тәэсир ясамый кала алмады, билгеле. Аларның бит шигъри-әдәби аңнары иске Маяклар сүнгән, ә яңалары әле табылмаган үзгәрешләр чорында шәкелләште.

XX йөзнең 90 елларында шигъриятькә килгән Рөстәм Сүлти, Рәмис Аймәт, Марат Закирлар буыны безгә үзләренең кабатланмас чоры турында шигъри Шаһитлыгын бирделәр, үз заманнарының авыру-яраларын да сөйләделәр...

*Дөнья буйлап яңа гасыр атлый.*
*Атлый золым, кан-яшь, ут аша.*
*Әйтерсең лә, минем аша килеп,*
*Ике гасыр килеп тоташа.*

*Ике гасыр бәргәләнә миндә.*
*Орыш бара җанда ник гелән?*
*Ут беләнме? Юк,юк! Гасырларны*
*Мин бәйлимен шигъри сүз белән.*

(Рәмис Аймәт, «2001 ел. Гыйнвар»)

Яки:

*Гамьсез-гафил буын! Тик син генә*
*Шушы афәтләргә тарыма!*
*Яра калды, яра...*
*Тама каны*
*Туган җирнең җепшек карына.*

(Марат Закир. )

Билгеле, бу буын Равил Фәйзуллиннар буыны төсле әдәбиятка «шартлау» да алып килмәгәндер (әдәбиятка «шартлаулар» гел кирәкмидер дә), шул ук вакытта ул Ркаил Зәйдуллалар буыны төсле бердәм, нык, үҗәт тә түгелдер. Гомумән, шунысы да бар: әдәбиятта еш кына "алтын гасыр"дан соң «көмеш гасыр» килүчән...

Нинди буын соң бу? «Югалганмы», «буынсызмы», «каһәрләнгәнме», «сонарганмы», «ачылмаганмы»—моны инде һәркем үзе өчен үзе шәрехли алыр. Ахыр чиктә: ул әле үз иҗади потенциалын ахыргача ачмаган буын...

Бер нәрсә төгәл билгеле: табигатьтә буыннар чылбыры өзелсә, яшәеш тәмамланган төсле була; шигъриятьтә дә буыннар чылбыры өзелсә, шигъри ут-факел да сүрелә, сүнә. Шигъри ут-факел сүрелсә, алдагы шигъри буыннар иҗатына булган ихтыяж да кимергә, югалырга мөмкиндер...

Ни генә әйтсәләр дә, бу буын килгән һәм Кояш-Ай астында, Күк һәм Жир арасында үз Сүзен ихлас күңелдән әйтергә тели! Ул матбугатта басыла, китапларын чыгара, укучылар алдында чыгышлар ясый... Бу буынның, шиксез, әйтер сүзе бар!

*Дөньяларның кайсы читендә мин,*
*Вакытларның кайсы чигендә,*
*Гомеремнең кайсы мизгелендә,*
*Хыялымның кайсы күгендә*
*Яшим икән?*

—ди Рәмис Аймәт «Айның аръягында» шигъри китабына кергән «Икән?!.» шигырендә. Гаҗәеп шигъри, үтә фәлсәфи-метафизик сораулар...

Юкка гына «Айның аръягында» китабына язган «Чикле чиксезлек» дигән кереш сүзендә Равил Фәйзуллин үзенә хас булган шигъри фәлсәфәдән чыгып, үзенә хас яшәү принципларыннан чыгып, яшь шагыйрь белән күпмедер дәрәҗәдә бәхәскә керергә омтылмыйдыр. Монда без остаз белән шәкертнең очрашуын гына түгел, ә шактый дәрәҗәдә төрле шигъри фәлсәфәләр очрашуын да ачык күрәбез төсле...

*Йолдызларга үрелгән чаклар*
*Мизгел генә икән ләбаса!*
*Нинди вакыт бу?! Колагыңнан*
*Югарыга тарта, йә—баса...*

*Нинди вакыт бу?! Дөнья куып*
*Чиксез киңлек житкән бер мәлдә,*
*Биләп алыр да сары сагыш,*
*Селкеп салыр дымлы җирләргә...*

—ди Марат Закир да исемсез шигырендә яшәешнең заман көзгесендәге үзенчәлекле, кырыс чагылышын күзәтеп.

Менә инде яшь шагыйрьләр чынбарлык белән очрашканнар да, үз күңелләрендә туган уй-фикерләрен безнең рухи сусау кичергән җаннарыбызга ирештерергә телиләр...

Ә нинди уй-фикерләр соң ул? Уйласаң, анласаң, шагыйрьләр өчен теләсә кайсы заманда да бер олуг теләк хас бит: ул—дөньяны яхшыртырга омтылу...

Күрәсең, һәр буын да әдәбиятка-шигъриятькә шул изге ният белән килә. Һәр буын да үзенчә Матурлык, Яхшылык, Сафлык, Гаделлек, Дуслык кебек идеалларга тугры калырга тели... Һәр буын да Күк һәм Җир арасында гүзәл тормыш—гармония—урнаштырырга алгысый...

Ләкин... шагыйрьләрнең ихлас хыялларына карап дөнья яхшы якка үзгәрдеме икән?.. Гасырлар дәвамында иҗат ителә килгән шигырьләр, көйләр, рәсем-сыннар кешеләр күңелен яхшы якка бордымы соң?.. Безнең күңелләребездә яшәгән идеаллар артык утопик түгелме икән?

Тукайның әрнүле шигъри юллары гасыр узгач та җанны авырттырып искә төшә:

*Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.*

Яки менә Равил Фәйзуллин да үзенең кайсыдыр бер әңгәмәсендә шигъриятькә үз буынының килүенең максаты-нияте дип дөньяны яхшырак, камилрәк, гаделрәк якка үзгәртү дип аңлаткан иде...

Ә менә аның 1989 елны язылган шигырендә түбәндәге юлларны укырга була:

*Яшәдең, эшләп җан аттың...*
*Йә, үзгәрттеңме бераз*
*Дөньяны, Илне?*

*...Сизәме тау—очып төшкән*
*тәмәке көлен?*

Яки менә аның фикердәше-буындашы Рәдиф Гаташ нәрсә дип язган иде үз вакытында:

*Җиттек микән максатларга,*
*йолдызларга?!*
*Кар астында—күпме гөлләр!*

Кайчак уйлап, фикер йөртеп куясың: дөньяга күпме изгеләр, пәйгамбәрләр ки-

леп узган, күпме шагыйрьләр, әдипләр иҗат иткән, рухи янган, ә ул һаман яхшырмый, камилләшми төсле. Әллә инде Мәһди килмичә кешелек яхшы якка үзгәрә дә алмыймы? Әллә Җаһилият заманы котылгысызмы икән?!..

Ләкин...ана карап кына, барыбер, Саф, Бәхетле Галәмнәрне тоеп белгән, Күкләр һәм Гөлләр белән аралашып яшәгән шагыйрь күңеле изге идеаллардан баш тарта алмый бит инде!.. Нәрсә дигән әле Жан Гоенно: «Чын хыянәт, рухны аны акларга чакырып дөньяны ничек бар шулай кабул итүдә чагыла.»

Якты идеаллар белән яшәгән шагыйрь җаны, билгеле, изге кыйммәтләрне оныта алмый.

Хәер... кайчак шулай да тоелып китә: бу мәсьәләгә—дөньяны яхшырак якка үзгәртү мәсьәләсенә—яшьрәк буын шагыйрьләре инде фәлсәфирәк карыйлар төсле. Әнә Марат Закирның «Ялгыз яфрак» шигырендә Күлне битараф тереклек итүдән уятам дип төшкән алтын яфрак ахыр чиктә гамьсез Күлнең корбанына әверелә...Ә Рәмис Аймәтнең «Тәүбә көтәм!» шигырендә түбәндәге юлларны укырга була:

*Күпме яктыртсам да дөньягызны,*
*Серле нурларымны аямый.*
*Белмәдегез кадерем!*

Алар—яшьрәк шагыйрьләр—инде җиһанда барысының да тиз генә яхшы якка үзгәрәсенә ышанып бетмиләр кебек, якты идеаллар алар өчен күпмедер дәрәҗәдә утопия булып кала. Шуннан күпмедер дәрәҗәдә яшәеш пессимизмы туа.

Рәмис Аймәтнең «Айның аръягында», Марат Закирның «Кояшлы төн» шигъри китапларын укыганда күңелдә шундый уй-фикерләр дә кала...

Китапларны тулаем карасаң, Марат Закирның да, Рәмис Аймәтнең дә шигъри җыентыгы дүрт төп өлештән тора. Һәм шигырь китапларының икесендә дә тема-идея ягыннан уртак өч бүлек бар: Милләт һәм Азатлык темасына багышланган бүлек, Сөю-Мәхәббәткә багышланган бүлек, Яшәү-Хәят турындагы фәлсәфи уйлануларга багышланган бүлек.

Әгәр игътибар итеп уйлансаң, бу аңлашыла да: алар өчен төп уртак хисси-фикри нокта булып яшәеш-хәят турында күңелнең түреннән үк килгән шигъри уйланулар тора. Фәлсәфи шигырьләр аларның икесен дә шагыйрь буларак та һәм Дәвер, Галәм баласы буларак та бөтен тирәнлегендә, бөтен киңлегендә ачып күрсәтә.

Бу буынга хас шигъри фәлсәфә дигәндә, шагыйрьләр яшәгән, иҗатлары шәкелләшкән заманның кабатланмас интеллектуаль атмосферасы, рухи эзләнүләре, кумирлары, әдәби-фәлсәфи мавыгулары да искә төшә... Әйткәнемчә, бу шагыйрьләрнең шигърияткә килүе үткән гасырның үзгәрешләр тулы дәверенә туры килде. Бу чорда бөек Ислам дине әкренләп тормышыбызга кайта башлады, озак еллар тыелган һәртөрле әдәбиятны уку мөмкинлекләре ачылды... Бу—әлеге елларның ин сөендергән ягы иде! Үзем дә шул буынның бер вәкиле буларак, ачык хәтерлим: Альбер Камю, Жан-Поль Сартр, Фридрих Ницще, Карл Ясперс, Серен Къеркегор, Мартин Хайдеггер, Абд-әл-Вахд-Яхья-Рене Генон кебек фәлсәфәчеләр безнең яратып укылган, «су урынына эчелгән», төрле кайнар бәхәсләргә нигез булып яткан «ят» та, «үз» дә фәлсәфәчеләребез иде... Кем белә, бәлки, яшәеш офыкларында иске Маяклар сүнеп, пыскып яткан, ә яңалары әле беленергә ашыкмаган дәвердә бу фәлсәфәчеләр аң кысаларыбызны азмы-күпме киңәйтеп тә җибәрә алгандыр... Аларга асылда хас булган экзистенциализм фәлсәфәсе дә безнең дөньяви күзаллауларыбызга тәэсир ясамый калмагандыр. (Соңрак, билгеле, бу фәлсәфәчеләргә карашыбыз теге яки бу якка зур үзгәреш кичерде). Яхшымы-начармы, бу—заманның бер сыйфаты, «үз Хэмингуэйларына, Евтушенколарына» интеллектуаль «модасы» иде ул...

Экзистенциализм фәлсәфәсе дигәннән... Үткән гасырның аеруча авыр чорларында (ике бөтендөнья сугышы, гражданнар сугышы, революцияләр) популяр ошбу фәлсәфә Рәсәй тормышының XX йөз ахырына да бик ятып тора иде төсле... Нәкъ менә шундый чорларда кешенең экзистенциаль ялгызлыгы (“ташланганлыгы”)

күренә, нәкъ менә шушы чорда кеше «мин»енең җәфаланып-алгысып Хакыйкатьне эзләве көчәя төшә...

"Чынлык—ул иң якыны. Әмма иң якыны кеше өчен иң ерагы булып кала»,—дип язган иде Мартин Хайдеггер кеше ачарга теләгән чынлыклар турында. Уйласаң, шагыйрь Рәмис Аймәт тә безгә шигырьләрендә еш кына үз җанының ерактан килгән әрнүен, үз "мин"енең кырыс дөнья шартларына «ташланганлыгын» сөйли түгелме:

*Бу дөнья—гарасат мәйданы.*
*Әллә соң яшәү дә—бер җәза?!*
*...Мин әле тумаган, ә инде*
*Күкләрдә укыйлар җеназа.*

(«Мин әле тумаган», 1998)

Яки:

*Үксез кыл мин төпсез, тар бушлыктан*
*Аваз салган өзелә-өзелә...*
*Давыл эчендәге бер Тынлык мин,*
*Тынлык эчендәге Зилзилә.*

(«Автопортрет», 2002)

Әмма теге яки бу фәлсәфәгә ярашу үзмаксат була алмый бит! Бер нәрсә ачык: фәлсәфәчеләр дә, шагыйрьләр дә безгә кешенең ялгызлыкка дучар булган үзлеге—«экзистенциясе»—турында ихлас сөйлиләр. Фәлсәфәчеләр дә, шагыйрьләр дә безгә кеше «мин»енең хакыйкый ярларга кайтырга алгысуын ирештерәләр...

Тик сорау гына кала: ни өчен шулай килеп чыккан соң? Ни өчен Хакыйкый Яшәеш югалган?..

Марат Закир китапка исем биргән «Кояшлы төн» шигырендә безне парадоксаль кичерешләр дөньясына алып китә:

*Төнлә генә бөтен шул мин—*
*Кичалсам төксе көнне...*
*Төн—әнкәм бул үксезеңә,*
*Җәлләмә тик сөтеңне.*

Парадокс: шигъри «мин» үзен якты Төндә генә тулысынча ача, таба...

*Синнән башка инде янә*
*Кемгә, төнем, табыныйм?!*
*Синнән башка, якты төнем,*
*Кемгә барыйм тагын мин?!*

Шагыйрьнең Төнгә сыгынуы гаҗәберәк тоелырга мөмкин... Кайсы ягы беләндер «Кояшлы төн» миңа татарның фаҗигале язмышка ия шагыйре Эдуард Мостафинның «Төнге кеше»сен, алман шагыйре Гелдерлинның төнгә язган одаларын искә төшерде.

Әйе, «Кояшлы төн»—фәлсәфи шигырь... Аңарда якты Төн кеше «мин»ен бозык чынлыктан аралаган гүзәл бер чынбарлык булып күз алдына баса. Көн—кеше яшәешенең, эшчәнлегенең, аралашуларының иң актив вакыты, әмма, болар барысы да бозык, кешелексез төсмер алганга, залим бер чак булып күз алдына баса. «Мин»гә кырыс Көн яшәешеннән кояшлы Төн чатырына «качарга» кала... Бу—«мин»нең кешеләр тудырган җәмгыятькә үзенчәлекле Үпкә актыдыр да... Ә аяз Төн—ерак кояшларның (еракта Хакыйкать төсле!..) янә табылган чагы...

Әйе, Хакыйкать әле табылмаган ярларда кала.

«Айның аръягында» китабын ачып җибәрүче "SOS" шигырендә (2002) шагыйрь Рәмис Аймәт, гомумән, Хакыйкатьне кара чоңгыл эчендә (кеше өчен әле табылмаган Хакыйкать шулай да күзаллана ала!) күрә:

*Кулым сузам. Телим коткарырга:*
*«Җитте вакыт. Уз ярыңа ка-а-айт!»—*
*Кап-кара бер чоңгыл үзәгендә*
*Бөтерелә ап-ак Хакыйкать.*

Аңлашыла: Хакыйкать ярына кайтмыйча, шагыйрь күңеле дә тынычланмаячак. Моннан аның эзләнүләре-өзгәләнүләре, күпмедер пессимизмы туа...

Әнә бит Равил Фәйзуллин да шул ук «Чикле чиксезлек» дигән кереш сүзендә Рәмис Аймәт шигъриятендәге төшенкелек мотивларына игътибар итеп узган иде:

*Ак кәфенгә тиздән төренер дә*
*Җир куйнына керер Өметем.*
*Үрмәләр дә җилләр... очыртырлар*
*Гомер китабымның соң битен.*

Ә менә «Мин әле тумаган...» бүлегенең соңгы шигырьләре тулысынча «бакыйлыкка күчү» темасы белән «эретелгән»: «Мин китәсе көн», «Миннән башка гына...», «Эзләмәгез мине...», «Зират җиле»...

Күренекле шагыйрә Лена Шагыйрьҗан да Рәмис Аймәт иҗаты турында язганда шундыйрак моментларга игътибар итә: «Шагыйрьнең эчке дөньясы шактый бай, үзенчәлекле... Гомумән, аңа нечкә романтика хас. Кайвакыт мин аңарда Гарсиа Лорка иҗатындагы газаплы тетрәндергеч җан авазларын да ишеткән кебек булам. Рәмис Аймәт шигырьләрендә безнең шигъриятебездә югалыбырак торган шомлы-драматик кичерешләр уянып китә кебек...»

Гарсиа Лорка...—фаҗигале язмышка ия бөек шагыйрь... Каян килә татар шагыйре Рәмис Аймәттә Лоркадагыдай «тетрәндергеч җан авазлары»? Каян килә бу үзенчәлекле фәлсәфи пессимизм? Әдәбиятны укып беләбез: Гарсиа Лорка да үз иҗатының максаты, кредосы итеп кешеләр күңелен яхшы якка алып чыгуны, кешеләр арасында мәхәббәткә, миһербанлыкка корылган мөнәсәбәтләр урнаштыруны санаган...

Марат Закир шигъриятендә дә Әрнү, Үпкә тойгылары шактый еш кабына... Аның өчен дә дөнья белән самими, эчкерсез, кешелекле мөнәсәбәткә керергә ашкыну кайчагында уңышсыз тәмамлана, җан яралары калдыра:

*Сөйләдем кайгыларымны—*
*Елмаялар төркем-төркем.*
*Шатлыгымны чиштем сезгә...*
*Чиштем—тыңламады беркем.*

*Бәгыремне ачкан килеш*
*Үтте шулай бер көн... Мең көн!*
*Хәтта җансыз таш та болай*
*Бер чәрдәкләнергә мөмкин.*

(«Мамык дивар")

Әйе, кешеләр еш кына бер-берен ишетмиләр, изге кыйммәтләргә хыянәт итәләр... Әмма, ана карап шагыйрьләр якты идеалларга ышанудан туктамый. Күктән бирелгән сәләтенә, бурычына тугры калып, дөньяны яхшыртырга теләү ниятеннән баш тарта алмый...

**Илшат ВӘЛИУЛЛА**

Миркасыйм
Госманов

# ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

### Мәгънәле үкенү

Татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергән студентларны укытучыларыбыз белән таныштырган чакта доцент Якуб ага Агишевны яше буенча андагы иң олы кеше дип тәкъдим иткәннәр иде. Йөз-чыраеннан аның шулай икәнлеге беркадәре сизелеп тора иде торуын. Чалара башлаган чәчләре, маңгаендагы тирән җыерчыклары шуны расласа да, буй-сынының җыйнаклыгы, төзлеге, хәрәкәтләренең чираклыгы, житезлеге, бигрәк тә фикерләү һәм сөйләшүдәге җанлылыгы, активлыгы әлеге хәбәргә бераз шикләнеп карарга да урын калдыра иде. Лекцияләрен тыңлый башлагач, шикләнүләр инануга да әйләнә язды.

Лекция дигәннән, бер-ике ел дәвамында аны төрле кешеләрнең төрлечә укуларын да күрергә, белергә туры килде безгә. Берәүләре, мәсәлән, чанада шуып кына барган кебек бик шома укыйлар икән үз лекцияләрен. Тик, чана эзе калмаучан яисә тиз генә юкка чыгучан булган шикелле, андый лекцияләрдә нәрсәләр хакында сүз баруы да хәтердә җуелып калмый икән. Икенчеләренең лекцияләрендә сине тәмам йокы баскан булыр. Өченче берсенең ык-мык килүеннән, каты арбада чокыр-чакырлы, сикәлтәле юлдан барган шикелле, тыныч кына калгып-йоклап та утыра алмыйсың. Андыйларны кафедрадан куып төшерердәй, урнына үзең үк барып басардай буласың. Тик... предметны гына бераз... белсәң икән...



Лекторларыбыз арасында, әлбәттә, дәресләрен матур итеп оештыручылар да юк түгел иде. Гәрчә мондый «матурлык» кайбер очракта бары тышкы культурага, тышкы эффектка гына корылган булса да. Андыйлар, билгеле, әлеге «ык-мыклар» фонында ялтырап торучан булалар. Ләкин берничә дәрестән соң андыйларына да йөрү теләге кими башлый.

Дөрес, мәсьәләнең асылын ачып, материалларның иң кирәкле төшләрен калку итеп күрсәтеп әйтә белә торган, фактларны истә калырлык дәрәҗәдә аңлатып лекция укучы лекторлар да бар иде бездә. Боларның кайберләре үз эрудицияләренең киң һәм тирән икәнлеген күрсәтү белән генә чикләнмиләр. Алар фактлар, бигрәк тә әлеге фактларның тарихи, фәлсәфи әһәмиятләре, эчке мәгънәләре белән кызыксындыра алулары аркасында тыңлаучыларның да белем ягыннан баеп калуына җирлек тудыралар.

Мондый лекторларның дәресләреннән, гадәттә, уйга калып чыгасың, «нигә бу шулай, ә тегесе алай түгел» дип төпченә башлыйсың, уйлануны дәвам итәсең. Менә шундый чын-чынлап истә кала торган, уйланырга мәҗбүр итә торган лекторлар

*Ахыры. Башы журналыбызның бнчы санында.*

исәбенә мин иң элек шул елларда безнең бүлектә эшләгән мәрхүмнәрдән Үзбәк Байчураны һәм Хатип ага Госман белән Якуб ага Агишевларны кертер идем. Ләкин боларның һәрберсе үзенчә, үзләренә генә хас сыйфатлар белән кызыклы иде.

Аудиториягә Якуб ага, гадәттә, кызу-кызу адымнар белән килеп керер. Биек кафедра янына барып басар да, мөлаем генә бер елмаеп, аудиториягә карап торыр. Шунда ук аның калын дип әйтерлек, ләкин бераз карлыга төшкән ягымлы тавышы да яңгырый башлар.

Вакыт-вакыт кафедра өстендәге кәгазьләренә дә күз салгалар. Аудиториягә мөрәҗәгать итеп сөйләгәндә күзләрендә бер күзлек булса, конспектларына карар өчен түш кесәсеннән икенчесен алыр. Берәр документ яки чәчмә өзекне укып бетергәннән соң тагын беренче күзлеген кияр. Шул рәвешчә ике күзлек чиратлашып гел алмашынып торыр.

Күзлекләрнең шулай туктаусыз «мендем-төштем» хәрәкәте иң истә кала торган тышкы күренешләрнең берсе иде. Әле дә хәтердә: Якуб аганың алтмыш еллык бәйрәменә багышланган әдәби кичәдә шәкертләреннән берсе, мәрхүм Шәйхи Садретдин, шул күзлекләр хакында язылган бер шигырен, дөресрәге, остазына карата ихлас ярату хисе белән сугарылган мәдхиясен укыган иде.

Ләкин Якуб ага лекцияләренең үзенчәлеген, кызыклылыгын бер күзлекләр алышынуга гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Аның дәресләренең үзенә тарту көче, беренчедән, тарихыбыздагы гаять әчтәлекле чорларның берсенә—XIX йөзнең икенче яртысы белән XX гасырның башындагы мәдәни, әдәби хәрәкәткә багышланган булуындадыр. Социаль яктан яңару кичергән, иҗтимагый аңлылык, җәмгыяви активлык көчәйгән, шулар нәтиҗәсендә яңа әдәбият оешкан, күпкырлы матбугат, халыкчан театр-сәхнә сәнгате туган чор хакында иде аның лекцияләре.

Икенчедән, лекторның материалны, ул чакта хөкем сөрә торган сәяси догмалар белән артык авыз чайкап тормыйча, һәм гади, һәм җанлы итеп оештыра алуы да безнең кызыксынуны көчәйтә иде, әлбәттә. Лекция дәвамында Заһир Бигиев һәм Муса Акъегетне, Тукай белән Сәгыйть Рәмиевне, яисә Дәрдемәндне булсын—кайсысы хакында сүз барса да, аларның төс-кыяфәтләренә кадәр күз алдына килеп баса иде. Чөнки Якуб ага әлеге иҗат ияләренең әдәби фикеребез тарихында тоткан урыннарын декларатив рәвештә генә билгеләү белән чикләнми, бәлки аларның һәрберсенең үзләренә хас сыйфатлары, холык-гадәтләре хакында да мәгълүмат биреп бара иде. Якуб аганы тыңлаган чакта, лекторның иҗатлары яктыртыла торган шәхесләрнең мирасларын яхшы белүдән тыш, аларның үзләрен дә ихлас яратуы сизелеп тора иде.

Өченчедән, аның бик күп шигырьләрне, бигрәк тә Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд һәм Һади Такташ әсәрләрен оста итеп гел яттан сөйләве сокландыра иде. Кайчакларын лекция вакытының дүрттән, яисә өчтән берен диярлек шигырь сөйләүгә бирә. Элektән таныш шигырьләр дә яңа сыйфатларын ачып, башкачарак янгыраган кебек була иде...

Якуб ага лекцияләрендә хәтердә озаграк саклана торган кызыклы, хәтта образлы дип әйтерлек детальләр дә еш була иде. Аларны лектор, гадәттә, лекция тукымасына мул итеп кыстырып барырга тырыша, шунысы белән үз сүзләрен җанландырып җибәрә. Мәсәлән, XX гасыр башында иҗтимагый тормышка көчле тәэсир ясаган, дөресрәге, аның җитәкчесе, бәлки иҗатчысы да булган татар буржуазиясен характерлаган чакта аның яңалыкка ашкынуын, киң дөньяга чыгарга омтылуын, шул ук вакытта үз милли традицияләрен дә сакларга тырышуын болайрак тасвирлаган иде:

—Бу чордагы татар сәүдәгәрләренең кыюлыкларын, Яурупага үзләренчә «тәрәзә ачарга» тырышуларын, шул юнәлештә күп нәрсәләргә ирешүләрен һәрвакыт истә тотарга кирәк. Шул ук вакытта аларның үз гореф-гадәтләренә, милли традицияләренә дә тугрылыклы булып калуларын да онытмыйк. Мәсәлән, Париж кадәр Парижга барып сәүдә иткән татар байлары анда да чын татар булып калырга тырышканнар. Шул теләкләренә ирешкәннәр дә. Яурупаның гел христианлык тәртипләре хөкем сөргән нәкъ уртасында бия симертеп, елкы итеннән казы эшләп, шуны ашап ятканнар. Христианнар өчен ат ите ашауның бөтенләй ят, хәтта тәмам «кыргыйлык» галәмәте икәнлеген белгән хәлдә дә үз теләкләрен үтәгәннәр!

Бу сүзләрдән соң ул горурланган һәм бер үк вакытта кисәткән кыяфәттә имән бармагын югары күтәреп көр тавыш белән әйтте:

—Буржуй-буржуй дигәч тә, безнең татар байлары белән бик шаяртмагыз: алар үзләренчә дөньяны селкетеп яши белгәннәр... Андый көчкә, ихтыярга ия булмасалар, дәүләт, христиан чиркәве тарафыннан хупланмаган, хәтта тыелган шартларда йөзләгән, меңләгән мәктәп-мәдрәсәләр, мәчетләр асрап, үз халкын алга җибәрү чарасын эзләрләр идемени?!.

Шулай әйтеп, аудиториягә сынаулы бер караш ташлап алгач, үзенең әлеге сүзләрен ялгыш аңламасыннар дигәндәй, дөресрәге, политик яктан да «хата» килеп чыкмавын теләгәндәй, сүрәнрәк тавыш белән өстәп куйды:

—Әлбәттә, болай итеп татар буржуазиясе ин элек үзенә эшләргә кирәкле укый-яза белә торган, ягъни белемлерәк хезмәткәрләр, приказчиклар җитештерүне күз унында тоткан. Ләкин моннан ахыр чиктә гади халык, хезмәт ияләре дә файда күргән: андый күзләре ачыграк хезмәткәрләр, приказчиклар капитализмга каршы көрәшкә актив катнашканнар...

Тәнәфес вакытында Якуб аганың янына барып, әлеге Парижда бия симертеп, казы ашап ятуга карата үземнең аңлавымны әйтеп карадым:

—Бәлки ресторанларында дуңгыз ите генә була торган шартларда шулай эшләгәннәрдер?

—Анысы да ихтимал, ләкин ул гына түгел төп сәбәп,—диде Якуб ага һәм челемен суырып куйды.—Татар байлары Яурупа шәһәрләрендә, гадәттә, берәр йәври ресторанлары булган җиргә якынрак фатир табарга тырышканнар, чөнки йәври ресторанында дуңгыз-фәлән булмый. Дуңгыз ите аларда да харам саналган. (Шунысы кызык, 1995 елда, Финляндиядәге татар җәмгыятендә лекцияләр укып йөргәндә, миңа шундый ук сүзләрне кабат ишетергә туры килгән иде. Мәсәлән, Окан Даһирның бабасы да, Яурупадагы зур шәһәрләрдә сәүдә йөрткән вакытларында, таксига утырып: «нах йүдин ресторан» дип кенә әмер бирә торган булган.)

Якуб аганың лекторлык сыйфатлары хакындагы сүзләремне шулайрак йомгаклыйсым килә: XIX гасырның нәкъ соңгы елында туган, XX йөзнең беренче чирегендә үскән, ир-егетлеккә ирешкән, җитлеккән кеше буларак ул шул чорны бик әйбәт белә, шунысы белән башка укытучыларыбыздан нык аерылып тора иде. Яшьли бәхет эзләп күп юлларны таптау, төрле җирләрдә була-була, Пенза якларыннан алып Архангельскига кадәрге araларны узу да, Казанга килгәч, мондагы әдипләрнең, артистларның, галим-голамаларның шактыйларын күреп белү дә аның лекцияләрендә чагылыш таба иде. Шуңа күрә безнең алда китаплардан гына укып белем туплаган «кабинет-бүлмә галиме» түгел, бәлки үз язмышы белән җанлы тарихны гәүдәләндергән шәхес—чорның шаһиты да басып тора иде...

• • •

Якуб ага Агишевның истән чыкмый торган тагын бер сыйфаты бар. Ул—аның гаҗәп ярдәмчел булуы иде. Бигрәк тә кешеләрнең сорауларына, үтенечләренә карата искитмәле дәрәҗәдә игътибарлы булуы.

Сорау, үтенеч дигәч тә, югары уку йортларында эшләүчеләргә күбрәк нинди мәсьәләләрдә мөрәҗәгать итүләре билгеле инде. Аеруча кабул итү имтиханнары бара торган чорларда.

Аспирантурада укыган, аннары яшь укытучы сыйфатында эшли башлаган елларда миңа да кабул итү имтиханнарына катнашырга туры килгәли иде. Менә шул вакытларда Якуб аганың миңа да, теге яки бу егеткә яисә кызга ярдәм кирәк, дип мөрәҗәгать итүе булгалады. Ел саен диярлек. Сирәк-мирәк булса да үзенең төп ватаны булган Пенза ягы кешеләренең балалары өчен дә сорый. Казандагы танышлары, дус-иптәшләре өчен дә килә иде.

Менә шундый «дус-иш» баласы өчен сораган бер очракта мин бераз каршылык күрсәтү (бәлки үземнең «бәямне күтәрү») теләге белән:

—Ата-анасы сорый дигәч тә... Болай эшләп авыллардан килә торган сәләтле яшьләрнең юлларын кисәбез түгелме соң?—дидем «важный» кыяфәт белән.

Якуб ага ирен читләрен кыегайтып, елмайган сыманрак итте дә, сораудан һөҗүмгә үк күчте:

—Үзенчә гаделлек сакларга телисеңме? Әллә сораучылар бер мин генәме? Башка укытучылар да шундый ук үтенечләрне алмыйлармыни? Аларга игътибар булганда калганнарына игътибар кирәкмимени?! Бу—бер. Икенчедән, шуны да онытма: мин ата-аналарын, әби-бабайларын яхшы белгән ышанычлы кешеләр өчен сорыйм. Агачы ничек, алмасы шундый. Ә авылдан килүчеләрнең сәләтләре болай да узачак. Аларның узулары сезнең үзегез өчен кирәгрәк. Мин бит боларын «тәгәрәтегез», минекен генә алыгыз дип әйтмим бит, бары игътибарлы булуыгызны гына сорыйм. Юкса бит махсус «батырасыз». Аңлыйм, дүрт-биш кешедән бары берсен генә сайлап алырга булгач, ике-өчен махсус төшереп калдыру кирәк була. Юри генә батырмагыз дип әйтүем...—аннары боерык биргән төсле кырыс рәвештә өстәп куйды.—Ярар, телеңә күп салынып утырма, әйткәнне онытма!

Аның кешеләргә ярдәм итүенең ихласлыгында бернинди шигем юк иде минем. Һәм ышанып әйтә алам ки, мондый арадашчылыгы бернинди матди мәнфәгатьләргә бәйле түгел иде. Гомумән ул елларда, соңгы чорның ямьсез күренешләреннән үзгә буларак, укуга керү өчен күрсәтелгән ярдәм (дөресрәге «игътибарлылык») өчен ала торган «әҗер» ихлас рәхмәттән ары узмый иде. Гәрчә монысы да үзенә күрә беркадәре тәртип бозу булса да...

Икенче юлы, бер якташының Пенза ягыннан килгән «оныкасы» өчен ярдәм сораган чакта, мин Якуб агага башка яктанрак килеп «бәйләнергә», дөресрәге, бераз шаяртып алырга теләдем:

—Кайчан булса да бетәрме соң бу пинзәкләр?..

Якуб ага гәүдәсен турайта төшеп миңа өстән генә карады:

—Ничә пинзәкне укырга керттең соң?!. Моңарчы бер генә кызый керүгә катнаштың түгелме? Аннары күпсенмә син: читтәге татарлар килүдән бөтенләй туктасалар, синең үз гомереңдә кыска булачак!.. Туктале, син үзең дә читтән килгән кеше түгелме соң?!.

Авызым ябылды, әлбәттә.

Ирексездән исемә бер әңгәмәләшеп утырган чакта аның ачыргаланып әйткән сүзләре төште: «Егерменче гасыр башы иҗтимагый тормышыбызның бер мөһим үзенчәлеге төрле җирләрдә, чит өлкәләрдә яшәүче татарларның Казанга тартылуында иде. Алар монда тупланып, кулга-кул тотынышып дигәндәй, элегрәк кризис кичереп торган татар культурасын, әдәбиятын кузгатып, алга таба этеп җибәргәннәр иде. Әйтик, башкорт якларыннан Галимҗан Ибраһимов, Мирхәйдәр Фәйзи, Себердән Габдерәшит Ибраһимов, безнең Мишәрстаннан Заһир Бигиев, Шәриф Камал, Һади Такташ, Фәхрелислам Агиев, Кәрим Тинчурин, ниһаять, Гадел Кутуй, Кави Нәҗмиләр... Әгәр төптәнрәк уйлап карасак, Тукай булып Тукайның үзе дә, сабый чакта ук моннан китеп, Җаек якларында ир җиткән, шагыйрь булып формалашкан, шуннан соң гына Казанга кайткан кеше бит!.. Менә шулай килүчеләр, кайтучылар күбәю аркасында татарның «каны яңарды». Нәтиҗәдә яңа әдәбиятыбыз гөрләп үсте, бай матбугатыбыз, театр сәнгатебез туды. Туктале, әтрафлырак фикер йөртсәң, әлеге саналган исемнәрне сызып ташласак, бик ярлыланып, бөтенләй үк өтекләнеп калабыз түгелме соң?!. Кызганычка каршы, соңгы вакытларда андый килүчеләр азая, сирәгәя бара. Нәтиҗәсе дә күзгә күренә башлады инде. «Казан арты, Казан арты» дип шапырынулар басып китте хәзер дөньяны. Татар бер Казан арты, бер Татарстан гына түгел ул!..»

Шулай итеп, Якуб аганың «Казанга читтән килүче татар яшьләренә карата игътибар кирәк» дигән фикере минем аңыма нык кына сеңеп калды. Шуңа күрә имтихан вакытларында кемнең кайдан килүе хакында да белешергә тырыштым. Ректоратта эшләгәндә дә чит өлкәләрдән килүчеләргә карата деканат тарафыннан игътибарлык таләп итүне онытмадым.

Дөрес, читтән килеп безнең факультетка имтихан бирүчеләрнең нигездә рус мәктәпләреннән чыккан яшьләр булуы мәсьәләне бераз кыенлаштырып җибәрә иде. Мәсьәләгә шушы яктан караганда, үзебезнең Казанда рус мәктәпләрен тәмамлаучы һәм татар факультетына керергә теләүчеләр дә шулай ук игътибарга

лаек булып чыгалар түгелме соң?..

Якуб аганың «кан янарту» хакындагы сүзләре дә, образлы тәгъбир рәвешендәрәк әйтелгән булса да, мәгънәле һәм дөрес иде. Аның хакта уйлануны һаман дәвам итәм.

Кешеләр җәмгыяте өчен дә зарур бу канун-законның кайбер күргәзмәле мисаллары да күз алдында. Әйтик, хәзерге безнең авыллардагы сарыкларга күз салыгыз. Бигрәк тә көтүдәге берле-ярылы тәкәләренә. Мөгезләре урак кадәрле, бот араларындагы хикмәтле «капчыклары» җиргә үк тию дәрәҗәсендә. Ләкин үзләренең буйлары мәчедән чак кына зуррак, әйбәт эттән кечерәк. Менә шундый тәкә кисәкләре үзләренең «апа-сеңелләренә», хәтта тудырган үз аналарына да менеп атланып нәсел орлыгы сиптерәләр...

Мин Тянь-Шань тауларында малчылык белән көн күрүче күчмән казакъларның, монголларның көтүләрен искә төшерәм. Аларның куй тәкәләре көзгә таба үсә төшкән бозаулар, хәтта кечерәк таналар кадәре булалар иде. Һәрхәлдә, унике-унөч яшьлек үсмер малай чакларыбызда андый тәкәләргә атланып уйнарга ярата идек. Үзебезне егып, аннары сөзеп көтүдән куганга кадәр...

Күчмәнлектә яшәүче малчы халыклар да нәсел өчен тәкәләрне үз көтүләрендәге бәрәннәрдән калдырмыйлар. Бәлки сайланган бәрәннәрне башка көтүләрдән алмашып алалар. Шул рәвешчә көтүләрдә кан янарып тора. Өстәвенә алар сарык һәм кәҗә тәкәләрен җәйләрен аерым көтәләр, бары кара көздә генә өергә кушалар. Бездәге сыман ел тәүлегенә «уйнашка» юл куймыйлар. Димәк, бездә мондый сәнгать тәмам онытыла язган икән.

Бер карауга бары җан-җанварлар өчен генә хас булып тоелган мондый гомум биологик канун кешелек җәмгыятендә дә бәхәссез көчкә ия. Күпчелек халыкларда якын кардәшләр арасында өйләнешүне хупламау, хәтта тыю гадәтләре шул канунның танылуы. Үз кавемнәре эчендә генә йомылып яшәргә мәҗбүр ителгән, шуңа күрә үзара өйләнешеп яшәгән кечкенә диаспораларның дүрт-биш буыннан соң сүнеп югала барулары да шул канунннан килеп чыга торган күренеш, нәтиҗә.

Халыкларга хас рухи дөньяларының, мәдәни традицияләренең дә үзләренчә «каннары» була. Шартлы рәвештә аны этник-милли мәнфәгать һәм тарихи традиция белән чагыштырырга (бәлки «дип әйтергә» дә) мөмкиндер. Йомылган кавемнәрнең мәнфәгатьләре тарая, ваклана, традицияләре дә ярлылана, саега, тәмам корый.

Кавемнең үзе дә бетүгә таба йөз тота...

Димәк, җыеп әйткәндә, Якуб ага тарафыннан «кан янару» хакында узып барышлый гына әйтелгән фикер—буш сүз, матур образ гына түгел икән.

• • •

Кешеләргә Якуб ага күрсәтә торган ярдәмнең—бары киң күңеллектән, ихлас теләктәшлектән килүен раслый торган тагын бер фактка тукталу артык булмастыр. Аны мина шул вакыйганың сәбәпчесе үзе сөйләгән иде.

Татар бүлеген әйбәт тәмамлаган бер егетне аспирантурага тәкъдим итәләр. Ләкин ул елларда Мәскәүдән тамчылап кына бирелә торган урыннарның аз булуы, җитмәве аркасында егетебез туган авылына кайтып китәргә мәҗбүр була. Анда ул бераз мәктәптә укыткалый, күбрәк комбайнда эшли...

Икенче елны, урак өсте кызган көннәрнең берсендә, егет исеменә аспирантурага керер өчен имтиханга чакырган телеграмма килеп төшә. Ашыгыч рәвештә Казанга юнәлгән егетнең кайбер документлары җитеп бетми. Мәсәлән, эшләгән җиреннән тиешле характеристикасы булмый. Бу факт соңгы имтиханны бирәсе көнне генә ачыклана. Егетне имтиханга кертмиләр. Шул ук көнне Мәскәүгә җибәреләсе исемлектән аны сызып та ташлаган булалар. Егет тагын авылга кайтып китәргә туры килә дигән фикер белән коридорда уйланып торганда, әллә кайдан Якуб ага килеп чыга. Мәсьәләне аңлауга ук ул, егетне ияртеп, туп-туры ректор бүлмәсенә керә.

Мәсьәләнең сәбәбен ишеткән ректор, алдында кул куяр өчен әзерләнгән, Мәскәүгә китәчәк исемлеккә карап ала һәм документ булу үтәлергә тиешле кагыйдә икәнлеген әйтә.

—Бар андый документ!—ди Якуб ага һәм егеткә дәшә.—Әйдә, күрсәт кулларыңны!

Сарырак чәчле, ак тәнле егетнең мазут-солярка сеңүдән каралып беткән учларына ишарәләп, доцент Агишев өстәп куя:

—Комбайннан төшеп, ашыгыч килү аркасында характеристикасын алырга өлгермәгән ул.

Ректор Михаил Тихонович Нужин бер әлеге каралып беткән кулларга, бер Якуб агага карап тора да, шаркылдап көлеп җибәрә:

—Дәлил ышандырды, Якуб Хәлилович, исемлекне янадан төзетермен. Ә сез, Альберт Яхин, тизрәк барып имтиханыгызны бирегез!

Ректор шунда ук имтихан алучыга күрсәтмә язылган кәгазь кисәген дә тоттыра.

Аспирантураны Альберт Шамил Усманов иҗатына багышланган диссертация белән тәмамлый. Доцент Агишев җитәкчелегендә эшләнгән ул хезмәт нахакка репрессияләнгән әдипнең эшчәнлегенә гадел бәя бирелүгә, мирасы кайтарылуга үз өлешен кертә. Филология фәннәре кандидаты А.Яхин күп еллар «Чаян» журналының баш мөхәррире булып эшли, аннары университетта татар әдәбияты кафедрасына җитәкчелек итә. Соңгы ун-унбиш ел дәвамында ул мәктәпләр өчен әдәбият буенча дәреслекләр язу белән мәшгуль. Укучыларда әдәби әсәр өстендә уйлану, мөстәкыйль фикер йөртү сәләте тәрбияләүне максат итеп куя торган янача язылган дәреслекләр. Беренчедән алып унберенче сыйныфка кадәр икешәр дәреслек, ягъни егерме ике китап чыгарып өлгерде инде ул. Хәзер югары уку йортлары өчен дә әдәбият буенча кулланма язу өстендә эшли.

«Болар өстендә эшләгәндә,—ди Альберт Яхин,—күз алдында гел ике кеше торды: Хатип ага Госман, Якуб ага Агишев. Соңгысының тавышын һаман ишетеп торам кебек тоям үземне!»

Ниһаять, шуны да өстәп куясы килә: Альбертны имтиханга чакырган телеграмманы, кафедра мөдире булмаса да, үзенең җәйге ялда икәнлегенә карамастан, Якуб ага үзе җибәргән икән. Ул, димәк, шулай узган елны университетны бетереп киткән, урын җитмәү аркасында укуын алга таба да дәвам итә алмаган егетне истән чыгармаган!

* * *

Якуб ага ярдәмчелегенең күңелле, хәтта көлкеле дип әйтерлек мисаллары да бар иде. Шулардан берсе.

Совет чорында үз вакытында ук бирелеп тора торган хезмәт хакларын ирләре, әгәр тәүфикълы булсалар, хатыннарына төгәле белән кайтарганнар. Хатыннары исә көн саен иртә белән транспортка һәм көндез ашханәдә бер ашарлык кына акчаны санап биреп ирләрен эшкә озатканнар. Такы-токылы гына эш хакы исәбенә яшәгән гаиләләрдә киң таралган гадәт шундый иде.

Мондый гадәт Агишевлар гаиләсендә дә хөкем сөргән, күрәсең. Ләкин Якуб агабызның хатыны Хәдичә апа исәпкә ала торган (ягъни таныган!) көндәлек чыгымнарыннан тыш өстәмә хаҗәтләре дә булган икән. Ул, мәсәлән, эштән арып кайтышлый, берәр кафега кереп, ничектер «эконом иткән» акчасына бокалы өч кенә сум тора торган арзанлы кызыл шәрабтән берне йотып, шулай җылынып кына кайтырга ярата торган була. Тик кайбер вакытларда анлык та акчасы калмаса, ул бурычка алып торгалаган.

Студентлар да акчаны шулай кысып тоту юлын тапканнар икән. Мәсәлән, бер бүлмәдә яшәүче дүрт студент стипендияләрен бергә кушып, арада эчми, тәмәке тартмый торган берәрсенә тапшырганнар. Аңар көндәлек ипи, ярма, чәй-шикәр, ара-тирә кильки консервасы алу кебек бурыч та йөкләнгән. Менә шундый «хәзинәче» егетләрнең берсе Якуб ага белән якынрак аралашкан, аның ышанычын казанган. Шуңа күрә бокал өчен акчасы үзендә калмаган чакларда Якуб ага әлеге егеттән бурычка алып торгалаган. Анысын да ул үзенчә башкарган: егетнең янына килеп сүзсез-нисез генә өч бармагын күрсәткән, янәсе өч сум кирәк. Егет тә берсүзсез өч саргылт берлекне, яки бер яшькелт өчлекне (Хрущев сумнары!) әкрен генә картның кесәсенә шудырган. Мондый әҗәт тәртипле рәвештә кайтарылып торды, диде бу хикәяне миңа сөйләүче каләмдәшем.

Әмма бер көнне Якуб аганың өч бармак күрсәтүе хикәяченең тәмам «банкрот булган», ипи алырлык та тиеннәре калмаган, стипендия исә ике көннән соң гына тиячәк вакытына туры килә. «Хәзинәче» шуны әйтүгә Якуб ага: «Шунда тор»,—дип китеп бара. Дүрт-биш минут та узмый, ышанмады микән, үпкәләде микән, дип аптырашта торган егетебез янына тагын килеп чыга Якуб ага һәм әкрен генә аның кулына егерме сум тоттырып: «Ашагыз, әҗәткә түгел, шаулама!»—дип китеп тә бара.

Күрәсең, кафедрага кереп, берәр укытучыдан оялмаслык дәрәҗәдә зуррак күләмдә әҗәт алып, шуннан ач студентларга да мул итеп өлеш чыгарган икән шәраб яратучы карт...

* * *

Якуб ага ярдәмнәре җимешен мин үзем дә муллап татыган идем. Моның бер мисалын «Шура» журналына төзелгән библиографик күрсәткеч язмышында да күрергә мөмкин.

Монарчы бер кат язып чыкканымча, студент елларында ук (1959-1963), Әбрар Кәримуллинның «котыртуы» буенча, «Шура» журналында басылган материалларның тулы күрсәткечен төзегән идем. Эш процессында мина, әлбәттә, кайбер укытучылар, бигрәк тә чорны әйбәт белгән Якуб ага белән әллә ничә кат очрашырга, киңәшергә туры килгән иде.

Күрсәткечнең сайланма өлешен һәм кереш мәкаләнең текстын машинкада бастыргач, соңгы фикерләрен белер өчен кульязманы берничә укытучыга, җөмләдән Якуб агага да бирдем. Өч-дүрт көн узгач ул:

—Укып утырам, әйбәт кенә бара хәзергә. Иркенләп сөйләшер өчен өйгә килерсең,—диде.

Аларның Каюм Насыйри урамындагы фатирларында монарчы да берничә кат булганым бар иде. Билгеләнгән көнне килдем. Мин керүгә үк Якуб ага җәмәгатенә дәште:

—Хәдичә, чәеңне, пәрәмәчләреңне бирсәң дә була.

Бер-ике чынаяк чәйдән соң:

—Кульязманны төгәл карап чыктым,—диде Якуб ага, чынаягын этебрәк куйды.—Әйбәт кенә нәрсә килеп чыккан икән. Риза казый турындагы сүзләреннән, фикерләреннән канәгать калдым. Мин дә аны төрле яклап мактауга лаек кеше дип исәплим. Маладис, һәрхәлдә! Ләкин бүгенгә сүзне артык куертып тормыйм. Дөресен әйткәндә, син «Шура»ны хәзер миннән әйбәт беләсең инде: һәр мәкаләсен, тышлык битләрендәге игъланнарына кадәр укып чыккансың икән. Ә мин нәрсә? Соңгы елларда аерым мәкаләләрне генә караганым бар. Яшь чакларда укыганнарның күбесе онытылган инде. Заманында аны без чиратлашып укый идек. Библиографияне караганда кайберләрен искә дә төшереп утырдым. Тик күбесе онытылган икән... Шуңа да сүзне куертмыйм дип әйтүем. Дөрес, синең мәкаләңдә миңа ошап җитмәгән төшләре дә бар. Син кайбер фикерләреңне әйткәндә, бигрәк тә кайберәүләргә дәгъва белдергәндә, артык катгый рәвештә хөкем чыгарасың. Алай ярамый, улым, башкаларны үзеңә дошман ясарга ашыкма. Андыйлар син тырышмасаң да җитәрлек булыр. Фикереңне әйт әйтүен, тик башкаларга да урын калдыр. Хәй карт әйтмешли, арадан башкалар да узып китәрлек булсын... Кульязманың кырыйларында андый төшләрен күрсәтә бардым. Шуларны игътибар белән укып төзәтеп чык. Килештекме?

Мин ризалык белдереп баш иэдем. Канәгать булган Якуб ага шкафтан бер шәраб шешәсе алып, ике рюмка да китерде. Гаҗәпләнүдән күзләрен зуррак ачып караган Хәдичә апа:

—Нишләвең бу, Йакып, оныкаң тикле бала белән чудит итмә инде!..—дип куйды.

Ә ул, чукраграк карчыгы алдында гафу үтенгән сыман елмаеп катырак тавыш белән:

—Ярар, анасы, ачуланма инде. Бу егет зур эш башкарган бит, шуны бер билгеләп алырга кирәк!—диде.

Чәй-мәйләр шул рәвешчә тәмам булып, китәргә дип кузгала башлагач, Якуб ага бераз туктап торырга кушты, икенче бүлмәгә кереп китте. Аннан журнал сыманрак

зур форматтагы бер китап алып чыкты. Мин шунда ук танып алдым. Бу—Исмәгыйль Рәминең «Татар вакытлы матбугаты» дигән мәгълүм альбом-китабы иде. Сирәк очрый торган әйбер. Аның белән мин кулъязмалар бүлегендә танышкан, шунда җентекләп укып чыккан идем.

—Мә, истәлек булсын үзеңә. Миңа караганда сиңа күбрәк кирәк булыр ул.

—Сакланып калган икән!—дидем мин сокланып.

—Очраклы гына сакланып калды монысы,—диде Якуб ага,—бик күбен үзем үк яндырган идем...

—Ничек үзегез?..

—37 елны, әнә алып китәләр, менә алып китәләр, дип, төн саен энкебеды кешеләрен көтеп яшәгән көннәрдә. Гаеп тагар өчен өстәмә дәлилләр булмасын дип, элекке китап-журналларны яндырырга туры килде шул. Ике көн яндырдым. Хәтта кызудан галанка миче ярылып чыккан иде... Һи, нәрсәләр генә юк иде элек миндә!.. Монысын бераү алып торган булган, соңра астыртын гына кайтарып биргән иде үземә... Ярар, файдасын гына күр!

Түбәм күккә җитәрдәй булып сөендем әлеге бүләк өчен. Шәхси китапханәмдәге иң кадерле китапларның берсе булыр дип уйладым. Тик...

Моннан соң дүрт-биш ел узып, үзем дә укытучы булып эшли башлаган елларның берсе иде. Яз айларының ахыры, җәйнең башы икәнлеген әле дә яхшы хәтерлим. Университет ишегалдындагы (дөресрәге иске китапханә артындагы) бүлмәбезгә бераз арыган, тыннары кысыла төшкән Якуб ага килеп керде. Исәнлек-саулык сорашып бераз утыргач, сулышы да басыла төшкәч, әлеге альбомны сорады:

—Бер әйбәт дус кешенең оныкасы быел аспирантура бетерәсе, кандидатлык минимумын тапшырасы икән. Шуңа кирәк иде ул китап. Сорап бабасы үзе килгән бит. Беразга биреп тор инде. Эш беткәч үзем үк кайтарырмын.

Бирдем, әлбәттә. Күп тә узмый үзем бер командировкага китеп бардым. Аннан кайтуга археографик экспедициягә юнәлдем. Җәйге тәгътилләр дә узды. Көзен Якуб аганың чирләп хастаханәгә эләгүен, аннан туберкулезларны дәвалый торган махсус шифаханәгә озатылуын ишеттем. Альбом турында уйларлык та түгел иде.

Шулай итеп, Хуҗа әйтмешли, ничек килгән булса, шулай ук китеп тә барды әлеге кадерле китап.

* * *

«Шура» библиографиясенә килгәндә, аның сайланма вариантын тулысынча хуплаган Якуб ага—ике җаваплы редакторның берсе (икенчесе доцент Әнвәр Әфләтунов иде)—әлеге чәйдән соң атна-ун көн узгач мине ияртеп, гыйльми эшләр буенча проректор профессор Мансур Абдрахманов янына алып керде. Анда Якуб ага гына сөйләде, әлбәттә. Проректор мәсьәлә хакында игътибар белән тыңлады. Эшнең нәрсәдән гыйбарәт, нәрсәгә терәлеп калуын аңлагач (аның Якуб аганы чын-чынлап ихтирам итүе ачык күренеп тора иде), ул сүзне гадәтенчә кыска тотты. Нәтиҗәдә күрсәткечнең сайланма өлешен аерым китап итеп бастырып чыгару мәсьәләсе хәл ителде, ягъни планга кертеләчәк булды. Өстәвенә нәшрият белән төзүче арасында махсус килешү төзелү һәм беркадәре гонорар да түләнү хакында күрсәтмә дә бирелде. Шулай итеп, мәсьәлә бик җиңел хәл ителде диярлек.

Мин ректораттан канатланган сыман очынып чыктым, әлбәттә. Якуб ага да канәгать иде. Тик...

Корректурасы да килгән китапның язмышы кискен борылышка дучар булды: махсус күрсәтмә нигезендә корректура сүтелде, бу хакта уйлау да «башка вакытларга» калдырылды...

Күңелсез хәбәр ишетелүнең икенче көнендә коридорда очраган Якуб ага «нишләргә дә белмим инде!» дигән төсле, сүзсез генә кул учларын җәеп, иреннәрен кыса төшеп, мәгънәле рәвештә башын чайкап торды. Күзләре әллә ничек моңлы иде аның.

1963 елда булган иде бу хәл. Элегрәк Сталин төчкерүеннән һушларын җуя торган, аннары Хрущев җикеренүеннән калтырап яшәүче өлкә комитеты түрәләренең сач урынына баш та ала торган заманнары иде шул.

Кыскасы, журнал үзе чыгып 45-50 ел узгач кына төзелгән библиографик күрсәткечнең сайланма өлеше дә шулай «корсакта килеш буып» үтерелгән иде. Бары типографик хаталар белән чуарланган корректураның ике нөсхәсе генә торып калган иде. Берсе—китапханәдәге кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә, икенчесе—үземнең архивымда.

Бу күрсәткечнең һәм күңелсез, һәм көлкеле дип әйтерлек гыйбрәтле язмышы хакында тәфсиллерәк мәгълүматны аның 2000 елда чыккан тулы вариантындагы кереш мәкаләдән табарга мөмкин (кабат басмасы «Гасырдан-гасырга» исемле китапның 416-431 битләрендә).

Менә шулай сайланма варианты сүтелеп, тагын 40 ел узгач кына Раиф Мәрданов белән бергә чыгарган тулы күрсәткечтәге кереш сүземдә мин хезмәтне 1950-1960 елларда Казан университетының татар бүлегендә укыткан бер төркем остазларның якты истәлекләренә багышладым.

Исемлек «һәрвакыт яшьләргә хәерхаһ булган Якуб Агишев» белән башлана...

* * *

Тулаем алганда, Якуб ага илгәзәк табигатьле, ягъни ачык күңелле, башкаларга карата һәрвакытта диярлек теләктәшлектә булучы, бер сүз белән әйткәндә, чын хәерхаһ кеше иде. Шул ук вакытта аның холкына кызып китү, хәтта кинәт дөрләп кабыну, андый чакларда дуамалрак гамәлләр, хәтта тупаслык күрсәтү дә ят түгел иде. Менә, ихтимал, аның даими туры сүзлеге, фикерләрен ярып әйтү гадәте дә җирлек булгандыр. Холкының мондый сыйфаты аның пенсия яше тулгач кафедрада артык озак эшли алмавының да бер сәбәбе иде бугай.

Студентлар үзен бик яраткан, үзе дә шундый ук хискә ия булган укытучы кешенең эштән шулай «иртәрәк» китүенең тагын бер сәбәбе дә бар шикелле. Монысы, минемчә, кафедра мөдире Хатип ага Госманга бәйлерәк иде. Чөнки үзенчә көчле характерга ия кафедра мөдиренең баш бирмәүчән холыклы кешеләрне бик үк өнәп бетермәве билгеле иде. Аларның һәр икесе табигатьләре буенча бер-берсенә охшамаган, хәтта антогонистик рухтагы шәхесләр иде. Бер үк вакытта икесе дә үзләренә хас ихтирамга лаек әйбәт сыйфатларга ия, ягъни һәр икесе дә үзләренчә матур, гүзәл затлар иде (Хатип ага турында аерым сөйләргә дә кирәк булыр әле).

Якуб ага холкының әлеге дуамалрак үзенчәлекләрен күрсәтә торган мисалларга мөрәҗәгать итүне урынлы табам. Ләкин мин монда аның холкының «тискәре» якларын «фаш итү»не максат итеп куймыйм, юк (кемнең генә шәхси кимчелекләре булмас!). Бәлки болай итү аның үзе тап булгалаган шундый мизгелләрдә үзен ничегрәк сизүен, ничегрәк тотуын күрү өчен дә кирәктер дип уйлыйм.

Бер мәсьәлә буенча киңәшү теләге белән, алдан телефонда килешеп, икенче көнне кичкырын өйләренә бардым. Ул шактый кәефсез кыяфәттә, хәтта бөтенләй караңгы дип әйтерлек чырай белән утыра иде. «Авырыйсыз бугай, бәлки башка вакытта килермен»,—дип гафу үтенеп, чыгып китәргә дә уйлаган идем.

—Юк, утыр!—диде ул кырт кисеп. Бераз сүзсез утыргач, кулын бер селтәп әйтеп куйды.—Әй шунда, кәефем бик кырылды әле бүген. Обкомга барган идем. Теге элекке шәкертем (исемен генә атады) янына. Бер өметле яшь галимгә ярдәм күрсәтүен сорар өчен. Кердем керүен, утырдым. Бераүгә шундыйрак ярдәм кирәк иде, дидем. Тик әлеге егетнең исем-фамилиясен генә әйтә алмыйм бит шунда—онытты м! Тел очында гына әйләнә үзе. Тик әйтә генә алмыйм. Тирләп тә чыктым!.. Ә ул, җүнсез, ачы елмаеп, «исемен дә белмәгән кешегә адвокат булып йөрисең икән», димәсенме!.. Җеннәрем чыкты, сикереп тордым да: «Минем яшькә җиткәч, карарбыз әле, үзең ничек булырсың икән!»—дип, ишекне шарт ябып чыгып та киттем. Ә ул артык мәшәкатьтән котылуын сизгәндәй елмаеп кала бирде... Уңмадым шәкертләрдән, уңмадым... Вакытында аның үзенә дә мин ярдәм кулын сузмаган булсам... Уңмадым шул...

—Шәкертләрегез бер ул гына түгел бит,—дидем аны юатырга теләгән төсле.

—Шулаен шулай, ләкин иң өметлесе, иң югары дәрәҗәгә ирешкәне шул иде бит. Болай булгач, калганнарыннан ни өмет!..—дип, бер каләре вакыт башын иеп утырды.

Шулай кәеф кырылу сәбәбен сөйләп алгач, эче бераз бушады бугай, алай юк нәрсәдән кызып китүенең сәбәбен дә үзенчә тапты шикелле:

—Обкомга барганчы ук кәефем кырылган иде кырылуын. Тагын шул исерек Рөстәм килеп ачуландырган иде...

Картның ачуланып әлеге шәкертенә бәреп әйткән сүзләре фәрештәнең амин дигән мизгеленә туры килгән икән, күрәсең. Әлеге түрәнең үзе дә, житмешләрдән узгач, тәмам маразымга батты, кәнәфиенә ябышып ятса да, эшли алмаслык хәлгә калды...

Икенче бер вакыйга да характерлы.

* * *

Жәвад Алмаз дигән укытучыбыз татар әдәбиятының иң борынгы катламнарына кереп, әйтик, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабын җентекләп өйрәнә башлаган галим иде. Истәлекнең яңа кульязмаларын табып, текстның басма вариантка кермәгән сыйфатларын ачып, җитди рәвештә сүз әйтү мөмкинлекләренә ирешә барган кеше иде ул.

Ләкин анын шулай тирәннән казынуы һәм башка мәсьәләләр буенча да «иреклерәк» рухтагы сүзләр ычкындыргалавы рәсми даирәләргә ошап бетмәгән, күрәсең. Аның соңгы елларда гына Ташкәнт якларыннан килгән булуы, ягъни «килмешәклеге дә», ихтимал, билгеле роль уйнагандыр.

Жәвад Алмазның оригиналь фикер йөртүгә сәләтле кеше булып, кайчакларын шактый кыю сүзләр дә әйтү гадәте чыннан да бар иде. Беренче курста аның җитәкчелегендә «Кыйссаи Йосыф» дастанының бер кульязма күчермәсе буенча курс эше язганлыктан, янына консультациягә барган чакларда, миңа да ишетергә туры килә иде кыю-кыю фикерләрне. Башка студентлар да шулай турысын әйтә торган сыйфаты өчен аны яраталар, хөрмәт итәләр иде, минемчә. Һәрхәлдә, югарыдагы оешмалардан андый теле артык озын вә «шөбһәле» кешене «укыту-тәрбия эшләреннән читләштерү кирәклеге» хакында махсус күрсәтмәләр булганлыгы бик тиз расланды.

Бәйләнер, җәзалар, ягъни эштән куар өчен сәбәбе дә табылды. Кырык яшьлек тол ир кешенең бер студент кызга гашыйк булуы, аңар өйләнергә теләге барлыгын белдерүе җитә калды шунда. Китте җыелышлар оештырып бәйләнүләр. Әйтерсең лә, хатынсыз укытучыларның үз студентларына өйләнүләре, яки студентларның укытучыга гашыйк булу фактлары бер дә булмаган төсле!

Шул вакытта бүлектәге партия оешмасы секретаре булып торган кешенең активлыгы күзгә ап-ачык күренеп тора иде. Моңарчы Жәвад Алмаз янына кергәләп йөргән, анардан вак-төяк бүләкләр дә алгалаган кызыйга басым ясап, махсус чыгыш ясарга әзерләүләре хакында студентлар арасында чыш-пыш сүзләр дә ишетелгәләгән иде. Башка укытучыларның уйга батулары, борчылулары фонында әлеге активлык аерата ачык сизелде.

Ә уйланулар, борчылулар нигезсез түгел: Жәвад Алмазның җәзалануы белән бергә «Кыйссаи Йосыф» китабының өйрәнелүе туктала, димәк, язма культурабыз тарихы өчен мөһим бер тема да ябыла дигән сүз иде. Кыскасы, татар әдәбияты, язма культурасы тарихы, вакытлыча булса да, зур югалту, чын әзерлекле белгече китү алдында тора иде. Күпчелек укытучылар, яшь белгечләр нигездә менә шундый фикердә булдылар.

Килеп чыккан вәзгыятьне иң авыр кичергән кешеләрнең берсе, һичшиксез, Якуб ага иде. Жәвад Алмаз эштән сөрелеп, бераз вакыт узып тынычлана төшкәч, ул өлкә комитетына махсус барып аны якларга, аңа башка җирдән берәр эш бирүләрен сорарга ният кыла. Шул рәвешчә кирәкле белгечне дә, ул эшли торган теманы да Казанда саклап булмасмы дип өметләнә. Алдан яхшылап киңәшеп, килешеп куяр өчен Казаннан бөтенләй китәргә җыенып йөргән Жәвад Алмазны үз янына чакырта.

Авыр хәлдә калуыннан нык ачыргаланган һәм үзен бөтенләй гаепсез дип санаган, шуңа күрә бер университетка гына түгел, хәтта бөтен Казанга үпкәләгән Жәвад

Алмаз, сүз башлануга, кайнап торган гасабыйлыгын тыя алмыйча: «Сез барыгыз да сволочьлар»,—дип әйтеп сала. Сискәнеп киткән Якуб ага, гаҗәпләнгән төстә: «Мин дәме?»—дип сорый. Үзен әхлаксызлыкта (аморальлектә!) «фаш итү» җыелышында мәсьәләнең «серен», ягъни процесс технологиясе сәбәпләрен белгән, хәтта утызынчы еллар «җиле» исүеннән котлары чыккан укытучыларның үзен яклап бер сүз дә әйтә алмауларыннан хәтере калган, тәмам рәнҗегән Җәвад Алмаз: «Әйе, син дә!»—дип җавап бирә. Якуб аганың «җененә килеп тия» бу бер генә сүз. Ул корт чаккан кебек сикереп тора да: «Алайса ник килдең монда? Ник килдең?! Кит моннан! Бар, чык!»—дип, үзе чакырган кешене үзе үк куып та чыгара.

—Тыелып кала алмадым бит шунда! Ә теге җүнсез, әдәпсез фәлән дә...—дип сүгенеп үк җибәрде Якуб ага, аннары борчылуының төп сәбәбен дә әйтте.—Аның җүнсезлеге, әдәпсезлеге аркасында мин дә әдәбиятыбызның, культурабызның дошманына әверелдем бит! Юкса бит обкомга барып, Фикрәтнең үзенә үк кереп, саклап кала алган булыр идем аны. Табеев бит обкомга кадәр безнең университетта эшләгән кеше. Мине әйбәт белә, хөрмәт итә. Күптән түгел бер очрашканда яныма ук килеп кулын биреп күреште, хәлләремне сорашты. Мин үтенсәм, архивтан, китап палатасыннан булса да, берәр урын табып бирер иде ул... Хәзер инде утыз җиденче ел түгел ләбаса!..

Утызҗиденчеләрне болай телгә алу Якуб агада, башкалардан үзгә буларак, гомумән сирәк очрый иде. Репрессияләрне телгә алу белән кәефе кырыла, үз кәефен үзе кырмас өчен, минемчә, алар хакында сөйләшергә дә теләми иде ул.

Әлеге сүзләрдән соң Якуб ага беркадәр вакыт башын түбән иеп, идәндәге әллә нинди ноктага төбәлеп утырды. Ул чын-чынлап, ихлас күңелдән борчыла, көенә иде.

—Хәзер бездә «Йосыф китабын» аның шикелле нечкәлекләренә кереп өйрәнә алырлык кеше калмады бит инде. Тиз генә булмас та андый кеше. Аның гарәпчәсе дә, фарсычасы да, үзбәкчә белән иске төркичәсе дә бергә иде... Ә «Йосыф китабы» ул әллә ничә буын татарны әдәп-әхлакка өйрәткән, аларда зәвык хисе тәрбияләгән бөек китап ул!..

—Бәлки тагын чакырырсыз үзен...—дидем мин, мәсьәләне җүнләп белмәгән килеш.

Якуб ага өметсез рәвештә кулын гына селтәде:

—Юк шул инде... Бераз тынычлангач, кичә, эзләтеп караган идем үзен. Өченче көнне үк Ташкәнт ягына китеп барган икән...

Җәвад Алмазның лингвистик яктан әзерлекле, күп телләр белүе хакындагы сүзләр нигезле иде. Үзе яки нәселе Сембер якларыннан чыккан булса да, яшьлек чоры һәм күп гомере Урта Азиядә узган иде аның. Шуңа күрә табигый рәвештә үзбәк һәм таҗик телләрен үзләштергән бу кешегә гарәпчәдән дә төпле белем алу мөмкинлеге туа.

Икенче дөнья сугышы тәмамлану чорында, мәгълүм булганча, Берләшкән милләтләр оешмасын оештырган чакта, Советлар Союзы бу оешмага СССР составындагы союздаш республикаларны да кертү ниятендә була. Урта Азия республикалары өчен әлеге оешмада эшләрлек кадрлар әзерләү буенча да тиешле чаралар күрелә. Мәсәлән, гарәпчә һәм инглизчә яхшы сөйләшә алырлык белгечләр әзерләү өчен махсус төркемнәр оештыралар. Бу эшкә Ленинград ориенталистларын да җәлеп итеп укыта да башлыйлар. Ялгышмасам, монарчы да югары юридик белеме булган Җәвад Алмаз да, үзе кат-кат әйткәнчә, шундый сайланган төркемгә эләгә. «Телне тирәнтен үзләштерер өчен шарт дип Коръән текстын ятлаттылар»,—дип искә ала иде ул.

Ләкин Украина һәм Белорусиядән башка союздаш республикаларны БМОга кертү насыйп булмый.

Җәвад Алмазның тагын бер сүзе истә калган: «Берара диннәрнең фәлсәфәсе белән кызыксынып, шул тема буенча Ташкәнттә шактый бай әдәбият—тәгәл бер китапханә туплаган идем. Беркөнне энкебеде кешеләре килеп төяп алып киттеләр аны. Үземне дә шактый вакыт интектерделәр...»

Моннан соң Казанга килеп, тел белеме буенча аспирантура уза ул. Ялгышмасам, профессор Латыйф Җәләй җитәкчелегендә. Илленче елларда Казан университетында безгә гарәп теле буенча дәресләр биргән һәм шартлатып дигәндәй Казаннан сөрелгән (1961), белемен кирәкле урында файдалана алмыйча Ташкәнт якларында эшсез тинтерәп йөреп дөньядан киткән (1976) Җәвад Алмаз менә шундый катлаулы язмышлы кеше иде.

Димәк, Якуб аганың борчулы сүзләре нигезле булган икән.

* * *

Әле тасвирланган хәлләрдән күренгәнчә, Якуб аганың холкында үзенә генә хас кытыршылыклар булса да, ул гомумән, бая гына әйткәнемчә, сүзнең чын мәгънәсендә илгәзәк, кешеләр белән тиз һәм матур аралашучан, төгәлрәк әйткәндә, күңелле итеп аралаша белүчән шәхес иде. Башкаларның күңелен күрү аның үзе өчен дә күңелле иде, минемчә. Шундый үзенчәлеген күрсәтә торган бер сәфәр һаман хәтердә саклана.

1962 елның җәендә Казакъстаннан әти белән әниебез килгән иде. Киленнәрен, кодагый-кодачаларын күреп, Казанда бераз кунак булгач, бергә-бергә Уфа—Салават якларына барырга ният кылдык. Төп теләк—Үзәк Азиянең сахраларында гына гомерләре узган картларга кодрәтле Идел-Чулман дәрьяларын, гел җырланган серле «ямьле Агыйдел буйларын» күрсәтү иде. Әтиебезнең Салаваттагы күптән күрешмәгән апасын күрергә дә теләге бар икән. Шулай ук үзебез өчен дә бераз сонгарган туй сәяхәте булыр дидек. Шул ният белән билет алырга дип елга портына бардым. Һәм Якуб аганы очраттым. Ул да Уфага җыена икән. Көлешә-көлешә бер пароходка билетлар алдык.

Каюталарга урнашып, ак пароходыбыз кузгалып китүгә үк, Якуб аганы туганнарым белән таныштыра башладым. Әти-әниебез белән ул ихтирам саклап тәкәллефле рәвештә күрешеп чыкты. Хатыным Салисәне, исемен әйтеп, тәкъдим иткәч:

—Салисә, салисәтөн, сөләсә, сөләсәтөн,—дип гарәп теле дәреслекләрендәге мәгълүм күнекмәне кабатлады[1] һәм әтиебезгә карап әйтте,—Аллага шөкер, киленегез үзебезнең халыктан, хәтта безнең үк кавемнән икән. Бәрәкалла!

Узган елны көзен дә ул, коридорда очрашкач, миннән турыдан ярып сораган иде:

—Өйләнгәнсең икән дип ишеттем. Кемгә? Кәләшең үзебезнең халыктанмы диюем?

Мин җавапны шаяртыбрак биргән идем:

—Хәтта үзегезнең мишәрдән үк!

Шуннан соң гына Якуб ага «бәрәкалла» дип котлаган иде. Ул минем шул шаяртуымны да онытмаган булып чыкты. Һәрхәлдә, моннан соң ул Салисәгә карата гарәпчә исемнең «сөләсә» вариантын күбрәк куллана иде: «Сөләсә киленнең хәле ничек?.. Сөләсәңә дә сәлам әйт» һ.б. Шуны ул пароходта барганда ук башлап җибәрде: «Сөләсә кызым, чәй пешереп җибәрсәң иде...»

Мондыйрак шаяртуның яңа танышлар арасында булуы, табигый ки, рәсмилеккә, тәкәллефкә баштан ук урын калдырмаган иде.

Якуб аганың да, әтиебезнең дә күңелләре булсын дип, мин Казанда ук җинел шәраблардан берничә шешә алган идем. Сәфәр башлануны һәм танышлыкны «юыйк» дип, берсен өстәлгә чыгарып куйдым. Канәгать булган картларның күзләре ялтырады.

Өстәл янында төп сорашучы, төп сөйләшүче, әлбәттә, Якуб ага булды. Ерак бабалардан алып бүгенге оныкларга кадәр сорашып утырды ул. Шаяртып та алгалады. Бераз вакыт шулай каютада гына гөрләшеп утыргач, палубага чыктык. Якуб ага элек Иделнең кайлардан ничегрәк агуы, хәзер исә аның кинлеге никадәрле икәнлеге хакында тәфсилләп сөйләп барды.

---

[1] Салисә—өченчегә, сөләсә—өчәрләп дигән мәгънәгә туры килә. Бу исем дә, Вахидә (беренче), Сания (икенче), Рабигъә (дүртенче), Халисә (бишенче) кебек, гадәттә балаларның туу тәртибе буенча бирелгәнгә охшый.

Бер ара, «әйдәгез, сезнең ише чүл дөяләренә кызык булыр» дип, әти белән әнине пароход буенча «экскурсиягә» алып китте. Кечкенә генә пароходны өч палубасына, трюмына кадәр карап чыктылар.

Картларның чын-чынлап хозурланулары музыкаль салонда башланды. Без кергәндә анда бер яшь чибәр ханым пианинода татар көйләрен уйнап утыра иде. Якуб аганың танышы да булып чыкты үзе: мәгълүм гарәпчә-фарсыча алынмалар сүзлегенең авторларыннан Касыйм Хәмзиннең кызы Гөлнара туташ икән.

Җыйнак салонның түрендә торган, ак чехол белән тышланган диванга барып утырган Якуб ага безнең картларны да үз янына чакырып алды. Дүрт-биш көй уйнаганнан соң беркадәре арыган Гөлнара туташ, бармакларын угалап, китәр өчен урыныннан тора башлаган иде, диванда байларча җәелеп утырган Якуб ага аның тагын уйнавын сорарга тотынды. Беркадәре әмер биргәнчә дә итеп, шул ук вакытта матур, тәмле сүзләр белән мактый-мактый, кул-аягына аның саулык, тазалык телители үтенде ул. Карыша алмады Гөлнара, тагын уйный башлады. Халык җырларыннан соң композиторларның әсәрләре яңгырады. Якуб ага Салих Сәйдәшев җырларын башкаруны сорады. Алар яңгыраган чакта ул әллә ничек монаеп, башын түбән игән, күзләрен йомган хәлдә уйга батып утырды. (Мин соңрак кына башка кешеләрдән аның үз заманында Салих Сәйдәшев белән якыннан аралашкан дус булганлыгы турында ишеткән идем).

Мин ул кичәдә үзебезнең картларның ничек утыруларына, һәр көйне ничегрәк тыңлауларына күбрәк игътибар итәргә тырыштым. Бу үзешчән экспромт концерт Якуб ага өчен асылда хәтер яңарту гына иде. Әмма монарчы андый тамашаны бары кино һәм телевизорларда гына аз-маз күргән «чүл дөяләре» өчен мондый «җанлы» башкару күктән эзләгәнне җирдән табу шикелле чын могҗиза иде. Үзе дә вакыт-вакыт моңлы итеп җырларга ярата торган әниебез күзләрен бер ноктага төбәгән хәлдә уйга калган. Әтинең исә чак кына ачылган авызы һәр көйнең буеннан-буена кадәр ябылмый диярлек. Бер көйдән икенчесенә күчкән арада гына ул, беленер-беленмәс елмайган чырай белән, бер Якуб агага, бер үз карчыгына карап ала иде. Аннары тагын алга таба омтыла төшеп, яртылаш ачык авызын йоммаган килеш, уйнаучыга карап хәрәкәтсез кала...

Ниһаять, тәмам арыган Гөлнараның куллары салынып төште, «зинһар, җибәрегез инде» дигән сыманрак ул Якуб ага ягына ялварулы кыяфәт белән карап торды. Йокысыннан уянып киткән төсле айнып алган Якуб ага сикереп торып Гөлнараның янына барды. Аның бер кулын алып тәкәллефле рәвештә бармакларыннан үпте, пышылдап кына рәхмәтләрен әйтте. Чын артистларча матур килеп чыкты картның бу эше. Мондый ук реакцияне көтмәгән Гөлнараның йөзләре алсуланып китте. Үзе тиз-тиз атлап китеп тә барды...

* * *

Иртәгесен картлар белән минем арада бер кечкенә конфликт кисәге чыга язды.

Ресторанннан иртәнге ризыкны ашап чыккач, бүген дә күңелле генә йөрсеннәр дип, картларны тагын шәраб белән сыйладым. Берәр чынаяк кына салдым. Ләкин төшке ашка барганда әтинең шактый әлҗе-мәлҗе килүенә, Якуб аганың исә кирәгеннән артык әсәрләнгән, әтәчләнгән кыяфәтенә игътибар иттем. Үзләренә шул да җитә калган икән, дип нәтиҗә чыгардым. Картларча хәлсезлектер, күрәсең, моннан соң чынаякны тутырмыйчарак салырга кирәк булыр, дип тә уйладым.

Ресторанга кергәч, Якуб ага официантны урынсызрак шелтәләп алды. Күрше өстәлдәге бер рус егетнең «Чо без конца калякаете?» дигән сүзләренә тозлап, борычлап җавап бирергә тотынды. Әрепләшүгә миңа да катнашырга туры килә язды.

Төштән соң карасам, әтиебез тәмам мәлҗеп ятакка ауган, Якуб агабыз исә һаман палубада шаулап йөри иде. Өстерәп дигәндәй каютасына кертеп, түшәгенә яткыздым.

Бары кичке чәйгә чыкканда гына алар бераз нормальрәк хәлгә килгәннәр иде. Шуңа күрә шелтә белән рәк:

—Болай бер чынаяктан гына исерә торган булгач, шәраб эчүне туктатырга кирәк! Башка кешеләрдән, Гөлнарадан да оят бит!—дидем.

Әйттем әйтүен, ләкин үзем Якуб аганың күтәрелеп бәрелүен, хәтта кирәгемне үк бирә башлавын көткән идем. Тик реакция бөтенләй киресенчә булды. Якуб ага ике учын да күтәреп, тәмам килешкән, буйсынган кыяфәт белән:

—Ярар, ярар, башка бирмә, эчмибез. Чыннан да ямьсез килеп чыга икән. Эчмибез бүтән! Шулай бит, Габделәхәт? Әйе, эчмибез башка...—диде.

Мин җинел сулап куйдым: Аллага шөкер, көтелгән конфликт шома гына узып китте.

Бу кичнең дә бер өлешен музыкаль салонда уздырдык. Якуб ага көндезен бик арыгангамы, Гөлнараны артык җәфаламады, өч-дүрт көйдән соң рәхмәтләр әйтеп, чыгып китәр өчен аңардан рөхсәт тә сораган булды. Тәмам артистланды «баудан ычкына язган» картыбыз!

* * *

Иртәгесен уянсак, Агыйделгә кергәнбез икән. Дөнья манзарасы бөтенләй үзгәргән Идел һәм Кама-Чулманнан үзгә буларак, монда җир, елганың ярлары тәмам якынайган иде. Агачлары, үлән-куаклары да кул җитәрлек җирдә генә. Чәчәкләренә кадәр ап-ачык! Вакыт-вакыт тугайларда көтүләр күренә. Чалгы тоткан кешеләр дә очрый. Кизәнеп-кизәнеп печән чабалар. Чалгы кайрауларына кадәр күренә. Кайберләре кулларын изәп сәламләп калалар...

Искә ирексездән бала чакта дәреслектән укыган, шуннан ятлап алган бер шигырьнең аерым юллары төшә; аларны кабатлыйм:

*Идел буйларында киң болында*
*Җылкыларың утлый чабында.*
*Оҗмахларың торсын бер ягында,*
*Шул болында йөргән чагында...*
*Ары башта шунда бер тугайда*
*Тезелеп кенә печән чабалар;*
*Чаба торгач алар туктыйлар да,*
*Моңландырып чалгы җаныйлар...*

—Карәле, Фазыл Туйкинны да беләсең икән, кайдан укыдың?—диде Якуб ага.

—Голҗадагы татар мәктәбе өчен утызынчы елларда чыгарылган «Туган тел» дәреслегеннән. Мәктәптә укыган чакта ятлаган идек. Калган өлешләрен оныткамын... Ә Фазыл Туйкин кем соң ул?

—Фольклорчы галим, шагыйрь кеше дә иде. 1937 елда харап иттеләр үзен...

* * *

Әңгәмәнең күңелсезрәк якка кереп китүен теләмәде шикелле Якуб ага: «Әйдәгез, күләгәрәк җиргә барып утырыйк»,—дип, палубаның кояш төшми торган җиренә алып китте барыбызны. Тал чыбыкларыннан үрелгән кәнәфиләргә җайлашкач, ул элекке Пенза ягы авылларындагы гореф-гадәтләр хакында көлкеле һәм гыйбрәтле хәлләрне сөйли башлады. Төрле йолалар турында сөйләгәндә җыр-такмазалардан мисаллар китерә, аларны көлкелерәк итәр өчен мишәрчә әйтелештә янгырата. Безнең картлар аңламаган диалектал сүзләрне әдәби телгә күчереп бирергә дә онытмый. Шул рәвешчә, ул гомерләре чит халыклар арасында узган, үзе әйтмешли, «чүл дөяләре» ише кунакларның белемнәрен дә арттыра, күңелләрен дә күтәрә иде.

Кайбер очракларда кызыклылык өчен аның «шыттырып», ягъни арттырыбрак җибәрүе дә мина сизелеп тора иде. Хикәянең андый төшләрендә «син дәшмә әле» дигән сыман, миңа карап күзләрен кысып куйгалый. Шунда ук мәзәк-анекдотларны кыстырып, аларны реаль тормышта булган хәл кебегрәк тәкъдим итәргә дә өлгерә. Аның кайсы авылда булганлыгын да «күрсәтергә» онытмый.

Бигрәк тә Якуб ага шәкерт чакларын яратып хикәя итә иде. Мәдрәсә ятагындагы уеннар, шаярулар хакында сөйләгәндә хикәя аерата җанлы килеп чыга иде.

Монарчы исләре китеп тыңлап утырган әниебез:

— Карагыз әле, Якуб агай, кайда, ничек ашап-эчә идегез соң?—дип сорады.

—Үзебез пешерә идек, чиратлашып. Дөресрәге, зуррак малайлар пешерә, ә без ярдәм итәбез,—дип җавап бирде хикәяче һәм, тыңлаучыларның шулай игътибар итүләреннән канәгать булган хәлдә, хикәясен тагын да «бизәп җибәрергә» теләде.— Ашарга бик тиз әзерләү әмәлен дә белә идек. Мәсәлән, күкәй, ягъни йомырка пешерергә кирәк булса, кәрәсин лампасының пыяласы өстенә куя идек үзен. Тиз пешеп чыга иде шунда, учак-мазар ягып, казан асып торасы түгел!

Ләкин нәкъ шул төштә үз гомерендә кәрәсин лампасыннан шактый файдаланган әниебез аның «шыттыруын» тотып алды:

—Алай булмас, Якуб агай,—диде ул тураебрак утырып, җитди төс белән,— лампаның корымы чыгып, куыгы корымлана, өйгә дә начар ис чыга бит алай пыяла очына әйбер куйгач!

Якуб ага сискәнгән кебек бер мәлгә тукталып калды, аннары шаркылдап көлеп җибәрде:

—Карәле, Габделәхәт, мондый сүзгә ышанмый торган хатын белән утыз-кырык ел ничек тора алдың соң?.. Әйдә, киттек, үзебез генә йөрик әле!—дип урыныннан торды һәм өстәп тә куйды.—Дөрес тоттың, Гөлҗиһан сеңлем, безнең үзебезнең дә авызыбыз шулай бер пешкән иде. Шул исемә төште бит әле!..

Мона җавап итеп әни дә көлеп алды:

—Яшьрәк чагымда балага бирәсе сөтне үзем дә шулай «җылытып» лампа куыгын каралткан, аны юам дип шартлаткан идем!

Якуб аганың «үзебез генә йөрик әле» дигән сүзләренең серен төш вакыты җиткәч, дөресрәге ашарга кергәч, аңлагандай булдым: картларның икесе дә ярыйсы гына кызып алган иде. Якуб аганың үз запасы да булган икән, дип уйладым башта.

Кызмачалыклары исә төштән соң тагын да арта төште...

Шулай итеп, мин алып бара торган «тәрбия чаралары» челпәрәмә килгән иде.

Ничек шулай килеп чыгуның сәбәбен Уфага житеп, Якуб ага белән кочаклаша-кочаклаша аерылышкач, дөресрәге, шул көнне үк автобуска утырып Салават ягына юнәлгәч кенә белдем. Дөресрәге, серне әти үзе көлә-көлә сөйләп бирде: мин салып биргән бер чынаякны эчкәннән соң, палубага чыккач, Якуб ага: «Тамакны чылатырга да җитмәде бу! Кытыклап кына куйды. Әйдә, үз көнебезне үзебез күрик әле»,—дип, пароходтагы мөмкинлекләрне белмәгән әтине аскы каттагы буфетка алып төшкән. Шул гадәтләрен көн саен кабатлап торганнар икән.

... Алматыга барган саен картларым гел Якуб аганың хәлен сорашып, сәламнәр әйтергә кушалар, күкәй «пешерү», буфет маҗараларын искә төшереп көлешәләр, ак пароход белән музыкаль кичәләрне сагынып күзләрен яшьләндереп алалар иде.

Инде менә, кырык елдан артык вакыт узгач, ул чакларда үземә гадәти генә кебек тоелган шул сәфәр, шул көннәр искә төшсә, гомеремнең матур мизгелләренең берсе күптән узган икәнлеген аңлап, мин дә елмаю катыш көрсенеп куям...

* * *

Карчыгы Хәдичә апаның үлеп китүе Якуб ага өчен, һичшиксез, тирән хәсрәт, төзәлмәс җәрәхәт булды. Хатыны үзеннән шактыйга олырак, шуңа күрә алданрак картайган булса да, алар, минемчә, соңгы көннәренә кадәр бер-берсен аңлап, хөрмәтләшеп, тату яшәделәр (тормыш булгач, төрле чаклар булгандыр, әлбәттә). Үзара кычкырышып сөйләшүләре дә бер-берсенә ачудан түгел, бәлки һәр икесенең дә, бигрәк тә Хәдичә апаның, колаклары авыраюдан иде. Кайчакларын, без әңгәмәләшеп, киңәшеп утырганда: «Йакып, Йакып, дим, нәк дәшмисең?»—дип килеп керә. Якуб ага исә: «Нәрсә, анасы, нәрсә?»—дип, аңа ишеттерә төшеп җавап бирә, артык сүз әйтеп куймасын дигәндәй, көлә-көлә, бер кадәре алҗый башлаган карчыгын икенче бүлмәгә алып китә иде.

Кайберәүләрнең әйтүләренә караганда, аларның кушылулары да үзенчәлекле булган икән (бу хакта Якуб аганың үземә берәр нәрсә сөйләгәнен хәтерләмим). Коточкыч ытлык, ачлык хөкем сөргән егерме беренче елда булган икән бу хәл.

Ерак җирдән туган якларына җәяүләп кенә кайтып баручы, озакка сузылган

ачлыктан, чирдән тәмам йончып беткән, башка бер адым да атларлык хәле калмаган егет, ягъни Якуб, юл читендә аңын югалтып яткан була. Кайдандыр пар атлы тарантаста кайтып баручы бер ханым—миллионер Дибирдиевләрнең яшьли тол калган кызы Хәдичә—кызганудан әлеге егетне арбасына салып, өенә алып кайта. Дәвалый, ашата-эчертә, тәрбияли, тырыша торгач, аны аякка бастыра. Булдыклы, чибәр генә егетне үзендә эшкә дә калдырганга охшый Хәдичә. Тора-бара алар бер-берсен ошаталар, яратышалар, аннары, табигый, кушылып та куялар. Хәдичәнең беренче иреннән калган улы Абдулланы Якуб үз баласы кебек кабул итә.

Димәк, Хәдичә апаны күмгәндә Якуб ага үзен үлемнән коткарган, аннары баласының анасы булган, илле еллап бергә гомер кичергән иң якын кешесеннән аерылган икән...

Таяк өстенә тукмак дигәндәй, Рөстәм исемле яраткан улының бәхетсезлеге, еш-еш запойга бирелүе, ниһаять, үлеп тә китүе картның тез артларына да, җилкә тамырларына да суга. Элек тә хастаханәләргә эләккәләгән Якуб ага соңгы көнелсез хәбәрне шәһәрдәге туберкулез диспансерында яткан чакта ишетә. Шуннан бер малайны җибәреп хәбәр иткәч, мин дә барып җиттем. Күмәргә нибары җиде-сигез кеше генә килгән иде.

Кабер өстендә елап торган Якуб ага бөтенләй бөрешеп, кечерәеп калган иде. Әбит элегрәк ата кешенең Рөстәмнән, аның киләчәгеннән өмете зурдан иде. Улының математик булуы, доцентлык дәрәҗәсенә ирешүен бик горурланып сөйли иде ул. Анасы үлеп, үзе дә ешрак «авырый» башлаган Рөстәмнең чире көчәйгәннән көчәя, чираттагы запойдан чыга алмый...

* * *

Соңгы мәртәбә Якуб аганы Арча кырындагы алтынчы хастаханәдә күрдем. Бер кешелек тар палатада ята иде ул. Шәһәрдән шактый ерак махсус шифаханәдән китереп салганнар, чире артык көчәеп киткәнгә хастаханәгә күчергәннәр икән.

Үзе мине салкын гына каршылады. Теләмичә генә исәнләшүдән соң шактый вакыт сүзсез калды. Гел тәмәке пыскытып ятты. Бер папиросы бетүгә икенчесен кабызды. Түшәк янындагы тумбасы өстендә унбиш-егерме кап иң арзанлы «Север» папиросы өеме. Карават янындагы түгәрәк савытында исә төберчекләр тау булып өелгән. Минем ни өчен күп тартасыз, дип сорарга теләвемне сизгән төсле әкерен генә әйтеп куйды:

—Яшәүнең мәгънәсе калмады инде, тизрәк китәсе иде...

Димәк, тәмәкене ул үзен агулар, үлемен тизләтер өчен шулай күп тарта икән...

Бер кадәре шулай сүзсез яткач, минем хәлләрем, эшләрем хакында да сорашкан булды. Тик элеккечә кызыксынып түгел, бары формаль рәвештә генә.

Аны бер нәрсә дә хәзер кызыксындырмый иде...

Берәр нәрсә кирәкмиме дигән соравыма башын гына чайкап җавап бирде (алып килгән әйберләремә дә карамады—үзем генә тумбочка эченә куйдым).

Унбиш-егерме минут чамасы шулай гына утыргач, китәргәдер дип ниятләп, кузгала башлаган идем, ул кулы белән ишарәләп утырырга кушты. Әкерен генә сөйли башлады:

—Ашап-эчеп кенә, лекцияләр укып, сөйләп кенә йөрүдән тәм табып, гомерне заяга уздырган икәнмен. Үзеннән соң өметле нәсел, ичмасам, җүнлерәк берәр китап та калмагач... Тукай турындагы бер брошюра гынамы? Дәреслекләр язган да булды... Үзем исән чакта ук искерделәр алар...

Тагын бер папирос алып кабызды. Аны тартып бетергәнче башка дәшмәде. Төберчекне ташлагач кына:

—Ичмасам, истәлекләр дә язмаганмын. Кайларда гына йөрмәдем, кемнәрне генә күрмәдем мин... Барысы да үзем белән бергә китә хәзер. Югала...

Аны юатыр өчен «Юк, Якуб ага..» дип кирәкле сүзне эзли-эзли авызымны ача башлаган идем, ул, чыраен сытып, кулы белән ишарәләп дәшмәскә кушты:

—Кирәкми... Мәгънәсез инде... Ярый, син кайт инде. Бар, артык утырудан мәгънә юк. Бүтән килеп йөрмә. Хуш...

Аптыраган килеш хушлашыр өчен кулымны суздым. Тик ул үзенекен бирмәде, кирәкмәс дигәнне белдереп, учын гына селеккәләп алды:

—Килүең өчен рәхмәт. Башка килмә...

Дүрт-биш көннән соң Хатип ага Госманны очраттым.

—Әле генә Якуб агай янында булган идем,—диде ул күңелсез генә.—Килүемне яратмады. Сөйләшмәде дә... Кечерәеп, куырылып кына калган...

Тагын берничә көннән аның шәһәр тышындагы махсус хастаханәгә озатылуын ишеттек.

Шунда йөрәге тибүдән туктап, күзе дә йомылган икән.

• • •

Соңгы көннәрендә шулай хастаханәдән хастаханәгә сөрелгән картның үз фатирына да сыймыйча интеккәнлегe хакында ишетергә туры килде. Карчыгы үлгәч, иске фатирын тапшырып, җайлырак булмасмы диптерме шунда бер бүлмәле квартирага күчә. Анда асрау рәвешендә янына сыендырган бер кардәш тиешле ятим кыз белән тора. Анысы кияүгә чыгып бәбиләгәч, чирең балага йога дип, авыру картны элек кухняга чыгара, аннары бөтенләй үк өйдән дә кысырыклый башлый...

Шул рәвешчә чир көчәйгәннән көчәя.

Вафаты алдыннан ул «мин үлгәч шушы телефон белән хәбәр итәрсез», дип язып калдырган була. Альберт Яхин телефонын. Ә ул бу вакытта сәфәрдә була. Атна-ун көн узгач кына кайта.

Җәсәдне суыткычтан алалар.

Аны җәйнең эссе бер көнендә, университетта читтән торып укучыларның кызу сессияләре барган вакытта, химик корпусның актлар залыннан чыгардылар. Ул көнне минем өч лекциям бар иде. Тәнәфес вакытында гына залга кереп, аның бәләкәйләнеп калган гәүдәсе алдында башымны бер иеп тагын лекциягә кереп киттем.

Ә халык, бик җайсыз вакыт булуга карамастан, гаҗәп күп җыелган иде аның җеназасына.

Лекция вакытында да, аннан соң да мәрхүмнең «барысы да үзем белән бергә китә» дигән фаҗигале сүзләре колак төбендә яңгырап торган кебек булды. Чөнки хастаханәдән чыккач та, соңрак та Якуб аганың әлеге сүзләре хакында гел уйлаган, аларның фәлсәфи мәгънәләрен эзләгән, барлаган, бер табып, бер югалткан идем.

«Югалту» дигәч тә, минем үземнең дә, кечкенә генә булса да, гаебем бар андый югалтуда. Ул—Якуб ага белә торган кайбер элекке җырларны, халык шигырьләрен, мөнәҗәт кебек әйберләрне үз вакытында язып алмавым.

Арада «Йосыф китабы» калыбында элекке шәкертләр иҗат иткән бер пародия сәнгатьчәлеге белән аерата гыйбрәтле иде, минемчә. Анда Зөләйханың көянтә асып суга барулары, нәрсәгәдер ачуы чыккан Йосыфның көянтә белән аны бәреп егулары тасвирлана иде.

Асылда элекке чор татар тормышы күренешләрен көлкеле пародия алымнары белән гәүдәләндергән юмористик һәм сатирик әсәр иде ул. Аны мәрхүм әйбәт кенә белә иде.

Язып алыйм дигән чакларымда: «Башка берәр вакытта»,—дип, гел артка чигерә барды ул.

Үзем дә нык була белмәгәнмен шул...

Шул рәвешчә, шәкертләр иҗатының бер кызыклы, оригиналь истәлеге дә китеп барды аның белән. Югалды...

Югалтулар бер ул гына микән әле?!.

• • •

Язманы башлаганда үзенә «әлләни тәэсир итмәгән кешеләр дә була» диебрәк әйткән, ләкин шунда ук әлеге сүзләремә карата шик тә белдергән идем. Кулга

каләм алып, уйлана-уйлана кәгазь тырный торгач, әлеге раслауның да, шикләнүнең дә—һәр икесенең дә бер үк вакытта дөреслекне чагылдыруын аңладым. Әйтик, гадәти очрашу-сөйләшүләрдән, аларны аерым-аерым алганда, бер төрлерәк, хосусый факт сыманрак нәтиҗә чыкса, шуларның һәммәсен бергә кушып карасаң, икенчерәк нәтиҗәләрнең, тәэсир дип әйтерлек күренешләрнең булганлыгын тоясың икән. Әйтелгән уй-фикерләрнең, кылынган яисә тормышка ашмый калган гамәлләрнең кабул ителгәнлегенә, яки кире кагылган булуларына карамастан. Чөнки син аларны барыбер хәтерләп калгансың, хәтта онытмыйсың да. Ягъни һәрвакытта диярлек исәпкә аласың. Кабул итсәң дә, кире каксаң да. Мондый күренешләргә карата бездә бик кулай сүз бар—гыйбрәт.

Гыйбрәтле сүз, гыйбрәтле эш, гыйбрәтле күренешләр кебек үк гайрәтле язмышлар да була икән.

Хәтер «китабымның» битләрен актаруга сәбәп булган ике шәхес тә—Якуб ага Агишев белән Габделхәй ага Хисмәтуллин да (бер алар гына түгелдер әле!..)—шундый гыйбрәтле язмышка ия шәхесләр иде, минемчә. Нәрсәләре беләндер бер-берсенә якын торган, шул ук вакытта үзара бөтенләй охшашмаган бу шәхесләрнең язмышларында, әгәр игътибар беләнрәк карасаң, алар яшәгән чорның уртак сыйфатлары да чагылыш таба.



*Хезмәттәшләр арасында. 50нче еллар.*

Берсе үз чорының әшәкелекләреннән көлемсерәп, яисә ачыргаланып сөйләшкәләгәне, икенчесенең исә алар турында искә дә алырга теләмәгәне хәлдә дә.

Аларның гадәт-холыкларын, эш-гамәлләрен, төрлечә бәяләргә, төрлечә нәтиҗә чыгарып, язмышларыннан да төрлечә гыйбрәт алырга мөмкин. Шул ук вакытта бер гыйбрәтнең уртак булуы да бәхәссез сыман.

Ул охшашлык тормыш-язмышның бик үзгәрүчән, ышанычсыз һәм үзенчә «мәкерле» булуыннан гыйбарәт. Моның шулай икәнлеге Хәй аганың шикшөбһәләре белән үзенчә киң карашка дәгъва иткән рәвештә шартларга яраклашуы һәм «хәйләкәрлегеннән дә» сизелә. Якуб ага кичергән катастрофик үзгәрешләрдән исә әлеге «мәкерлек» ап-ачык күренеп тора.

Шул ук вакытта сау-сәламәт чорың, яраткан эшләрең белән, үз кәсебең буенча шөгыльләнә алуыңның вакытлы гына очрак булуы, әмма вакытлы гына булса да, бу якты дөньядагы чорыңда кичергән бәхетле мизгелләрең икәнлеге дә бәхәссездер, әлбәттә...

*2005 ел, август-октябрь,*
*Наратлы, Казан*

# ОРЕНБУРГНЫҢ ФИДАКАРЬ ЗАТЫ

Татар әдәбияты һәм мәдәнияте өлкәсендә тирән эз калдырган күренекле шәхесләргә багышланган эзләнүләре һәм табышлары белән танылды Мәдинә Рәхимкулова. Татар энциклопедик сүзлегендә аның хакында «үз төбәге тарихчысы һәм педагог» дигән билгеләмә теркәлгән. Оренбург өлкәсе татар җәмгыяте эшчәнлегендә иң актив катнашучыларның да берсе иде ул. Аның арабыздан китүенә дә ике ел тулып килә инде. Соңгы айларын ул туган-үскән төбәгеннән бик еракта— Санкт-Петербург каласында, уртанчы баласы Диләрәсе карамагында үткәрде һәм шунда вафат булды.

Мәдинә Фәтхи кызы Рәхимкулова 1916 елда элекке Оренбург губернасының «башкорт ягы» авылларының берсендә мулла гаиләсендә дөньяга килә. Атасы Фәтхи 1924 елда муллалык вазифасын калдырып, мәктәптә укыта башлый. Аның үрнәгендә балалары да укытучы булырга хыялланып үсәләр. Бөек Ватан сугышы алдыннан Мәдинә апа Оренбург педагогия институтының физика-математика факультетына укырга керә. Институтны тәмамлагач ул, 1943—1953 елларда, өлкәнең Мостай районы үзәгендә һәм Оренбург шәһәрендәге татар урта мәктәбендә балалар укыта. 1953—1971 дә Оренбург авыл хуҗалыгы институты студентларына белем бирә. Бер үк вакытта педагогия фәне кандидаты дәрәҗәсе алу өчен хәзерлек эшләренә керешә. Оренбург, Уфа архивларында булып һәм революциягә кадәр нәшер ителгән газета-журнал битләрен тикшереп, шул хезмәте өчен бик күп материал туплый. 1971 елга аның «Революциягә кадәрге Россиядә татар мәктәп-мәдрәсәләрендә фәнни дисциплиналарны укыту» дип исемләнгән зур хезмәте тупланып, галимнәргә тапшырыла. Бу җитди хезмәттә патша чоры татар уку йортларында кулланылган хисап, алгебра, астрономия, физика, география, биология, зоология һәм химия дисциплиналары дәреслекләре, аларның авторлары турында СССР күләмендә беренче мәртәбә әтрафлы материал туплап бирелә. (Ул хезмәтнең бер нөсхәсен автор сиксәненче елларда Казан дәүләт университеты китапханәсенең кульязмалар бүлегенә тапшырды.)

Шушы зур хезмәтен туплаганда Мәдинә апага архив киштәләрендә хәрәкәтсез яткан бик күп документлар, кызыклы язмалар белән танышу насыйп була. Шуларга нигезләнеп ул Казан, Уфа, Оренбург шәһәрләрендә нәшер ителүче газета-журналларга күпсанлы мәкаләләр, очерклар язып тапшыра. Аның Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә багышлап язылган бер мәкаләсе нигезендә минем тарафтан күләмле (52 битле) очерк әзерләнде һәм ул хезмәт икебез исеменнән «Казан утлары» журналында, «Мәдрәсәләрдә китап киштәсе» дип исемләнгән җыентыкта басылып чыкты (Казан, 1992).

М. Рәхимкулова Оренбургта яшәп иҗат иткән олуг шәхесләребезнең тормышын һәм иҗатын барлауга да күп көч куйды, аларның эшчәнлеген күпсанлы мәкалә һәм аерым хезмәтләрендә яктыртты. Аның аеруча яратып һәм олылап искә алган шәхесләреннән Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдинев белән Дәрдемәнд иҗәнлеген билгеләп үтү кирәктер. «Ризаэтдин бине Фахрутдин» исемендәге русча беренче хезмәте 1975 елда Уфада басылган иде. Аерым мәкаләләре төрле елларда татар һәм рус матбугатында дөнья күрделәр. Риза казыйның үз хезмәтләреннән дә берничәсен Мәдинә апа гарәп шрифтыннан кирилицага күчереп, Казан белән Уфа нәшриятләрендә бастырып чыгаруга иреште. Зур күләмле «Җәвамигуль-кәлим шәрхе» (дин белгече Равил Үтәбаев-Кәрими төзәтмә-шәрехләүләре белән) Казанда әүвәл «Иман» (1995), бер елдан соң Татарстан китап нәшриятларында дөнья күрде. «Тәрбияле хатын» китабы шулай ук «Иман» нәшриятында чыкты (1996). Олуг галимнең «Әхмәд бай» китабы әүвәл татар, аннары рус телләрендә Оренбургтагы «Яңа вакыт» газетасы ярдәме белән нәшер ителде (1978, 1995). Оренбургта Риза хәзрәт яшәгән (1906—1918) элекке йорт урынындагы бинага истәлек тактасы куйдыру мәшәкатьләрен үз өстенә алучы да Мәдинә апа Рәхимкулова булды. (Татарстаннан читтәге бер шәһәрдә түгел, Казаныбызның үзендә татар кешесенә андый эшне башкарып чыгуның ничаклы мәшәкатьле булуын күпләребез ишетеп яки укып

беләдер, мөгаен.) Оренбургта Дәрдемәнд гаиләсе 1893—1925 елларда яшәгән йортка истәлек тактасын куюны оештыручыларның да берсе Мәдинә апа булуын әйтеп үтим.

Мәдинә апа белән ире, укытучы Якуб ага Шабакаев Оренбург һәм Ульян өлкәләре картларыннан алтмышлап борынгы җыр язып алалар. Текст һәм ноталары белән ул язмалар һәм аларның кассетага алынган вариантлары Казанда Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре Г. Макаров белән Р. Ягъфәревкә, музыка белгече Й. Исәнбәткә тапшырыла. Шундый ук кассеталарны һәм татар әдәбиятының күренекле вәкилләре иҗатын барлауга багышлы башка язмаларны Мәдинә апа чит илдәге Осло университетына да алып бара (ул уку йортында аның өлкән кызы Динә белән кияве укыталар).

Оренбургта алтмышынчы еллардан бирле татар зыялылары җәмгыяте актив эшли. Ел әйләнәсендә алар шәһәр күләмендә әдәбият, мәдәният кичәләре, әдәби укулар оештырып, татар халкын үз тирәләренә туплап килделәр. 1980 еллар ахырында ул җәмгыять «Туган тел» оешмасы буларак рәсми теркәлде. Аның эшчәнлегендә иң актив катнашучылар арасында М. Рәхимкулова белән Я. Шабакаев булды. Шул җәмгыять тырышлыгы белән туксанынчы еллар башында өлкәдә радио һәм телевидениедән татар телендә тапшырулар оештырылды, «Яңа вакыт» газетасы чыга башлады. Педагогия институтының 1960 елларда ябылган татар-башкорт бүлеге, педагогия училищесе эшли башладылар. Мәдинә апа дистә елга якын шул училищедә укытты. Яхшы билгеләренә укыган берничә укучыны үз исеменнән акчалата бүләкләү тәртибен кертте.

Мәдинә апаның шигырьләр язуын да әйтми китү гөнаһ булыр. Миндә аның шигырь үрнәкләре саклана. Дистә еллар дәвамында ул Дәрдемәнд улы Җәгъфәр Рәмиевнең һәм Төхфәт Ченәкәй-Сәмәвинең шигырьләрен дә аерым дәфтәрләргә туплады. Аларны китап итеп бастыру уе тормышка ашмагач, 1990 еллар ахырында шул дәфтәрләрне дә Казан университеты китапханәсенә җибәргән иде. Казан милли-мәдәни үзәге архивы да аның бай мирасының бер өлешен үзенә алдырды.

Мәдинә Рәхимкулова кебек зыялы милләтпәрвәр шәхесләр кимемәсен иде дигән теләктә калучы

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**

---

## ИГЪТИБАР! КОНКУРС!

### «Яңа дәвер кешесе»

Мең яшьлек башкаласы булган татар дөньясына журналыбызның мен санын бүләк итү һич очраклы хәл түгел, чөнки «Казан утлары» Илебез тарихына, халык язмышына турыдан-туры бәйле.

Үткәнебез меңнәр белән язылды. Яңа меңьеллыкка—яңа дәвергә аяк басуыбызга да әле кайчан гына. Кем ул Яңа дәвер кешесе? Кальбе, яшәеше, кылган гамәлләре нинди? Яңа дәвердә кешелекне нинди могҗизалар көтә? Гел хөрриятккә, үзгәрешкә, муллыкка, үсешкә омтылганда инсаният, әхлак, гаилә, мәхәббәт исән калырмы? Мөхтәрәм язучыларыбызны әлеге проблемалар борчыймы?

Кыскасы, «Казан утлары» журналы, яңа хикәяләргә ачык конкурс игълан итә. «Яңа дәвер кешесе» бәйгесенә килгән хикәяләрнең күләме бер табактан артмаска тиеш.

Җиңүчеләрне акчалата бүләкләр көтә:

**I урынга**—25 мең сум
**II урынга**—15 мең сум (ике бүләк)
**III урынга**—10 мең (өч бүләк)

Хикәяләр 2007 елның декабренә кадәр кабул ителәчәк.

**«Казан утлары» журналы редакциясе**

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***"СӨЛӘЙМАН МӨҺЕРЕ"*** – Сөләйман пәйгамбәр кулындагы Аллаһының күркәм исемнәре язылган мөһерле йөзек. Пәйгамбәр шул тылсымлы хасияткә ия булган йөзеге ярдәмендә диюләр һәм җен-париләрне буйсындыра алган. "Кыйссасел-Әнбия" дә бер диюнең шул йөзекне кулга төшерүе һәм вакытлыча тәхеткә менеп утыруы турында сөйләнә. Тылсымлы йөзекне Сөләйман пәйгамбәргә Әрхәм исемле балык табып кайтарган.

Йөзекнең мөһерендәге гексаграмма бер-берсенә карата 120 градуска борып, берсе өстенә икенчесе салынган тигезкырлы ике өчпочмактан гыйбарәт, ягъни ул алты чатлы йолдызны ("Дауд йолдызы", "Дауд калканы" яки "Магендауд") тәшкил итә. Ривайәтләргә караганда, имештер, Давид Голиафка каршы сугышка шундый алты почмаклы калкан тотып чыккан.

Бу гексаграмма борынгы Кытайда еш очраган "инь-янь" билгесе яки христианнардагы тәре тамгасы кебек үк капма-каршы көчләрнең (*күк* һәм *җир*, *рух* һәм *материя*, *вакыт* һәм *фәза*-суфиларда: *ань* һәм *мәкан*, *аң* һәм *тән* һ.б.) бер-берсенә үтеп керүен символлаштыра.

Алты почмаклы йолдыз Израиль дәүләте байрагында да сурәтләнгән. Хәзерге мөселманнарның бу гексаграммага тискәре мөнәсәбәте шуның белән дә аңлатыла. Ләкин еврейләр әлеге тамганы 1897 елда Бөтендөнья сионистлары оешмасының Базель шәһәрендә җыелган конгрессында гына үз байраклары өчен символ итеп алганнар. Ә 1933 елгы 18 нче конгрессларында ул еврей халкының байрагы сыйфатында кабул ителгән. 1944 елда Англия премьер-министры Уинстон Черчилль аны Фәләстыйнда төзелгән Еврей бригадасының байрагы итеп раслый, аннары, 1948 елның маенда, шушы "Дауд йолдызы" сурәтләнгән байрак Израиль дәүләтенең рәсми байрагы сыйфатында кабул ителә.

***СӨМБЕЛӘ БӘЙРӘМЕ*** *тар.* – Бу бәйрәм көзге көн-төн тигезлеге (21-23 сентябрьләр, фарсыда *михриган*) көннәрендә, ягъни *көзге сәвия* мизгелендә үткәрелгән һәм *Нәүруз бәйрәмен* хәтерләткән. Сары чәчле матур һәм сүзгә җор бер кыз баланы Сөмбелә / Сөнбелә итеп киендергәннәр дә, көзнең ничек киләчәген юрау өчен аңа читләтеп кенә сораулар биргәннәр. Әйтик, әгәр "Чиләкме, чүмечме?" дигән сорауга Сөмбелә-кыз "Чиләк" дип җавап бирсә, көз яңгырлы булыр дип юраганнар. Сөмбеләнең җавабына өлкәннәр дә колак салган, җавабы күңелләренә хуш килсә, алар "Юравың юш килсен" дип хуплап торганнар.

***СӨННӘТЛӘҮ*** *гт.* – Сөннәткә утырту, *хитан* (*г.*). Ир балаларның җенес әгъзасы очындагы тире каплавычны кисеп алудан гыйбарәт. Кайчагында сөннәтләүне дә тәһарәт төренә кертәләр.

Сөннәткә утырту гадәте мөселманнар белән яһүдиләрдә генә түгел, Австралиядә, Полинезия утрауларында, Африкада, Америкада (Мексика) һ.б. төбәк халыкларында да таралган. Мондый йола борынгы Мисырда ук билгеле булган, ягъни аны мөселманнарга гына хас йола дип әйтеп булмый. Эфиопларга бу йола мисырлылардан кергән, яһүдиләр дә аны мисырлылардан алганнар (моны Геродот яза). Гарәпләр ир баланы 6-15 яшьләр арасында сөннәтләгәннәр. Гомумән, сөннәткә бирүдә билгеле бер

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

яшь вә ай юк дип карала. Шулай булса да, балигъ булган вакытка кадәр сөннәтле булу тиешле. Рокыйя Максудның "Ислам" исемле китабында сөннәткә утырту гадәттә *гакыйка йоласы* үткәргән көнне эшләнә, бала зәгыйфь булган очракта бераз вакытка гына кичектереп торырга мөмкин дигән искәрмә бар. Коръәндә сөннәтләү ритуалына карата бернинди күрсәтмә дә юк. Әхмәтһади Максудиның "Шәригать хөкемнәре"ндә "Ир балаларны унынчы яшенә кадәр сөннәткә утырту" сөннәт гамәлләр исәбенә кертелгән. Риваятьләргә караганда, сөннәтләүне беренче булып Ибраһим пәйгамбәр керткән. Ә пәйгамбәрләр туганда ук сөннәтле булып туалар, һәрхәлдә хәдисләрдә шулай диелгән.

М.Б.Пиотровский кайбер мөселман илләрендә Исламга кадәрге йола-кыз балаларны сөннәтләүнең дә сакланганлыгы турында яза.

Сөннәткә утыртылган бала өендә аш үткәрү йоласы да булган (мәс., Себер татарларында һәм Урта Азиядә—*сөннәт туе, угыл туе*). Сөннәт туена килгән кунаклар бала бишеге янына куелган ләнгәзгә (поднос, ләгән) вак акча яки тәм-том салганнар. Мондый туйлар Төркиядә соңгы вакытларга кадәр сакланган.

Таки әд-дин Әхмәд әл-Макризи (1364-1442) үзенең "Каһирә мәхәлләләре һәм ядкярләре турында үгет-нәсихәтләр" китабында Мисыр хәлифәсе солтан Бейбарсның 1264 елда Каһирәдә үзенең улын сөннәтләү уңае белән тантаналы бәйрәм уздыруы турында яза. Солтанның улы белән бергә, 1645 ир баланы да сөннәткә утыртканнар.

Бездә сөннәткә утырту йоласын *сөннәт бабасы* (Себер татарларында-*аптал, аптал бабай*) башкарган, хәзер исә бу еш кына медицина хәзерлеге булган кеше тарафыннан эшләнә һәм, әлбәттә, гигиена таләпләре җиренә җиткереп үтәлә. Ә сөннәтчеләр элек баланы сөннәткә утырткач ярага юкә черегe сибә торган булганнар. Төркиядәге шәһәрләрдә әледән-әле: "Фәнни сөннәтче", "Гигиеналы сөннәтче" дигән игъланнарга тап буласың. Шулай да тикшеренүчеләр хәзерге вакытта башкарыла торган сөннәтләү операциясенең тискәре йогынтылары булу ихтималы турында кисәтәләр. Сөннәткә утырту гомуми наркоз астында эшләнгәнгә күрә, диләр алар, сөннәтләүнең дини йола буларак мәгънәсе җуела, чөнки сөннәткә утыртылучы бала йолада бөтенләй катнашмый... Ул гына да түгел, бу рәвешле үткәрелә торган операция вакытында сабыйлар кыска вакытлы булса да гомуми наркоз тәҗрибәсе алалар, нәтиҗәдә киләчәктә наркотик матдәләр тәэсиренә тотрыклылык бусагасы түбәнәергә дә мөмкин. Моның исә җәмгыятьтә наркоманиянең таралышына шактый йогынты ясау ихтималы бар...

Төрекләр ир баланы күбесенчә 7-12 яшьтә сөннәткә утырталар. Гадәттә моны сентябрь аеның башларында, уку елы башланганчы эшлиләр (Төркиядә мәктәптә укулар 15-20 сентябрьдә башлана). Сөннәтләр алдыннан малайның чәчен алалар, төп догаларны белүен тикшерәләр. Малайга матур костюм кигезәләр, иңбашы аркылы тасма бәйлиләр, аңа "Машалла!" дип язылган була. Шуннан соң малайны атка, дөягә яки арбага утыртып, сөннәтчегә алып баралар. Төрекләрдә һәм көрдләрдә сөннәтләү вакытында малай янында ир кеше була, аның роле исә христианнардагы хач атасы кебегрәк. "*Кивре*" дип атала торган бу кеше яшь мөселманны балигъ булганга тикле үз химаясенә ала.

Ә Казан татарларында, Карл Фукс язганча, ир баланы өч, биш яше тулгач сөннәткә утыртканнар, баланың яше җөп сан (мәс., дүрт, алты кебек) белән күрсәтелгәндә сөннәткә утыртылган бала үлә дигән хорафат яшәп килгән. Ул заманнарда сөннәтче кешегә 50 сумга кадәр акча биргәннәр. Сөннәтләгән вакытта Коръән сүрәсе укылган.

Әстерхан һәм Себер татарларында сөннәт көненә (*сөннәт туе*) ныклап хәзерләнгәннәр. Сөннәткә утыртуны малайга так (1,3,5,7 h.б.) яшь булган елларга туры китергәннәр. Сөннәт туе башкача *сөннәт катымы* (хәтеме, ягъни мөһере) дип тә аталган. Бу көнне угылга яңа кием кидергәннәр, авылдашлары аңа бүләкләр һәм акча биргәннәр, авылда йөгереш һәм көрәш ярышлары, ат чабышлары да уздырылган, җиңүчеләргә киемлек ситсы бүләк иткәннәр.

Сөннәтләүче кирәк мөселман булсын, кирәк башка булсын—аерма юк. Ягъни, гыйлемен белсә, теләсә кем сөннәтләсен—барыбер. "Сөннәтләүчеләр Сөләйман Фарси нәселендән булырга тиешле" дигән сүз асылсыздыр" (Р.Фәхреддин).

Сөннәтчегә акчалата да түләгәннәр, бозау яки сарык бирү гадәте дә булган. Электә аерым нәселләр сөннәтче баба булу хокукларына ия булганнар (мәс., Казанда гомер иткән татар зыялысы Мөхәммәт Хәмитовлар нәселе). Зөя өязендәге Кошман һәм Казан өязендәге Масра авыллары шундый сөннәтчеләр белән дан тоткан.

Сөннәткә утырту йоласына табибларның карашында фикер төрлелеге булса да,

күпчелек тикшеренүчеләр аның әһәмиятен таныйлар. Сөннәтле балаларда күп кенә авыруларның булмавы моннан йөз еллар элек билгеләнгән факт. Кайбер мәгълүматларга караганда, хәтта бума хастасы, истерия һәм паралич авырулары да сөннәткә утыртканнан соң тукталган очраклар бар. 1865 елда ук инде Парижда халыкара конгресс, сифилис белән авыруны кисәтүдә нәтиҗәле чараларның берсе буларак, мәҗбүри рәвештә сөннәтләүне тәкъдим иткән иде. XX гасырда Һиндонезиядә үткәрелгән тикшеренүләр дә бу нәтиҗәне расладылар. Гөмбәчек һәм эренле башка авыруларга карата да шуны ук әйтергә мөмкин. Америка галимнәре хәрби госпитальләрдә 200 мең кешене тикшереп, сөннәткә утыртылмаган кешеләрдә сидек юлларының авырулары 11 тапкыр ешрак очравын ачыклаганнар. Сөннәт йоласы гамәлдә булган халыкларда ирләрнең җенес әгъзасында яман шеш (рак) авыруы очрамый диярлек, хатыннарында да аналык муентыгында бу авыру шактый сирәгрәк күзәтелә. Урта Азия табиблары фикеренчә, ир балаларны сөннәтләү фимоз һәм парафимоз авыруларыннан коткара, сидек юллары ялкынсыну куркынычын кисәтә, сөннәтле балаларда төнлә боелык тотмау дигән нәрсә дә сирәгрәк очрый икән.

Әлбәттә, гигиена таләпләре үтәлмәгән очракларда һәм хәзерлексез кеше тарафыннан сөннәткә утыртылган баланың үлү очраклары да булган. Мәс., заманында Ислам диненә каршы "армый-талмый көрәшкән" атеист Ибраһим Гыйльфановның "Ислам дине турында" дигән китабында Татарстанда Әлмәт районы Нәдер авылында Рәшидә һәм Фоат Миңлебаевлар гаиләсендә булган фаҗига, Лениногорскида яшәүче Сабир Хәйрисламовның бердәнбер улы җиде яшьлек Галимҗанның сөннәтләгәннән соң үлеп китү очрагы Ислам йолаларына каршы мисал итеп китерелгән.

Имештер, сөннәт бабалары, кул арты китмәсен дип, йөзенче баланың әгъзасында кыл калдыралар һәм нәтиҗәдә бала үлә икән дигән сүз дөрес түгел, чөнки берәр сабыйның үлеменә сәбәп булган сөннәтчеләр Кыямәт көнендә мең елга тәмуг утында калдырыла дигән язылмаган канун бар. Мондый "йола" турындагы имеш-мимешләр хәзер дә йөри. Мәс., язучы Р.Батулла бер танылган артистның шундый "йөзенче бала" булып, медицина аркасында гына котылып калганлыгы турында сөйләгән иде, әмма мондый фактны раслый торган дәлилләр юк дип әйтергә кирәк.

Йәһүдиләрдә Муса пәйгамбәр канунын үтәү йөзеннән, Гайсә (Иса) туып сигезенче көнне (1 гыйнварда) аны сөннәткә утырталар һәм исем кушалар. Христианнарда бу көн бәйрәм дип игълан ителгән була һәм апостоллар (йәлавычлар) чорында гына гамәлдән чыгарыла. Ләкин апостол Павелның "Римлыларга хат"ында дүртенче бүлек "христианнар өчен мәҗбүри булган сөннәтләү"гә багышлана әле. XVIII гасыр ахырындагы рус календарьларында да 1 гыйнвар Иисусны сөннәтләү көне буларак ("*Обрезание господне*") билгеләп үтелә. Хәер, бу факт соңгы вакытларда чыккан православие календарьларында да яшерелмәгән.

Иске Васыятьнең "Яшәеш" китабында 17 нче бүлекнең 11-13 нче шигырьләрендә катгый күрсәтмә бар: "Тәнегезнең очындагы тирене кисегез: бу Минем сезгә васыятем булыр. Сезнең каумегездә һәрбер ир җенесендәге сабый бала сөннәтләнсен..." Күрәбез ки, христианнарда Изге Библиядәге ачык күрсәтмә үтәлми икән.

Хәзерге вакытта яһүд табиблары йогынтысында АКШта кайбер христиан малайларын да сөннәтләүләре билгеле. Дөрес, иудаизмның реформачыл агымы тарафдарларында баланы сөннәткә утырту мәҗбүри шарт итеп каралмый.

Бала туып җиденче-сигезенче көндә сөннәтләү йәһүдләргә иярү була дигән фикер шәргый дәлилгә корылмаган. Әгәр табиблар зарар юк дисәләр, җиденче көндә булса да, аннан соң да сөннәтләргә ярый.

Генетикада тышкы йогынтыларның нәселдән бирелмәвен исбатлауче дәлилләрнең берсе итеп мөселманнарда күп гасырлар буена ир балаларны сөннәткә утырту нәтиҗәсе буларак сөннәтле балалар тумауны да китерәләр. Ләкин халыкта кайбер балалар хакында "сөннәтле булып туган" дигән сүзне дә ишетергә туры килә.

Татарда сөннәткә утыртуны "бабага бирү" дигәннәр. Темников (Төмән) якларында сөннәткә утырту йоласын *пике келәве* (*пике*-пәке) дип атыйлар.

Шунысы кызык, Инҗилнең татарчага тәрҗемәсендә сөннәтләү "кистерү" сүзе белән бирелгән. //*Сигез көннән соң, Баланы кистерер вакыт җиткәч, Аны анасы эчендә була башлаганчук фәрештә атаганча, Иисус дип атаганнар.* (Лука, 2:21).

*Дәвамы киләсе саннарда*

# Фирдәвес Гарипова

## АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

### Балтач (Юлсубино)

Балтач (Юлсуба) авылы район үзәге Балык Бистәсеннән 27 чакрымда, тимер юл станциясе Арчадан 70 чакрымда утырган.

Балтач (Юлсуба) авылы байтак тарихи чыганакларда һәм халык авыз иҗатында телгә алына.

Казан ханлыгы чоры авылларын тупланган исемлектә авыл Енсубино (хәзер Юлсубино), Котлы Бүкәш янында, Нугай юлы өстенә урнашкан дип искә алына (Е. И. Чернышев мәгълүматы). XVIII йөздә Балтач авылында 112 ясаклы татар яшәгән. Бу чыганакта авыл исеме Елсубина (Юльсубино), она же Елсова Балтачи дип бирелгән. А. Артемьев җыеп чыгарган авыллар исемлегендә авыл Юльсубина (Балтачи) дип теркәлгән һәм андагы 116 хуҗалыкта 351 ир-ат 385 хатын-кыз яшәве теркәлгән. Авылда бер мәчет булган. И. А. Износков авылны болай сурәтли. Авылдагы 137 хуҗалыкта 463 ир-ат һәм 461 хатын-кыз гомер кичергән, алар ислам дине тотканнар. Халык дуга бөгеп сату белән шөгыльләнгән. 1898 елда басылып чыккан җыентыкта авыл Юлсубино (Балтач) дип бирелә һәм анда 1190 татар кешесе яшәгән.

Авылда беренче мәчет бинасы сакланган.

Мәхәллә рәсми рәвештә XIX гасыр башында теркәлгән. Авылның метрика дәфтәрләре 1830 елдан алып барылган. Чыганаклар буенча мәчетнең 1875 һәм 1905 елларда бина кылынуы мәгълүм. Мәчетнең хәзерге вакытта сакланган кирпеч бинасы 1915 елдан соң Казан өязенең Байчура авылы кешесе Мөхәммәтвәли Сәфәргали улы Вәлитов акчасына төзелгән. Казан губерна идарәсенең төзелеш бүлеге, башта ризалык бирмәсә дә, мәхәллә халкы куелган таләпләрне үтәгәннән соң (төзеләчәк мәчет мәйданы 20 сажинлык арада чистартылган), мөселманнарның үтенечен канәгатьләндергән. 1909 елда беренче мәхәлләдәге 125 хуҗалыкта ир-ат затыннан 442 кеше исәпләнгән.

Руханилар хакында түбәндәге мәгълүматлар бар. 1853 елның 9 мартыннан гыйбадәтләр Габдрахман Габделхәлимов җитәкчелегендә үткәрелгән. Аңа ярдәмчеләр итеп 1871 елның 15 ноябрендә Нуретдин Фәхретдинов (1845 – 1909), ә 1899 елның маенда улы Хуҗахан Габдрахманов (туган елы – 1866) билгеләнгән. 1902 елның гыйнварында Хуҗахан хәзрәт беренче мәхәлләнең имамы, ә 1911 елның гыйнварында имам-хатыйб булып расланган. Хуҗахан Габдрахмановның кызы – күренекле татар шагыйрәсе Зәйнәп Бәширова (1903 – 1984).

Икенче мәчетнең 1887 елда төзелгән бинасы сакланмаган. 1884 елның 3 декабрендә Казан губерна идарәсе раслаган проект буенча бу мәчет 1887 елда төзелгән булган.

Яңа оешкан мәхәлләнең беренче имам-хатыйбы итеп Чистай өязенең Яңа Әмзә авылы (хәзер Татарстанның Октябрь районына керә) кешесе Габдрахман Хәбибуллин билгеләнгән. Ул 1895 елда Мамадыш өязе Усали авылының беренче мәхәлләсенә күчкән, бу урынга Самара губернасы Бөгелмә өязе Әбдекәй авылыннан Мөгаллим Галәветдин улы Шәмсетдинов сайланган.

Өлкән буын авыл исеме барлыкка килү турында болай сөйли.

Берничә балта остасы гаиләләре белән күченеп килеп, бер урынга төпләнергә уйлаганнар. Бу тирәләрдә урман булган һәм анда юкәләр үскән. Ялга туктаган балта осталары умарта кортлары сырып алган юкәләрне күреп, сокलануларын яшерә алмыйча, «тач бал гына икән бу яклар» дип сөйләшкәннәр. Авылның исеме дә халык теленә

*Дәвамы. Башы журналыбызның 6 санында.*

ярашып, Тач балдан Балтачка әйләнгән, имеш. Бу халык уйлап чыгарган этимология. Балтач атамасы төрки халыклар яшәгән урыннарда, Татарстан җирлегендә дә берничә урында очрый. Балтач йә этноним, йә кеше исеме булырга мөмкин.

Юлсубино исеме кайдан килеп чыккан? Анысын кем кушкан?

Шунысы игътибарга лаек, тарихи чыганакларда, Казан ханлыгы чоры авыл атамаларын теркәгән исемлектә авылның беренчел исеме Юлсубино (татарча Юлсуба) дип бирелә. Атама барлыкка килү турында халык телендә йөргән, хәтерендә сакланган фикер болай.

Авылда борын-борыннан бик яхшы җил тегермәне булган, анда он тарту өчен тирә-күрше авыллардан еш килә торган булганнар. Менә бервакыт тегермәнгә дип рус авылыннан берничә кеше юлга чыга. Алар Күгәрчен авылына килеп җитәләр һәм тегермәнле авылга ничек барырга дип сорашалар. Берничә кеше аларга су буйлап дип аңлатып җибәрә. Ә руслар Юлсубино дигән авыл икән бу дип уйлап китәләр. Имеш, шул рәвешле Юлсубино атамасы барлыкка килгән. Бу халык тарафыннан уйлап чыгарылган фикер, халык этимологиясе. Казан ханлыгы чорында искә алынган борынгы Юлсуба авылы нигезләнгәндә, бу тирәләрдә руслар яшәмәгәннәр.

Авыл атамасы авылны нигезләгән йә Юлсуба исемле шәхескә, яисә Юлсуба этнонимына нигезләнгән. Борынгы этнонимнар төрки җирлекләрдә кеше исемнәре булып та ныгып калганнар. Авыл тарихына, авыл атамасына мөнәсәбәтле яңа материаллар авыл исемнәренең, ягъни Юлсуба һәм Балтач атамалары борынгы төркиләрнең, аларның дәвам итүчеләре татарларның тамыры еракка, чал тарихка барып җитүен, һичшиксез, тагын да дәлилли.

Авыл табигате урман-суларга бай, шуның белән матур да. Авыл аша Чошы суы агып үтә, ул Чошы аланыннан башлана. Шарлы суы да авыл эченнән ага. Балан елгасы янында элек-электән баланлык булган. Шуңа нисбәтән елга әлеге исемне алган. Чишмәләр дә шактый күп. Күгәрчен чишмәсе — Күгәрчен авылына бара торган якка урнашкан өчен шулай аталган. Сафа чишмәсен (халык Сапа дип йөртә) шул исемдәге кеше карап торган. Авылда моннан башка тагын Алатай, Изгеләр, Закир бабай, Хөсәен, Күз, Чумар чишмәләре бар. Авылда чишмә-чыганакларга игътибар бик зур. Аларны һәр язда авыл халкы тәрбияләп, чистартып, коймаларын буяп, таш булганнарын агартып, агачлар утыртып торалар.

Авылдагы бер тауның атамасы — Алып бабай чабатасын каккан тау. Авыл халкы Алып бабайны үз авылларының борынгы бабасы дип сөйли. Бу бабай зур гәүдәле булуы белән дә күрәзәчелеге белән дә аерылып торган дип искә алалар. Бервакыт ул, кыр эшләреннән кайтып килгәндә, ял итәргә утыра, чабатасын кага һәм шул урында тау барлыкка килә. Бабай тапкыр һәм зирәк булган. Алып баба белән бәйләнешле авыллар борынгы булалар, бу авыл да — борынгы.

Шарлы тавы дип йөртелә торган тау да авылга ямь өстәп тора. Аю күле түбәсе тавыннан хәтта Чистай җирләре күренә икән. Югарыда әйтеп кителгәнчә, урманда юкә үскән, агачлар баллы булган, аларны аюлар да яраткан. Шул тау янындагы күлдә аюлар су коенган дип сөйлиләр. Хәзер бу күл кипкән, ә тау Аю күле түбәсе дигән исем алып калган.

Каенлык үзәне авыл яныннан башланып урманга кадәр дәвам итә, озынлыгы 2 чакрымнар. Хәзерге вакытта алан җәй көннәрендә үләннәргә һәм төрле матур чәчәкләргә күмелеп балкып тора, аның ике ягы — басу. Элек бу үзәндә шаулап каен агачлары үскән. Ул каеннарны инде кисеп бетергәннәр, ләкин барыбер ул урын чәчелми, ә үзән Каенлык үзәне дип атала...

Күрше Ямаш авылы белән ике арада Шәйхел күпере бар. Элек бу урында күпер булмау сәбәпле юл йөрү бик авыр булган. Шуннан соң авылның Шәйхел исемле бер кешесе:

*Ямаш белән икарада (ике арада)*
*Бар күперсез бер елга,*
*Адашасың да батасың,*
*Күбесенчә шул юлда,—*

дип шигырь чыгарган. Бу шигырьне район гәзитендә дә бастырганнар. Шуннан соң күпер салганнар, ә күпергә Шәйхел исеме ябышып калган.

Урманнарны урманчы исеме белән Әхмәт урманы, Рифат урманы дип атыйлар. Аланнар кем печәнен чаба, кем тәрбияләп тора — шул кеше исеме белән йөртәләр. Юлларның исемнәре түбәндәгечә: Интәркә, Маш янындагы юл, Чаллы юлы, Тегермәнлек юлы.

Авылдагы бер урам исеме игътибарга лаек. Ул — Томски урамы. Шушы урамда яши торган берничә кеше Себергә, Томскига эшкә барып акча эшләп кайта торган булган. Шуңа күрә урам шәһәр исеме белән атала башлаган, имеш.

Авылда хуҗалыклар саны 380 чамасы. Мәктәп унберьеллык, бинасы ике катлы. Мәдәният йорты, балалар бакчасы, китапханә эшли. Авыл тарихын яктырткан музей да булган, ләкин ул таркалган.

Авылга газ кергән, юлларга асфальт түшәлгән.

Авылда изгеләр зираты бар. Түбән оч зиратына авыл халкы мәрхүмнәрне җирли. Халык зиратны карап тора, коймасы нык. Мәетләрне җирләү өчен кирәкле әйберләр тотарга зират эченә яңа йорт салынган.

Ярдәмчесез калган өлкәннәргә халык ярдәм итә.

Элек авылда мәчет һәм мәдрәсә эшләгән. Революциядән соң мәчет манарасы киселгән, ае төшерелгән. Мәчет хәзер эшли. Мәдрәсә дә бар.

Балтач (Юлсуба) авылында хезмәткәр гаиләсендә җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Габдрахман улы Фәйзуллин (1943) туып-үскән. 1990 — 1995 елларда ул Татарстанның Югары Советы депутаты булып сайлана.

## Карадуган

Карадуган авылы Балтач районында, район үзәгеннән 7 чакрым ераклыкта урнашкан.

Карадуган атамасы шактый күп тарихи чыганакларда һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә искә алына.

Е. И. Чернышев мәгълүматларына караганда, бу авыл Казан ханлыгы чорында ук булган. Казан өязе теркәү кенәгәләрендә (1602 — 1603 еллар) Карадуган атамасын очратабыз. А. Артемьев (1866 ел) мәгълүматларына караганда, Карадуган авылындагы (Шушма суы буена утырган) 26 хуҗалыкта ислам дине тота торган 112 ир-ат һәм 132 хатын-кыз яшәгән. Авылда бер мәчет, элемтә станциясе, сөргенгә озату этабы булган. Карадуганда XVIII йөздә, төгәлрәк итеп әйткәндә 1878 елларда 41 йорт исәпләнеп, аларда 133 ир-ат һәм 126 хатын-кыз гомер иткән. Авылда бер агач мәчет, элемтә станциясе, тимерче алачыгы, мәйханә һәм өч ашханә була. И. А. Износков (1885 ел) авыл турында мондый мәгълүмат бирә: «Арбаш суының уң ярына һәм Себер элемтә юлына урнашкан Карадуган авылында ислам диненә өндәүче Искәндәр исемле изге кеше күмелгән. Бу авылга тагын ислам диненә кире кайткан, ә элек керәшен исәпләнгән татарлар яшәгән Ташчишмә пүчинкәсе дә карый. Авылдагы 46 хуҗалыкта 247 ир-ат һәм 237 хатын-кыз исәпләнгән, шуларның 88 ир-аты, 72 хатын-кызы ислам дине тота; 58 ир-ат һәм 57 хатын-кыз исламга кире кайтканнар (элек алар керәшен татарлары булганнар). Ташчишмә пүчинкәсендәге 21 хуҗалыкта исламга кире кайткан 102 ир-ат һәм 106 хатын-кыз яшәгән. Тормыш-көнкүрешләре уртача булган. Халык иген иккән, он тарткан, тимерчелек белән шөгыльләнгән. Авылда элемтә станциясе, 2 ашханә, 2 мәйханә һәм 2 тимерче алачыгы булган. К. П. Берстель җыеп бастырып чыгарган җыентыкта (1908 ел) Карадуганда 549 татар кешесе яшәгәнлеге әйтелә. В. П. Семенов редакциясендә басылып чыккан (1901) күп томлы тарихи чыганакның 5 нче томында авыл искә алына.

Нәҗия Борһанова язуына караганда, Карадуган авылы халкы июнь ае ахырларында күршедәге Арбаш, Югары Кенә, Түбән Кенә, Кенә башы, Таузар, Югары Шубан, Түбән Шубан кешеләре белән Кенә җыены бәйрәм иткән.

Карадуган авылында Мортаза байның 1911 елда салдырган кунакханәсе 1734 номеры белән «Татарстан республикасы: тарих һәм мәдәният һәйкәлләре» дигән китапта теркәлгән.

Карадуган атамасы нәрсә аңлата?

Карадуган – кара һәм дуван сүзләре кушымтасыннан тора. Кара – төс белдерә торган нугай (кыпчак) этнонимы. Этник яктан чыгып караганда, нугайлар ике төркемгә бүленәләр: ак нугайлар һәм кара нугайлар. Телләре дә ак нугай һәм кара нугай диалектларыннан тора. Кара нугайдан кала кара берәмлеге белән түбәндәге этнонимнарны атарга мөмкин булыр иде: каракалпак, каракидан, каракыргыз, кара папахалылар, карабүрекле, таулы карабахлар, каракыпчак, каратабын, кара болгар, карабаганалы, кара сираклы, каратума, каратанып, каракытай, каратаулы, каракалмык, каракойлы, каракөзәк, карачогды һ. б.

В. В. Бартольд фикеренә караганда, төс белдерә торган сүзләр күпчелек очракта җир йөзенең символик рәвештә төс белдерә торган төшенчәләре белән тәңгәл киләләр: кара – төньяк, сары яисә ак – көнбатыш; кызыл – көньяк; күк – көнчыгыш.

Карадуганның дуган өлеше төрки дуван этнонимына барып тоташа. Дуваннар, күрәсең, безнең төбәккә кыпчаклар, аерым алганда нугайлар белән килгәннәр.

Татарстанның Казан арты төбәгенең кайбер сөйләшләрендә иренләшмәгән «а» авазы кулланыла. Диалектолог Н. Б. Борһанова язуына караганда, бу аваз акустик яңгырашы ягыннан нугай төркеменә керә торган төрки телләрнең «а» авазына якын. Ул Казан арты халкы теленә XV – XVI йөздә нугай этносы белән килеп кергән. Татар халкы этногенезына нугай этносы катнашуы турында Миркасыйм Госманов, Әхмәт Булатов, Ләйлә Махмутова, Наҗия Борһанова, Равил Фәхретдинов, Марсель Әхмәтҗанов һәм башка галимнәр язалар.

Дуван этносы күп кенә төрки халыклар килеп чыгышына катнашкан. С. М. Абрамзон мәгълүматларына караганда, дуван этносы кыргызларның черик кабиләләре составында очрый. Галимнәр язуына караганда, дуван кыргызларның чонг-багыш кавем-кабиләләре составында, дувана рәвешендә үзбәк-кураминнар этногенезына, башкортлар формалашуга катнашкан.

Тарихи чыганакларда 1664 елда Казан юлы өстендә Дуван өязе теркәлгән. 1713 елгы документларда Елкичи-Дуваней вотчинасы искә алына. XVIII йөздә Россиядә үткәрелгән Генеральь ызанлау материалларында Уфа өязендә – Дуванай, Бәләбәй өязендә Удельный Дуван, Монастырь Дуваны авыллары барлыгы әйтелә. Элекке Дон гаскәрләре өлкәсендә Дуван авылы һәм аның янында Дуван исемле коры елга теркәлгән. Пермь өлкәсенең Кунгур районында Дуван суы буенда Дуван авылы утырган. Молдованың Чадыр Луган районында Дуван үзәне янында Казаклия Чадыр авылы бар. Элек бу урында нугай авылы Дуан урнашкан булган. Каспий диңгезе ярындагы Карадуван бистәсе – нугайларның элекке башкаласы.

Шулай итеп, дуван кавем-кабиләләре күп кенә төрки халыкларны, шул исәптән татар халкын формалаштыруда да катнашканнар.

Карадуган аксакаллары сөйләвенә караганда, элек авылның бөтен тирә-юне калын урман булган. Авыл халкы якындагы Таузар авылыннан күчеп килеп утырган. Карадуган халкы телендә Урта басу, Коры яисә Чәткәнә, Баклауш (Хәтнә), Миржән су-инешләре, Каракүл исемле атамалар еш кулланыла.

Яңа Дуван (татар), Иске Дуван (чуваш) авыллары Тау ягы төбәгенең Чүпрәле районында да бар. Рус Дуваны авылы да булган, ләкин хәзер ул беткән.

Яңа Дувандагы (1859) 42 йортта 143 ир-ат һәм 158 хатын-кыз, ә Иске Дувандагы 39 йортта 136 ир-ат һәм 138 хатын-кыз яшәгән. Рус Дуванында йортлар саны бары ун булган. Анда 42 ир-ат һәм 45 хатын-кыз исәпләнгән.

Яңа Дуван авылы тирәсе дә географик берәмлекләргә шактый бай. Аның янынннан Чынлы су буе, Кала елгасы, Кураклы, Чик, Ком, Илмәк, Кирәмәт, Багур, Өч кизләү, Каен, Чиялек, Чик һәм башка елгалар ага.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# *Бер сорауга—бер җавап*



***—Без барыбыз да бер «шинель»дән чыкканбыз дигәндәй, Казан Дәүләт университетының 1944 елда ачылган тарих-филология факультеты, аерым алганда, аның татар теле һәм әдәбияты бүлеге безнең мәдәнияткә, әдәбиятка, педагогика һәм фән өлкәсенә күпме талантлы шәхесләр, милли кадрлар әзерләп бирде! 1984 елда җисеме һәм статусы беркадәр үзгәртелсә дә, ул бүгенге көндә дә үзенең шушы тарихи миссиясен уңышлы дәвам итә. Яңа факультет эшчәнлегендә, беренче скрипка буларак, Сез—оештыру һәм педагогика өлкәсендә төпкә җигелеп тартучыларның берсе дисәк, һич тә арттыру булмастыр. Уңышларыгыз һәм хәл итәсе проблемалар хакында берничә сүз әйтсәгез, бүгенге студентлар һәм яшьләргә карата кыскача бәя биреп китсәгез иде…***

**Искәндәр Аяз улы ГЫЙЛӘҖЕВ,** *КДУның татар филологиясе һәм тарихы факультеты деканы, профессор:*

— Әйе, бездә татар теле һәм әдәбияты укытучылары, тел, әдәбият, матбугат, фән белгечләре әзерләнә. Бүгенге көндә факультетта 500 ләп студент һәм 40 ка якын аспирант укый икән—бу инде зур көч, арсенал. Аспирантурага иң актив, сәләтле яшьләрне тартырга тырышабыз. Булачак галимнәр әзерләү—шулай ук зур, мәшәкатьле, матди чыгымнар сорый торган эш. Бире дә хөкүмәтнең ярдәме дә бик кирәкле безгә.

Бүгенге яшьләргә исә бәяне төрле яклап бирергә мөмкин. Әйткәнемчә, тырыш, актив, сәләтле студентлар җитәрлек бездә. Күп нәрсәләр, әлбәттә, яшь кешенең үзеннән дә тора. Үҗәтлек, зур максатлар куеп яшәү, белемгә һәм камиллеккә омтылыш… Шушы сыйфатлар тора-бара үзенең җимешләрен (нәтиҗәсен) бирми калмый бит ул. Аннары, шунысын да әйтеп китик: гадәттә, безнең факультетка яшьләр күбрәк авылдан, район төбәкләреннән килә. Ә авылда, үзегез беләсез, туган тел, гореф-гадәтләр, әхлакый-рухи кыйммәтләр, ни генә әйтсәк тә, чагыштырмача тулырак һәм тазарак хәлдә саклана.

Студент яшьләр арасында юкны бушка аударып, күңел ачып, шәләй-вәләй йөрүчеләр дә юк түгел, билгеле. Тагын бер борчулы нәрсә бар: яшьләрнең билгеле бер өлеше китап укудан бизеп бара. Ә бит безнең халыкта «китап сүзе» дигән бик тә мәгънәле гыйбарә бар. Яхшы, кызыклы, чын художестволы китапларда күпме мәгънә, уй-фикер, хис һәм эстетик байлык катламнары посып ята. Боларны үзең укып, үз йөрәгең аша үткәргәндә генә көчле, белемле, мөстәкыйль фикерле шәхес булып өлгерергә мөмкин.

Безнең стратегия—заман таләпләренә җавап бирердәй югары зәвыклы шәхес тәрбияләү, туган телебез һәм әдәбиятыбызның язмышы, киләчәге өчен җан атардай яңа буын, интеллектуаль көрәшчеләр әзерләү. Шушы бурыч үтәлгәндә генә глобаль киңлеккә, ягъни халыкара масштабларга чыгу, фәнни һәм рухи аралашу, тарихыбыз вә татарлыгыбызны башка халыклар, илләр алдында таныту мөмкинлекләре күбрәк булачак, минемчә.

Туган телне һәм әдәбиятны саклап калу өчен безгә башкалабыз Казанны, тагын да башка шәһәрләребезне татарлаштырырга кирәк. Уртак көч белән, барлык мөмкинлекләр белән! Юкса соңлавыбыз бар. Ата-ана, өйдәге гаилә тәрбиясе дә бик мөһим. Мактану булып яңгырамасын, мәсәлән, әтием Аяз Гыйләҗевнең—танылган язучы, әнием Нәкыянең Казан мәктәпләренең берсендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булуы минем язмышыма бик зур йогынты ясады.

Безне өмет, татарның киләчәге яшәтә. Базда дары бетмәгән әле.

Җәмил
Зәйнуллин

# АМАЗИГЛАР КЕМНӘР АЛАР?

Амазиглар белән беренче тапкыр 1972 елда, Судан республикасында тәрҗемәче булып эшләгән вакытта очраштым. Алар Судан геология оешмасында вакытлыча ялланып жир казу, бораулау, скважиналарга су китерү кебек һ.б. шундыйрак эшләрне башкаралар иде. Совет геологлары, геодезия белгечләре ул елларда Суданның казылма байлыклары картасын төзү белән мәшгуль. Амазигларның гарәп телендә сөйләшә белә торган житәкчеләре бар иде. Барлык боерыкларны ул гына бирә һәм нәрсә эшләргә кирәклекне бик кыска гына итеп аңлата да белә иде. Кичләрен алар үзләре генә җыелышып ашларын ашыйлар, җырларын җырлыйлар. Амазиг булмаган бер генә кешене дә араларына кертмәсләр иде. Ни булса шул булыр дип, бер кичне амазиглар янына бардым һәм аларның җырларын тыңларга рөхсәт сорадым. Башлыклары белән сөйләшкәнне барысы да астан гына карап күзәтеп тора башладылар. Кулымдагы "Сокол" исемле кечкенә радиомны кабыздым да амазигларның башлыгына тоттырдым. Ул үзенең янында урын күрсәтте һәм ике көпшәле итеп камыштан ясалган кыска гына бер уен коралын миңа бүләк итте. Мин аларның җыр-моңнарын озак итеп тыңлап утырдым ул кичне. Бик моңсу иде ул көйләр. Гарәпләр белән бер чүлнең балалары булсалар да һәм тыгыз аралашып яшәсәләр дә, көйләрендә уртаклык тапмадым, хәтта дини эчтәлектәге җырлары да башкача. Шулай итеп, мин амазиглар белән дустанә мөнәсәбәт урнаштыра алдым. Гарәп дуслар мине гел кисәтеп торсалар да, амазигларга ихтирамым ныгый гына барды. Беренчедән—амазиглар тарихын үз халкыбызның тарихи фаҗигасенә охшаттым, икенчедән—курку белмәс, шул ук вакытта эчкерсез, ифрат садә күңелгә ия халык, күзгә туп-туры карап сүзләрен әйтәләр, ярдәмчелләр, соңгы кисәк икмәкне дә мохтаж кеше белән бүлешәләр. Низаглы хәлләр чыкканда да арка яктан һөҗүм итмиләр, күзгә-күз, йөзгә-йөз торып сугышуны артык күрәләр.

Ә хәзер амазигларның тарихына күз салыйк..

Галимнәрнең фаразлавынча, бәрбәриләрнең төньяк Африка җирләренә килеп урнаша башлауларына унбер мең елдан артыграк вакыт узган икән. Бу бик горур халыкның борынгыдан килгән үз исеме—амазиг, ягьни хөр, ирекле кеше. Амазиглар яшәгән җирләрне финикиялеләр, румлылар, вандаллар, византиялеләр, испаннар, итальяннар, төрекләр, французлар басып алган. Географик урыны да менә сәбәпче булгандыр, мөгаен. Чөнки Марокко белән Европаны ундүрт чакрым киңлегендәге Гибралтар (гарәпчә исеме Җәбәл әт-Тарыйк) бугазы гына аерып тора.

Римлылар амазигларны мауруслар, маврлар, ягьни кара тәнлеләр дип атап йөрткән. Бу исем бүгенгәчә сакланып калган. Гәрчә амазиглар ак тәнлеләр расасына керсәләр дә.

Сигезенче гасырның 681 елында гарәпләрнең даңлы каһарманы Окъба бин Нәфигъ, амазиглар илен византиялеләрдән азат итеп, гарәп халифатына кушып куя. Бертуктаусыз үзара сугышып, кан коешып яткан амазиг кабиләләренең күпчелеге үзләре теләп ислам динен кабул итәләр. Ислам дине таркау кабиләләрне берләштерә, мәчет-мәдрәсәләр төзетә һәм иң мөһиме—амазиг халкын юкка чыгудан саклап кала.

Гарәп әмире Муса Ибне Носәйр 705 елда яңа яулап алынган җирләрне мәгъриб исеме белән атап йөртергә дигән әмер чыгара. 808 елда хакимияткә яңа әмир Идрис Икенче килә. Шул елларда Мәгъриб корольлеге оеша башлый һәм XX гасыр башына кадәр бәйсез дәүләт булып яшәп килә.

Бүген амазиглар бүлгәләнгән хәлдә Африканың алты илендә яши: Мароккода, әл-Җәзаирда(Алжир), Мисыр Гарәп Республикасында, Туниста, Мавритания Ислам Республикасында, Ливия Гарәп Халык Җәмаһириясендә.

Бүгенге Марокко корольлегендә амазиглар халыкның 60% тәшкил итсәләр дә, аларның бернинди милли хокуклары юк. Хакимият аларны тизрәк гарәпләштерү сәясәтен алып бара. Амазиглар ана телендә белем алудан мәхрүм ителгән. Амазиг телендә китаплар, газета-журналлар нәшер ителми, радио-телевидение тапшырулары да юк. Бүгенге көндә амазигларның саны 20 миллионнан алып 40 миллионга кадәр дип фаразлана: 50% Мароккода, 30% әл-Җәзаирда, 20% Туниста, Мисырда, Ливиядә. Франциядә 1,2 млн. амазиг яши, шулай ук Бельгия, Голландия, Германия, АКШ, Австралия кебек илләрдә дә амазиг җәмгыятьләре яшәгәнлеге мәгълүм. Бу мәгълүматлар 1997 елда Канар утрауларында узган Бөтендөнья амазиглары конгрессында хәбәр ителә. Бөтендөнья амазиглары конгрессы 1995 елда Франциядә оешкан иде. Ул елларда Марокко хөкүмәте амазиглар турында ишетергә дә теләми иде әле.

Аурупа дәүләтләрендә яшәүче амазиглар арасында сәүдә белән көн күрүчеләр дә, студентлар, язучылар, табиблар, халыкара хокук белгечләре һәм башка бик күп укымышлы кешеләр бар. Алар, кайда гына булсалар да, газиз ватан бер генә була дип, үз ватаннары белән тыгыз элемтәдә яшиләр, анда калган кардәшләренә, туган кабиләләренә һәртөрле ярдәм итеп торалар.

Чит илләрдә белем алып кайткан укымышлы амазиглар милләттәшләренең хокукларын яклаучы көрәшчеләр сафына басалар. Рәсми хакимият амазиг балаларына үз исемнәрен куюны катгый тыя, гарәпчә исемнәрне генә кушарга рөхсәт итә. Амазиглар яшәгән авыл, шәһәр исемнәре дә бары гарәп телендә генә аталып йөртелә. Амазиг мәдәни хәрәкәте оешмалары тарихны укыту китапларын дөрес итеп, хакыйкатьне бозмыйча язуны һәм яңадан бастырып чыгаруны, амазиг-бәрбәр теленә Мароккода рәсми статус бирелүне таләп итәләр. Бүгенге Мароккода гарәп телендә нәшер ителгән тарих китапларында амазиг-бәрбәриләрнең үткәне бары кара төстә генә языла һәм җаһил кавем итеп тасвирлана.

Тагын бер тапкыр тарихка күз салыйк әле. 1912—1956 елларда Марокко Франциянең протектораты хәлендә яшәде. Баскынчылар амазиглар-гарәпләр арасында моңарчы яшәп килгән каршылыкларны бик оста итеп файдаландылар. Менә бер генә мисал: колониаль хакимият махсус хәрби уку йорты ачып укырга амазиг яшьләрен генә алды. Әлбәттә инде укыту француз телендә генә алып барылды. Бу уку йортында амазиг баларын диннәреннән ваз кичтерү өчен барлык мөмкинчелекләр дә тудырылган була. Училищеда саф күңелле, самими табигатьле мөселман амазиг егетләренә төрле өстенлекләр вәгъдә ителә, махсус әзерләнгән миссионерлар аларны ата-бабалары диненнән ваз кичтерәләр. Шулай итеп, хәрби училищедан алар инде христиан динендәге бәрбәри ялчы-офицерлар булып чыгалар. Француз гаскәриләренең өр-яңа хәрби киемен кигән амазиг егетләрен гарәпләр өстеннән күзәтчелек итә торган хәрби җәза төркемнәренә кушалар. Колониаль хакимият моның белән ике җитди проблемадан котыла: беренчесе—гарәпләр-амазиглар арасында яшәп килгән киеренкелекне тагын да катлауландыра, икенчесе—амазиг халкы арасында колонистларга тугрылыклы, үз халкының мәнфәгатенә битараф булган ялчы катлам булдыра, бердәмлекне эчке яктан таркатуга ирешә.

Бүгенге Марокко (гарәпчә Мәгъриб) хакимияте амазиг-бәрбәриләр мәсьәләсен иртәме-соңмы барыбер хәл итәргә тиеш булачак. Батыр йөрәкле бу халык һәртөрле кимсетүләрне, чикләүләрне күп күрде, озак чыдады. Бернәрсә дә бу дөньяда мәңгелек түгел, һәрнәрсәнең бер ахыры-чиге була. Амазиг-бәрбәриләр проблемасы төрле халыкара форумнарда тикшерелә башлады. Аурупа матбугатында да Марокко амазиг-бәрбәриләрнең тулы хокукларын яклап язылган мәкаләләр басылып тора.

Марокконы танып белергә теләгән кеше Дрис Шрәйби хикәяләрен укый ала.

Француз телендә иҗат итүче бу язучы—амазиг-бәрбәри халкының күренекле улы. Ул, горбәтлектә яшәргә мәҗбүр булса да, үз иленең сулышын тоеп, аның кайгы-хәсрәтләрен йөрәге аша уздырып, газиз мәдәниятеннән аерылмыйча иҗат иткән. Дрис Шрәйби әсәрләре гади тел белән язылган, бик җинел укыла. Аның күп кенә хикәяләрен укып, язучының үз язмышын да күзалларга мөмкин. Дрис Шрәйби хикәяләре Марокко матбугатында гарәп телендә бик аз басылган. Аның әсәрләрен туган илләре Марокконы, әл-Җәзаирны, Тунисны калдырып бәхет эзләп Аурупага киткән һәм шунда яшәп калган гади кешеләр яратып укыйлар. Чөнки бу хикәяләрдә аларның караңгы, бәхетсез тормышлары бәян ителә. Дрис Шрәйбинең бер хикәясендә Америка Кушма Штатларыннан килгән бер хәрби кеше гарәп үсмереннән болай дип сорый:

—Син кем, французмы?

Үсмер егет: Юк, дип җавап биргән.

Америкалы: Телен французча, киемен дә аурупача, син соң кайсы кавем баласы?

Үсмер: Мин гарәп.

Америкалы: Гарәп телендә сөйләшүче, гарәпчә киенүче чын гарәп кешесен кайдан табарга була соң?

Үсмер егет: Әнә тегендә, дип ымлап каберлеккә таба күрсәтә...

Мароккодан Дрис Шрәйби, М. Хәйреддин, әл-Җәзаирдан Кәтиб Ясин, Мәүлүд Мәммәри, тунислы Альбер Мемми кебек язучылар гарәп әдәбиятында беренчеләрдән булып тормышка яңача тәнкыйди күз белән карап, чынбарлыкны тасвирлап иҗат итүчеләр. Алар барысы да әсәрләрен француз телендә язалар, әмма аларда күтәрелгән проблемалар гарәп дөньясыннан алынган.

Алты ел элек, 2000 елда француз телендә Мөхәммәд әл-Әйуби төзегән "Бәрбәр халык әкиятләре" китабы басылып чыкты. Автор аларны 1990—1997 елларда Марокконың бәрбәриләр яши торган Урта диңгез буйларында җәйрәп яткан Риф төбәгендә, Әйт-Вәрйагел районында язып алган. Бу китапка амазиг-бәрбәриләрнең тылсымлы әкиятләре тупланган. Бәрбәри әкиятләренең эчтәлегендә башка халыкларның әкиятләренә охшашлыкларны да табарга, очратырга мөмкин.

Шул урында амазиглар турындагы сүзебезне туктатып торыйк, аны бераз соңрак дәвам итәрбез... Күптән түгел (19-21 апрельдә) Казан дәүләт университетында Рәсәй-гарәп диалогы исеме астында халыкара фәнни конференция булып узды. Бу конференциядә Сүрия, Мисыр, Тунис, Мароккодан килгән күренекле галимнәр катнашты. Гарәп дәүләтләре берлеге каршындагы АЛЕКСО оешмасының генераль директоры, фәннәр докторы Мөнҗи Бусниңанын Казанга икенче тапкыр килүе. Ул университетның 200 еллык юбилее бәйрәмендә катнашкан иде. Бу юлы да ул үзенең чыгышында татар мәдәнияте, тарихы, әдәбияты белән гарәпләрне дә таныштыру кирәклеген әйтте. Зур мәдәнияткә ия булган бу бөек халык турында гарәп илләрендә әлегә бик аз беләләр, диде ул.

Мароккодан килгән галим, фәннәр докторы Габдеррәхим әл-Гатави миңа үзенең фәнни хезмәтләрен бүләк итте. Бу хезмәтләрдә татар халкы, аның тарихи үткәне, әдәбияты, мәдәнияте турында язылган. Ул—Рабат шәһәрендә урнашкан Мөхәммәд Бишенче исемле университетта гуманитар фәннәр факультетында профессор. Шуны да әйтеп узыйк: гарәп дөньясында чыга торган бер генә газета-журналда да татар халкының тарихына, аның галимнәре Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗанига багышлап зур хөрмәт белән язылган бер генә мәкаләнең дә монарчы басылып чыкканы булмады. Бу галим үзенең "Нәфазу губарин-нисьян гьән бәгьзи әмҗәди шагьби Татарстан" (Татар халкының тарихтагы игелекле гамәлләрен онытгырырга маташучыларның хәтерен битарафлык тузаныннан арындыру.) мәкаләсен инглиз, француз, рус, татар галимнәренең фәнни хезмәтләренә таянып язган. Казан университеты китапханәсендә саклана торган гарәп телендәге кульязма китапларга галим аеруча игътибар иткән һәм алар турында "Әт-Тәәрих вәл-фикьһ", "Дирасәт фи мәфаһим исламийә" исемле китапларында тәфсилләп язып та чыккан. Бу могьтәбәр зат татар галимнәренең хезмәтләрен ислам дөньясында танытуның зарурлыгын, үзенең чыгышында, берничә тапкыр кабатлап әйтте. Аның сүзләрен Бөтен гарәп язучылары берлегенең башлыгы Гали Укълә Ирсан да куәтләде һәм

кичекмәстән татар әдипләренең әсәрләрен гарәп теленә, гарәп телендәге матур әдәбиятны татар һәм рус телләренә тәрҗемә итә башларга кирәк диде.

Түбәндә тәкъдим ителәчәк амазиг-бәрбәриләрнең ТЫЛСЫМЛЫ ӘКИЯТЕ "Солтан кызы һәм 101 киселгән баш" дип атала..

Бер бик дәһшәтле солтанның бердәнбер кызы гына булган, ди.Солтан кызын бик яратканга аның шуклыкларына исе китмәгән, нәрсә генә эшләсә дә аны гаепләмәгән. Берзаман кыз әтисенә әйткән ди: «Көннәр буе бу сарайда синең хатыннарың, колларың арасында ята-ята туеп беттем, тыным кысыла башлады. Атка атланып сәяхәткә чыгасым килә. Ялгызыма гына күңелсез булачак, шуңа күрә миңа атта яхшы чаба белгән кырык яшь кызны табып юлдаш итеп җибәр», дигән.

Солтан барлык кабиләләргә үзенең әмерен җиткергән. Озак та үтми, барлык кабиләләрнең иң мөхтәрәм аксакаллары солтан яшәгән Дәр әл-Мәкзен шәһәренә кызларны атка атландырып китереп тә җиткергәннәр. Солтан кызы атына сикереп тә менгән һәм җилдәй җитез итеп атын чаптырып китеп тә барган, ди. Әлбәттә, теге кырык кыз да аңа ияргәннәр.

Көннәр уза торган. Ә кызлар кырларны, урманнарны, дәрьяларны кичкәннәр, рәхәтләнеп ял иткәннән соң кире әйләнеп кайтканнар, имеш.

Бу хәбәр кабиләләрнең аксакалларына да барып ирешә. Алар, кызларның язмышы өчен борчылып, солтанга төрледән-төрле бүләкләр алып тагын сарайга килгәннәр дә капка төбендә кырык үгезне корбан чалып, солтаннан кызларны кайтарып җибәрүен ялварганнар. Солтан вәгъдә биргән бирүен дә. Үз кызын чакырып, солтан аңарга болай дигән:

—Аксакаллар кызларының тагын сиңа ияреп урман-кырларны гизеп йөрүләрен теләмиләр. Мин аларны кире өйләренә кайтарып җибәрәм, ә сине кияүгә бирәм.

Кыз әтисенә:

—Кем дә кем сугышып мине җиңә алса, мин аңарга гына кияүгә чыгачакмын,—дигән.

Билгеле инде, солтан яраткан кызының куйган шарты белән ризалашкан һәм бөтен ил халкына: " Кем дә кем минем кызым белән сугышып аны җиңсә—ул минем киявем һәм варисым булып калачак",—дигән хәбәрне тараткан.

Бу хәбәр илнең барлык почмакларына тарала. Барлык кабиләләрнең курку белмәс яшь җилкенчәкләре күңелендә, солтанның кызына өйләнәм дә аның тәхете варисы булачакмын, дигән өмет чаткысы кабына.

Солтан сараена беренче батыр килеп тә җитә. Ул баскан җирендә биеп торучы сугыш атына атланган, ә кулында кылычы ялтырый. Солтан кызы да атына атланып чыгып җитә. Ике арада алыш башлана. Кызның осталыгы, батырлыгы бар халыкны таң калдыра. Күп тә үтми, ул егетне атыннан бәреп төшергән уңайга аның башын чабып өзә. Мескен егетнең башын солтан сараеның капка баганасына асып куялар. Ләкин егет халкын моның белән генә куркытып буламыни, солтан кызы белән көрәшергә дип яңадан-яңалары килеп кенә тора. Кыз да бик чая, үткен зиһенле, батырларча сугыша. Ул һәрвакыт җиңүче булып кала һәм җиңелүчеләрнең саны йөзгә җитә.

Бер авылда бик ярлы һәм үзе бик тә ямьсез бер көтүче яшәгән, ди. Беркөнне ул да өенә кайтып солтан сарае капкасындагы хәлләрне әнисенә сөйләп биргән, ди. Ана мескенкәй, бөкре, бөтен тәнен тилчә баскан шыксыз улының бу сүзләрен ишетеп бик гаҗәпләнгән, шулай булса да аның өметен кисмәгән. Аның үзсүзле улы, йорттагы карт алашага атланып, солтан кызы белән сугышырга китеп барган. Әнисе дә аңарга ияргән. Мескен ана бәхетсез улының солтан кызы белән сугышуын карап торган. Көтүченең

башы да җиргә тәгәрәгән. Моны күргән ана солтан кызы янына килеп: "Капкагызга асылган йөз баш җитәр инде сиңа, бир миңа газиз улымның башын, минем аны туган авылыма алып кайтып җирлисем килә,»—дигән. Солтан кызы риза булган.

Ана, өстеннән ямалып беткән иске җиләнен салып, улының башын шуңа ураган да, җансыз калган гәүдәсен аркасына күтәргән килеш, бер кабиләдән икенче кабиләгә барып, солтан кызына каршы тора алырлык батыр егетне эзләп йөргән, ди. Ләкин күпме генә йөрсә дә андый баһадирны очрата алмаган. Мескен ананы бер карт күргән һәм аңарга болай дигән:

—Син чишмә янына бар, батырларның батыры һәркөн үзенең яраткан бахбаен шул чишмәдән су эчертергә алып килә. Ул килер алдыннан гына чишмә суын болгатырсың. Бу хатын нәкъ шулай эшләгән дә.

Батырларның-батыры озакламый чишмә янына килеп тә җиткән. Ат болганган суны эчмәгән. Шунда басып торган карчыкны күреп, егет ачу белән:

—Әй син, җен карчыгы, нигә чишмә суын болгаттың?—дип кычкырган.

Мескен ана аңарга барысын да сөйләп биргән. Моны ишеткәч, батыр егет атына атланган да патша кызы белән сугышырга дип сарайга юл тоткан. Ул кая һәм нәрсә өчен барганлыгын әтисенә дә сөйләп биргән. Егетнең әтисе улының теләгенә каршы чыкмаган, ләкин улын сынап карарга теләгән. һәм, үзен танытмас өчен, башына япма ураган да атына атланып сугыш булачак урынга барган.

Шулай итеп, батыр егет каршына үзенең әтисе сугышырга чыккан. Егет җиңгән һәм кылычы белән селтәнеп "дошманын" үтерергә җыенганда гына... әтисе йөзен ачкан! Моны күргән егетнең кылычы кулыннан төшеп киткән. «Мин синең батырлыгыңны сынап карыйсым килде. Хәзер инде, улым, синең җиңәчәгеңдә шигем юк»,—дигән әтисе.

Солтан кызы да килеп җиткән. Кыз егетнең күзләрен күреп беравык һушы китеп карап торган да атыннан җиргә сикереп төшкән һәм егет алдында тезләнеп:

—Мине үзеңә ал, өйлән миңа,—дигән.

Солтан кызы әтисенә кайтып:

—Мине батырларның-батыры һәм матурларның-матуры бик булдыклы бер егет җиңде, мин аңарга кияүгә чыгарга ризалаштым,—дигән.

Солтанның һич кенә дә кызыннан аерыласы килмәгән, һәм егет кызны сорарга килгәч, аңарга:

—Кызым үлде шул инде, без менә ничә көннән бирле кара кайгыга батып утырабыз. Менә бу халык безнең кайгыбызны уртаклашырга җыелды,—дигән.

Егет ышанмаган һәм үзенең атына атланып юырткан бит каберстанга. Аңарга, солтан кызын менә шунда җирләделәр, дип бер каберне күрсәткәннәр. Егет каберне казытып ачтырган. Менә шунда солтанның ялганы фаш ителгән. Солтанга кызын кияүгә бирүдән гайре бер чара да калмаган. Зурдан кубып туй иткәннәр. Туйдагы ризыкның муллыгы турында сөйләп тә, язып та бетерерлек булмаган. Шулай итеп, курку белмәс батыр йөрәкле солтан кызы үзенә лаек булган ирне тапкан, ди...

## «Татар энциклопедиясе» битләреннән

# Б

**БИКТИМЕРЕВА** (Биктимерия) Галимәтелбәнат (1876, Казан өязе Кышлау а., — 30.11.1906, Рязань губ., Касыйм өязе Яубаш а.), язучы, мөгаллимә, җәмәгать эшлеклесе. Мулла нәселеннән. Түбән Үри авылында (хәзер Арча р-ны) атасы Лотфулла ахун тарафыннан ачылган кыз балалар мәктәбендә белем ала, 16 яшеннән шул мәктәптә мөгаллимә була. 1895 елда кияүгә чыгып, иренең Касыйм өязендәге туган авылы Яубашка күчеп китә. Шул ук елда Яубашта кызлар мәктәбе ача. Иҗат эшенә дә яшьтән керешә. Хатын-кызның гаиләдәге урыны, ятим балалар тәрбияләү алымнары, кыз балаларда укуга омтылыш уяту мәсьәләләренә багышланган «Тәргыйб-бел-бәнат» («Кыз балаларны кызыксындыру», 1892), «Хөсне-л-васыйа» («Гүзәл тәрбияче», 1895), «Мөгашәрәт әдәбе» («Аралашу әдәбе», С.-Петербург, 1895) китаплары авторы. Б. әсәрләрендә чәчмә форма шигырьләр б-н аралашып бара. 1905-07 еллар революциясеннән соң көндәлек матбугатта актив язышa, хатын-кызларны белемгә, актив җәмәгать эшләренә өндәгән публицистик мәкаләләрен бастыра.

Әд.: Галимәтелбәнат Биктимерия (1876-1906). Өмет йолдызлары. К., 1988; Бурнашева З. Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан. К., 1971; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том; Галимәтелбәнат Биктимерова // Азат хатын. 1988. N 7.

*М.В.Гайнетдинев.*

**БИКЧӘНТӘЕВА** Әминә Әхмәт кызы (26.1.1913, Казан – 18.4.1986, шунда ук), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1938). 1941-51 елларда авыл мәктәпләрендә укытучы, «Яшь ленинчы» г-тасында әдәби хезмәткәр, ТАССР МС каршындагы Радиолаштыру комитетында балалар өчен тапшырулар редакциясе мөхәррире, 1952-55 тә Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты бүлегендә мөхәррир. Әсәрләре 1938 елда басыла башлый. 1958 дән профессиональ рәвештә әдәби иҗат эше б-н шөгыльләнә. Балалар өчен язылган беренче шигырь җыентыгы «Бүләк» 1940 елда дөнья күрә. Аның балаларга багышланган «Бакча гөлләре» (1949), «Бүген һәм иртәгә» (1954), «Дачада» (1954), «Беренче чәчәкләр» (1960), «Яз бүләкләре» (1962) исемле шигырь китаплары зур популярлык казана. «Ана йөрәге» (1959), «Мин аңлармын сине» (1966) повестьларында гаиләдә һәм мәктәптә яшүсмерләрне тәрбияләү проблемасы үзәккә алына. Б. әсәрләренең төп темасы – туган җир табигатенең матурлыгы, кешедә намус, вөҗдан тәрбиясе, балалар б-н әти-әниләр мөнәсәбәте. Б.ның шигырьләре, хикәяләре һәм повестьлары әниләрнең балаларга карата мөнәсәбәтенә хас булган җылылык, самимилек, ихласлык б-н сугарылган. ТАССРның Мактау граматосы б-н бүләкләнә (1983).

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1963; Без өмет йолдызлары. К., 1973; Минем таныш-ларым К., 1983.

Әд.: Шәрәфи Г. Күңелдәге эзләр // Азат хатын. 1982. N12; Тәрҗеманов Ж. Чәчкә кебек матур һәм хуш исле // Ялкын.1983. N1; Кукушкин Р. Ә.Бикчәнтәева турында // Канатлы дөнья. К., 1984.

*Г.М.Габделхакова.*

**БИКЧУРИН** Мирсалих Мирсәлим улы (1820, Оренбург ш. – 7.3.1903, шунда ук), шәркыятьче, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе, хакыйкый статский советник. Морзалар нәселеннән. 1838 елда Оренбургтагы Неплюев хәрби уч-щесен тәмамлагач, Оренбург чик буе комиссиясе канцеляриясендә тәрҗемәче (драгоман) булып эшли. 1841-78 елларда Неплюев кадетлар корпусында гарәп, фарсы, татар телләрен укыта, бер үк вакытта (1850-69) Оренбург чик буе комиссиясе каршында казакъ балалары өчен ачылган мәктәптә татар һәм казакъ теле дәресләре алып бара. 1870 елларда Оренбург ген. губернаторы канцеляриясендә тәрҗемәче һәм хәрби гимназиядә укытучы булып эшли. Рус гаскәрләренең 1865, 1866, 1871-73 елларда Урта Азиягә ясаган яуларында тәрҗемәче сыйфатында катнаша. «Начальное руководство к изучению арабского, персидского и татарского языков с кратким объяснени-

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынннан басылып килә.*

ем существующих в Оренбургском крае наречий башкир и киргизов и приложением к нему русско-персидско-татарских слов, разговоров и прописей» (К., 1859) исемле уку әсбабы авторы. Анда, чагыштырма лексик-грамматик материалдан тыш, Шәрекъ халыклары фольклоры һәм язма әдәбиятыннан аерым үрнәкләр дә урнаштырылган. Рус география җәмгыятенең Оренбург бүлеге хакыйкый әгъзасы; 1890 еллардан Оренбург Гыйльми архив комиссиясе рәисе. 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир орденнары кавалеры.

Әсәр.: Начальное руководство... К., 1859; Туркестанская область. Заметки статского советника М.С.Бекчурина... К., 1872.

Әд.: Миңнегулов Х., Садретдинов Ш. XIX йөз татар хрестоматияләре. К., 1982; Миннегулов Х. Татарская литература и восточная классика. К., 1993; Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов. Дооктябрьский период. М., 1989.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**БИКЧУРИН** Шамил Мотыйгулла улы (3.1.1928, Әлмәт р-ны Миңлебай а. – 17.1. 1991, Лениногорск ш.), язучы, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1988). М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсны тәмамлый (1967, Мәскәү). 1952-58 елларда «Альметьевнефтестрой» трестында ташчы, 1958-62 дә «Ильич васыятьләре» (Лениногорск ш.) шәһәр г-тасында сәнәгать бүлеге мөдире булып эшли. Беренче язмалары 1957 елда «Совет әдәбияты» ж-лында басыла. «Ташлы тауда» (1959) һәм «Истәлекле таш» (1961) җыентыкларына кертелгән хикәя һәм очерклары татар авылы тормышындагы үзгәрешләр, нефтьчеләр, төзүчеләр, энергетикларның хезмәт казанышлары турында. «Тальян моңы» (1961 елда куела) муз. комедиясе һәм «Бергә, гомергә» (1963; 1964 елда куела) драмасы тамашачыларда кызыксыну уята. Киң җәмәгатьчелеккә Б. 1972 елда «Казан утлары» ж-лында (№5-7) басылган «Каты токым» романы б-н таныла. Нефтьчеләр тормышына һәм аларның мактаулы хезмәтенә багышланган бу роман 1974 елда аерым китап булып татар телендә, «Твёрдая порода» исеме б-н рус телендә басылып чыга, 1976 да ВЦСПС президиумы һәм СССР Язучылар берлегенең махсус бүләгенә лаек була. Роман словак, украин телләренә тәрҗемә ителә. 1981 елда «Казан утлары» ж-лында Б.ның ш. у. нефтьчеләр тормышыннан алып язылган икенче күләмле әсәре – «Тирән катлам» (рус теленә тәрҗемәсе «Глубокий пласт», 1983) романы басыла. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Әд.: Миңнуллин Ф. Прозаның гражданлык йөзе // Якты юллар. К., 1975; Галимуллин Ф. Тирән катламнарны ачканда // Казан утлары. 1980. №4; Бикмухаметов Р. Дни и ночи буровой // Литературное обозрение. 1974. №9; Воронов В. Привычная естественность // Литературная газета. 1975. 3 дек.; Мустафин Р. Человек и коллектив // Дружба народов. 1975. №7.

*Ф.М.Мусин.*

**БЛИНОВА** Эльмира Гафур кызы (9.8.1955, Казан), язучы. Рус телендә яза. Казан. пед. ин-тын тәмамлый (1979). 1980 елларда яза башлый. «Сабантуй» (1984), «Шәһәр агачлары» («Городские деревья», 1985) шигырь, «Зинһар өчен, игелекле булыгыз!» («Будьте добры, пожалуйста!», 1989) проза җыентыклары авторы. Б. әсәрләре стиленә гадилек һәм нәфислек, лирик тәэсирлелек хас. Балалар өчен язылган шигырьләрендә йомшак юмор, баланың эчке дөньясына карата ихтирам үзен нык сиздерә. 1991дән Израильдә яши.

**БҮКӘЛИ** (Пүкәли) Фәхреддин Арслан угылы (1801, Казан губ., Мамадыш өязе, Пүкәл а. – 1881, шунда ук), шагыйрь. Казан өязендәге Кенәр, Хәтнә авыллары мәдрәсәләрендә белем ала. Хәтнә авылының имам-хатибы һәм мөдәррисе. Күренекле замандашларына (Ш.Мәрҗани, Г.Түнтәри, Г.Курсави һ.б.), ш.у. улы Таҗетдингә багышланган мәдхия һәм мәрсияләр авторы. Гали Чокрыйның «Фәүзен-нәҗат» («Котылу юлы») әсәрен мактап язган шигыре дә бар. 1874 елда бер төркем иске фикерле муллалар, Ш.Мәрҗанинең «Назурател-хак...» хезмәтен тәнкыйтьләп, «Мозаһәрәтел-кәлимә әл-җәрүдә әл-ләти хыййа фил ән-Назурат» («Назуратта әйтелгән сүзләргә караш...», 1874) исемле китап бастыралар. Б., Мәрҗани фикерләрен яклап, үзенә тарафдар берничә кеше б-н берлектә, әлеге китап авторларына каршы шигъри җавабын иҗат итә. Бу шигъри җавапларны Ш.Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Булгар» хезмәтенең 1 нче томы кушымтасына урнаштырган. Б.нең кульъязма шигырьләр җыентыгы Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

Әд.: Мәрҗани мәҗмугасы. К., 1915; Фәтхи А. Кульъязмалар тасвирламасы. XII

чыгарылыш. К., 1968; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том; Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

*М.В.Гайнетдинев.*

**БОБОРЫКИН** Пётр Дмитриевич (15.8.1836, Түбән Новгород ш. – 12.8.1921, Италия, Лугано ш.), язучы, драматург, әдәби тәнкыйтьче. «Малкуарлар» («Дельцы», 1872-73), «Кытай шәһәрчеге» («Китай-город», 1882), «Василий Тёркин» (1892) романнары, повестьләр, пьесалар, мемуарлар, мәкаләләр авторы. 1853 елда гимназияне тәмамлый һәм Казан ун-тына укырга керә. А.М.Бутлеров, М.Я.Киттары лекцияләрен тыңлый, мавыгып химияне өйрәнә. 1855 тә Дерпт ун-тының химия бүлегенә күчә. Беренче әдәби тәҗрибәләре гимназиядә укыган елларга карый. Казанда яшәгән чоры «Хаерле юлга!» («В путь-дорогу!» 1862-64) автобиографик романында һәм «Ярты гасыр эчендә» («За полвека», 1906-13 «Русская мысль» ж-лында, соңыннан китап булып 1929 да басыла) истәлекләрендә урын ала. Б. әсәрләренә детальләрнең, шартларның, көнкүрешнең төгәл бирелеше хас. Аларда Казан ун-ты укытучыларына (Д.И.Мейер, Н.А.Иванов, А.М. Бутлеров, Е.Ф.Аристов), студент тормышына, пьесалар уйналуга, балларга һәм дворяннар җыены утырышларын күрсәтүгә зур урын бирелә.

Әсәр.: Избранные сочинения. М., 1982; Воспоминания. 2 томда. М., 1965.

Әд.: Красовский В. Проблемы натурализма в русской литературе и творчество П.Д.Боборыкина // Из истории русского релизма конца XIX – начала XX века. М., 1986.

*Л.Е.Бушканец.*

**БОЛГАРИ СӘУБӘН** (Сәүбән ибне Ногман әл-Болгари әл-Җияши) (19 йөз урталары), шагыйрь. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. Шигырьләр һәм үгетнәсыйхәт характерындагы риваятьләр тупланган «Мәншаэ әр-рижа» («Өмет итү чыганагы», 1866) исемле дини-дидактик кульъязма китап авторы. Кульъязма Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

Әд.: Фәтхи А. Кульъязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш. К., 1968.

*М.М.Әхмәтҗанов*
*Бурнашева З., к. Гыйффәт туташ.*

**БОХАРАЕВ** Равил Рәис улы (18.10.1951, Казан), язучы. Казан ун-тын тәмамлый (1974). Беренче шигырьләре 1970 елларда рус телендә языла. «Приметы века» («Гасыр билгеләре», 1974), «Яблоко, привязанное к ветке» («Ботагына бәйләнгән алма», 1977), «Знак Августа» («Август билгесе», 1981), «Время цветов» («Чәчәкләр чоры», 1985), «Вокруг Тукая» («Тукай даирәсендә», 1989), «Трезвые пиры» («Аек табыннар», 1990) шигырь җыентыклары авторы. Г.Тукай һәм М.Җәлил шигырьләрен рус теленә тәрҗемә иткәндәге уңышлары өчен М.Җәлил исем. Татарстан комсомолы бүләгенә лаек була (1986). 1991 елдан Лондонда яши. Проза әсәрләре арасында аеруча әһәмияткә ия булган һәм авторның кеше гомеренең тирән мәгънәсен аңлауга омтылуын чагылдырган китабы – «Дорога Бог знает куда» («Алла үзе генә белгән юл», 1999). Канада, Англия, Һиндстан, Германия, Венгрия, Италия, Төркия матбугатында басылган татар, инглиз, венгр телләрендәге шигырьләр, татар халкының тарихына һәм мәдәниятенә багышланган мәкаләләр, ТР Президенты М.Ш.Шәймиев турындагы китап авторы. Инглиз тикшеренүчесе-лингвисты Д.Мэттьюс б-н берлектә инглиз телендә «Татар поэзиясенең тарихи антологиясе»н әзерләп (кереш сүз, комментарийлар, юлга юл тәрҗемә авторы), Лондонда бастырып чыгарды (2000). 1992 дән Би-би-си, «Голос Америки» («Америка тавышы») һәм «Свобода» («Азатлык») радиостанцияләрендә Татарстанга, татар мәдәниятенә багышланган тапшырулар алып бара. Б. иҗатына көчле образлылык, тарихи дөреслек, тирән фәлсәфилек, киеренке әхлакый һәм дини эзләнүләр хас.

Әсәр.: Президент Минтимер Шаймиев и модель Татарстана. Курзон-Блиц, Лондон-С.-Петербург, 2000; «Quest», quaternion (four different wreaths of sonnets in English, Hungarian, Russian and Tatar languages). Islam International Publications Ltd., Surrcy, England, 1994; Islam in Russia: the Four Seasons, monograph,Curzon Publishers Ltd.,London, England, 2000.

Әд.: Шевелёва И. О книге Р.Бухараева «Редкий дождь» // Новый мир. 1982, N1; Соложенкина С. Разлуки – нет... // Литературное обозрение. 1986, N7.

*Р.Ә.Мостафин.*

**БУБЕННОВ** Михаил Семёнович (21.11.1909, хәзерге Алтай крае, Икенче Поломошново а. – 3.10.1983, Мәскәү), язучы. Әсәрләре 1927 елда басыла башлый. 1931-41 елларда ТАССР р-ннарында, «Красная Татария» г-тасында (1935 тән) эшли. 1939

елда Ә.Вәлиев б-н берлектә «1918 елда Казанны ак интервентлардан азат итү» («Освобождение Казани от белоинтервентов в 1918 году») дигән китап, М.Савосин б-н берлектә Хәсән күле тирәсендә барган героик сугышлар турында хикәяләр («Ватан өчен» — «За Родину» җыентыгына кергәннәр, 1939) яза. «Язгы ташу» («В половодье», 1940) җыентыгында урын алган хикәяләр һәм «Үлемсезлек» («Бессмертие», 1940) тарихи-рев. повесте — Кама буенда барган Гражданнар сугышы вакыйгаларына нигезләнеп язылган. Б.ка зур танылу Бөек Ватан сугышы турында язылган «Ак каен» («Белая берёза», 1 нче кит., 1947, СССР Дәүләт бүләге, 1948; 2 нче кит., 1952), чирәм җирләрне күтәрү турындагы «Бөркет даласы» («Орлиная степь», 1959), яшь төзүчеләр, Себерне үзләштерү турындагы «Текә яр» («Стремнина», 1970) романнары китерә. Ике Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Собрание сочинений. 4 томда, М., 1981-82.

Әд.: Ачкасова Л.С. Творчество М.С.Бубеннова: Автореф. дисс., К., 1953.

*Л.С.Ачкасова.*

**БУЛАТОВА** (Рафигуллина) Клара Гариф кызы (18.3.1936, Сарман р-ны Татар Карамалысы а.), шагыйрә, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), авыл мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Шигырьләре 1956 елдан «Ялкын», «Азат хатын», «Казан утлары», «Чаян» ж-лларында басыла. Нефтьчеләргә, төзүчеләргә, авыл хезмәтчәннәренә багышланган «Язлар алда» дип исем. беренче лирик шигырьләр җыентыгы 1967 елда дөнья күрә. «Һәрвакыт янымда» (1969), «Җәйләр житсә» (1972), «Гел кояшка карап» (1981), «Печән өсте» (1986), «Хәтер тәрәзәләре» (1989), «Миләш кагы» (1991) китапларындагы шигырьләрдә замана кешесенең уй-хисләре, тирән кичерешләре чагыла. Б. поэзиясенең нигезендә тормыш һәм иҗади хезмәт шатлыгы, тугрылык, дуслык һәм мәхәббәт кебек якты хисләр ташкыны. Балаларга атап язылган «Марс китабы» (1982), «Курка димәгез мине» (1994) китапларына кертелгән шигырьләре күңел җылысы, җиңелчә юмор б-н аерылып тора.

Әсәр.: Шушы яктан, шушы туфрактан без. К., 2000; Әрнү. К., 2003.

Әд.: Маннур Ш. Хәерле юл телим // Казан утлары. 1971. №2; Вәлиев М. Мәхәббәт яшәргә тиеш // Казан утлары. 1990. №3; Зәйнашева Г. Шатлыгымда хәсрәт орлыгы бар, хәсрәтемдә — бәхет орлыгы // Мәдәни җомга. 1996. 29 март.

*Г.М.Габделхакова.*

**БУЛГАКОВ** Александр Николаевич (25.8.1911, Кырым, Феодосия ш. — 11.4.1978, Казан), язучы. Мәскәү төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлый (1937), Ерак Төньяк һәм Ерак Көнчыгыш төзелешләрендә эшли. 1953 елдан Казанда яши, төзелеш оешмасында баш инженер була. 1957 елдан башлап беренче хикәяләрен һәм очеркларын «Смена», «Огонёк», «Наш современник» ж-лларында бастыра. «Буран аша» («Сквозь пургу», 1958), «Юл тауга күтәрелә» («Трасса поднимается в горы», 1959), «Яшибез» («Будем жить», 1965), «Төньяк җиле» («Северный ветер», 1971) хикәя һәм повесть җыентыклары авторы. 2 Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. Справ. К., 1970; Белостоцкий Ю. Якты эзле еллар // Социалистик Татарстан. 1971, 25 авг.; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## *«Казан утлары» архивыннан*



*Идел-Урал җәмгыяте әгъзалары. Өстәл артында уртада — Гаяз Исхакый. Токио. 1933 ел.*



*Язучы Кави Латыйп. 1996 ел.*




*Үткән гасыр әдипләре. Сулдан уңга — Әмирхан Еники (1909 — 2000), Гомәр Бәширов (1901 — 1999), Шәйхи Маннур (1909 — 1980). 1965 елгы фото.*



*Язучы Рафаил Төхфәтуллин (1924 — 1994) укучылар белән очрашу вакытында. 1984 ел.*



*Композитор Резеда Ахиярова. 1995 ел.*



*Язучы Эдуард Касыймов (1930 — 1986) 1978 елгы фото.*

## *Укучы сүзе*

Исәнмесез, кадерле редакция!

Сезнең журналны күп еллар буе укып барам, соңгы 10 еллык саннарның күбесе миндә бар. Үземнең ата-бабалар, тамырларым Туймазы якларыннан. Инде мәрхүм бианам Жәүһәрия шул яктагы Чукадыбаш авылыннан. Ул сөйли иде, Чукады — волость авылы, базар,ярминкәләр еш була, анда татары, чуашы — бөтенесе килә иде, дип.

Менә шул бианам Жәүһәрия, хәтере бик шәп булып, бихисап җыр белә иде — шул турыда сүзем. Кичләрен Казан радиосын тыңлыйбыз. Шунда «Туган тел» җырын тапшырсалар, ул: «Чукадыда шушы көйгә икенче төрле җыр җырлыйлар иде», — дип сөйли торган иде. Базарда бер татар бабае шушы көйгә «Озын гомер» дигән җыр башкарып, шуннан көен шөбердә уйнап күрсәткән. «Шөбер өрә торган иде, — дип әйтә иде бианам, — кешеләр, аны тыңлап, елыйлар иде, шул хәтлем моңлы, матур уйный иде. Үзебезнең татар бабае, үзебезнең татар шөберендә. Скрипкә, гармун соңрак таралды. Хәзер ул шөберне ишетеп булмас инде.

«Шөбер — татарныкы, чуашныкы түгел», —ди торган иде ул.

Шулай итеп, әйтергә телим, безнең татарда шушы шөбер дигән музыка коралы бар ул — аны искә төшерергә генә кирәк, куллана башларга. Менә бу «Озын гомер» җыры, гади генә кебек күренсә дә, шунысы белән мөһим — анда бүген онытылган көй, моң сакланган. Ул көй, моң — татар шөберенең эзләрендә. Аны югалту тоташ бер катлам мәдәниятебезне, тарихи чорны югалту ул. Шөбер шул мәдәни катламны күтәрер иде. Бүген безнең «Көнбатыш Башкортстан» җирләрендә юкка гына курай культурасын көчләп кертмиләр. Бу курай экспансиясенә без татарның иң борынгы катлам мәдәниятен, көй-моңнарын каршы куярга тиешбез, бер көнлек эстрада гына бу экспансиягә каршы тора алмас. Әлбәттә, шөберне бүген «Көнбатыш Башкортстанда» — Туймазы, Октябрьский, Бәләбәйдә, Дүртөйле, Нефтекамада күтәрергә бирмәсләр, ә инде Уфа турында — сүз дә юк, моны бары Казан гына эшли ала.

Җырның сүзләрен җибәрәм.

### Озын гомер

**Үткән гомер, озын гомер**
**Язгы чишмәдәй булды.**
**Язгы чишмәдәй булды да**
**Искә алырга калды.**

**Безгә тиклем ошбу юлны**
**Күпме бабамнар үткән.**
**Күпме бабамнар үткән дә**
**Гомер җомгагын сүткән.**

**Бездән соң да бу юлларны**
**Күпме балалар үтер.**
**Күпме балалар үтер дә**
**Бәхетле гомер көтер.**

**Гомерләре, ризыклары**
**Идел-сулардай булсын.**
**Идел-сулардай булсын да**
**Җырлап сөйләргә калсын.**

**Үткән гомер, озын гомер**
**Агым сулардай булыр.**
**Агым сулардай булыр да**
**Искә алырга калыр.**

Җыр элекке волость үзәге Чукадыбаш авылында җырланган. Көе — «Туган тел» көенә якын, ләкин озын итеп, сузыбрак башкарыла. Бианам ул шөберне якынча шул 1930 елларда күреп ишеткән. Шөберне хәзер чуашлар яңадан куллана башлады («Нарспи» фольклор ансамбле). Татарның да шөбере бар.

**Илһам ӘМИРХАНОВ,**
*Уфа*

**Редакциядән:**
*Музыка белгечләре укучыбыз күтәргән мәсьәлә турында фикерләрен әйтми калмаслардыр дип ышанабыз.*

### ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ УҢАЕ БЕЛӘН ШИГЪРИЯТ ТАНТАНАЛАРЫ

## Татарстанда

***

Һәр елның 15 апрелендә даһи шагыйребез Габдулла Тукайны искә алу, аның Татар зиратындагы каберенә чәчәкләр салу күркәм гадәткә әверелде. Быел бирегә халык аеруча күп килде. Алар арасында республика дәүләт учреждениеләре, министрлыклар һәм ведомстволар, иҗат берлекләре, җәмәгать оешмалары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, халык депутатлары, дин әһелләре, шигърият сөючеләр, чит ил кунаклары бар иде.

«Президент фәрманы белән игълан ителгән Әдәбият һәм сәнгать елы зур юбилейларга, шул исәптән Габдулла Тукайның 120 еллыгына туры килде,—диде Татарстан Премьер-министры урынбасары—Мәдәният министры Зилә Вәлиева үз чыгышында.—Тукай татар халкы тарихында аерым урын алып тора. Быел шагыйрь иҗатына багышланган бик күп чаралар уздырыла. Бүген безнең төп бурычыбыз—бөек шагыйрь һәрчак безнең белән булсын өчен аның истәлеген мәңгеләштерү».

Искә алу мәрасимендә шагыйрьләр Шәүкәт Галиев, Роберт Әхмәтҗан, Роберт Миңнуллин, Камал театрыннан Зөһрә Шакирҗан һәм Илдус Әхмәтҗан чыгыш ясады. Аннары зыярәт кылуда катнашучылар, Харис хәзрәт Салихҗанга кушылып, Тукаебыз рухына дога кылды. Матәм җыенын Г. Тукай җәмгыяте рәисе, әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов алып барды.

***

Апрель аенда «Тукай укулары» үткәрү даими мәдәни чарага әверелеп бара. Аны Габдулла Тукай җәмгыяте шагыйрьнең әдәби музее белән берлектә оештыра. Мондый укуларда, гадәттә, республикабыз районнарыннан килгән укытучылар, мәктәп балалары, шигърият сөючеләр катнаша.

Олуг юбилей елында үткәрелгән «Тукай укулары»нда галимнәр Тәлгат Галиуллин, Хатыйп Миңнегулов, Таһир Гыйләҗев, Марсель Ибраһимов, язучылар Рабит Батулла, Ренат Харис, Айдар Халим, Зиннур Мансуров, шулай ук Харис хәзрәт Салихҗан, Казанның 11 нче гимназиясе укытучысы Зөләйха Хафизова һ.б.ларның докладлары, чыгышлары тыңланды. Әлеге чыгышларда Габдулла Тукай шәхесенең төрле яклап ачылуы белән беррәттән, аның иҗатына һәм гомер юлына кагылышлы яңа мәгълүматлар да бәян ителде.

***

Арча районы бөек якташларының юбилеена быел аеруча ныклап әзерләнде. Яңа Кырлай музей комплексы, шулай ук мәчет, авыл мәктәбе, китапханә бинасы, юллар төзекләндерелгән, биредәге бакча һәм күл тагын да күркәмрәк төс алган, Тукай һәйкәле әр-яңадан бронздан коелган...

«Без Кырлайга изге урынга килгән кебек җыелабыз. Гомумән, бирегә килгән һәрбер татар кешесе үзен туган ягындагы кебек тоя, - диде Татарстан Премьер-министры урынбасары—Мәдәният министры Зилә Вәлиева төзекләндерелгән музей комплексын ачу тантанасында.—Олуг язучылар биргән төбәккә аяк басу һәрвакыт күңелдә бөеклек хисе уята. Чыннан да, Тукай яшәгәндә телебез дә, халкыбыз да яшәр... Шагыйрьгә бәйле истәлекле урыннарны төзекләндерү эше дәвам итәчәк. Кушлавыч та, Өчиле дә, һичшиксез, Тукайга лаек дәрәҗәгә ирешер».

Яңа Кырлайдагы төзекләндерелгән музей комплексы белән танышканнан соң юбилей тантанасы Арча районы үзәгенә күчте.

Арча муниципаль районы башлыгы Алмас Нәзиров, тәбрикләү сүзе әйткәч, «Илаһи моң булып яши Тукай бүген дә» дип исемләнгән конкурста җиңүчеләргә бүләкләр тапшырды. Аннары Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Әлфәт Закирҗанов чыгыш ясады. Бәйрәм сәхнәсендә Казаннан килгән шагыйрьләр Тукайга багышланган шигырьләрен укыды.

Кунаклар арасында халыкара фәнни-гамәли конференциядә катнашкан күренекле галимнәр дә бар иде.

Арчадагы тантаналар турында бәян иткәндә тагын бер фактны әйтеп узу кирәк: моннан 60 ел элек Арча педагогия көллиятенә (ул вакытта училище дип аталган) Г. Тукай исеме бирелгән булган. Ләкин кемнәрнеңдер битарафлыгы аркасында ул алты дистә ел буена әйләнешкә кермәгән.

Ниһаять, муниципаль район хакимияте һәм көллиятнең яңа житәкчесе тырышлыгы белән мәшһүр Тукаебыз исеме көллият биографиясенә яңадан кайтарылды.

***

Габдулла Тукайның туган көнендә—26 апрель иртәсендә башкалабыздагы Кол Гали, Г. Тукай, М. Жәлил, Г. Державин, А. Пушкин һәйкәлләренә чәчәкләр салынды. Г.Тукай һәйкәленә чәчәк салу мәрәсимендә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Премьер-министр Рөстәм Миннеханов, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Президент аппараты житәкчесе Юрий Камалтынов, Премьер-министр урынбасары—Мәдәният министры Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары Александр Гусев һәм Римма Ратникова, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин, министрлыклар һәм ведомстволар житәкчеләре, халык депутатлары, әдәбият һәм сәнгать әһелләре катнашты.

М. Жәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасы янындагы Г. Тукай һәйкәле алдында үткәрелгән Шигърият бәйрәмен кереш сүз белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов ачып жибәрде. Аннары Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева Президент Минтимер Шәймиевнең 2006 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре бирү турындагы Указын игълан итте, яңа лауреатларга ижат уңышлары һәм саулык-сәламәтлек теләде. Быелгы Дәүләт премиясенә ия булган әдәбият һәм сәнгать әһелләре исеменнән язучы Марсель Галиев рәхмәт сүзе белән чыкты.

Шигърият бәйрәмен күренекле шагыйрь Рәдиф Гаташ алып барды. Тантанада Россия Мәдәният һәм кинематография буенча федераль агентлык житәкчесе Михаил Швыдкой, Россия Язучылар берлеге рәисе урынбасары Анатолий Парпара, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Равил Бикбаев, Чуашстан профессиональ язучылар берлеге рәисе Валерий Тургай, Мари Иле Язучылар берлеге рәисе Василий Крылов, Башкортстанның халык шагыйре Марат Кәримов, Алтай халык шагыйре Бронтай Бедюров, Мордовиянең атказанган язучысы Камил Тангалычев, үзебезнең шагыйрьләрдән Равил Фәйзуллин, Шәүкәт Галиев, Роберт Әхмәтжан, Роберт Миннуллин, Разил Вәлиев, Харрас Әюп, Шамил Маннапов, Илдус Гыйләжев, Зиннур Мансуров, Госман Садә, Флера Гыйззәтуллина, Лена Шагыйрьжан, Резеда Вәлиева, Салисә Гәрәева, Эльмира Шәрифуллина, Бикә Рәхимова, Нәжибә Сафина, Флера Тарханова, Лилия Газизова, Илсөяр Иксанова, Фәйрүзә Мөслимова, Танчулпан, Луиза Янсуар, Гөлназ Вәлиева, Рәмис Аймәт, Сергей Малышев, Марат Закир һ.б.лар чыгыш ясады. Шигърият бәйрәмендә республикабыз сәнгать осталары һәм балалар башкаруында Габдулла Тукай әсәрләре һәм аның шигырьләренә язылган жырлар яңгырады.

***

«Тукай—халыкның бәгыреннән өзелеп төшкән моңы, аның вөжданы, әмма шул ук вакытта киләчәккә өмете дә, сынмас рухы да. Шуңа күрә ул мәңгегә татарның күңелендә, сүзендә, теләндә, гамәлендә кала. Кыска гына гомер эчендә үз халкын зур биеклеккә күтәрә алу чын әйдәмәннәргә, каһарманнарга гына хас сыйфат... Безнең изге бурычыбыз—халкыбызның дәрәжәсен тагын да күтәрү, икътисадта һәм сәясәттә Тукай дәрәжәсенә лаек булырлык гамәлләр кылу»,—диде Президентыбыз Минтимер Шәймиев М. Жәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулуга багышлап уздырылган тантаналы кичәдә.

Россия Президенты В. Путин да бөек татар шагыйренең юбилее уңаеннан үзенең котлавын юллаган. Аны Россия Мәдәният һәм кинематография буенча федераль агентлыгы житәкчесе Михаил Швыдкой укып ирештерде.

«Габдулла Тукайны дөнья мәдәниятенә безнең кардәш республикабыз Татарстан үстереп бирде. Бу олуг шагыйрьнең мирасы чын мәгънәсендә бөтен төрки дөньяның зур байлыгы дип аталырга лаек. Бу хәл миндә чиксез горурлык уята». Әлеге сүзләр Әзәрбәйжан Республикасының Россиядәге илчесе, «ТЮРКСОЙ» оешмасының генераль директоры Полат Бюль Оглының котлау хатыннан. Аларны «ТЮРКСОЙ» халыкара оешмасының генераль директоры урынбасары Мостафа Балчык житкерде.

Башкортстан Республикасы Президенты Мортаза Рәхимовның, башкорт халкының сәламен Башкортстан Премьер-министры урынбасары мәдәният һәм милли сәясәт министры Илдус Илишев ирештерде.

Олуг шагыйребезне искә алу кичәсендә Татарстан, Башкортстан, шулай ук Мәскәү, Санкт-Петербургның мәшһүр артистлары З. Сөнгатуллина, И. Газиев, Ф. Килдеярова, В. Лановой, Э. Агджи, Ч. Хамматова, А. Шаһиморатова һ. б. чыгыш ясады.

***

27 апрельдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы янындагы мәйданда «Туган тел бәйрәме» үткәрелде. Инде байтак еллар дәвамында оештырыла торган әлеге тантана татар теленә—шагыйрьләр теленә мәдхия жырлау төсендә узды.

### ЛАУРЕАТЛАРНЫ ЗУРЛАУ

Мәгълүм булганча, 12 июнь—«Россия көне»ндә Мәскәүдә «Йосыф кыйссасы» дигән балетны ижат иткән өчен композитор

Леонид Любовскийга, спектакльнең либретто авторы, Татарстанның халык шагыйре Ренат Хариска, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры биючесе Нурлан Канетовка сәнгать өлкәсендәге зур казанышлары өчен Россиянең дәүләт премиясе тапшырылды.

Җиңүчеләргә премияләр тапшырганда Россия Президенты Владимир Путин: «Илебез мәдәнияте тарихында беренчеләрдән булып Татар опера һәм балет театрының иҗат коллективы Шәрыкның «Йосыф кыйссасы» дигән эпик поэмасын балет телендә сөйләп бирүгә иреште»,—диде.

ТР Президенты М. Ш. Шәймиев тә Дәүләт премиясе лауреатларына котлау юллады. «Үзенчәлекле талантыгызны тану, ватаныбыз сәнгатен үстерүгә керткән өлешегезне югары бәяләү бу. Яңа татар милли балет спектакле туу бөтен илнең мәдәни тормышында әһәмиятле вакыйга, күпмилләтле Россия Федерациясендә төрле халыклар мәдәниятен уңышлы үстерүнең ачык үрнәге булып торуын күрсәтә» диелгән анда.

15 июнь көнне яна лауреатларны Казан Кремлендә Татарстан Президенты М. Шәймиев кабул итте.

## КАЗАНДА ПУШКИН КӨНЕ

6 июнь көнне Пушкинның Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янәшәсендәге һәйкәле янында шагыйрьнең 207 еллыгы Шигырь бәйрәме итеп зурлап билгеләп үтелде.

Бәйрәмне Премьер министр урынбасары—Мәдәният министры З. Вәлиева һәм Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе И. Ибраһимов ачып җибәрде.

Пушкин көнен әзерләүдә Мәдәният министрлыгына һәм Язучылар берлегенә Казанның М. Горький музеенда, Казан дәүләт медицина университетында һәм Казан дәүләт университетында эшләп килүче әдәби берләшмәләр ярдәм иткән. Шагыйрьнең үлемсез шигырьләре белән бергә, яшьләр үз шигырьләрен дә укыды.

Пушкинның һәйкәле Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итү уңаеннан бронзадан яңартылып куелган иде. Бронза һәйкәл янында шагыйрьнең алтындай шигырьләре, җырлары яңгырады. Бәйрәм тантанасын шагыйрә Лилия Газизова алып барды.

## КАЗАНДА—ЯҢА ВУЗ

Россия Мөфтиләр шурасы һәм Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте ислам динен укыту буенча яңа югары уку йортын—Казан ислам институтын гамәлгә куйган.

Гамәлгә куючылар шурасы утырышы Мәскәүдә узган. Яңа вуз мәгариф эшчәнлеген фәкать дин өлкәсендә генә алып барырга ниятли. КИИ ректоры итеп Россия ислам университетында дин фәннәре кафедрасына җитәкчелек иткән Руслан Таһиров билгеләнгән. Шунысы игътибарга лаек: яңа уку йорты уставы Россия ислам университетыннан Казан ислам институтына турыдан-туры күчүне күздә тота икән.

Аны тәмамлаучылар Россия мөфтиләр советы эшләгән үрнәктәге югары белем турында диплом алып чыгачак.

## «ӘКИЯТ»КӘ ӘКИЯТИ ӨЙ

ТР Дәүләт Советында Казанның яңа курчак театры бинасы проектларын тәкъдир итү барышында театр төзү өчен урын билгеләнде. Петербург урамында—элеккеге «Победа» кинотеатры каршында төзеләчәк ул.

Казан курчак театры 1934 елда элеккеге чиркәү бинасында эшли башлаган. «Әкият» театрында хәзер ике труппа—татар һәм рус труппалары эшли. 2004 елның ноябрендә театр үзенең 70 еллыгын билгеләп үткән иде. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев нәкъ менә шул чагында театр өчен яңа бина төзергә, ә чиркәүне диндарларга кире кайтарырга вәгъдә бирде. Хәзер бу вәгъдә тормышка ашырга охшый.

ТР төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры Марат Хөснуллин әйтүенчә, архитекторлар яңа театр проектын эшләү буенча зур эш башкарган. Театрда 2 зал булып, аның берсе—350, икенчесе 150 урынга исәпләнгән.

## ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

Май аенда Татарстан Язучылар берлеге Әлмәт оешмасының гомуми җыелышы булды. Анда нефть төбәгендә яшәп иҗат итүче каләмдәшләребез үзләрен борчыган көнүзәк мәсьәләләр турында фикер алышты. Зөфәр Дәүләтов Әлмәт язучылар оешмасының җитәкчесе вазифасыннан азат ителде. Язучылар оешмасына яңа җитәкче итеп танылган драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Исхакый премиясе лауреаты Данил Салихов сайланды.

Җыелышта Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты рәисе Мансур Хафизов һәм Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе шагыйрь Илфак Ибраһимов катнашты.

## ЛИТВАДА ОЧРАШУЛАР

Литвада Россия көннәре кысаларында Вильнюс һәм Висагинас шәһәрләрендә Татарстан Республикасының Әдәбият һәм сәнгать көннәре узды.

Литва татар җәмгыяте (ул 3,5 мең чамасы татарны берләштерә. Җитәкчеләре – Алас Якубаускас һәм Зилә Кәримова) һәм Татарстан Мәдәният министрлыгы тәкъдиме белән оештырылган бу чарада композиторлар Резеда Әхиярова, Олег Любивец, җырчы Идрис Газиев, рәссам Фәридә Хәсьянова катнашты. Делегациягә Татарстанның халык

шагыйре Ренат Харис житәкчелек итте.

Висагинас мәдәният сараенда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, рәссам Ф. Хәсьянова әсәрләреннән күргәзмә оештырылды. Соңыннан автор бу әсәрләрен әлеге шәһәрнең татар җәмгыятенә бүләк итте. Шул ук мәдәният сараенда әдәби-музыкаль кичә дә узды. Анда Р. Әхиярова һәм О. Любивецның И. Газиев башкаруында җырлары, романслары, шулай ук итальян халык җырлары яңгырады. Р. Харис үзенең шигырьләрен укыды. Татарстан делегациясен Россия Федерациясе илчелеге киңәшчесе Т. Шлычкова да сәламләде.

Шәһәр янында Татарстанның әдәбият һәм сәнгать эшлекләләре делегациясе катнашында сабан туе узды. Ә Вильнюсның Театр һәм кино музее залында татар әдәбияты һәм музыкасы кичәсе үткәрелде. Анда РФнең Литвадагы Гадәттән тыш һәм Вәкаләтле илчесе Б. Цепов тәбрикләү сүзе әйтте. Ул Татарстан делегациясен илчелектә кабул итте.

## КАЗАНДА «ШВЕЦИЯ КӨННӘРЕ»

Май аенда Казанда «Швеция көннәре» узды. Татарстан Мәдәният министрлыгы, ТР Президенты аппараты, Швециянең Россиядәге вәкиллеге һәм Казандагы Швеция үзәге тарафыннан әлеге мәдәни чара Россиянең тугыз шәһәрендә гамәлгә ашырылучы «Sweden Upgrade» проекты кысаларында оештырылды. Бу унайдан 17 майда—Халыкара музейлар көне алдыннан Татарстан Милли музеенда берьюлы берничә күргәзмә ачылды. Аларның берсе—«Рус-швед язмышы: Мария Павловна» дип атала. Анда XX гасырда төшерелгән фотографияләр урын алды.

18 майда ТР Милли музеенда швед журналисты, язучы һәм тәрҗемәче Стеффан Скотт хезмәтләре күргәзмәсе эшли башлады. Ә Швециянен Гетеборг Сәнгать мәктәбе профессоры Эстер Шалев-Герц чит илләргә күчеп китүче кешеләрнең язмышларына багышланган видеокүргәзмә тәкъдим итте.

## ЯЗУЧЫ ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАДЫ

Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова Ш. Мәрҗәни исемендәге Тарих институтында «Урта Идел халыкларының тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүдә М. Г. Худяковның роле» дигән темага тарих фәннәре буенча кандидатлык диссертациясе яклады. Татар халкы турында йөзгә якын фәнни хезмәт язган, «Очерки по истории Казанского ханства» дип аталган китабы өчен 1936 елда атып үтерелгән рус тарихчысы Михаил Худяков турында бу монография әлегә иң ышанычлы фәнни хезмәт булып тора. Диссертациянең фәнни житәкчесе—тарих фәннәре докторы Равил Әмирханов, рәсми оппонентлары—тарих фәннәре докторы Сәлам Алишев һәм тарих фәннәре кандадаты Булат Хәмидуллин булдылар. Диссертацияне яклау барышында тарих фәннәре докторлары Дамир Исхаков, Әзһәр Мөхәммәдиев, Равил Фәхретдинов, Петр Старостин һәм башкалар монографиягә югары бәя бирделәр. Нәтиҗәдә, Фәүзия Бәйрәмованың хезмәтен гыйльми совет әгъзалары бертавыштан яклап чыкты һәм аны тарих фәннәре кандидаты булырга лаеклы дип тапты.

## АКЧАРЛАК КАНАТ КАГА

Яшь язучыларның «Иделем акчарлагы» дигән конкурсы янәдән башланып китте. Аны «Идел» яшьләр үзәге һәм «Мәдәни җомга» газетасы үткәрә. Конкурста шигырь, әкият, хикәя, пьеса, гомумән, әдәби әсәрләр иҗат итүче һәркем катнаша ала, тик аларның яше 30 дан артмаска тиеш. Конкурс өч этапта үткәрелә.

Беренче этап—2006 елның 1 сентябренә кадәр дәвам итәчәк. Икенче этап—әдәби әсәрләрне тикшерү. Аның нәтиҗәсе жюри тарафыннан сентябрь ахырында игълан ителә. Финалга узган яшь язучыларга октябрь аенда «Байтик» лагерена конкурсның йомгаклау—өченче этабына чакыру җибәрелә. Лагерьда конкурска сайлап алынган әсәрләргә анализ ясала, күренекле язучылар, әдәбият-сәнгать әһелләре белән очрашулар уздырыла, җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы була.

Иҗат әсәрләренең темасы чикләнмәгән. Төп таләп: әдәби әсәрләр компьютерда җыелган булырга тиеш. Конкурс ачык.

Әдәби әсәрләр җибәргәндә үзегез турында кыскача белешмә бирү, төгәл адрес һәм хәбәрләшү өчен телефон номерын күрсәтү мөһим. Безнең адрес: 420107, Казан шәһәре, Санкт-Петербург (элеккеге Свердлов) урамы, 12 нче йорт, «Идел» яшьләр үзәге.

Тел./факс: (843) 292-78-25,
яисә e-mail: mc-idel@yandex.ru

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Жәйге хозурлык».

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Саимә Ибраһимова**.

# Яңа китаплар




Солтан Шәмси. **Күк капусы ачылса...** Эзотерик язмалар, тарихи әсәр, хикәяләр публицистика.—Казан: Татар кит. нәшр., 2006.—430 б. Тиражы—2000 данә.

Китапка язучының соңгы елларда язылган «Күк капусы ачылса...», «Адәмне кем коткарыр?» дип аталган тарихи-дини-фәлсәфи уйланулардан торган бәяннары, эзотерик язмалары кергән. Шулай ук мәшһүр татар мәмләкәте Алтын Урданың таркалу чорына багышланган, дәүләттә барган ватандашлар сугышын җентекләп яктырткан тарихи әсәре, хикәяләре һәм публицистикасы урын алган.

Язучының 60 яшьлек юбилее уңаеннан чыгарылган бу китапка кереш сүзне Альберт Хәсәнов язган.

Китапның мөхәррире—Ф. Хафизов, рәссамы—Р. Шәмсетдинов.




Роза Мулланурова. **Ялгыз каеннан да ялгыз...** Хикәяләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.—239 б. Тиражы—2000 данә.

Язучы, журналист Роза Мулланурованың монарчы китаплары чыккаласа да, бусы—чагыштырмача зур күләмле сайланма тупланмасы. Анда авторның егерме хикәясе кергән. Хикәяләрнең геройлары—саф хисләргә бай, чын сөюнең кадерен белә торган, тормышка ышанычын җуймаган, кыйбласына тугры кала алган ихлас күңелле гади кешеләр. Хикәяләрдәге шәхесләр язмышы укучыларны битараф калдырмастыр.

Китапның мөхәррире—Р. Заһидуллина, рәссамы—И. Вәлиәхмәтов.



Саимә Ибраһимова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)